ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

1.2008





**Шиһабетдин Мәрҗани**

*(1818–1889)*

**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2008*

**1**

(1023)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөсният**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*


**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа елда гамьле уйлар. ........ 5

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Марсель ГАЛИЕВ. Миндә бара күк һәм җир тартышы... *Шигырьләр.* ........ 9
Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА. Нишләттегез Гөлкәйне?! *Повесть.* ........ 13
Мөхәммәт МИРЗА. Адәм баласына. *Бишьюллыклар.* ........ 55
Әхәт ГАФФАР. Коелы өй. *Хикәя.* ........ 59
Фирдәвес ГАЛИЕВА. Тозак. *Хикәя.* ........ 65
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Антка тугры калсам... *Шигырьләр.* ........ 70
Шамил МАННАПОВ. Гомер үрендә уйланулар. *Шигырьләр.* ........ 74
Вазыйх ФАТЫЙХОВ. Сират күперендә. *Шигырьләр.* ........ 80

**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Рафаэль МОСТАФИН. Әдәбиятыбызның иҗат баганасы. ........ 83
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Гомернең бер елы. *Көндәлек сәхифәләреннән.* ........ 90

**ГАМӘЛ**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Сүнмәс ут янында уйда без. ........ 98

**ХӘТЕР**

Марс ГАИТОВ. Җырга багышланган гомер. ........ 119

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Намуслы кешеләр. ........ 129

**ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИНЕҢ ТУУЫНА 190 ЕЛ**

Айдар ЮЗИЕВ. Милли идеологиягә нигез салучы. ........ 138

**РИНАТ ТАҖЕТДИНОВКА 70 ЯШЬ**

Луара ШАКИРҖАН. Бер сөйләшү—бер гомер. ........ 145

**«ШУРА» ЖУРНАЛЫНА 100 ЕЛ**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Тарихыбызның тутыкмас бер көзгесе... ........ 152

**ФӘТХИ БУРНАШНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ**

Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Идеология корбаны. ........ 156

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ........ 163

**АК ҖИЛКӘН**

Рәйсә ЮСУПОВА. Тетчер мажаралары. *Хикәя.* ........ 169
Харис ЗАКИРОВ. Карамзин нәрсә дигән? *Хикәя.* ........ 175
Аптыраган әле монда. *Хат.* ........ 180

«Казан утлары» архивыннан. ........ 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 186

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Слово гл. редактора»: Р. ФАЙЗУЛЛИН. «Новый год: новые проблемы».
«Проза и поэзия»: повесть Р. ГАБДУЛХАКОВОЙ «Что сделали с Гулькей?», рассказы А. ГАФФАРА «Дом с колодцем», Ф. ГАЛЕЕВОЙ «Капкан; стихи М. ГАЛЕЕВА, М. МИРЗЫ, Ф. ГАБДРАХИМА, Ш. МАННАПОВА, В. ФАТИХОВА.
«К 80 летию А. Гилязова»: статья Р. МУСТАФИНА и страницы из дневника А. Гилязова.
«Память»: статья М. ГАИТОВА «Жизнь посвященная песне».
«Литературная критика»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Размышление о книге «Сияние огней неугасимых»; статья М. ВАЛЕЕВА «Честные люди».
«К 190 летию Ш. Марджани»: статья А. ЮЗИЕВА.
«Искусство»: беседа Л. ШАКИРЗЯНОВОЙ с актером Камаловского театра Р. Тазетдиновым к его 70 летию.
«К 100 летию журнала «Шура»: статья М. УСМАНОВА «Зеркало нашей истории».
«К 110 летию Ф. Бурнаша»: А. АХМАДУЛЛИН. «Жертва идеологии».
«Белый парус»: рассказы Р. ЮСУПОВОЙ, Х. ЗАКИРОВА.
Из страницы «Татарской энциклопедии».
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Зимний вечер»; писатель Р. ВАЛЕЕВ;

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Chief Editor's word»: R. FAYZULLIN.
«New year: new problems».
«Prose and poetry»: Story by R. GABDULHAKOVA «What happened to Gulke?», stories by A. GAFFAR «House with well», F. GALIEVA «Trap»; verses by M. GALEEV, M. MIRZA, F. GABDRAHIM, SH. MANNAPOV, V. FATIHOV.
«To 80th anniversary of A. Gilyazov»: article by R. MUSTAFIN and pages from A. Gilyazov's diary.
«Memory»: article by M. GAITOV «Life посвященная to song».
«Literary criticism»: A. TIMERGALIN. Reflection about book «Light of inextinguishable fires»; article by M. VALEEV «Fair people». A. TIMERGALIN. Reflection about book «Light of inextinguishable fires»;
«To 190th anniversary of Sh. Mardjani»: article by A. YUZIEV.
«Art»: interview of L.SHAKIRZYANOVA with Kamal theatre actor R. Tazetdinov to his 70th anniversary.
«To 100th anniversary of magazine «Shura»: article by M. USMANOV. «Mirror of our history».
«To 110th anniversary of F. Burnash»: A. AHMADULLIN. «Victim of ideology».
«White sail»: stories by R. YUSUPOVA, H. ZAKIROV.
From pages of « Tatar encyclopedia».
Diary of social-cultural life.
On our covers: writer R. VALEEV

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 26.12.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-1674 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.

# ЯҢА ЕЛДА ГАМЬЛЕ УЙЛАР

Үтеп киткән елда зур сәясәт дөньясында да, мәдәният-матбугат өлкәсендә дә шактый гыйбрәтле хәлләр булды. Вертикаль хакимият түрендәге «шахмат уеннары»на яки сайлау компанияләре хикмәтләренә дә тукталып тормыйча, үзебезнең матбугат хәятына кагылышлы ике вакыйганы гына әйтеп узам. Онытырлык түгел алар. Беренчесе—Казан үзәгендәге данлыклы Матбугат йорты белән саубуллаштык, икенчесе—республикада чыгып килгән бик күп басмалар, хөкүмәттән рәсми «котылып», ирекккә, үзбашка чыкты, ягъни акционерлык ширкәте булып оешты. Бер җөмләгә сыйган шушы информациядә монарчы күрелмәгән тарихи акцияләр төене ярылып ята. Мәгънәләрен тәфсилләп бәян итсән, сүзем озынга китәр. Шулай да... Матбугат йорты—әдәбият, нәшрият, газета-журналлар, гомумән, мәдәни тормышның житмеш еллап чорын үзенә сеңдергән тарихи бина, ничә буын талант иясләренең иҗади аралашып «кайнау» урыны иде. Аның бетүе символик мәгънәгә ия түгелме? Дөрес, бина бик нык тузган булып чыкты, нәшрият-редакцияләргә күченми мөмкин дә түгелдер. Алга таба ни-нәрсә булыр ул урында? Шәһәр үзәгендәге күз кызыгырлык җир буш тормас, әлбәттә. Һәрхәлдә, рухи учак торгызылырга охшамаган.

Акционерлыкка күчү исә газета-журнал редакцияләре өчен көтелмәгән хәл булды. Үткән елның август аенда югарыдагы кабинетлардан чыкты ул карар. Акционерлыкка бирләшү—үз көнеңне үзең күреп, булдыра алсаң, баеп яшәргә омтылу дигән сүз. Кыскасы, акча эшләү, мөмкин булса, күп итеп эшләү! Әгәр дөньяда идеология—милли идея, тел, әдәбият, сәнгать кебек төшенчәләр булмаса, акча эшләүгә көйләнү дөрестер дә. Әмма тарих галәл хөкемче: цивилизацияле дөньяда илләрнең, халыкларның дәрәҗәсен, югары сәнгатьләре белән бергә, аларның рухи биеклекләре, фәнни казанышлары аша билгелиләр... Шунысын да онытмыйк: монарчы матбугатны «дүртенче хакимият» дип тә йөрттеләр бит. Бүгенге көндә абсолют күпчелек басмалар, бигрәк тә милли (бу очракта русча булмаган) телләрдә чыккан басмалар үз-үзләрен асрый алмыйлар. Моның тарихи сәбәпләре бар. Табыш чыганагы булып торган реклама безнең матбугатта үзмаксат була алмый. (Сүз дәүләти идеологик тәрбиягә өлеш кертмәгән бульвар яки вулгарь басмалар турында бармый.) Ихтимал, узган гасырның 70 нче елларында кайбер басмалар (әйтик, «Казан утлары», «Азат хатын» («Сөембикә») үзбаш яши, хәтта табыш алып яши дә алган булырлар иде. Чөнки тиражлар йөзәр мең белән йөрде. Хәзер вәзгыять бөтенләй бүтән. Сәбәпләре аңлашыла. Хөкүмәт үз ярдәменнән ташламаса, матбугатка кагылышлы заказларын акционерлар җәмгыяте (ОАО)—хәзер инде җәмгыятебез дип әйтергә кирәк—аша уздырса, беренче чорда, бәлки, әле ару гына яшәп тә булыр. Шулай дип өметләник. Әмма бу дәвамлы булырмы? Җитәкчеләр үзгәреп, карашлар үзгәрмәсме? Без барлы-юклы мөстәкыйльлегебезне җуеп (самоликвидацияләнеп, сүзе генә дә ни тора!), инде мәңге кире кайтып булмас чикне үтәбез бугай. Базар—тотрыксызлык символы түгел, ул сәгатьләп үзгәреп тора. Базар, шулай ук, тәрбия һәм әхлак мәйданы да түгел. Беркөн безгә, «Чүкечегез булмаса, кадакны скрипкә белән кагыгыз!» дип әйтүләре дә бик мөмкин.

Соңгы дистә еллар эчендә без гел үзгәртеп корулар, тоташ реформалар, яңадан-яңа сәяси фиркаләр төзү эйфориясендә яшибез шикелле. Тарихи дәвамчанлык җитенкерәми димме?.. Үзебезнең матбугат тарихына күз салсак, анда азмы-күпме мантыйкый доктрина һәм табигый эзлеклелек булган. Һәр тармак-өлкәнең—үзенең максаты, сәясәте, шул нисбәттән, үзенең идеологик-тәрбия органы булган. Әйтик, балалар һәм үсмерләр әдәбияты—элегрәк комсомол, соңрак яшьләрнеке дип йөртелгән министрлык эгидасында булган; әдәби журналлар эше белән, нигездә, Язучылар оешмасы җитәкчелек иткән; сәнгать өлкәсендәге газета-журналлар Мәдәният министрлыгына караган; мәктәп-тәрбиягә кагылышлы басмалар—Мәгариф министрлыгына... Алар әлеге басмаларның учредительләре—оештыручылары сыйфатында җитәкчелек иткәннәр. Аңлашыла һәм мантыйкка сыя торган тәртип. Өстәвенә, әле бу басмаларның көндәлек һәм фактик яктан

дөньяга чыгару буенча төп булышчысы, гомумхуҗасы—Матбугат һәм информация министрлыгы булган. Заманасында уңышлы гына эшләп килгән бу министрлык (совет заманындагы Нәшрият, полиграфия эшләре һәм китап сәүдәсе идарәсе) моннан ун еллар элек бетерелде. Аннан соң газета-журналлар һәм нәшриятларның яңа хуҗалары пәйда булды. Берничә ел Элемтә (?) министрлыгына, аннан «Татмедиа» агентлыгына буйсынып яшәде мөхәррирләр. Хәзер без, шул оешма җирлегендә оешкан акционерлар җәмгыятенә карыйбыз. Төгәлрәк әйткәндә, ачык акционерлык ширкәтенең филиаллары саналачакбыз. Гасырлар буе баш редактор-мөхәррирләр йөртелгән затлар шул филиалларның директорлары дип аталачак. Кызыклы метаморфоза. Тагын нинди реформалар булыр, әйтү кыен.

Әле күптәнме XXI гасырга (милади белән санаганда) керәбез дип, дулкынланып, яңа хыял-ышанычлар белән янып йөргән идек. Яңа гасырның җиде елы инде үтеп тә китте. Сау кешегә ун елы да, бүтән еллары да тиз килеп җитәр. Нинди алгарышлар булды, өмет иткәннәребезгә ирешелдеме? Кояш астындагы җиһанда татар милләтен күбрәк таныта алдыкмы, дөресрәге, саклана алдыкмы? Фикерләр каршылыклы. Бер яктан, Казанның меңьеллыгы уңае белән горурлык хисләре уятырлык олуг гамәлләр булды. Казан дөньякүләм дәрәҗәле шәһәргә әверелеп бара. (Тик шуны да онытмыйк: без аны татарның башкаласы дип санасак та, ул бик күпләр өчен монастырьлар һәм икона-тәреләр шәһәре дә). Казан—халыкара милли мөнәсәбәтләр, милләтләр язмышы турында җитди сөйләшүләр аренасы хәзер (татар конгресслары, Татарстан халыклары съезды, бөтендөнья татар галимнәре җыены, федерализм мәсьәләләре буенча югары дәрәҗәдәге халыкара форумнар, төрле илләрнең җитәкче даирәләре белән даими очрашулар һ. б.).

Болары бик әйбәт. Әмма күпләрне гомуми, илкүләм милли мәсьәләләрнең хәл ителмәве борчый. Россия халыкларының телләре аянычлы хәлдә. Бу урында әз генә хәтер чигенеше ясап, РФ Президенты В. Путинның 2002 елның 30 августында Бөтендөнья татар конгрессында ясаган чыгышыннан бер өзек китерәсе килә (очрашуда үзем дә катнашкан идем, ул мизгелләр бик хәтердә): «Абсолютно недопустимо, если кто-то говорит о том, что нужно сокращать изучение родного языка». Кызганыч, Россия Президенты сүзләре белән Дәүләт Думасы законы берсен-берсе сызып ташлый. Дәлилләрме? Алар күз алдында. Әле күптән түгел (15 ноябрь 2007 ел) Дума безнең өчен гаять зур «бүләк» әзерләде (аның русча аталышы болай: «Закон, отменяющий национально-региональный и школьный компоненты в государственном общеобразовательном стандарте»). Шунысы сәер: бу законга Президент инде кул куйган (!) диләр. Мондый гамәлдән соң, әлбәттә, логика дигәннәре бик мескен хәлдә кала... Шундый закон кертелгәч, рус теленнән тыш, башка милләт телләре «гөрләп чәчәк атачак» инде! Хәер, Дәүләт Думасының безнең телебезгә мөнәсәбәте билгеле: татар язуын латин графикасына күчерүне тыйган депутатлар җыены бит ул! Ә менә, мәктәпләрдә православие дине фәнен укытуга бик тә лояль үзләре. Гаҗәпләнергә кирәк тә түгелдер, байтак республикалардагы рәсми һәм иҗтимагый оешмаларның күп тапкыр мөрәҗәгатьләренә карамастан, күпмилләтле Россиядә координацион үзәк—милли мәсьәләләр буенча министрлык та юк бит. Аның урынына милли төсмер бирелмәгән региональ үсеш министрлыгы төзелде. Күрәсең, Ак патша варислары, СССР таркалгач, милли мәсьәләләр бетте дип уйлыйлардыр... Әмма милли мәсьәлә ул мәңгелек! Чөнки Ходай биргән яшәүдә үз-үзеңне саклау теләге инстиктив табигый хәл.

Мәгълүм хакыйкать: милләтнең милләт буларак төп билгесе—аның теле. Тел булмаса, милләт тә юк. Безнең, бәлки, көчле милләттә булырга тиешле кайбер нәрсәләрне башкарырга хәлебездән дә килмидер. Тарихи үткәннәр рухны шактый какшаткан. Әмма, теләк һәм үзаң көчле булганда, телне саклауда һәр кешенең үз мөмкинлекләре бар. Моның өчен көчле ихтыяр кирәк! Ә ихтыярны сындыру яки аны бөтенләй булдырмау өчен шартлар җитәрлек. Кайберләрен югарыда әйтеп тә уздык. Хәтерегезгә төшерик: моңарчы гасырлар буе безнең телне халык—нигездә, фольклор, язма әдәбият һәм дин (мәчет-мәдрәсәләр) саклап килде. Соңрак боларга театр, матбугат, радио кушылды. Үткән гасыр урталарына кадәр татарлар яшәгән

бөтен җирдә туган телебез, мон-көйләребез яңгырап торды. Мәктәпләрдә уку ана телебездә барды. Хәзер күрәбез: гомуммасштабта алганда, телебезнең таралыш чикләре күзгә күренеп тарайды. Бу хакта Бөтендөнья татар конгрессының күптән түгел генә үткәрелгән корылтаенда да ачынып сөйләделәр. Татар дип саналган мәктәпләргә килеп карасаң, укучыларның күбрәк нинди телдә сөйләшкәннәрен яхшы күрәсең. Татарлар төзегән мәчетләрдә еш кына вәгазьләрне дә русча гына ирештерә кайбер дин әһелләребез. «Шунысы хак: фәкать туган телдә иман инә кеше җанына!». Эфир-экраннардан, сәхнә түрләреннән «Татарча солянка»ларны еш ишетергә туры килә... Шулай да, минемчә, телебезне саклап калуда бөтен мөмкинлекләр ябылып бетмәгән әле. Шуларның берсе—татар телендәге басмаларны, бигрәк тә, иҗтимагый әһәмияте булган әдәби-нәфис басмаларны халыкка мөмкин кадәр күбрәк тарату. Әдәби телнең чыганагы, саклану мәйданы шуларда бит! Кемнәрдер татар матбугатының кыюлыгын, заманчалыгын шик астына да алмакчы була. Татарча чыккан төп басмаларны җентекләп укып баручы буларак, андый фикер белән килешеп үк бетмәс идем. Халыкның үзаңын үстерүгә ярдәм итәрлек бик тә җитди, бик тә төпле язмалар дөнья күрә татар матбугатында. Хикмәт шунда: кемнәр укый аларны, һәм алар күпме? Безнең газета-журналларны, нигездә, анда күтәрелгән мәсьәлә-проблемаларны күптән аңлаган бер үк зыялы даирә укый. Ә фикерләр, беренче чиратта, ул проблемаларны аңламаган, яки аңлап бетермәгән даирәләргә юнәлтелгән! Язмалар төп адресатка барып җитми булып чыга, яки ул кешеләр аларны туган телдә укымый... Дәүләт оешмалары, учреждениеләре офисларында, хәтта урам киоскларында татар телендәге газета-журналлар юк дәрәҗәсендә. Булмаганны ничек укымак кирәк! Җитди сүзнең түмгәктән яки биек мөнбәрдән әйтелүендә аерма зур. Кайда һәм кем тарафыннан әйтелүе дә бик мөһим. Фикер, матбугатның биш йөз данә чыга торган басмасыннан әйтеләме, әллә биш йөз мең данәлесендә әйтеләме? Минемчә, тарихи тамыры, милли рухы булган басмаларның тиражы кимендә илле мең данәләр булырга тиеш. Ә хәзергә аларның әбүнәчеләре әйтелгәннән җиде-сигез тапкырга кимрәк. Әйтик, хөкүмәт карамагында калган берничә рәсми басманың татарча гомумтиражы егерме меңнән дә артмый. Фәлән миллион татар кешесенә шуны бүлеп карагыз! Тираж ул—сәясәт, ул—тел язмышы. Бу эшне үз агымына кую—кичерелмәс ваемсызлык. Эшне дәүләти кайгыртучанлык белән оештыра белгәндә, резервлар җитәрлек. Татар теленең дәүләт теле булып саналу турындагы канунның гамәлдән чыгарылганы юк бит әле!

Тел хәзинәсенең төп асыл бакчасы, әлбәттә, әдәбият, беренче чиратта, классик әдәбият. Төптәнрәк уйлап карасаң, төп байлыгыбыздыр әле ул. Җисми байлыкларның, гадәттә, милләте булмый. Алар, яуланып яки таланып, кулдан-кулга күчеп йөри. Әдәбиятны үзләштерү-урлау (милләтләр арасында андый хәлләр дә булгалый!) кыенрак. Әнә шул әдәби байлыгыбызны саклар өчен дә кирәк әле ул туган телебез! Көндәлек матбугат һәм китап басу эше, бергә үрелгән асылбау шикелле, аерылгысыз. Газета-журналларга кагылышлы проблемалар (тираж, укучылар даирәсе) нәшриятлар эшенә дә хас. Дөрес, республика җитәкчелеге китапның иҗтимагый әһәмиятен ярыйсы ук яхшы аңлый. Китапка мөнәсәбәт начар булса, төп нәшриятларыбыз йөзләгән исемдә яхшы китаплар чыгара алмас иде. Бу хәзергә шулай. Эш башына туган телне белмәгән, татарча бер китап та укымаган, бер җөмлә дә төзи белмәгән яңа буын килсә, эшләр ничек булыр?

Телнең хуҗасы халык булса, калыплаучысы—язучы. Чын язучы талантлы әсәрләр язып, алда әйтеп үтелгән төп байлыгыбызны арттыра. Шөкер, бүген әле безнең классик дәрәҗәдә иҗат итәрлек берничә дистә язучыбыз бар. Табигатьтән бирелгән халык байлыгы бит алар! Саклыйсы, тиешле шартлар тудырып, иҗат иттерәсе генә... Гомер бакый әдәбиятның мәктәпләрдә махсус фән булып өйрәнелүе дә аның төп рухи байлыгыбызның берсе икәнлегенә дәлилдер. Шуңа күрә, җан авазы—телнең язучы өчен ни дәрәҗә газиз икәнлеге аңлашыла да. Тел бетсә, әдәбият бетә, әдәбият бетсә—сәнгатьнең күп төрләре юкка чыга. Хәзерге чорда телне саклау өчен көрәш, ул асылда милләтне саклау өчен көрәш. Бетерүче факторның басымы арткан саен, каршы тору көче дә бермә-бер арта, көрәш кискенләшә генә. Авар халык шагыйре

Рәсүл Гамзатов тикмәгә генә, «Әгәр бүген телем бетсә, иртәгә мин үләргә әзер», димәгән инде. Икенче бер халык язучысы, үзебезнең Нурихан Фәттах болай дип язып калдырган иде: «Әгәр тиздән минем телем бетә икән, озакламый тамырым корый икән, бу дөньяда ник яшәргә дә, ник яратырга, балалар тудырырга, чәчәкләр үстерергә? Нигә җырлар, китаплар язарга?.. Икенең берсе: йә тере килеш туфракка әйләнергә, йә көрәшергә! Мин көрәшергә булдым». Әйе, көрәшергә, көрәшергә! (Җәяләр эчендә булса да әйтеп узыйк: әнә, безнең күзлектән караганда, яшәве гарантияләнгән дип саналган телне, ягъни рус телен ничек яклап көрәшәләр. Чит илләрдә, әйтик, Балтыйк буе илләрендәге берәр мәктәптә рус теленә әз генә кагылышлы хәл булса, бөтен дөньяга шаулыйлар!). Ә бездә? Бездә... хәлләр бүтәнчәрәк шул. Бездә һәр ел, һәр көн Туган телне яклау елы, Туган телне саклау көне булырга тиеш тә бит!.. Халык арасында төрле холыклы кешеләр булган кебек, язучыларның да төрлесе бар. Кемнәрдер, бәлки, туган тел кысылса да, әсәрләремне бүтән телләргә тәрҗемә итеп, үземне, халкымны бар дөньяга күрсәтә алам, дип тә уйлыйдыр. Ай-һай! Ашы-зәмине булган туфракта гына кешеләр күзе төшәрлек нәфис гөлләр шыта ала.

Туган тел, милли әдәбият язмышы турында язу җинел түгел. Кайчандыр дәүләтен җуйган милләт баласы өчен бигрәк тә. Каләм йөгергән һәр сүз, һәр җөмлә астында күңелдән саркып чыккан әллә никадәр әрнү, өмет катыш, гасабилану ята... Кайчак уйлап куясың: бу борчулы фикерләрне тезеп утырганчы, бер шәп шигырь язсаң соң! Дөньяда объектив глобаль процесслар бара, барыбер әллә ни кыра алмыйсың... Юк!.. Җон баскан күңелләрен тынычландырып, пошмаслыкларын, битарафлыкларын аклап, андый гәп куертучы «акыллы башлар» бездән башка да җитәрлек. Кояш астында аерым кеше буларак та, милләт буларак та лаеклы урын дауларга теләк бар икән—гамь белән яшәргә, көрәшергә туры килә.

Шулай да, шигъри юллар язасы килә. Яңа яуган кар кебек чиста, ак-пакь лирик шигырь. Язылыр, иншалла, күңелдә булгач, язылыр. Туган телебез сау-имин булсын! Йөрәктән чыкканны йөрәкләре белән аңларлык, укырлык, тыңларлык укучы милләттәшләребез исән булсын! Хәерле Яңа еллар һәммәбезгә!

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре,*
*«Казан утлары» журналының баш мөхәррире,*
*Татарстан ФА шәрәфле академигы.*



Марсель
Галиев

# МИНДӘ БАРА КҮК ҺӘМ ҖИР ТАРТЫШЫ...

## Мин болай идеммени

Манылды күңел күкләре
Шәфәкъләр кызылына.
Ис китми генә әсәрәм
Дөньяның кызыгына.

Мин болай идеммени соң,
Мин болай идеммени!
Сары яфраклы сабырлык
Көзенә килдеммени?..

Поездлар үтә еректан,
Наратлар арасыннан
Бәрхет шау булып саркуы—
Юату көе сыман.

Китәсе килми, китәсе...
Каласы да килми шул.
Поездыңнан соңга калсаң,
Кадерең дә кими шул...

Наратлар да шәфәкъ ягын
Карыйммы каерылып?
Аларга хасмы—җан ашу
Урманнан аерылып?

Яшел чалмалы наратлар
Төштә түгел, өнендә
Ялгыз-ялгыз бер аварлар
Олыгаю төнендә.

Нигә соң болай уйланам,
Әллә көз сулышыннан.
Рельслар кереп югала
Урман борылышыннан;

Учтагы язмыш сызыгы
Кинәт өзелгән сыман...

## Тузан булып

Көбә күлмәк. Булат кылыч. Иярле ат.
Мин шул дәвер тоягыннан
Сыктап калган туфрактан—

Тузан булып, гөлдән-гөлгә
Куньп киләм еректан.

Марсель ГАЛИЕВ (1946)—*шагыйрь, прозаик, публицист; күпсанлы китаплар («Апрель кылы», «Догалы еллар», «Рух» һ. б.), шул исәптән дүрттомлык «Сайланма әсәрләр» авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Атлы Болгар ядкәре

Капкаларың ачыламы Көнкарашка;
Мәңгелек гамь уелганмы һәрбер ташка;
Җиһаныңда мондый кала бармы башка?!

Әй, аткынам, атым, аткынаем,
Томыласың,
Тояклардан очкын чәчрәп яна,
Кытыкланып көлә япан дала.

Капкаларда усал җилләр кагышымы;
Тәкъдирме бу, әллә Ходай каргышымы;
Каракошлар дәррәү чукый һәр ташыңны?!

Әй, аткынам, атым, аткынаем,
Ник дулыйсың,
Ияреңнән җайдак чәчрәп кала,
Кара сөрем яга япан дала.

Күкләр сорый: болгаттыңмы Болгарыңны;
Йә, ашыгып, кылычыңны болгадыңмы;
Үз башыңны үзең чабып куймадыңмы?!

Әй, аткынам, атым, аткынаем,
Канлы яшең
Әрем бәбәгенә чәчрәп тама.
Томан каплап җылый япан дала.

## Утлы дәрт

Төнге гөмбәз—түм-түгәрәк тирмә,
Уртасында балкый Җир шары.
Шул шарның бер нәни ноктасында
Үрсәләнә тормыш учагы.

Әле дөрли, ярсу айгыр булып,
Аягүрә басып, талпына,
Күмеренә кысып бар сулышын,
Җилгә сусап, әле бер тына...

Күкнең текә гөмбәзеннән, кинәт,
Таеп китә йолдыз, атыла.
Учагыннан ыргып чыккан ялкын
Шул йолдызга таба тартыла.

Кушылалар... Утлы йомгак булып,
Шартлап куя учак—мең очкын!
Чая йолдыз шушы мәлдә җуя
Галәми дәрт кергән очышын.

Юктан—барга, бардан юкка чыгу
Серен Тәңре белә, билгеле.
Күк-Ата һәм Җир-Ананың бу бит
Күз кысышкан илаһ мизгеле.

## Ходайга да бик күңелсез булыр...

Аргамаклар аягүрә басып,
Кешнәп ауган дәверләр сыман,
Убылыр татар тарих бәгыренә—
Легендалар калкыр җан сорап.

Бу—хыялда. Чынбарлыкта исә
Куеп карыйк гадел хөкемгә:
Горур үлә белү горурлыгы
Бирелгәнме безнең кавемгә?

Үзе теләп бетә бара халык,
Гүя үз-үзенә үч итә;
Ничә гасыр буе, чимал булып,
Төрле кавемнәрне үрчетә.

Бетә-бетә шулай бетә торгач,
Коргаксыр да язмыш казаны,
Торып калыр ялгыз бер могикан!
Бик гыйбрәтле булыр азагы.

Олыларлар соңгы могиканны,
Илләр буйлап, зурлап йөртерләр.
Нинди бөек халык булган, диеп,
Дөнья аңа карап фикерләр.

Ә көнчеллек, татар көнчелеге
Бетәрме соң Җирдә, ниһаять,
Хәтәре дә бетсә, татары да,
Нинди хәлгә калыр бу хәят?

Юк, тагын да татар бер калкыныр;
Соңгы могиканнан көнләшеп,
Үрчи башлар соңгы могиканнар,
Тешләшеп тә янә, үчләшеп.

Бәхәс кубар, әрсез могиканнар
Төрле кыйтгаларда дан алыр.
Иң актыкта мин—беренче дигән
«Татар чире» Җиргә таралыр.

Ә барыбер соңгы могиканга
Бетү чираты бер җитәчәк.
«Күзгә кырып салыр» татар беткәч,
Киләчәксез калыр киләчәк.

Ходайга да бик күңелсез булыр,
Галәм үкенечен татырлык:
—Җирдә бармы тагын берәр халык.
Саллы исем белән атарлык?!

Менә шунда инде яңабаштан
Уйлап чыгарырлар татарны!

## Мәхәббәт балдагы

Килмә син, килмә күңелгә,
Күңлемдә, үкенеп, күмелмә;
Айның да сул ягы—күгемдә.

Манма булырсың да хисләреңнән,
Әрнү килер эрем исләреннән.

Кайтма син, кайтма кабаттан,
Күпме җан канатын канаткан:
Бу Җирдә Иблискә таң аткан.

Манма булырсың да сагышыңнан,
Үкенерсең гадел ялгышыңнан.

Китмә син, китмә хәтердән,
Мәңгегә калырга әзерлән:
Гөл булып шытарсың кабердән.

Манма булырсың да яңгырларда,
Елмаерсың ... бер өн яңгырар да...

## Хәтер тавында

Син, дисәм... Чыңлый күңелнең
Көмеш кыңгыраулары.
Җилкенеп калка гомернең
Чаптар атлы еллары.

Син, дисәм... Исемең серен
Беркемгә ачмасам да ... —
Иң ләйсәнле гол кабына
Исемнәр бакчасында.

Син, дисәм... Җиләкле җилне
Кушып үргән толымың
Искә төшеп, урап ала,
Шул толымың колы мин.

Син, дисәм... Хәтер тавында
Яшеннәр бәрелешә.
Бу—гомерлек якты әрнү—
Гел ерак, гел янәшә.

Син, дисәм... Иң чытлык йолдыз
Чаткылап, күкне бизи.
Син киткән эзләрне үбеп,
Тәкъдир миңа кул изи...

## Хәтер бурлагы

Чибәрләнә, чытлыклана кызлар,
Кытыклана күңел кыллары.
Уйлары да бүтән, туйлары да...
Бу балга син—дегет нибары.

Юанычка дәва—бу гомернең
Булачагы түгел, булганы.
Үткән заман фигыльләрен, кайтып,
Сөйрә, әйдә, хәтер бурлагы.

## Гаҗиз сорау

Үз-үземә читтән көлеп карыйм:
Каян килгән мондый сабырлык?
Юкка гына әйтмиләрдер әле:
—Теге чакларыңны сагындык...

Шаулы табыннарда тел сайратып,
«Богемачыл гомер» кичердем:
Хәмер әмеренә бирелми дә
Тормыш кызыгыннан исердем...

Хыянәтсез булдым тугры сүзгә,
Санга суктым дуслар өммәтен.
Корыч тавыш белән кайчак сүктем
Дөньялыкның шикле кыйммәтен...

Очынулар, ачынулар аша
Кабул булды күпме теләгем?
Кысыр туфракларга чәчмәдемме
Сәләт дигән Ходай бүләген?—

Чәчкәнмендер. Сусыл шытымнарны
Бөгелеп лә кемнәр җыйгандыр...
(Каләм тотса, мәхлугы да безнең—
Үрә баскан кәрлә җиһангир...).

Чын остазлар инде бетә бара,
Юшкынлана телнең коесы.
Нәфеселәләр сүз имгәтә. Җырда—
Көй аякка төшү тойгысы.

Күпләргә мин туры карый алмыйм;
Мәкер сүрүләре ертыла.
Керләнгәндер ишек тоткалары,
Андыйларның кермим йортына.

Менә тагын китеп барам әле
Сүз табасы кызган табыннан.
Кичерегез, ыспай бокалларым,
Кырын карап китсәм, талымлап.

Җан авыша ялгызлыкка таба,
Тән-читлекнең сыный ныклыгын.
Миндә бара Күк һәм Җир тартышы.
Кагып иңнән дөнья ваклыгын
Тома ялгыз калгач, тәкъдиремә
Гаҗиз сорау бирә аламмы:
—Җаным белән Күккә ашаммы мин,
Тәнем белән Җирдә каламмы?...

☘



Рәмзия
Габделхакова

# НИШЛӘТТЕГЕЗ ГӨЛКӘЙНЕ?!

ПОВЕСТЬ

Минем сеңлем бик куркак иде. Ул карангыдан курка иде. Ул тагын үрмәкүчләрдән һәм бичурадан курка иде. Әни ана дөньяда бичураның юк икәнен кат-кат әйтсә дә, сеңлем барыбер курка иде. Чөнки бичура турында һәркөнне искә төшереп торучы мин бар. Гөлкәй никтер әнигә түгел, миңа ышана. Мин ана бичураның бер күзле, озын борынлы, ап-ак чәчле булуын сөйлим. Аның һәр төндә минем янга килеп, үзе белән алып китәргә теләвен сөйлим. Ә ул, күзләрен зур ачып, куркуыннан тәмам куырылып мине тыңлый. Аның иртәгә өйдә берүзе каласы бар. Иртән әни белән әти эшкә, ә абый белән мин мәктәпкә китәбез. Сеңлем өйдә ялгыз калмас өчен, күзләрен уа-уа иртүк тора, киенә, ашыга-ашыга ашый. Аннары миңа ияреп урамга чыга. Мин артыма борыла-борыла ана кычкырам: «Бар, кайт, йөрмә минем арттан!» Әмма Гөлкәй тыңламый, иреннәрен кысып, терт-терт янәшәдән атлавын белә. Мин адымымны тизләтәм. Ул да миннән калмый. Мин йөгерәм, Гөлкәй дә йөгермәкче була. Тик барыбер минем арттан житешә алмый, чапкан уңайга түмгәккә абына да, жиргә тәгәри. Ул еламый, бары үзенең өлгермәячәген аңлап, өзгәләнеп кычкыра: «Апа, калдырма мине! Мин куркам!» Ә мин көлә-көлә чабам: «Бар, бар, өйгә кайт, анда сине бичура көтә!» Хәзер үзем дә аптырыйм, нигә шул кадәр рәхимсез булдым икән мин?!

Ә бервакыт сеңлем югалды. Ул көнне мин мәктәптән беренче булып кайттым. Сеңлем өйдә юк иде. Мин аны ишек алларыннан, бакчадан, урамнан, күршеләрдән эзләдем. Тик Гөлкәй беркайда юк иде. Абый кайткач, сеңлемне эзләп бөтен авылны әйләнеп чыкты, ләкин—файдасыз. Гөлкәйнең югалуы турында белмәгән кеше калмады, бичара әни борчылудан ни уйларга, ни кылырга белмәде. Әллә бәкегә төштеме икән, дип шикләнүчеләр дә булды. Чөнки ике ел элек сигез яшьлек бер малай шулай батып үлгән иде, аның үле гәүдәсен язын гына таптылар. Мин әле үлемнең нәрсә икәнен аңламыйм, әмма үлгән кешене жир астына күмгәннәрен беләм, ә анда аны кортлар ашый имеш. Шуны уйлап минем котым оча, үземне, без үсеп житкәнче үлемгә каршы барыбер берәр нинди дару уйлап табачаклар, һәм без беркайчан да үлмәячәкбез дип юатам. Мин сеңлемнең үлүен теләмим, аны кызганып елыйм, элек рәнжетүләрем өчен үкенәм. Әгәр ул табылса, исән булса, аны башка беркайчан да рәнжетмәс, куркытмас идем, дип ант итәм.

Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВА—*шагыйрә, прозаик; «Көзге яшен», «Көмеш түн» һәм башка китаплар авторы. Лениногорск шәһәрендә яши.*

...Бәхетебезгә, яхшы хәбәр китерүче булды, төш вакытындарак Гөлкәйнең ике малай белән олы юлга таба чыгып баруын күргәннәр икән. Ике малай, дигәч, барыбызның да эченә җылы керде. Болар безнең күрше авылда яшәүче туганнарыбыз Айрат белән Айдар булырга тиеш. Бу елгыр малайлардан бөтенесен дә көтәргә була, болар инде илгизәр халык. Чөнки әтиләре Салават абый шофер, еш кына малайларын үзе белән утыртып йөри. Районны гына түгел, тирә-күрше шәһәрләрне дә айкап чыктылар. Очрашкан саен мактанып сөйлиләр. Имеш, тегендә булганнар, монда булганнар, тегене күргәннәр, моны күргәннәр.

Бу хәбәрне ишетүгә, әти энесенә шалтыратты. Хак, Гөлкәй, чынлап, та шунда икән. Тегеләре чакырган да, бу ияреп киткән. Мин беләм инде, өйдә ялгыз утырмас, бичура белән очрашмас өчен дөнья читенә дә китәргә риза ул хәзер. Сеңлебезнең әзенә төшкәндә вакыт соң иде инде, шуңа күрә Салават абый аны иртәгә иртән китерергә булган.

Икенче көнне мин мәктәптән кайтканда Гөлкәй өйдә иде. Бөдрә чәчле кечкенә башын учларына салып, нидер уйланып тыныч кына тәрәзәдән карап утыра. Килеп керешли үк котын алдым моның:

—Ну, Гөлкәй, эләгә хәзер сиңа! Күрмәгәненне күрәсен, әни үтерә сине!

Гөлкәйнең йөзе агарып китте, болай да зур күзләре шар булды:

—Минем үләсем килми!

—Килмидер дә бит, нишләтим, качып йөрмиләр аны. Үтерә булгач, үтерә, әни үзе шулай диде.—Болай да куркак сеңлемне үчекләү миңа кызык иде. Гөлкәй әкрен генә урындыктан шуып төште дә, бер сүз дәшми, шыпырт кына алгы бүлмәгә кереп китте. Мин әни әзерләп калдырган ашны җылытырга куйдым, чәйне кабызып җибәрдем. Табын коргач, сеңлемә дәштем:

—Әй, ашарга чык!—Гөлкәйне карау минем вазифа иде.

Әмма ул чыкмады.

—Гөлкәй, сиңа дәшәм ич. Сангырауландыңмы әллә?!—дип кычкырдым мин.

Инде алай да күренмәгәч, тәмам түземлегем бетеп, алгы бүлмәгә керсәм, Гөлкәй анда юк. Йөрәгем жу итеп китте. Тагын югалса, нәрсә дип җавап бирермен?! Тотындым моны эзләргә. Карасам, караватастына кереп качкан бу, мәче баласы кебек шунда бөрешеп утыра.

—Нишлисең анда? Ник ашарга чыкмыйсың?

—Апа...—ди бу мескен, елак тавыш белән.—Син әнигә минем монда икәнне әйтмә, яме... Минем үләсем килми...

Мин пырхылдап көлеп җибәрдем: «Алайса, ачтан үлгәнче утыр инде шунда». Әмма яшисе килү ашыйсы килүне басты бугай, Гөлкәй тәки урыныннан кузгалмады. Әни кайткач, әлбәттә инде, аның иң беренче соравы: «Гөлкәй кайда?» булды. Мин кулым белән карават астына төртеп күрсәттем. Әни ачулы иде, иләп:

—Чык аннан, дуңгыз баласы! Кара, кая кереп качкан бит, юньсез. Акылга утыртам хәзер мин сине! Тәмам котыбызны алдың, җәфа!—дип оршына-оршына Гөлкәйне өстерәп чыгарырга маташты. Әмма почмакка ук сыенып утырган сеңлемнең тыны да чыкмый. Ахыр чиктә үзебез караватны күчердек.

—Тискәре бала, качып мингерәтүең җитмәгән, сүз тыңламыйча да җанга тиясең!—диде әни. Ул башын, тезләрен кочып, бер йомгак булып утырган Гөлкәйне тартып торгызырга теләгән иде, тик шул чак көтелмәгән хәл килеп чыкты: сеңлем шапылдап идәнгә ауды да, аңын югалтты. И шунда әнинең куркулары! Сулар сибеп, битенә суккалап, Гөлкәйне, ниһаять, һушка китергәч, ул инде аны орышмады, кочаклап елый-елый:

—Әй, кызым, башка безне болай куркытма, зинһар. Ни уйларга да белмәдек бит. Кая баруыңны әйтеп йөрергә кирәк,—дип җайлап кына кисәтте.

Тик барыбер... Тик барыбер шул көннән соң Гөлкәй тотлыга торган булып калды...

* * *

... Автобус әкрен генә алга бара. Юл озын әле. Яртауга житәргә ике сәгатьләп вакыт бар. Гөлкәй яшәгән Яртау шәһәре белән Шенталы арасы ике йөз чакрым чамасы. Бүгенге заман өчен әлләни зур ара да түгел югыйсә. Әмма Гөлкәй белән безнен ара гел ерак булды. Һәм мона мин үзем, бары үзем гаепле.

Их, Гөлкәй, Гөлкәй... Югыйсә мине бик ярата, гел мина тартыла иде бит ул. Уйнарга чыгарга жыена башласам: «Апа, мин дә синен белән барыйм әле»,— дип ялына иде. Ә мин зур кыз, янәсе, бала-чага ияртеп йөримме сон?! Кечләрен дә мина килеп сыена: «Апа, икәү бергә ятыйк әле, мин берүзем куркам». Мин аны тагын янымнан куам.

Безнен гаиләдә һәркемнен үз тормышы иде. Ул кадәр туганлык, бер-беребезгә тартылу булмады да кебек. Борчаклар кебек төрлебез төрле яры сибелешеп яшәдек. Хәтта әни белән әти арасында да әллә ни якынлык, жылы хисләр юк иде шикелле. Әти оста итеп гармунда уйный, бик матур жырлый иде. Аны әледән әле туйларга, төрле мәжлесләргә чакыралар, һәм ул анда һәрвакыт ялгыз йөри. Шулай бәйрәм итеп йөри торгач, әти тәмам эчүгә сабышты, Горбачев заманында илдә аракы кытлыгы башлангач, ниндидер суррогат эчеп, түбән оч Салихжан абый белән икесе бер көндә агуланып үлделәр. Ике атнадан минем туй буласы иде... Әтинен нинди кеше икәнен дә, анын күнелендә нинди уйлар бөтерелгәнен дә мин анламый, белми калдым. Анын дөньясы безнен өчен ябык иде. Менә хәзер уйлыйм, Гөлкәй холкы белән әтигә охшаган бугай, ул да үзенә бер аерым, йомык күнелле, серле зат. Әниебез ифрат чибәр, авылда бер иде. Үзем шаһит, кибеткә тәмәкедер, аракыдыр алырга кергән абыйлар ана әллә нинди матур сүзләр әйтеп мактыйлар иде. Иртәнге чыкка манылган карлыгандай кара күзләре гел йөгереп, дәртле нур сибеп торалар. Гәүдәсе кызларныкы кебек ыспай, жыйнак. Олыгайгач та матурлыгын жуймады ул. Тик теге начар чир, яман шеш дигән нәрсә генә ул матурлыкны бер ел эчендә ашап-ялап бетерде.

Әле әти исән чакта ук авылда анын турында төрле имеш-мимешләр йөри иде. Имеш, колхоз рәисе Лотфулла абый белән яшерен мәхәббәтләре бар, имеш, кибеттә бикләнеп яталар... Лотфулла абыйнын хатынын паралич суккан, ул урамга да чыга алмый өендә чирләп ята иде. Бәлки бу сүзләрдә дөреслек тә булгандыр. Чөнки Лотфулла абый безнен гаиләгә гел ярдәм итеп торды. Әни авыргач, аны Казанга алып барырга үз машинасын да биреп торган иде.

Абый, авылнын данлыклы сугыш чукмары, армиядән кайтып та тормыйча, хезмәт иткән жирендә, дөнья читендә үк, Камчаткада яшәп калды. Хәтта әтине жирләргә дә кайта алмаган иде. Әни авыргач, хәл белергә кайтты кайтуын, тик бу сонгы кайтуы булды. Унжиде ел эчендә абыйдан бары өч хат килде. Шул кыска гына, чын мәгънәсендә уч төбе хәтле генә ул хатлардан без абыйнын өйләнүен, аннары улы тууын һәм ахыр чиге анын ошбу гаиләсе белән аерылып, кабат өйләнүен белдек. Абыйнын калган тормышы безгә билгесез булып, Камчатканын серле томаннарына төрелгән иде.

Гаиләбезнен шундый таркау, туганлык жепләре белән беркетелмәгән булуында әти һәм әни арасындагы салкынлык сәбәп булмадымы икән? Алар, бер-берсеннән ирекле булып, һәркайсы үз тормышы белән яшәргә омтылды бугай. Дөрес, гаиләбездәге мондый мөнәсәбәтләргә минем ул чакта исем дә китми иде. Чөнки уйланып, боегып утырырга вакыт юк, яшьлек дәрте кергән кызнын үз дөньясы, мәхәббәт дигән серле, татлы хиснен ни икәнен яна белә башлаган чак. Башта—күнел ачу кайгысы гына, иптәш кызлар белән очрашабыз да, колак исләре чыгара-чыгара, егетләр турында ләтчит сатабыз. Көндезләрен, мәктәптә чакта, кулдан-кулга хатлар йөри, кичләрен—тугайда «свидание». Беренче тапкыр егетләр белән кочаклашып, беренче үбешүләр... Әй, кем башыннан гына узмаган инде яшьлекнен бу самими, гүзәл мизгелләре. Шундый

чакта синдә энең яки сенлең кайгысымы? Ә Гөлкәй уч иткәндәй, һаман минем итәккә ябышкан: «Апа, синең белән барыйм әле...» Ялгыз иде шул ул, бигрәкләр дә ялгыз иде. Тотлыгуы аркасында дуслары да булмады бугай.. Тотлыккан кешене тыңлап бетерергә олы кешенең дә сабырлыгы җитми әле, ә бала-чаганы әйтәсе дә юк инде. Үзенең уйчанлыгы, җитдилеге белән дә Гөлкәй башкалардан аерылып тора, шуңа күрә яшьтәшләренә аның белән аралашу, уйнау күңелсез дә булгандыр, мөгаен. Үзе яшь булса да, күңеле карт иде сыман аның, сөйләшүе дә балаларча түгел, ничектер олыларча җитди иде.

Сеңлемнең беркайчан да артык сүз сөйләшмәвен, аңа сөйләгән сернең мәңге дөньяга чыкмаячагын яхшы белгәнгә, мин кайчакта аңа күңелемне бушата идем. Чөнки кичләрен, егетләр белән очрашып кайткач, күңелдәге хисләрне тыеп торып булмый, кем беләндер бүлешәсе килә. Ә иртәгәгә хәтле түзеп торыр чама юк. Андый чакта Гөлкәй мине тын да алмый тыңлый, әллә аңлый, әллә юк. Хәер, анысы минем өчен ул кадәр мөһим дә түгел. Сөйләшү гел бер яклы гына булмасын өчен, бервакыт мин аннан сорадым, болай юри генә, сүз югында сүз булсын дип кенә:

—Гөлкәй, ә сиңа берәрсе ошыймы соң?—дип сорадым.

Җавап бөтенләй мин көтмәгәнчә булды.

—Ошый...—диде Гөлкәй.

Кызыксынуым, түземсезлегем хәттин ашты:

—Кем ул, кем ?

—Ә син беркемгә дә әйтмисеңме соң?

—Юк инде, нишләп әйтим ди?!

Гөлкәй шактый гына дәшми торды, аннары кабат сорады:

—Чынлап та, апа, беркемгә дә әйтмисеңме?

Мин аның йөрәк серен мәңге чишмәскә ант иттем.

—Сигезенче класста укучы Зиннурны яратам мин, апа. Аның белән сөйләшәсем килә. Тик оялам. Хат язсам, көләр дип куркам. Нишлим икән, апа?—Йөрәгенә мәхәббәт кошы кунса, шулай ул, әллә нинди телсезләрне дә сандугачтай сайрата. Димәк, бу кызыйның да хисләре тәмам ташып чыккан, кемгә бушатырга белми аптырап, йөдәп йөргән чагы. Апасы белән киңәшми тагын кемгә дәшсен?

Мин Гөлкәйдән биш яшькә олы. Мәхәббәт, егетләр мәсьәләсендә шактый шомарган унҗиде яшьлек, әни әйтмешли « бүгеннән тотып кияүгә бирерлек» кыз. Шуңа күрә, тамак кырып, бик эшлекле кыяфәт белән акыл өйрәтергә керештем:

—Ә ул сиңа игътибар күрсәтәме соң? Синең белән сөйләшкәне бармы?

Гөлкәй уйланып торды.

—Сөйләшкәне юк та... Тик ул тәнәфестә гел миңа карый.

Мин көлеп җибәрдем:

—Анысы чүп кенә лә, сиңа шулай тоела гына. Әгәр ул сине ошатса, хат язар, очрашырга теләр иде. Син аның өчен бала-чага гына бит әле. Юк, сеңлем, үзең беренче хат язып, кеше көлдермә.

Бу кырыс сүзләрдән соң Гөлкәй ни кичергәндер, белмим. Чөнки аның йөзен күрмим, өйдә ут сүнгән, икебез дә юрган астында ятабыз. Хәер, унике яшьлек баланың күңел халәте мине кызыксындырмады да. Ул үзе дә сүз башлавына үкенде, ахры. Байтак кына дәшми торгач: «Апа, бу турыда беркемгә дә әйтмә, яме»,—дип тагын кабатлады.

—Курыкма, әйтмәм,—дидем мин. Һәм икенче көнне үк көлә-көлә дус кызларым Сәрия белән Әнисәгә сеңлемнең йөрәк серләрен түктем:

—Безнең Гөлкәй дә гашыйк булган икән! Мыштым гына йөри, уйламассың да! Вәт кызлар, хәзерге яшьләрдә уку кайгысы юк. Без аның кебек чагында башны бәрә-бәрә укый идек, әйе бит?!

Кызлар кычкырып көлде. Чөнки өчебезнең беребез әлифбадан башка китап укыган кеше түгел, дәресләргә әзерләнүнең ни икәнен дә белмичә, өлгерүчеләр

сафының койрыгында чак-чак эленеп торучылар идек. Мәктәпнең отличниклары, күзләрен йома-йома шигырь ятлаганда, хатын-кызга тормышта мәңге кирәге чыкмаячак мәсьәләләр чишеп утырганда, без урамда, укытучыбыз Луиза апа әйтмешли, «трай типтек», егетләр белән үбештек. Алга китеп булса да әйтим, өчебезгә адәм рәтле бер диплом кисәге булмаса да, беребез дә бу дөньяда югалып калмады. Чөнки дөньяга безнең заман, әрсезләр заманы килде!

Серен сатуым турында Гөлкәй икенче көнне үк белде. Теге ачык авызлар, сер тотмас үрдәкләр үчекләргә уйлаганнар бит моны. Гөлкәй кизләүгә суга төшеп барганда, капка турыларында көнбагыш чиртеп утыручы Сәрия белән Әнисә аны туктатканнар да, болай дигәннәр:

—Гөлкәй, сөенче сиңа!. Хәзер генә Зиннур үтеп китте, сине сорады, килсен, су буенда көтәм, диде. Бар, йөгер! Китеп бармасын тагын.

Әйтеп кенә калсалар бер хәл, пырхылдап көлгәннәр дә бит әле, юньсезләр. Ә Гөлкәй үзеннән көлгәнне болай да ифрат авыр кичерә, тотлыгуы аркасында да гел ирештереп, үртәп торалар бит. Бик гарьләнгән, үртәлгән ул, су буена төшеп тә тормыйча, буш чиләкләрен күтәреп кире кайтып киткән.

Гөлкәй миңа берни дә әйтмәде. Бу турыда, авыз ерып, кызлар үзләре сөйләде:

—Комач кызыл булды Гөлкәең, оялудан суга баруын да онытып, өегезгә сыпыртты! Шулай ул мәхәббәт!

Мин бу вакыйгага әлләни игътибар бирмәдем. Гөлкәйнең яшерен мәхәббәте дә, тәнәфесләрдә аңа караучы Зиннур исемле малай да минем өчен вак мәсьәлә иде. Үз хәлем хәл, яңа гына армиядән кайтып төшкән дөньяда бер чибәр егет Ярулла белән мәхәббәт куерткан көннәрем. Башкалар ник шунда әйләнеп капланмый!

Гөлкәйдәге үзгәрешләрне бары берничә көннән соң гына сизә башладым. Ул минем белән сөйләшми икән бит! «Апа» дип яныма килеп ятмый, артымнан иярми, соравыма җавап бирми. Әйтерсең, мин юк! Болай да аз сүзле Гөлкәй бөтенләй йомылды. Шунда гына сиздем, аңладым, бик авыр хәл икән ул сине кешегә санамаулары! Тегеләй дә дәшеп карыйм Гөлкәемә, болай да... Юк, ирнен кыса да, ишетмәмешкә салышып китеп бара. Ул үзенә бикләнде, күңелен миңа да, башкага да түгел, көндәлеккә бушата башлады. Мин ул көндәлекне Гөлкәй өйдә юк чакта урлап укыдым, тик үзем өчен берниндә кызык тапмадым. Зиннур турында да, башка егетләр турында да бер сүз юк иде анда. Гөлкәй күбрәк үзе турында язган, уйларын, хыялларын түккән. Миңа рәнҗүен дә язып куйган: «Үз апаң да саткач, кемгә ышанырга?! Мин аны мәңге гафу итмәячәкмен.»—дигән. Бу сүзләрне уку авыр булды, ләкин инде нишләсәм дә Гөлкәйнең ышанычын кайтара алмый идем. Сеңлем белән без гүя читләр идек...

* * *

Байтак еллар үткәч, кечкенә улымны алып, авылга иптәш кызым Әнисәләргә кунакка кайтканда, мин бер егетне очраттым. Безнең авылга олы юлдан өч-дүрт чакрым керәсе бар. Автобустан төшеп калып, юл чатында басып тора идем, бәхетемә, безнең якка таба бер җиңел машина борылды. Кул күтәрмәсәм дә, яныма килеп туктады. Безнең авыл кешеләре юлчыны юлда бастырып калдырмый. Бер машинада хәтта унлап кеше утырып кайткан чаклар булды. Андый вакытта унайлы-унайсыз дип сырланып тормыйсың инде, ишәккә утырырга да риза буласың.

Ә бу юлы заказ биреп чакырткан кебек, йомшак утыргычлы иркен, майларың эрерлек җылы машина эчендә хуҗадан башка беркем юк, утырып түгел, ятып барсаң да була.

—Рәхмәт... кем дип әйтим... Безнең авылныкыдыр бит?—дип сүз башладым мин сүз югында сүз булсын дип.

—Әйе.

—Яшьләрне таныл та бетереп булмый шул. Мәктәпне тәмамлауга авылдан киттем бит мин.—Руль артында утырган киң җилкәле, куе кара чәчле егет чынлап та, миңа таныш түгел иде.

—Ә мин сезне таныйм,—диде егет.—Сез Гөлкәйнең апасы.

—Бергә укыган идегезме әллә?

—Шулайрак.

Егет башка дәшмәде, үз уйларына чумды, авылга килеп җиткәндә генә:

—Гөлкәйгә сәлам әйтегез,—диде.

—Кемнән дияргә соң?

—Зиннурдан диярсез, әгәр онытмаган булса.

Зиннур... Мин аны искә төшердем. Кайчандыр Гөлкәй яраткан егет шушы икән. Ул да аңа битараф булмаган, димәк. Әнә бит, ни гомер узгач та, онытмаган.

—Беләм, беләм,—дидем.—Гөлкәй сиңа гашыйк иде бугай.

Ул чакта ук сер сатканны, хәзер ярый да ярый инде. Шул сүзләрне әйтүем булды, егет тормозга китереп тә басты. Машина кинәт туктаудан улым белән икебез дә алга сөрлегеп киттек. Кисәк кенә безгә таба борылган Зиннур белән чак кына маңгайга-маңгай сөзешмәдек. Шул арада мин аның куе зәңгәр күзләрен, тулы иреннәрен күрергә өлгердем. Чибәр иде Гөлкәйнең яраткан егете, һай, чибәр иде! Шундый егетне онытып, ничек теге юньсезгә кияүгә чыккан диген?! Зиннур кебекләр өчен утка-суга керерсең.

—Сез чынлап әйтәсезме, Нурсинә апа?

—Әйе инде, нишләп алдашып торыйм. Үз туганымны беләм бит инде! Аның белән синең хакта байтак серләштек,—дидем мин бераз чытлыкланып. Үземнең Атласымны үлеп яратсам да, яшьлектәге гадәт үзенекен итә, чибәррәк ир-ат заты күрдем исә, авыз үзеннән-үзе ерыла, күз уйный башлый.

Минем сүз Зиннурны уйга салды бугай, карашын каядыр еракка төбәп, үрмәкүч тәпиләредәй озын, сирәк керфекләрен күбәләк канатыдай каккалап торды да, башын чайкап:

—Белмәдем! Мин бит Гөлкәйгә дәшү түгел, якын килергә дә курка идем. Бигрәк горур иде бит ул. Аның өчен йөрәк байтак янды инде. Яратканын сиздергән булса соң...

«Әле хәзер дә соң түгел, Гөлкәй ялгыз»—димәкче идем, тик Зиннурның уң кулындагы алтын балдакны күреп алып, телемне тешләдем.

Әйе, Гөлкәй ул чакта иреннән аерылган, ялгыз иде. Аның кияүгә чыгуы да сәер булды. Әни Гөлкәйне сорарга кайтасыларын әйткәч, мин аптырап калдым. Чөнки Гөлкәй өй кошы булып гел өйдә утыра, ни клубка, ни кичәләргә, очрашуларга йөрми. Гомере буе карт кыз булып, ялгыз яшәргә тиеш кебек иде ул. Мин аның кем белән булса да яратышып, очрашып йөрүен, йә булмаса хат алышканын хәтерләмим. Шуңа күрә, Гөлкәйне сорарга киләләр дигәч, бер аптырашта калсам, булачак кияүне күргәч, артыма ук утыра яздым. Килешә-килешми дип тормыйча, Гөлкәйнең йөзенә бәреп әйттем ул чакта:

—Кайдан таптың бу мунча пәриен?—дидем.

Гөлкәй дәшмәде.

—Ичмасам, яратасыңмы соң син бу адәм кисәген?

Шул чакта Гөлкәй кеше ышанмаслык дәлил китерде:

—Аның әнисе яхшы, без бергә эшлибез,—диде.

Мин кияүгә чыкканда, булачак иремнең анасын да, атасын да, туганнарын да тикшереп тормадым, Атластан башкалар мине борчымый иде. Атласның берсе- берсе бишкә торырлык дүрт кыз туганы үзләренең барлыкларын соңрак белдерделәр. Әмма алар бишкә торса, мин берүзем унга торырлык идем, тәмле телем, мең төрле хәйләм белән Атласымны да үз ягыма аударгач, көрәш минем файдага тәмамланды. Чөнки мәхәббәтне җиңәрлек көч әле дөньяга тумаган. Мин ир белән торуның ни икәнен яхшы белә идем, шуңа күрә Гөлкәйнең

акылсыз сүзләре ачуымны китерде:

—Төнлә анасын кочаклап ятарсынмы?—дидем.—Әйтте диярсен, тора алмыйсын син монын белән, барыбер аерыласын. Мәхәббәттән башка яшәп булмый ул, сенлем!

Минем сүзләр дөрескә чыкты. Гөлкәй чынлап та аерылды. Әни авыргач, эшеннән китеп, аны карарга авылга кайтты да, шуннан соң инде кире китмәде. Ире янына гына түгел, хәтта Әлмәткә дә кайтмыйча, Яртауга барып урнашты. Мин анын яшьлек мәхәббәтен күргәндә Гөлкәй чынлап та ялгыз, тик инде Зиннур башканыкы иде.

•••

Яртауда мине беркем дә каршы алмады, каршы алырга тиеш тә түгел иде, чөнки Гөлкәй мин киләсен белми. Гаиләмне, бөтен эшемне ташлап, ерак юлга чыгуымнын сәбәбе дә Гөлкәй турында инде менә ничә айлар буе хәбәрсез булуымда иде. Ах-вах килешеп, алай еш очрашып, аралашып яшәмәсәк тә, барыбер бер-беребезнен исәнлеген белешеп тора идек. Гадәттә Гөлкәй үзе шалтырата, хат язмаса да, бәйрәмнәрдә, туган көннәрдә котлаулар җибәреп тора. Ин гаҗәбе дә шул булды, ни минем туган көндә, ни хатын-кызлар бәйрәмендә Гөлкәйдән бер хәбәр килмәде. Житмәсә, җомгага каршы бик яман төш күрдем. Имеш, әни өйгә кайткан да, кисәк-кисәк ит тозлый. Мин аптырап: «Нигә шулай күп тозлыйсын?»—дип сорыйм икән. Әни ашыга-ашыга җавап бирә: «Үзем белән алып китәм. Безгә хәзер ит күп кирәк, озакламый Гөлкәй дә килә, ул бит ит ярата»,—ди... Шабыр тиргә батып уяндым. Бу төшне берничек тә хәерлегә юрап булмасын яхшы анлап, мин икенче көнне үк, Атласнын сукрануына да карап тормыйча, төенчекләремне төйнәп юлга кузгалдым. Жаным тыныч түгел, күкрәгемә гүя боз тулган, бөтен эчемне өшетеп, калтыратып тора.

Автобустан төшкәч, шәһәр үзәгенә, Гөлкәй торган йортка ашыктым. Биш катлы кирпеч йортнын беренче катындагы бер бүлмәле фатирны без бергәләп сатып алган идек. Ни өчен шулай дим, чөнки әни авыргач, Гөлкәй аны карарга авылга кайтты. Һәм шул кайтуыннан ире янына башка китмәде дә. Әнинен елын үткәргәч, без йортны саттык һәм шул акчага Яртаудан Гөлкәйгә шул кечкенә генә булса да фатирны алып бирдек. Абый бу эшкә бөтенләй катнашмады, ризалыгын белдереп хат кына язды. Ә минем тормышым житеш, өемдә муллык, шуна күрә исталеккә әнинен мамык шәле белән тегү машинасын гына алдым да, калган бөтен әйберне Гөлкәйгә илтеп бушаттык. Сенлемнен тормышы начар түгел, тик һаман сыңар канат булып яшәве генә эчне пошыра иде.

Күпме шалтыратсам, шакысам да, ишек ачучы булмады. «Гөлкәй, сенлем, бу мин, апан, ач!»—дип ялвардым. Тик мина шомлы тынлык кына җавап бирде. Аптырагач, күршеләренә шалтыраттым. Колга буе бер ябык карт чыкты да: «Ее уже давно не видно, может в больнице, а может и померла»,—дип котымны алды. Әйберләремне ишек төбендә калдырып урамга чыктым. Гөлкәйнен фатир тәрәзәләре ишегалдына карый, тик пәрдәләр ябык, берни күренми. Шулай да, жирдән бер таяк алып, тәрәзәгә кактым. Бу инде аптыраганнан, чарасызлыктан гына эшләнгән эш иде. Шулчак, йа Ходайның рәхмәте, пәрдәләр тирбәлеп куйды, һәм мин тонык тәрәзәдә сенлемнен аксыл ябык йөзен күрдем. Ул ниндидер буш, битараф караш белән мина карап торды да, кабат пәрдә артына кереп югалды. Гөлкәйнен мондый битарафлыгы эчемне пошырса да, исән-имин күрүемә сөенә-сөенә, ишеккә йөгердем. Ул ачык иде. Тик Гөлкәй мине каршыламады, мин кергәндә ул урында ята иде. Алып килгән әйберләремне урнаштырып та тормыйча, анын янына килдем:

—Исәнме, Гөлкәй! Ни булды сина? Авырыйсынмы әллә?

Ул дәшмәде, буш карашын стенага төбәп ятуында булды. Мин анын йөзенен

ябыклыгына, сарылыгына аптырап карап тордым. Мондый ябыклык, мондый сарылык миңа таныш иде... Йөрәгем жуу итеп китте: « әни чире...»

—Гөлкәй, кай жирең авырта, сеңлем?

Сеңлемнең иреннәре кыймылдап куйды:

—Хәлем юк...—аның тавышы үтә дә көчсез, зәгыйфь иде.

Куркыныч төш юкка гына кермәгән икән шул...Йөрәгемә шом үрләде, күзләремә яшь тулды. Гажиз карашымны кая төбәргә белмичә бүлмә буйлап йөгерттем. Шунда гына фатирдагы үзгәрешләрне абайлап алдым. Гажәпләнүемнең чиге булмады. Чөнки монда Гөлкәй яткан караваттан белән түгәрәк өстәлдән башка берни калмаган, бүлмә шып-шыр, буш иде. Ни булган монда? Йә Раббым, ни булган?!

—Гөлкәй, кайда синең әйберләрең? Телевизорың, диваның, шкафларың кайда?

Ниһаять, сеңлем миңа таба борылды, нидер исенә төшерергә теләгәндәй, кашларын җыерып уйланып торды, торды да:

—Минем скрипканы урладылар,—диде. Шул сүзе белән гүя болай да миңгерәгән башыма китереп сукты. Аны акылыннан язган дип уйларга тулы нигез бар иде...

Ә сеңлем ифрат тыныч, буш, битараф карашын миңа төбәгән дә, мыскыллаган кебек сүзен дәвам итә:

—Мин инде скрипкада уйнарга өйрәнгән идем...

Аның белән сөйләшүнең файдасызлыгын аңлап:

—Әйдә, бергәләп чәй эчәбез,—дидем. Чынлап та, юлдан соң тамагым кипкән иде.

—Минем ашыйсым килә,—диде сеңлем.

—Хәзер бирәр нәрсә әзерләрбез.

Ярый әле сумка тутырып азык-төлек алып килгәнмен. Чәй әзерләгәч, мин аны табынга дәштем. Сеңлем урыныннан кузгалды... Һәм минем каршымда... тире белән сөяктән генә торган бер җан иясе пәйда булды. Торып баскач та ул кинәт чайкалып китте, аннары кабат урынына утырып:

—Монда гына алып кил,—диде. Әни дә шулай ябык, көчсез иде...

Китергән тәм-томны кабаланып ашарга керешкәч кенә мин сеңлемнең ни дәрәҗәдә ач булуын аңладым. Авыру кешеләр болай ашамый. Шул уй күңелемә җылы кертеп җибәрде. Гөлкәйнең:

—Апа, минем ит ашыйсым килә,—дигән сүзләрен дә ишеткәч, күңелемдәге шомлы, авыр уйлар таралып киткәндәй булды. Болай булгач, өмет бар! Өмет бар!

Икенче көнне, өйдәгеләргә хәбәр бирергә дип, иртүк телефоннан сөйләшергә киттем. Гөлкәйне ташлап китә алмавымны, тиз генә кайтып булмасын әйтергә кирәк иде. Билгеле, Атлас ризасызлык белдерде, йорт тулы мал-туар, аларны кем карый, дип сукранды. Алай авыргач, Гөлкәйне үзебезгә алып кайт, монда карарсың, диде. Гөлкәйнең безгә кайту түгел, ишек алдына да чыгарлык хәле юк икәнен ничек аңлатасың аңа? Кеше ышанырлык хәлмени. Ярар, исән кешеләр яшәр ничек тә, Атлас янында ике малай бар. Мәктәптә генә укып йөрсәләр дә эш рәтен беләләр. Ә мин монда, сеңлемә кирәк. Миннән башка аның беркеме юк.

Тукта, нишләп булмасын ди әле? Ул бит эшли иде. Эштәгеләре ник хәл белергә килмәгән? Кеше ачтан үлеп ята, ник берсе килеп карасын!

Гөлкәйнең үзәк почтада эшләвен белә идем. Халидә исемле дус кызы бар икәнен дә белә идем. Кереп сораштырып карарга булдым. Ни булган Гөлкәйгә? Сәламәтлеге ташып торган яшь-яшь кеше нигә мондый хәлгә төшкән?

Сөйләшү пунктыннан чыктым да, почтага юнәлдем. Бер тәрәзә янында беркем юк иде, шунда утырган кара тут йөзле, калын кашлы хатынга мөрәҗәгать итеп:

—Гөлкәй Ризвановны чакырыгыз әле,—дидем.

—Кем ул?
—Кассирмы инде, контролермы шунда...
—Бездә андый кеше юк.
—Ә Халидә?
—Фамилиясе ничек?
—Белмим.
—Белгәч, килерсез. Монда справочный түгел.

Эчке бүлмәләргә илтә торган ишеккә юнәлгән идем, тоташ зәңгәрдән киенгән чалбарлы бер кырыс ханым минем юлыма аркылы төште:

—Посторонним вход воспрещен! Күрмисеңмени, акка кара белән язылган.

Әмма Ходай бар икән. Бирим дигән колына—чыгарып куя юлына. Нәкъ шул чак урам ягындагы ишектән ябык озын буйлы, сары курткалы бер яшь кыз йөгереп керде дә, бая гына мин сөйләшеп торган тәрәзәгә капланып:

—Дамира апа, шалтыратыгыз әле Халидә Мирзовнага, тизрәк чыксын. Банкка барырга машина килде,—диде. Күп тә үтмәде, тыюлы ишектә җыйнак гәүдәле, 30-35 яшьләрдәге бер сөйкемле ханым пәйда булды. Ул, үз исемен ишетүгә, миңа борылып карады, танымавына бермәл аптырап та калды бугай. Аның ашыкканын белгәнгә, вакытны сузмыйча, сүземне әйтеп калырга ашыктым:

—Нишләттегез Гөлкәйне?

Халидәнең йөзенә курку, аптырау галәмәте чыкты, күзләрен зур ачып:

—Ни булды ана? Кайда ул?—дип сорады.

—Өендә, ачлыкка интегеп ята. Ник хәлен белмисез? Сездә эшли бит ул!

Шулчак Халидә яныма ук килеп колагыма пышылдады:

—Ул монда эшләми. Мин үзем дә Гөлкәйне югалттым. Өенә әллә ничә бардым, ишек ачучы булмады.

—Ничек инде эшләми?!

—Сез аның апасымы?

—Әйе.

—Алайса, бүген кич белән мин сезгә киләм.

Ул сүзендә торды, килде. Әмма Гөлкәй никтер Халидә белән сөйләшергә теләмәде. Бер сүзгә катнашмыйча, Халидәнең сорауларына җавап бирмичә, ниндидер чит кеше сыман утырды, утырды да, кисәк кенә урынына барып ауды һәм үксеп-үксеп елый башлады. Мин ана тынычландыра торган дару бирдем. Күзләрендә яшьләре дә кипмәгән килеш, Гөлкәй ничектер бик тиз йоклап та китте.

Халидә исә, гаепле кеше сыман башын иеп, уйга батып утырды. Аннары миңа карамыйча гына сөйли башлады:

—Гөлкәй безне гаепли. Ләкин нишлик соң, Нурсинә апа?! Барыбызга да яшәргә кирәк бит! Розаның кызы түләүледә укый, иренә бернәрсә кирәкми, эчә дә эчә генә. Галяның чирле улын армиягә алырга торалар, көч-хәл белән майлап-җайлап йөри. Зәкиянең кредит түлисе бар. Барысының да койрыгы бозга каткан... Дөреслек артыннан чаба башласаң, үзең генә батасың... Заманасы шундый бит аның. Ярый ла Гөлкәй берүзе... Ана да кирәкми иде. Ни үзгәрә соң? Чебен дулап тәрәзә ватамы? Чүп кенә бит без алар өчен, бет кенә... Сыталар да китәләр.

Халидәнең бер олау сүзеннән мин берни дә аңламадым. Ул болай да билгесезлектән телгәләнгән күңелемә яңа сораулар гына өстәп китеп барды...

Тавык шулпалары, сөт ризыклары килеште Гөлкәйгә, йөзенә бераз төс керде. Ул инде элеккечә хәлсез түгел, йөгереп йөрмәсә дә, сөйләшә башлады. Аның сөйләвеннән мин шуны аңладым, чынлап та Гөлкәйнең скрипкасы булган, ул хәтта бер танышыннан дәресләр алып йөргән, яхшы гына уйный да башлаган. Ә диван белән шкафны, эшсез, акчасыз калгач, үзе саткан икән. Калганнарын, шул исәптән скрипканы да урлап чыкканнар. Көпә-көндез. Гөлкәй ишеген бикләргә онытkан булган. Шул арада кайсыдыр күреп, кереп

өлгергән. Тик үзенең нигә эшсез калуын Гөлкәйнең сөйлисе килмәде, сорауларымны җавапсыз калдырды. Гомумән, аңардан ни дә булса сорашу, төпченү файдасыз, ул бары тик үзе теләгәнне генә әйтә, әңгәмәнең дилбегәсе тулаем аның кулында иде. Минем көнем ашарга пешереп, аны карап, өйдә җыештырынып, кибетләрдә йөреп үтте.

Икенче көнне Халидә тагын килде, бу юлы буш кул белән түгел.

—Кызлар бирде,—дип өстәлгә азык-төлек тулы зур гына пакет китереп куйды.

Ул килгәндә Гөлкәй йоклый иде, шуңа күрә без шыпырт кына кухняда сөйләшеп утырдык.

—Нурсинә апа, Гөлкәйне үзегез белән алып китегез. Калдырмагыз берүзен,—диде Халидә.—Аңа хәзер санаторий кирәк. Нервылары какшаган аның.

—Ни булды соң аңа? Ник эшсез калды ул?

—Кирәк булса, үзе сөйләр, миннән сорамагыз,—диде Халидә.

—Мин Гөлкәйне алып китәрмен. Тик фатирына күз-колак булып торырга кирәк. Әнә бит, бөтен әйберен урлап чыкканнар. Үзе булмаганда, Алла сакласын, кереп тә утырырлар.

—Аның фатирын берәрсенә тапшырырга кирәк. Акчасы да була, түләп-карап та торырлар,—диде Халидә.

—И-и, аның белән йөрергә вакыт бармы? Монда ай буе ятып булмас бит.

Халидә бераз уйланып торды да:

—Әгәр ышансагыз, бу эшне миңа тапшырыгыз.

Ничек инде ышанмыйсың ди? Шулай сөйләштек тә. Халидәгә адресымны, өй телефонын бирдем. Ул Гөлкәй фатирының ачкычын үзе белән алып китте, иртәгә ясатып китерәм диде.

Икенче көнне Гөлкәйнең әйберләрен сумкаларга тутырырга керештем. Кәгазь тартмалардагы киемнәр арасыннан зәңгәр тышлы ике калын дәфтәр килеп чыкты. Ачып карамасам да аңлашыла, бу Гөлкәйнең көндәлекләре иде. Димәк, һаман яза, серләрен бары кәгазьгә генә ышанып тапшыра. Шулай да кызыксынуым җиңде, дәфтәрнең берсен алып, актарып карадым. Дәфтәр канатларындагы вак, тигез җөмләләр Гөлкәй күңелендәге бик күп серне ача ала иде. Тик боларны укып торырга әлегә вакыт та юк, аннары Гөлкәй күреп алса, үпкәләячәк иде. Шулай да мин соңгы биткә күз салырга өлгердем. Ул биттәге язуны күрми мөмкин дә түгел иде. Чөнки ак битне тутырып зур, исерек хәрефләр белән бары ике генә сүз язылган:

Нишләттегез Гөлкәйне?!

Укыдым да сискәнеп киттем. Шул ук сорауны мин Халидәгә дә биргән идем. Тик ул миңа берни әйтә алмады. Сорауның җавабы кемдә? Гөлкәй үзе аны кемгә атаган? Сеңлемнең бу хәлгә төшүенә кем гаепле? Көндәлекләрне укысам, бәлки күп нәрсәне белә алыр идем. Төнлә, Гөлкәй йокыга киткәч, мин аларны укыячакмын.

Ләкин ниятем чыңга аша алмады. Гөлкәй төне буе йокламыйча бәргәләнеп чыкты. Үксеп- үксеп елады, «Үләсем килә!» дип өзгәләнде. Мин ни эшләргә белмәдем, биргән даруларымның да ярдәме тимәгәч, ашыгыч ярдәм машинасын чакырырга туры килде. Өстенә ак халат кигән яшь кыз илтифатсыз гына Гөлкәйне карады да, ниндидер укол кадап китеп барды. Бу нинди чир, дип сораган идем, иңнәрен сикертеп: "Витафобия",—диде. Мин берни аңламадым, андый чир турында гомеремдә ишеткәнем юк иде. Гөлкәй йокыга киткәч тә,—көндәлек уку дәрте калмады—мин дә урынга барып аудым...

Фатирны Халидә карамагына калдырып, икенче көнне без Шенталыга кайтып киттек. Гөлкәй юл буе сөйләшмичә, тәрәзәгә карап барды. Хәер, бер сүз әйтте, җәй килгән икән, диде. Күрәсең, күптән урамга чыкканы булмаган. Тере мәет шундый буладыр инде... Ә мин сеңлемнең көн яктысында тагын да төссезрәк, ябыграк күренгән боек йөзенә карап, аны кызганып, үземне битәрләп кайттым. Шул гомер үз туганынның хәлен белми яшә инде. Әгәр, Алла

сакласын, үлгән булса... Гомерлек үкенеч бит. Юк, Гөлкәйне беркая да җибәрмим. Фатирын сатарбыз да, Шенталыга кайтып урнашыр. Хисапчы эшен кайда да табып була. Бергә яшәргә кирәк. Кайгыда да, шатлыкта да бергә.

Халидә бер айдан соң шалтыратты. Фатирга бер яшь гаилә керткән, акчасын бер елга алып куйган. Санаторийлар хакында да белешкән икән. Нәкъ менә нервы-йөрәк чирләрен дәвалый торган бик әйбәт «Хыял» шифаханәсенә юлламалар бар, шул акчага сыешып була, диде.

Гөлкәй бездә бераз хәлләнеп китте китүен, тәненә ит, йөзенә нур кунды. Әмма аның күңел халәте әлләни үзгәрмәде. Үз уйларына батып, күләгә кебек йөри, авызыннан «әйе», «юк»тан башка сүз чыкмый. Ичмасам бер көлеп, елмаеп карасын!

Ул еш кына урамга, капка төбенә чыгып баса да, карашын күккә төбәп нидер пышылдый. Шыпырт кына артыннан килеп сүзләренә колак салган идем, сеңлемне кызганудан елыйсыларым килеп китте.

—Әй болытлар, ак болытлар, алып китегез минем сагышларымны, үзегез белән еракларга-еракларга алып китегез. Күңелемә тынычлык килсен, өшегән йөрәгемә кояш нурлары тулсын. Агымсулар белән бөтен борчуларым агып китсен, җылы җилләр җаныма өмет бирсен, минем бу җирдә яшисем килсен! Ярдәм итегез миңа! И, Ходаем, рәхим-шәфкатеңнән ташлама! Җирне ничек яңартсаң, минем җанымны да шулай яңарт, яшәргә көч бир!

Яшисем килә, димәде Гөлкәй, «Яшисем килсен!»—диде. Нигә шул хәтле тормыштан, якты дөньядан бизгән соң ул? Мин моны берничек тә аңлый алмадым.

Санаторийга барырга ризалашырмы икән дип шикләнгән идем, Гөлкәй берсүзсез күнеп, әйберләрен җыя башлады. «Барасын киләме соң?» дип сорагач, «Миңа хәзер кайда да барыбер»,—диде. Бөтен нәрсәгә битараф булуны медицина телендә депрессия диләр. Кайберәүләр еллар буена бу халәттән чыга алмыйча, җансыз кеше кебек яши ди. Мондый чакта яшәү урынын алмаштырырга, яңа кешеләр белән аралашырга кирәк икән. Эштәгеләр миңа шулай диделәр. Шуңа күрә мин Гөлкәйне санаторийга җибәрү ягында идем.

Гөлкәй киткәч, гәрчә аның барлыгы әлләни сизелмәсә дә, миңа ямансу булып калды. Ничектер ул гел өйдә кебек, әле бер, әле икенче бүлмәдән килеп чыгар кебек тоелды. Чөнки тавышсыз-тынсыз гына, бары тик һавадан гына торган җан иясе кебек йөри иде ул. Сеңлем китеп берничә көн үткәч, мин аның көндәлекләрен искә төшердем. Гөлкәйнең караваты астындагы сумкала булгач, әлегә кадәр аларга берничек тә кагыла алмый идем. Инде иркенләп актара башладым. Көндәлекләрне Гөлкәй үзе белән алмаган, алар шунда, киемнәр арасында калган иде. Вак хәрефләрдән тезелгән тигез юллар әкияттәге йомгак җебедәй мине Гөлкәйнең серле караңгы тормышына алып кереп китте...

* * *

**7 август, 1989.**

Мин зәңгәр төсне яратам. Дөнья үзе дә гел зәңгәр төстән тора бит. Күк тә зәңгәр, йолдызлар да, диңгез дә... Зәңгәр чәчәкләр бар, тагы... зәңгәр күзләр бар. Аның да күзләре зәңгәр иде. Тик ул күзләргә мин туйганчы карый да алмадым. Әгәр карасам, кереп баткан булыр идем. Әгәр без бергә булсак, мин гомерем буе зәңгәр томан эчендә яшәр идем. Исерек кеше кебек. Мәхәббәттән исереп. Кадерлем... Ул да сине минем кебек яратамы? Әгәр шулай икән, мин бик бәхетле. Юк, ничек инде бәхетле булыйм ди? Ничек инде мин синсез бәхетле булыйм ди?! Әмма нишләргә соң? Шул кадәр озын гомерне синсез, мәхәббәтсез ничек яшәп бетәрмен мин? Синсез яшисем килми!!!

Төнә көнне мин бөтен көндәлекләремне яндырдым. Сезнең очта төн буе гармун тавышлары, җыр-көлүләр яңгырап торды, ә мин мунчага барып, мич

кабыздым. Төне буе шунда ак хыялларымны яндырып утырдым. Җидегән йолдыз җиде була, җиде әйтсәң, савап була... Мин сине җиде ел беләм икән. Җидене серле сан диләр. Серледер шул... Җиде елга—җиде көндәлек. Җиденче август. Синең туең... Ә мунча мичендә минем мәхәббәтем, ак өметләрем, якты хыялларым яна. Утка барыбер. Ул минем хисләремне комсызланып йота. Минем хыялларым аңа ашар ризык кына шул. Мунча ишеген яптым бит югыйсә, йөрәгемне телә торган бу дәртле шат көйләр кайдан гына саркып керә соң?! Син бәхетледер бүген. Аны үбәсеңдер. Ә ул нинди бәхетледер! Аннан да бәхетле кеше дөньяда юктыр да. Ул синең зәңгәр күзләреңә карый-карый көләдер... Ә мин бүген үләм. Әкияттәге су кызы кебек күбеккә әйләнәсе иде...

Җиденче август—Гөлкәйнең үлгән көне. Белегез: бу җирдә Гөлкәй дигән кеше юк. Бүген Гөлкәй үзенең җанын югалтты. Ул бүген үзенең җанын аның кәләшенә—безнең авыл балаларына биология укытырга килгән Сарман кызына бирде. Сарман кызы минем өчен яшәячәк. Чөнки ул аның белән.

**15 сентябрь, 1997.**

Мин Яртауда, үземнең фатирымда тәртип урнаштырып маташам. Минем үз оям бар. Тик бу ояда мин япа-ялгызым яшәячәкмен. Җыештырганда, китаплар арасыннан зәңгәр тышлы дәфтәрем килеп чыкты. Мин аның турында бөтенләй оныткан идем. Чүп-чар белән бергә чыгарып ташларга уйлаган идем дә, тик никтер кызганыч булып китте.

Мин хәзер тормышка башкачарак карый башладым. Менә кеше. Ул бар, ул синең яныңда, сөйләшә, көлә, йөри. Ул бар. Тик синең аның барлыгына исең китми, шулай булырга тиеш кебек, ул мәңге булыр кебек. Кеше яши, ул синең янәшәңдә йөри, монда гаҗәпләнерлек берни дә юк. Аның ни кадәрле кадерле, газиз зат икәнен син әле аңламыйсың да. Кай чагында аны күрмисең, ишетмисең, тыңламыйсың. Ә көннәрдән бер көнне ул юкка чыга. Син аны сагынасың, эзлисең, табышын ишетәсе, йөзен күрәсе, күзләренә карыйсы килә. Ләкин ул юк... Дөньяларны актарып эзләсәң дә, аны башка күрә алмыйсың, әйтер сүзләреңне җиткерә алмыйсың. Хәтта ул бик якында, аяк астында гына булса да... Чөнки ул кеше белән сине үлем аера. Ул кеше синнән мәңгелеккә киткән, башка очрашулар юк. Юк...

Әнине югалтканнан соң үзем дә упкынга төшеп киткән кебек булдым. Әтинең үлеме болай ук авыр булмаган иде кебек. Чөнки туган йортыбыз, әниебез бар иде. Апага да шулай авырмы икән? Аның янында ичмасам ире—Атлас җизни бар, ике улы—Ленары белән Илнары бар. Ә минем беркемем юк. Мин япа- ялгызым. Өч ел ир белән яшәп балам да булмады. Бала булмагач, ник яшәргә, тормышның ни яме бар? Барыбер яратмыйм ич мин аны. Шуңа күрә Әлмәткә кире кайтасым да килмәде. Апа белән җизнәй әйберләрне алып килештеләр, урнаштырыштылар да кайтып киттеләр. Алар киткәч, берни эшли алмыйча тиле кебек тәрәзәгә, минем өчен әлегә ят булган шәһәрнең урамнарына, шул урамда йөрүче бөтенләй чит кешеләргә карап утырдым. Ник килдем инде мин монда? Нәрсә эзләп, нәрсә көтеп? Нәкъ менә шул калага ашкындым бит. Әллә бәхетем, мәхәббәтем шушы шәһәрдә көтәме? Бөтен дөньяны, хәсрәт-кайгыларны онытып, гашыйк буласы иде! Яраткач, яшисе дә килер иде. Күңелдә бу кадәр бушлык булмас иде. Мәхәббәт, дөньяда Гөлкәй исемле бер хыялый җан бар икәнен онытма, кил син миңа, күңел күгемдә аккош булып оч, йөрәгемә очкын булып төш тә, учак ягып, туңган җанымны җылыт. Кил, мәхәббәт, читләп үтмә мине!

**20 сентябрь, 2002 ел.**

Исәнме, зәңгәр дәфтәр! Таныйсыңмы син мине? Таныйсыңмы? Күрәсеңме, нинди сәер бүген синең хуҗаң? Урамда—көз, ә минем күңелемдә гөлләр чәчәк ата, сандугачлар сайрый! Бүген Гөлкәйнең күзләреннән бәхет түгелә. Бүгенге көн кичәге көнгә бөтенләй, бөтенләй охшамаган! Юк, кичә белән бүгенне бутыйм бугай мин. Сәгать төнге ике бит инде. Шулай булгач, мин инде ике

көн бәхетле, ике көн! Бу бит шундый күп! Кайчагында бер мизгел дә бөтен тормышыңны яктыртырга житә. Ә монда ике көн! Рәхмәт, язмышым, рәхмәт сиңа! Син аны юлыма чыгардың, син мине ул үтәсе сукмактан алып киттең. Әгәр без очрашмаган булсак... уйларга да куркыныч, әгәр мин башка урамнан киткән булсам... Бу бит коточкыч югалту була иде. Югалту да түгел, бу тапмау була иде. Һәм минем бүгенгә көнемдә шатлык кояшы балкымый иде. Бу кояш төнемне якты, кышларымны жылы итәчәк. Аңлыйсыңмың син мине, дәфтәркәем-сердәшем? Барысы да шундый сәер булды. Бәлки могжизадыр? Мин бит аны төшемдә күрдем. Шундый ачык итеп, нәкъ өндәге итеп. Имеш, нindидер жыелыш бара икән. Кеше күп. Алда өстәл артында берничә ир утыра. Шуларның берсе никтер миңа төбәлгән. Мин башта игътибар итмим әле, аннары безнең карашлар очраша. Шулчак бөтен дөнья югала, бар нәрсәне томан төреп ала, бары тик без икәү, ул да мин генә калабыз. Аның карашы шундый назлы, жылы, бу караш йөрәгемә үтеп керә. Мин үземә төбәлгән зәңгәр күзләргә карап сихерләнеп, оеп утырам. Менә ягымлы ир урыныннан торып, каршыма килеп баса да, миңа кулын суза. Без кулга -кул тотышып бүлмәдән чыгып китәбез. Ишек төбендә ап-ак «Волга» машинасы тора икән. Ир миңа ишекне ача, аннары үзе рульгә утыра. Һәм без китәбез. Каядыр тауга таба менәбез, йөзебезгә батып барган кояшның алсу нурлары төшә. Кая барабыз, мин белмим, ләкин миңа шундый рәхәт, шундый тыныч. Күңелем тулы шатлык икән. Үзем уйлыйм: без икәү, без бергә!

Менә шундый матур төш күрдем мин, дәфтәркәем. Уянгач та озак айный алмыйча яттым әле. Күз алдымда миңа шундый яратып, назлап караучы һаман шул ягымлы ир булды. Мин ана төшемдә генә түгел, өнемдә дә гашыйк булдым. Аның карашы мине көне буе озатып йөрде, ул көнне мин гомердә булмаганча шат идем, көләч идем. Хәтта эштәгеләр сәерсенеп карадылар. Сөйләп кара син аларга, төшемдә күргән егеткә гашыйк булдым дип, кычкырып көләчәкләр.

Шул төшем, шул матур төшем чынга ашар дип хыялланырга да кыймаган идем югыйсә. Бу чынлап та бер могжиза булды!

Без эштән гел Халидә белән кайтабыз. Ул бу арада гүя вулкан өстендә яши, жаның кая куярга белми. Чөнки иренең мәхәббәте суынган, каядыр читтә йөри. Кайбер төннәрдә бөтенләй кайтмый икән. Халидә әрну-сагышларын миңа бушата. Мин ана берничди киңәш бирә алмыйм, бары тыңлыйм гына. Мохтарның да соңга калып та, куныл та кайтканы бар иде, тик миңа барыбер иде. Мин көнләшүнең нәрсә икәнен белмәдәм. Ә Халидә ирен бик ярата. Чөнки алар яшьтән үк яратышып, йөрешеп өйләнешкәннәр.

Кичә дә без бергә кайттык. Безнең йорт турысына житкәч, Халидәнең никтер миннән аерыласы килмәде. Ялгыз каласым килми, әйдә әзрәк урамда йөрик әле, диде. Мин ана каршы килә алмадым һәм без паркка таба юналдек. Быел көз бик матур килде. Аяз, якты. Аяк астына алтын яфраклар сибелгән. Шундый тәмле чиста һава, сулап туймалы түгел. Әкрен генә барабыз. Шул чак каршыбызга әллә кайдан гына кара күн курткалы таза бер ир килеп чыкты да, безгә эндәште:

—Кызлар, туктагыз әле, сезгә сүзем бар,—диде.

Без туктадык.

—Мин сезне семинарга чакырам, бик кызыклы тема. Күңелсез булмас, үзегез өчен ни дә булса алырсыз. Бүгенге заманда укымышлы, хәбәрдар булу кирәк.

Без, билгеле, аптырап калдык, бик сәер булып тоелды аның сүзләре. Мөгаен берәр товарга реклама ясамакчы буладыр, дип уйладым мин. Бу сәер бәйләнчек бәндәдән тизрәк котылмакчы булып, кул селтәп китеп барасы идек... Шулчак...

Шулчак каршы йорт почмагыннан аксыл плащлы, озын буйлы тагы берәү йөгереп чыкты:

—Фидаил, әйдә, башлыйбыз,—дип кычкырды.

Бу ул иде... Мин аны шундук таныдым, бу бит ул, төшемә кергән ир иде! Бер мәл чокырга төшеп киткәндәй мингерәп, югалып калдым. Халидә мине җиңемнән тарта, ә мин селкенә дә алмыйм.

—Менә, кунаклар чакырам да, ялындыралар, кермиләр әле,—диде Фидаил атлысы.

Аксыл плащлы ирнең кызыксынучан һәм зәңгәр нур белән тулы ифрат ягымлы карашы безгә күчте:

—Кызлар, әйдәгез, акыллы сүз тынлап чыгыгыз, үкенмәссез.

Һәм мин сихерләнгән кебек аңа иярдем. Халидә нәрсәдер кычкырды, әмма ул әйткән сүзләр акылыма барып җитмичә, сукмакка сибелеп калды...

Шулай итеп мин аңа таба атладым. Әгәр ул шул чакта тәмугка чакырса да, мин барыбер берсүзсез аңа ияргә идем.

Без таш йортның таш баскычлары буйлап икенче катка күтәрелдек. Ниндидер бүлмәгә кердек. Анда байтак кеше җыелган, тик аларның барысы да ир-ат затыннан иде. Кызык инде, ир-атлар күп булган җирдә гел караңгы төсләр хуҗа була. Ә хатын-кызлар җыелса, гүя гөлбакчага килеп керәсең, нинди генә якты, иркә төсләр булмый анда.

Мин аптырап, каушап калдым. Бу хәтле ир-ат арасында берьялгызым нишләп йөрим әле? Шулчак бәлки борылып чыгып китәсе булгандыр.

Ләкин минем китәсем килмәде. Чөнки шул кара төсләр арасында үзенең ак плащы белән аерылып балкып торган ир-егет күңелемне ымсындырып, үртәп тора иде. Юкка гына кермәгәндер ич ул минем төшемә?

Шулчак түрдә, өстәл артында утыручыларның берсе торып басты да:

—Башлыйбыз, иптәшләр, утырышыгыз,—диде.

Мин ишек кырындагы артсыз урындыкка урнаштым. Мине үзе белән ияртеп кергән ак плащлы ир нәкъ каршыма килеп утырды да, күзләремә туры карап, ничектер бик якын, үз итеп елмаеп куйды. Шул елмаюдан бөтен җанымтәнем балкып, җылынып китте, гүя ниндидер серле бер көч ике күңел арасында күзгә күренмәс күпер сала башлады.

—Җыелышны башлыйбыз, иптәшләр,—дип кабатлады да түрдәге ир, нидер сөйләргә кереште. Мин аны тыңларга, сүзләрен тотып, башыма салырга күпме тырышсам да, барып чыкмады, чөнки күңелемдә бөтенләй үзгә уйлар бөтерелә иде. Төшемдә күргән ягымлы затның җылы карашы астында оеп, бар дөньямны онытып, мәрткә китеп утырдым. Һәммәсе томан эчендә иде. Кыюланып, әллә ничә тапкыр карашымны аңа күчердем. Аның зәңгәр күзләре туп-туры миңа, бары миңа гына төбәлгән иде... Шул ягымлы караштан бөтен тәнемә ут йөгерде, йөрәгем ярсып типте, үсмер чагымдагы кебек, зәңгәр тирән күлләргә кереп чумарга, кире чыкмаска да әзер идем. Шундый күркәм ирнең игътибарыннан, җылы карашыннан бәхетнең җиденче катында канатсыз очып йөрдем.

Шулчак Ул урыныннан кузгалды, түргә табан атлады һәм өстәл янына килеп басып:

—Гамир Зәкиевич белән килешмим мин,—диде.—Нишләп әле без эшмәкәрләр белән генә эш итәргә тиеш? Әйе, алар бай, матди ярдәм күрсәтә алалар. Ләкин алар аз бит. Безгә гади халыкны, эшчеләрне, авыл кешеләрен үзебезнең сафка тартырга кирәк. Әгъзаларыбыз күбрәк булган саен, массалар белән ешрак аралашкан, очрашкан саен партиябез идеологиясе дә киңрәк таралачак. Сайлаучыларның төп өлеше—гади халык, шуңа күрә иң беренче очракта аларның ышанычын яулау кирәк.

Мин айнып киткәндәй булдым. Нинди җыелыш соң бу? Нинди партия? Минем үз гомеремдә сәясәт белән кызыксынганым юк. Телевизордан иң өнәмичә караган тапшыруым да—яңалыклар. Тегендә атканнар, монда шартлатканнар... Яшәргә куркырсың. Бер яхшы хәбәр юк. Бер үк кешеләрнең акыл сатулары да туйдырды инде. Сөйлиләр дә сөйлиләр. Тик бернәрсә үзгәрми... Алардан беркем бернәрсә өмет итми, тик Чечнядагы кебек сугыш кына булмасын.

Ә Ул әнә нәрсә ди... Димәк, Ул минем кебек дөньясын онытып утырмаган, тынлаган. Мин исә хыял дәрьясына чумып, кемнәрнең нәрсә әйтүен түгел, хәтта кемнәр сөйләгәнен дә искәрми калганмын.

Чөнки Анардан башка мине беркем, берни кызыксындырмады. Һәм бу сәер җыелышта мин бары тик төш белән өнне кавыштырырга теләп кенә утырдым...

Башкаларны тынлыйсым килмәсә дә, Аның һәр сүзен йотылып тыңладым. Һәм тынлаган саен үзем өчен якын, калерле була башлаган бу сөйкемле затның акыллылыгына, шулай оста итеп, ышандырып, аңлатып сөйли алуына сокландым. Тотлыкканга күрәме, бу кадәр кеше алдында чыгыш ясау түгел, хәтта үз иптәшләрем алдында да артык сүз әйтергә уңайсызланам, каушыйм мин. Минем өчен сөйләү гел газаплы бер эш булды. Ә ул үзен шундый иркен тота, сүзләрен кистереп әйтә:

—Партияләр күп, берсе дә начарны вәгъдә итми. Сайлау алдыннан барсы да сандугач булып сайрый башлый. Халык андый буш вәгъдәләргә ышанмый инде хәзер. Конкрет эшләр, нигезле сүзләр кирәк. Бүген халыкны ни борчый? Иң беренче, әлбәттә, эш мәсьәләсе.

—Дөрес әйтәсең, энем,—дип хуплап куйды шулчак кемдер.—Бөтен җирдә— бетерү дә кыскарту. Халыкка кая барыргадыр? Башны тора салып элмәккә тыгып булмый бит. Барыбызга да яшәргә кирәк.

—Шулай, хәлләр һич тә мактанырлык түгел. Безнең кечкенә генә шәһәрдә дә ике завод ябылды, меңләгән кеше эшсез калды. Ә ил буйлап күпме? Әлбәттә кәгазьгә матур сүзләрне күп язып була, һәркемне эш белән тәэмин итәбез, дип, алтын вәгъдәләр бирергә була... Тик мона халык ышанырмы? Кешеләрне үз артыбыздан ияртер өчен дәлилле сүзләр кирәк. Партиягә көчләп, куып кертеп булмый. Саныбыз аз булса да, нигезебез нык булсын, таянырлык ышанычлы, җиң сызганып эшләрлек кешеләребез булсын. Мин партиядән, «Гаделлек» партиясеннән нәкъ шуны, конкрет эшләрне өмет итәм. Һәм үзем дә бу партиягә эшләргә, халыкка хезмәт итәргә дип кердем.

—Илзат, син алай ашыкма әле.

Бу сүзләрне кем әйтте, мин хәтерләми дә калдым, колагымда шул исем генә яңгырады. Нинди матур, сөйкемле исем! ИЛЗАТ! Илзат...

—Без барсын да чәйнәп бирсәк, ниятләребезне ачып салсак, безнең бөтен идеяләрне башкалар урлаячак бит.—Өстәл артында утырган пеләш башлы кеше шулай диде.

—Урласыннар! Без бит партия өчен тырышып йөрмибез, халык тормышын яхшыртырга омтылабыз. Кем эшләсә дә, иң мөһиме нәтиҗәсе уңай булсын. Шулай түгелмени?

—Шулай, шулай. Дөрес сөйлисең,—диеште залдагылар.

Пеләш баш тамак кырып куйды:

—Сүзең беттеме, Илзат? Фикерең аңлашылды, теркәп куярбыз.

Дулкынлануданмы, эчке ярсуыннанмы Илзатның яңаклары алсуланган, киң маңгаена тирләр бәреп чыккан. Ул шундый сөйкемле, аның йөзеннән генә түгел, бөтен барлыгыннан гүя кояш нуры бөркелә. Бу кешенең эче-тышы балкый иде. Минем ана караган саен карыйсым килә. Мин инде ана муеннан гашыйк. Мин инде җаным-тәнем белән бу кешегә бәйләнгән. Әгәр аны бүтән күрмәсәм, сагыштан үләчәкмен. Хәлем шундый иде, бу җыелыш төнгә кадәр барса да, бер сүзем юк, тик Ул гына монда, күз алдымда булсын.

Ләкин җыелыш бетте. Ир-атлар гөрләшә-гөрләшә урыннарыннан кузгалдылар. Мин дә исерек кеше сыман ишеккә юнәлдем. Бик кадерле нәрсәм монда кала кебек, бик кадерле нәрсәмнедер мәңгегә югалтам кебек... Урамга чыккач та, аның белән очраштырган җирдән китәсе килмичә, таптанып тордым. Ни көтәм, үзем дә белмим. Шулчак... Йә Алла, бу төш түгелме?!

—Әйдәгез, мин сезне машина белән озатып куям. Ерак торасызмы?

Ни кызганыч, якын торам шул мин, бик якын торам... Урам аша гына

чыгасы. Нигә шулай якын торам икән?! Ә нигә дөресен әйтергә әле?

—Ерак.—Аллага шөкер, тотлыкмыйча әйтә алдым.

—Әйдәгез алайса, утырыгыз.—Илзат кызу-кызу атлап ак машинага таба юнәлде. Машина да төшнең дәвамы—ак төстәге җиңел машина иде... Бу—язмыш, дип уйладым мин. Кемнәндер, кайчандыр, бу дөньяда берниндиди очраклылык юк, барсы да ниндидер канунга буйсына, дип ишеткән идем. Әгәр шулай икән, без бәлки кемнендер ифрат күләмле, укып бетермәслек зур бер әсәренең геройларыдыр. Шул әсәрне язучы мине Илзат исемле серле зат белән очраштырган икән, аның дәвамы, ахыры да бардыр... Беләсе иде, нинди икән ул?

Илзат машинаның алгы ишеген ачып, миңа урын тәкъдим итте. Аннары үзе утырды. Без артык якын, янәшә идек. Һәм шулчак гаҗәп хисләр кичереп алдым: без гүя күптәнге танышлар, бер-беребезгә бик кадерле җаннар икән! Аңа килеп сыенудан, башымны киң җилкәсенә салудан үземне чак тыеп калдым. Нигә шулай якын миңа бу кеше? Әллә, чынлап та, без җирдә бер генә тормыш яшәмибезме һәм теге тормышыбызда Илзат белән бер тән, бер җан булганбызмы?

—Сезне кая илтергә?

Кая дисәм ераграк булыр икән?

—Боеклыга.

—Анда торасызмыни?

—Әйе.

—Шуннан йөреп эшлисезме?

—Әйе.

—Авырдыр ич.

—Юк.

—Унбиш чакрым аз ара түгел.

—Түгел.

—Авылда эш юктыр.

—Юк.

—Бөтен ил таралып бара. Гөрләп торган тормышны җимерделәр.

Мин дәшмәдем.

—Сез минем белән килешәсездер бит?

—Әйе.

—Сез бик сүзчән булдыгыз әле...

—Әйе...—шулай дидем дә, төртелеп калдым. Чү, нишлим мин, тутый кош кебек, бер сүзне такмаклап барам лабаса. Илзат минем хакта ни уйлар? Җитеп бетми моңа, дип уйламаса ярый ла... Их, шул тотлыгуларым булмаса! Нәрсәгә өметләнәм, кем турында хыялланам мин?! Миңамы соң инде шундый чибәр, акыллы егетнең сөйгәне булу?!

Менә инде шәһәрне дә чыктык. Машина тиз бара, Боеклыга да җитәрбез... Һәм безнең юллар мәңгегә аерылыр...

—Кайда эшлисез соң сез?

—Почтада.

—Кем булып?

—Кассир.

—Акча санау—әйбәт эш. Тик дөрес санарга кирәк, әйеме?

—Әйе.

—Җыелыштан нинди фикерләр белән чыктыгыз соң?

Бу сорауга «әйе», «юк» белән генә котыла торган түгел инде...

—Сез...—мин тотлыкмас өчен тирән итеп сулап куйдым.—Бик әйбәт сөйләдегез.

—Сөйләргә була ла анысы, эш күрсәтергә кирәк. Безнең халык кызык бит, барысы да зарлана, түрәләрне, хөкүмәтне сүгә. Ә үзенең кыл да кыймылдатасы килми, һаман башкалар эшләгәнне көтә. Бергәләп тотынсак кына, уңышка ирешеп була лабаса.

Нигә дәшмим соң әле мин? Әйтер сүзем бар бит югыйсә. Надан, буш кеше түгел ич мин. Их, шул тотлыгуым булмаса... Әй лә, надан булып күренгәнче... Минем Илзатка күршем Анна апа турында сөйлисем килде. Анна апа заводта инженер булып эшли, һәм ана барсы да Анна Михайловна дип дәшә иде. Эшсез калгач, базарда сату итә башлады. Аяк-куллары сызлап бик интегә. Базарда чүпрәк сатар өчен институтларда укып йөрдеммени мин, дип сукрана. Ул элекке елларны сагына. Барыбыз да тигез, бердәм идек, акчаны вакытында алып, бер-беребезгә кунакка йөрешеп, күңелле итеп яши идек, ди. Базарда безнекеләр күп. Ярый ла мин, завод ябылгач, хисапчылар курсында укып, почтага урнаша алдым. Чөнки яшь идем. Ә кырыктан узганнар берсе дә юньле эшкә урнаша алмады. Өлкән яшьтәгеләрне батып баручы корабтан иң беренче чыгарып ташладылар...

Минем Илзатка шуларны сөйлисем килде. Ярый ла вакытында тукталып калдым. Нинди завод, нинди Анна Михайловна ди?! Мин Боеклы кызы ләбаса...

Менә инде кайтып та життек. Юл чатындагы тукталышка житкәч:

—Шунда төшерегез,—дидем.

Илзат гажәпләнде:

—Нигә монда? Мин сезне йортыгызга ук илтеп куям.

—Юк-юк... Кирәкми,—дидем мин.

—Ярый алайса...—Илзат машинасын шәһәр ягына таба борып, нәкъ тукталыш янына килеп туктады. Кай арада төшеп, мина ишек тә ачты. Иратлар тарафыннан мондый игътибарны беренче күрүем бугай. Бу чынлап та, төш белән өн арасындагы ниндидер саташу, ахры...

Без кара-каршы басып торабыз. Илзат мина төбәлгән. Никтер китәргә ашыкмый.

—Без танышмадык та бугай. Мин Илзат булам. Сезне кем дип белик?

—Гөлкәй.

—Гөлкәй... Матур исем. Беренче ишетүем. Кайсы йорт сезнеке була инде, Гөлкәй? Бәлки кунакка килергә туры килер?—Илзат күзләрен кыса төшеп, кызыксынучан карашын моннан уч төбендә кебек күренеп торган авылга таба юнәлтте.

—Әнә,—дидем мин күземә беренче чалынган йортка төртеп.

—Яшел түбәле йортмы?

—Әйе.

—Яшел төсне яратам мин, тормыш төсе...—диде Илзат.—Йә, ярый алайса, Гөлкәй, бүгенгә саубуллашыйк. Кабат күрешербез дип өметләнәм. Безнең жыелышлар һәр атнада жомга көнне, шул ук урында үткәрелә. Килегез.

Мин аның зәңгәр нур сирпеп торган якты күзләренә туры карап елмайдым. Илзатка сөйкемле булып күренәсем килде. Онытмасын иде ул мине, мәхәббәт, соклану тулы карашымны онытмасын иде. Никтер бик рәхәт иде мина аның янында. Бу ягымлы кешедән аерыласы һич тә килми иде. Әллә алдаганымны әйтеп, кире утырып китимме икән, дип тә уйладым. Ләкин аның алдында алдакчы булып та каласым килмәде. Илзат хушлашырга дип кулын сузгач, кулымны аның зур учына салдым. Аның кулы жылы, йомшак иде. Ул үз итеп минем бармакларымны жиңелчә генә кысып куйды:

—Очрашканга кадәр алайса, Гөлкәй.

Машина кузгалып китте. Мин Боеклы авылы тукталышында япа-ялгызым басып калдым... Дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк иде.

Менә шундый хәлләр, дәфтәркәем... Бәхетемнән исереп йөрим хәзер. Үлсәм дә үкенмәм төсле. Юк, үләсем килми! Аны тапкач кына ник әле үләргә ди?! Дөнья шундый якты, шундый матур, чөнки анда Ул бар!!! Мин бит әле аны кабат күрәчәкмен. Менә жомга көн генә житсен. Жыелышка йөгереп барачакмын. Ул ни кушса, шуны эшлиячәкмен, кая чакырса, шунда барачакмын!

**27 сентябрь.**

Дәфтәркәем... Ул югалды... Юк ул, юк... Жомга көнен ничек көтеп

алганымны үзем генә беләм. Мәңге җитмәс кебек тоелган иде. Кадерлем белән очрашыр мизгелләрне сәгатьләп түгел, минутлап санадым. Ә ул җыелышка килмәде!!! Утырдым инде дивана кебек. Бер килгәч, ничек китәсең. Башыма берни кермәде. Теге пеләш абзый барыбызга да ниндидер кәгазьләр таратты. Аннары җыелышта катнашучыларның фамилияләрен язып алдылар: кем кайда эшли, кайда тора. Мин башта әйтергә теләмәгән идем, тик Илзат мине эзли калса, ничек табар, дип уйладым да, эш телефонымны биреп калдырдым. Күнелдә ниндидер өмет бар иде. Мин аның белән очрашуыма ышанам, барыбер ышанам! Юкка гына кермәде ич ул минем төшемә, әйе бит, дәфтәркәем? Ичмасам, син юат мине! Әй, юк шул, син тынлый гына беләсең... Кемгә сөйлим серләремне, кемгә түгим сагышымны?! Сагынам бит мин аны, са-гы-нам!!!

**7 октябрь.**

Бүген минем өчен кояш чыкты! Нинди могҗиза, нинди бәхет! Ул мина шалтыратты! Ярый әле, теге чакта акылым җитеп, телефон номерымны биргәнмен. Мин ул җыелышка башка бармадым. Әгәр ул анда юк икән, нишләп йөрим? Ә ул килгән, минем юклыкны сизгән, көткән, эзләгән! Үзе шулай диде. Мин сагыштан үләргә җитеп йөрим, ә ул мине эзли икән! Дүшәмбе көнне иртүк шалтыратты. Телефон трубкасын Галя алган иде, «Надо же, нашу Гульку мужчина спрашивает!» дип көлә. Мин үзем дә аптырап калдым: кем булыр икән?! Әллә апа белән бер-бер хәл булып, жизни шалтыратамы, дип тә уйладым. Ә баксаң... Аның тавышын мин шундук таныдым. Беренче сүзен ишетүгә үк, кайнар учакка эләккән кургаш кебек эредем дә төштем. Бүлектәге хатыннар колакларын тырпайтып, безне тыңлыйлар. Ничек каушамыйсың?

—Гөлкәй, хәлләрегез ничек?

—Яхшы...

—Авырмыйсыздыр бит?

—Юк...

—Ә мин сезне югалттым, Гөлкәй. Нигә җыелышка килмәдегез? Безне ташларга булдыгызмыни?

—Юк...

—Бу җомга килерсез бит?

Йә Алла, сорап тора тагын! Ничек инде килмим ди?! Ул гына булсын!

—Килермен.

—Алайса, җомгага кадәр, Гөлкәй. Мин сезне көтәм.

—Ярар...

—Сау булыгыз.

Мин дә трубканы куйдым. Үземә төбәлгән өч пар күз астында исерек кеше сыман чайкала-чайкала өстәл артына барып утырдым. Эшләү сәләтемне тулаем югалткан идем. Бу халәттә мин түшәмгә карап хыялланып кына ята алам. Алда тагы дүрт көн. Шул дүрт көнне дүрт дингез кичкәндәй кичәсе бар. Нидер эшлисе бар. Керем, чыгым... Кассирның башы һәрчак айнык булырга тиеш. Ә мин мәхәббәт шәрабы эчтем һәм тиз генә айный да алмам кебек... Менә шундый хәлләр, кадерле дәфтәркәем... Синең хуҗаң и-се-рек... Ил-за-а-а-ат, нишләттең син мине?! Нишләттең син Гөлкәйне?!

**11 октябрь.**

Бүген тагы Боеклыда булып кайттым әле. Вәт тиле, үз теләгем белән нужа куып йөрим. Ул минем тотлыгуымны сизде инде. Никадәр тырышсам да, барыбер тотлыктым шул. Сөйләшәсе килә бит. Телсез кебек баш кагып кына утырасы килми.

Ул шундый акыллы. Бу юлы да чыгып сөйләде. Бу юлы кешеләр дә күбрәк килгән иде. Түрдә утыручы теге пеләш абый Илзатка иркенләп сөйләргә ирек бирмичә, җитте, аңлашылды, дип никтер гел бүлдереп торды. Дөрес сөйли бит югыйсә Илзат.

—Һәр кешенең дә бай яшәргә, бәхетле булырга хакы бар. Байлык җитәрлек

безнен илдә, тик ана халык түгел, намуссыз бәндәләр хужа булырга маташа. Менә, нефтьне генә алыйк. Аны сатудан кергән акчаны һәр кешегә тигез итеп бүлеп бирсәк, безнең халык мохтажлыкның ни икәнен дә белмәс иде. Туган жиребез байлыгына үзебез хужа булырга тиеш! Шул нефть аркасында суыбыз, һавабыз пычрана, басуларыбыз таптала, безнең халык майга бата-бата аны жир астыннан чыгара, ә рәхәтен үзләре түгел, әллә кемнәр... бәлки әле тамчы да тир тамызмаган әрәмтамаклар күрә. Минем, мәсәлән, кеше хокуклары бозылмаган илдә, дөрес жәмгыятьтә яшисем килә. Гадел законнар тантана иткән илдә! Һәм шуның өчен көрәшәчәкмен дә! Закон алдында һәркем тигез булырга тиеш!

—Илзат, сабыр ит, кызма.

—Кызам әле! Минем кебек барысы да кызсын иде әле ул! Дәшмичә яхшы буласыңмы? Дәшмәгән саен таптыйлар. Әрләән кебек оянда посып утырып кына үзгәрми ул дөнья. Үз сүзенне әйтүдән курыкмаска кирәк. Әгәр һәр кеше үз хокукларын, гаделлекне яклап көрәшә башласа, түрәләр, караклар бу кадәр азмас иде! Күзгә карап халыкны, илне талыйлар. Ә без, сабыр, дәшмибез. Нидән куркабыз? Безне бөтен дөнья күзәтә, бөтен дөнья, Россиядә кеше хокуклары бозыла, дип чаң кага. Алар килеп якласынмы безне? Чечняны гына алыйк...

—Илзат, аңлашылды. Башкаларга сүз бирик.

Илзат ачуы килгән, үртәлгән кешедәй кул селтәде дә, урынына барып утырды. Әмма ул туктады дип кенә берәү дә сөйләргә атылып чыкмады. Теләсә нишләгез, безгә барыбер, дигән кыяфәттә утыручылар күпчелек иде. Минем Илзатның сүзләрен хуплап, ул дөрес сөйли, дип әйтәсем, аны башкалар алдында зурлыйсым, күтәрәсем килде. Тик һаман да шул тотлыгу итәгемнән тотып калды.

Илзаттан соң пеләш башлы ир сүз алды:

—Сайлауга вакыт аз калды, иптәшләр. Безгә үз членнарыбызны арттырырга кирәк. Дусларыгызны, туганнарыгызны партиягә тартыгыз. Халык арасында безнең партия турында сөйләгез. Халыкны үзебезнең якка аударырга кирәк. Өлкәннәр көнен йоклап уздырдык, хәерле булсын. Озакламый әнә Яңа ел бәйрәме житә. Менә шунда үзебезне күрсәтеп калырга кирәк. Белсен халык шундый партия барын. Бүләкләргә акча кызганмаска кирәк. Балалар йортына барып, берәр бәйрәм оештырып кайтсак та зыян итмәс. Бүләген-мазарын таратып дигәндәй. Менә шул хакта ныклап уйлашырга кирәк. Пиар-акция дигән нәрсә бар. Бездән генә калмаган. Әнә, Жириновский үзен күрсәтер өчен ил буйлап маймылланып йөри. Алардан үрнәк аласы бар. Һәр сайлауда Госдумага шулар кереп утыра. Кәмитчеләрне ярата халык бездә. Реклама өчен нинди ысул да бара.

—Бер маймыл булгач, житкән инде. Күпкә китсә, кызыгы бетә аның,—дип куйды кемдер.

Көлешеп-гөрләшеп, Жириновский турында мәзәкләр сөйли башладылар. Жыелышның житдилеге бетте. Өстәл өстендә өеме белән ниндидер кәгазьләр тора иде, бер ир-ат шуларны үзебез белән алырга, кешеләр арасында таратырга кушты да, жыелышны ябык дип белдерде.

—Нишлисез соң, Гөлкәй, керәсезме безнең партиягә?—дип сорады миннән Илзат кайтканда. Ул инде миңа күптәнге танышы итеп карый. Жыелыштан чыгуга яныма килеп: «Боеклыга барырга теләүчеләр юкмы?» дип елмайды. Мин дә нәкъ шулай тиеш кебек берсүзсез ак машина эченә чумдым. Бу юлы күңелем тыныч, чөнки Боеклы аша шәһәргә кайтучы автобус бар икәнен һәм аның кичке сигездән соң гына икәнен беләм.

Илзатның соравына, хисләремне яшермичә, «Синең артыңнан жир читенә дә барырга риза»,—дип жавап бирәсем килгән иде, тик алай әйтмәдем.

—Миннән ни... ф-ф-ф-айда инде?—дидем. Тотлыгуыма оялудан, битемә гүя ут капты.

—Безнең сафта һәр кеше кирәк һәм кадерле,—диде Илзат.—Тик сукырларча ияручеләр түгел, чын көрәшчеләр кирәк.

—Мин... к-к-көрәшче түгел...

Шулчак Илзат машинаны юл кырына чыгарып туктатты да, карашын миңа төбәде:

—Гөлкәй, дустым, күрмисең, аңламыйсыңмыни соң син илдәге хәлләрне?! Гади халыкның ничек интегеп яшәвен күрмисеңмени? Безнең байлар, күпчелек түрәләр үзләре өчен генә яши бит. Илнең киләчәге турында, халык турында кайгырткан намуслы җитәкчеләр бик аз. Яшь буынны алда ни көтә?! Аларга ни калдырабыз? Бу турыда беркем уйламый...—Ул башын чайкап, авыр сулап куйды:

—Ник шул чаклы битараф сез, аңламыйм.

Мин дә Илзатны аңламадым. Ни булган соң әле ул кадәр? Нигә шул чаклы үзгәләнә, баш вата ул?!

—Ярый, Гөлкәй, болай булгач, акны карадан аермагач, буталып та йөрмә инде син безнең җыелышларда. Никтер мин сине башка төрле күзаллаган идем. Хыялымда мине аңлый торган кеше итеп күргән идем. Көлсәң, көл, мин бит сине башта төшемдә күргән идем. Менә шулай икәү машинага утырып, тауга таба, якты офыкка таба китүебезне күргән идем. Өнемдә дә очраткач, шаккаттым. Юкка түгелдер бу очрашу дип уйладым... Ә без бөтенләй ят, чит кешеләр икән...

Мин Илзатны гаҗәпләнеп тыңладым. Бөтен тәнем буйлап ниндидер салкын дулкын йөгерде. Бу нинди могҗиза?! Без икебез дә бер үк төшне күргәнбез! Менә ни өчен ул миңа карап елмайган, менә ни өчен ул беренче күрүдә үк бик якын, кадерле кешем булып тоелган икән! Минем һич тә Илзатның күңелен төшерәсем килмәде.

—Әгәр син т-т-телисең икән, мин... «Гаделлек» па-партиясенә керермен...—дидем.

—Их, Гөлкәй, аңламыйни хикмәт?! Партиягә керүең түгел, мине аңлавың кирәк, дустым, фикердәшем булуың кирәк.

—Мин с-с-синең дустың... бу-лыр-мын...

—Дуслыкны сорап алмыйлар. Кичер, Гөлкәй, башыңны бутадым. Әйдә мин сине илтеп куйыйм да, хушлашыйк. Сәясәт хатын-кыз эше түгелдер инде ул. Жанна д Арклар мең елга бер генә туадыр. Илдә ир-атлар тәртип урнаштырырга тиеш. Шулай бит?!

—Әйе.

—Килештек алайса.

—Мин дә... сине төшемдә... к-күргән идем...

Илзат миңа төбәлеп сүзсез калды. Карашында аптырау иде.

—Алайса бу, чынлап та, язмыштыр... Язмышны үпкәләтергә ярамый, Гөлкәй!

Боеклыга килеп җиткәч, тукталышта бер-беребезгә сыенып диярлек басып, байтак кына сөйләшеп тордык. Мин Илзатның үземә кагылуын, кочаклавын көттем, аңа сыенасым, иркәләнәсем килде. Тик ул никтер җитди иде, миннән авыл турында сорашты. Ничә йорт бар, күпмерәк кеше яши, мәктәптә ничә бала укый, яшьләр авылда каламы... Аның сорауларына җавап бирә-бирә тәмам гаҗиз булдым. Мин ялган диңгезенә батканнан бата барам, бер ялганга икенчеләре өстәлә. Кайчан котылырмын бу газаптан? Ник кенә алдадым икән?! Автобус килер вакыт якынлашкач, мин Илзатны куып диярлек җибәрдем. Арыдым, әни борчыладыр, дидем. Хушлашканда ул кулымны озак кына җибәрми торды...

Менә шундый хәлләр, дәфтәркәем. Мин хәзер бу дөньяда ялгыз түгел, минем якын кешем, яраткан кешем, кадерлем бар. Әгәр аның белән очрашмаган булсам, тормышымның ни кадәр буш, мәгънәсез икәнен дә белми калыр идем. Кояшны күрми, караңгы базда яшәгән дә яшәгән булыр идем. Бу яшәү дә булмас иде әле, бары җан асрау гына булыр иде. Ә хәзер... Ә хәзер миннән

бәхетле кеше юк! Мәхәббәт бөтен тормышыма нур сибә, мина гүя канатлар үсте, атлап йөрмим, әочам! Халидә аптырый, ни булды сина, Гөлкәй, ди. Мин ана берни дә сөйләмим. Сина гына сөйлим, дәфтәрем, кешеләргә сөйләсәм, шатлыгыма күз тидерерләр дип куркам.

**25 октябрь.**

Мин бүген гариза язып «Гаделлек» партиясенә кердем... Илзат мина беренче «партия бурычы» да йөкләде инде. Боеклыга илтеп куйгач, кулыма бер кочак газет тоттырып, менә шуларны авылдашларына таратып чык әле, укысыннар, танышсыннар, кешеләрнен күзләре ачылсын, диде. Житмәсә, бу юлы тукталышта гына калдырып китмичә, фермалар янына, авыл очына ук китереп куйды. Газетларымны кочаклап, япа-ялгызым шунда басып калдым. Боларны таратып йөрсәм, сонгы автобуска өлгермәсем көн кебек ачык иде. Нишләргә? Илзат кушкан эшне дә үтәми ярамый. Күзенә ничек карармын? Ул бит мина ышана. Әллә сон берәр кая яшереп кенә калдырыйммы? Мин багана яктысына килеп газетнын берсен укып карадым. Анда «Гаделлек» партиясенен программасы басылган иде. Мина аларны ташлап калдыру кызганыч та һәм унайсыз да иде. Илзатка, анын дусларына хыянәт итү була ич бу. Алар халыкка яхшылык эшләргә йөриләр, тырышалар, гаделлек өчен көрәшәләр. Ә мин шул кечкенә генә эшне дә башкара алмыйм. Шулай уйладым да, тәвәккәләп, авыл ягына киттем. Ярый әле карангы төшкән, мине күрүче юк. Шәһәрнен асфальт урамнарында гына киеп йөри торган ботинкаларым белән пычрак ерып, йорттан йортка йөри-йөри, почта әржәләренә газетлар салдым. Инде бер урамны инләп чыккан идем, инде кулымдагы йөк шактый кимегән иде. Шулчак бөтен урамны балкытып, каршыма бер машина килеп чыкты. Мин көчле фаралар яктысында сәхнә уртасында берьялгызы басып калган артист хәлендә идем. Алар мине күрәләр, ә мин юк. УАЗ машинасы минем янымa ук килеп туктады, аннан алып гәүдәле бер ир-ат чыкты:

—Кем син? Нишләп йөрисен монда?

Тавышы коры һәм карт иде.

—Утыр машинага, тиз бул!

—Утырмыйм.

—Курыкма, урманга алып китмим. Идарәгә барабыз, шунда сөйләшербез,—диде ир.

Идарәдә идән юып йөрүче хатыннан башка кеше дә юк иде. Мине иялтеп килгән абый юеш идәндә зур-зур пычрак эзләр калдырып, ишек каршындагы бүлмәгә кереп китте. Зур куллары белән кочагына жыеп мине дә үзеннән калдырмады:

—Әйдә, әйдә, тизрәк атла.

Без бары тик өстәл һәм урындыклардан торган иркен бүлмәгә килеп кердек. Абзый телефоннан башка берни булмаган буш өстәл артына барып утырды да, кулы белән ишарәләп мина да утырырга кушты.

Бүлмәдәге бердәнбер лампочка яктысында абыйнын йөзе сары булып күренә, мангае гүя нәкъ урталай ярылган, куе кашлар уртасыннан чәч төбенә хәтле туп-туры тирән бразна сызылган иде. Күрәсен, кашларын гел жыерып йөрүче бик кырыс кешедер.

—Йә сөйлә. Нинди коткы таратып йөрисен монда?

—Б-б-бернинди дә к-к-коткы таратмыйм...

—Таратмыйсынмыни? Ә кулында нәрсә? Кая, бир әле...

Мин карышып тормадым, бер сүз дәшмичә, газетларны өстәлгә китереп куйдым. Абый аларнын берсен кулына алды да, йөзенә үк китереп укый башлады:

—Балаларга бушлай белем бирү... Тәк-тәк... Бушка медицина хезмәте күрсәтү... Шәп-шәп... Яна эш урыннары булдыру, тиешенчә хезмәт хакы түләү... Бусы тагы да яхшы...Бюрократия, коррупция белән кискен көрәш... Бусы бусыннан да яхшы. Ожмахта яшиселәр бар икән әле. Их, сенел, синен

дә башны катыралармыни? Ышанасыңмы шуларга? Моның кебек сүз боткасы белән дөнья тулган бит хәзер. Халык грамотный, бар да укый-яза белә. Сиптерәләр генә борчакны. Булганны бетермәскә иде! Ни пычагыма дип килеп тыгылдың инде син бу аферистлар арасына? Иренә бәлеш пешереп, өйдә утырасы урында...

Абыйның сүзләре мине рәнжетте. Үзем өчен түгел, Илзат өчен үртәлеп куйдым. Нишләп Илзат аферист булсын ди?! Ул үз эшенең хаклыгына, кешеләргә кирәклегенә чын күңелдән ышанып йөри, аның күңелендә бер начар уй да юк. Ә бу абый минем яратканымнан, аның эшеннән, изге максатхыялларыннан көлеп утыра.

—Күпме таратырга өлгердең?

—Белмим.

—Ярар, хәерле булсын. Боларын мичкә атарбыз. Партизанка Зоя булдым дисең инде. Син, сенел, шуны аңла: синең белән миңа ул Госдумада кем утырса да барыбер. Синең белән миңа эшләргә, халыкны ашатырга кирәк. Әкият сөйләп кенә бармый ул дөнья... Үзең кайда эшлисең соң?

—Эшләмим.

—Алай икән... Хуш, андый хәлләр дә булгалый. Эш белән проблема, канишны. Эшсез бәндә ашсыз бәндә инде ул. Ирең эшлиме?

—Әйе.

—Менә ансы шәп. Ә син юкны бушка аударып йөрисең инде... Кыяфәтеңә караганда шәһәрдән, ахры, үзең.

—Әйе.—Бу минем бердәнбер дөрес җавабым иде.

—Күпме түлиләр инде?

—Нәрсә өчен?

—Боларны тараткан өчен. Түлиләрдер бит? Төн уртасында бушка эшләп йөрмисеңдер.

—Бушка...

—Алай булгач, казаның бик үк тулы түгелдер инде... Ну-у-шту-у-ж, тилегә ут та юк, суд та юк. Бар, юлыңда бул. Бүтән күземә чалынма түлке. Дөнья болгатучылар синнән башка да җитәрлек.

Мин урынымнан кузгалмадым. Кая барыйм? Япа-ялгызым төнге юлга чыгып басмам бит.

—Абый, шунда гына куныйм әле мин. Иртүк китәрмен.

—Соң, балакаем, керереңнән алда чыгарыңны уйларга кирәк иде. Муеның тулы баш бит. Кунуын кунарсың да, менә иреңә ни диярсең.

Безнең сүзне тыңлап торган ахры, шулчак кайдандыр почмактан хатынкыз тавышы ишетелде:

—Салих шәһәргә барам дигән иде. Китмәгән булса.

—Бу вакыттамы?

—Ана кая ашыгырга?

—Шалтырат, белеш әле, Зөһрә. Булмаса, шунда, синең янда кунар инде. Үз башларына бәла эзләп йөрүчеләр бар бит, әй. Бәхетенә мин туры килдем, Шамил булса, ике дә сөйләшми милициягә илтеп атар иде.

Абый, минем газетларны култык астына кыстырып, урыныннан кузгалды, миңа карап, кырыс кына әйтеп куйды:

—Сенел, син абыеңны тыңла, мин начарга әйтмим. Как- никак синнән күбрәк яшәгән, күбрәк күргән.

Ул чыгып киткәч, Зөһрә апа телефоннан шалтыратып кем беләндер сөйләште, минем турыңда әйтте, кереп алырга кушты. Идән юучы хатынның шулай эшлекле кылануы мине бик гаҗәпләндерде.

—Син дә коммунист түгелдер бит?—дип сорады ул миннән.

—Юк.

—Ә безнен персидәтел коммунист. Яхшы кеше ул. Андыйлар районда бүтән юк та. Безнекеләр акчаны да вакытында алып тора. Бөтен авыл белән ана

исәнлек телибез. Пенсиягә генә озатмасыннар инде үзен. Яшьләр бик яман, чөнки нужа күргәннәре юк. Түрә булып киләләр дә, халык канын эчә башлыйлар. Әнә Өчтирәкләр персидәтелләреннән зар елыйлар, кешеләрне кыйный икән. Мафия белән дә бәйләнгән ди. Булыр да! Ике ел эшләмәде, клуб хәтле йорт төзеп куйды үзенә. Тоталар бит шуны. Элек булса... И элек бөтенләй башка тормыш иде. Бөтенесе дәүләткә, халыкка иде. Ә Хафиз, менә бу абыенны, персидәтелебезне әйтәм, дөньяда бер чисный кеше ул. Колхозның әнәсенә дә тимәде.

Мин Зөһрә апаны дәшми генә тынлап утырдым. Дөресен әйткәндә, миңа бу кешеләр икесе дә бик ошады. Алар миңа начарлык теләми иде. Авыл кешеләрен яратам мин. Алар эчкерсез була.

—Кая, кемне алып китәргә?

Бу көр, куе тавыш безнең сөйләшүне бүлде. Мин артыма борылып карадым. Ишек төбендә түгәрәк тулы битле, кечкенә юантык гәүдәле 40-50 яшьләр тирәсендәге ир басып тора иде.

—Әйдә, сеңел, такси килде,—дип гөрелдәп көлде ул.

Мин, Зөһрә апа белән саубуллашып, аңа иярдем.

Салих абый бик сүзчән булып чыкты. Үзе сөйли, үзе гөр-гөр көлә. Шундый шат, бар нәрсәдән канәгать кешене очратканым юк иде әле. Шәһәргә килеп җиткәндә мин аның турында барысын да белә идем инде. Йорт турыбызга җитеп, машинасыннан төшкәндә, Салих абый тагы кычкырып көлеп җибәрде:

—Вәт бит әй, нинди чибәр шәһәр кызын утыртып кайттым, танышa да алмый калдым. Буйдак бит абзаң, яхшы хатын кирәк миңа. Исемеңне булса да әйт әле.

—Минем ирем бар.

—Алай булгач, пас, сеңел. Кеше ярларына тимибез,—диде Салих абый.

Икенче көнне иртүк Илзат шалтыратты. Мин аңа артыгын сөйләп тормадым:

—Барсын да тараттым,—дию белән генә чикләндем.

—Рәхмәт, Гөлкәй. Син молодец! Без синең белән тауларны актарабыз әле,—диде Илзат. Тик аның сүзләре миндә әлләни шатлык уята алмады. Боеклы мине үзгәрткән, күңел күземне каплап алган алсу томан бераз тарала төшкән иде... Мин беренче тапкыр Илзат белән каушамыйча, дулкынланмыйча сөйләшә алдым. Мин беренче тапкыр Илзатның хаклылыгына шикләнеп карадым. Боеклы рәисе үзенең кырыс, тупас сүзләре белән күңелемдәге нурның бер өлешен сүндергән иде...

**1 ноябрь.**

Бүген җомга. Минем өчен бәйрәм көн. Аның белән очраша торган көн. Тик мин Илзатны бик күрәсем килсә дә, җыелышка бармадым. Чөнки ул мине тагы Боеклыга алып китәчәк. Ә миңа анда барырга, күренергә ярамый. Элек әле иркенләп йөри ала идем, ә хәзер юк. Мине Боеклы авылының өч кешесе таный: Хафиз абый, Зөһрә апа һәм Салих абый. Бүген урамда да ямьле түгел, коеп яңгыр ява. Ноябрьнең беренче көне. Яратмыйм шул айны, караңгы, салкын ай. Үзем өйдә утырсам да, күңелем Илзат янында. Эзли, көтәме икән ул мине? Сагынамы икән? Өстендә һаман ак плащмы икән? Бигрәк килешә инде ул аңа. Бүген дә ялкынланып, илһамланып чыгыш ясыймы икән? Дүшәмбе шалтыратырмы икән ул миңа, берәр җылы сүз әйтерме?

**11 ноябрь.**

Юк, шалтыратмады. Көне буе телефоннан күземне алмый, аннан хәбәр көттем. Куллан эш китте. Тик мине чакыручы булмады. Илзат югалды. Ә мин аның адресын да, телефон номерын да белмим. Белсәм дә, эзләп йөрмәс идем инде. Мин эзләгәннән генә ни файда? Ил -зааааат!!! Кайда син? Ник оныттың Гөлкәеңне?

**12 ноябрь.**

Бүген дә шалтыратмады... Мин аңа газет таратыр өчен генә кирәк булганмындыр инде. Йомышы үтәлгәч, Гөлкәй дә кирәкми... Нигә шулай

беркатлы икән мин? Нигә ышандым мин аңа? Хәзер үзенә башка авыл кызын тапкандыр, газетларын аңа тоттыргандыр...

**13 ноябрь.**

Бүген дә шалтыратмады... Көн шундый озак үтә. Башымда, күнелемдә гел ул гына. Телефон шалтыраган саен сискәнеп куям. Кабынам да, сүнәм, кабынам да сүнәм. Мина түгел икәнен белгәч, күнелемне бушлык тырный башлый. Дөньяда иң авыр газап, телефон өстенә карап, үзеңне чакыруларын көтү икән...

**15 ноябрь.**

Бүген җомга. Көне буе, җыелышка барыйммы, юкмы, дип икеләнеп йөрдем. Шул хәтле аны күрәсем, аңлашасым килде. Тик горурлык та бар. Ул башлап үзе хәбәр бирергә тиештер ич. Әгәр мине оныткан икән, җыелышка барып кимсенеп йөрүдән ни файда, яна яра гына алып кайтырсың. Бармыйм дигән идем дә, түзмәдем, эштән соң туп-туры шунда киттем. Ишегалды караңгы иде, агачлар арасындагы бер эскәмиягә утырдым да, шымчы кебек урамны күзәтә башладым. Кешеләр берәмләп тә, төркемләп тә килә тора, подъездга кереп югала тора. Минем аларда эшем юк, мин таныш шәүләне, таныш адымнарны көтәм. Тик ул күренмәде. Алдарак килгәндер, эчтә утырадыр дияр идең, машинасы да күренмәде. Шул чак подъездан берәү йөгереп чыкты да, туп-туры мина таба килә башлады. Мин урынымнан кузгалып, ашыга-ашыга каршы яктагы йортка таба киттем. Кача-поса йөрүләрем бушка гына булды. Мин Илзатымны югалттым. Без аның белән бары өч тапкыр очрашып калдык. Ләкин өч минем сан түгел бит. Минем саным—җиде. Илзатны башка беркайчан күрмәсемә ышанмыйм мин, барыбер ышанмыйм! Әле безнең бергәләп тауга менәсебез бар! Әйе бит, дәфтәрем.

**20 ноябрь.**

Мин аптыраашта. Ни булды икән аңа? Бүген эштән кайтып килә идем, бер абый туктатып дәште. Вакыт сорыйдыр дип сәгатемә карый башлаган идем, бу әйтә: «Син, сенел, безнең партия кешесе түгелме соң? Ник җыелышларга йөрмисең?» ди. Коелдым да төштем. Мине әллә кемнәр таный икән. Илзат булмагач, ниемә миңа ул җыелышлар. Бармыйм да мин анда бүтән. Алай димәдем инде, «авырыйм» дип алдадым. «Сез парлашып югалдыгыз әле, теге кайнар башлы егет тә күренми. Ул булмагач, кызык та түгел»,—диде абый. Кайнар башлы егетнең Илзат булуына бер шигем юк иде. Әллә нишләп киттем. Ни булган Илзатка? Бәлки ул авырыйдыр? Күнелемә шом керде. Мин аңа үпкәләп йөрим тагын. Әгәр инде җыелышка килмәгән икән, сәбәпләре җитдидер. Ул бит партиягә шул хәтле бирелгән кеше, аягында йөрерлек булса, үрмәләп булса да килер иде. Ни булды икән аңа?! Кайдан эзлим, кайдан табыйм, ничек хәлләрен белим?!

**22 ноябрь.**

Бүген беренче кар яуды. Дөнья яктырып китте. Урамда шундый матур. Шул карлы сукмакларда Илзат белән җитәкләшеп йөрисе иде. Минем шундый яратасым, яратыласым килә. Илзатны сагынам. Күрсәм, бер сүз дәшмичә, күзләренә генә карап утырыр идем. Сагынуыма түзә алмыйча, мин аңа хат яздым.

Исәнме, матурым, бердәнберем, яратканым, җан атканым! Төнге йокыларымнан, җан тынычлыгымнан мәхрүм итүчем, яшәвемнең мәгънәсенә әйләнгән ягымлы кешем минем! Син бар, димәк мин дә яшим. Син йөргән урамнарда йөрим, син сокланган зәңгәр күккә, серле йолдызларга, ак карлы дөньяга мин дә сокланам. Тик мин сине күрү бәхетеннән мәхрүм. Мин сине югалттым, кадерлем. Безнең карашлар ерак йолдызларда гына очраша. Сине һәр көн күрүчеләр, зәңгәр күзләренә төбәлүчеләр, һәр көн синең йомшак, назлы тавышыңны ишетүче бәхетле кешеләр бардыр. Очар кош булып, бар дөньяны айкап, сине эзләп табасым, тәрәзәнә кунып сиңа түйганчы карыйсым килә! Яратканым, газизем минем! Синең өчен күнелемдә иң назлы, иң кайнар сүзләремне саклыйм, чәчләреннән иркәли-иркәли аларны сиңа әйтәсем килә.

Сине күргәннән соң йөрәгемдә дөрләп кабынган мәхәббәт учагы көннән-көн көчлерәк яна. Аның ялкынында, иге-чиге булмаган сагыш утларында мин дә янам. Янам, янам, янам... Нинди генә газаплы булса да, мин ул ялкынның сүнүен теләмим.

**27 ноябрь.**

Мин инде бу халәтемә, көне-төне сагынуларга, аны югалтуыма, өметсезлеккә күнгән, йөрәк ярсуларым да басылган, җаным бу коточкыч бушлыкка ияләшкән иде. Гомеремнең өч бәхетле көнен кат-кат искә төшереп, юксынып, шул көннәрнең балкышы, җылысы белән юанып, шуна да риза булып яши идем. Тыныч көннәремә буран булып кабат ул килеп керде. Эш сәгате тәмамланып килә иде инде, мине телефонга дәштеләр. «Ападыр» дип уйладым. Тик Галя мәгънәле елмаеп: «Мужчина! Такой приятный голос,»—диде. Бу ул—Илзат иде...

—Исәнме, Гөлкәй...

Аның йөрәгемә сеңгән йомшак ягымлы тавышын ишеткәч, бөтен тәнем калтырап куйды. Тавышым да калтырап чыкты:

—Исәнме... сез...

—Ә нигә «сез»?! Без дуслар түгелмени?

—...

—Гөлкәй, ник дәшмисең?

Нәрсә дииим?! Мин тәмам аптыраешта.

—Гөлкәй, мин сине урамда көтәм.

Көтелмәгән шатлыктан башым әйләнеп китеп, чак егылмадым. Бер минут көтәргә дә сабырлыгым юк иде, тиз-тиз генә пәлтәмне элдем дә, урамга очтым, чынлап, очтым. Кай арада, ничек төшеп җиткәнемне үзем дә сизми калганмын. Урамга чыгуга, ишек төбендә үк таныш «Москвич»ны күреп алдым. Менә аның ишеге ачылды, анннан Илзат чыкты да елмая-елмая каршыма атлады. Аны күрүгә бөтен үпкәләрем җилгә очты..

—Әйдә, утыр, Гөлкәй. Минем сина әйтер сүзләрем күп.

Кузгалып киттек. Мин әле һаман авыз ачып бер сүз әйтәлмим. Уянып китәрмен дә, машина да, Илзат та юкка чыгар кебек. Ул үзе дә дәшми. Кая барабыз, мин белмим, мина барыбер. Тик туктамасын, бу матур төш кенә өзелмәсен.

—Син мине югалттыңмы, Гөлкәй?

Сорап тора тагын!

—Юк...

—Мин сина шалтырата алмадым шул, гафу ит. Укырга җибәрделәр бит. Бер ай Мәскәүдә булып кайттым. Иртәдән кичкә кадәр дәресләр. Алай да, берике тапкыр шалтыратып карадым, тик сине юк диделәр.

—Чыккан булганмындыр.

Шундый сихри, шундый гүзәл төш һәм шундый гади сөйләшү... Җаным күкләрне иңли, ә үзем җирдә.

Ә урамда бөтерелеп-бөтерелеп кар ява. Фара утлары яктысында алар тоташ көмеш җеп булып күренә. Кая барабыз икән без? Шәһәр кырына, шәхси йортлар ягына таба борылдык. Карлы урамнар буйлап бара торгач, кызыл кирпечтән төзелгән мансардалы бер йорт янына килеп туктадык. Йортның тәрәзәләре караңгы иде. Илзат машинасыннан төшеп, тимер капканы ачты. Мин дә төштем. Күңелем тулы сорау булса да, бер сүз дәшмәдем. Илзат мине мондый матур йортка түгел, хәтта җир читенә, ялкын эченә, карурманнарга алып китсә дә, бер сүз дәшмәс идем, «кая», дип тә, «нигә» дип тә сорап тормыйча ияреп идем. Иң мөһиме—ул минем янымда. Мәхәббәттә мин кол, бары кол гына...

Чү! Онытып та җибәргәнмен: мин Боеклы кызы лабаса! Өйдә мине «әни көтә» бит... Моны онытмаска кирәк. Ләкин бу карлы-буранлы көндә һич кенә дә Боеклы тукталышында басып каласы килми...

Өйгә керүгә мин Илзатка: «Әниләргә хәбәр итәсе иде, кайтмасам, борчылырлар»,—дидем.

—Минем сотовыйдан шалтыратсаң гына инде. Монда телефон юк.

Кесә телефоннары белән эш иткән юк иде, аптырап калдым. Илзат хәлемне аңлады:

—Номерларын әйт, үзем җыям.

Мин Халидәнең телефон номерын әйттем.

—Сөйләшеп бетергәч, менә бу кнопкага басарсың,—дип, Илзат уч кадәрле телефонын миңа сузды.

Миңа тагы алдашырга туры килде. Халидә «алло, алло» дип берничә тапкыр кычкырды да, трубканы куйды, ә мин, киресенчә, «сөйләшергә» тотындым:

—Әни, бу мин әле, Гөлкәй. Мин бүген кайтып тормыйм, Халидәләрдә кунам. Аның бүген туган көне. Борчылмагыз, яме.

Шуннан соң гына күңел тынычлап, үзебез кергән өй эченә күз салдым. Монда салкынча иде. Бу йорт әле өр-яңа, биредә тормыш сулышы сизелми, кемдер яши дип әйтә торган да түгел. Бүлмә уртасына ук, камин каршына куелган ике кресло, диван һәм кечкенә генә бер өстәлне санамаганда, бүлмә буш диярлек иде.

—Монда берәү дә тормый,—дип җөпләде минем уйларымны Илзат.—Газны аз гына, торбалар туңмаслык кына ягалар, шуңа салкынча. Хәзер мичкә ягып җибәрәбез.

Ул өстендәге саргылт кыска тунын салып, көрән төстәге йон свитердан гына калды.

—Син әлегә чишенми тор, Гөлкәй. Йә салкын тидерерсең,—диде. Аннары ишек янындагы элгечтән кара куртка алып киде дә, урамга чыгып китте, бер кочак утын күтәреп керде.

—Бу йорт минеке түгел, бик якын бер дустымныкы. Бер кичкә сорап тордым. Иркенләп синең белән сөйләшәсем килә, Гөлкәй. Сагындым үзеңне.

Мин кәнәфидә утырам, Илзат миңа арты белән тора. Ул идәнгә тезләнгән дә, каминга утыннар тыгып маташа. Миңа аның күзләре күренми, сүзләре генә килеп ирешә. Ул сүзләр йөрәгемне сыйпап узса да, күңелдә ниндидер ризасызлык, ышанмау, үртәлү бар. Мондый сүзләрне сагынганыңа артыңны куеп әйтмиләрдер инде... Күзләренә карап әйтәләрдер. Ниһаять, мич тә кабынды, ялкын телләре комсызланып агачларны ялый башлады. Илзат курткасын салып, минем янәшәдәге икенче кәнәфигә утырды.

—Яратам утка карарга. Күңел тынычланып китә. Әллә нинди сер, кыргый көч бар утта,—диде ул карашын мичтән аермый гына.

—Кояш та ут бит, зур бер учак,—дидем мин.—Әгәр кояш җирдән ерагайса, без барыбыз да туңып үләчәкбез. Әгәр якынайса, янып көл булачакбыз. Җирдәге тормышка кояш хуҗа. Кояш мәхәббәт кебек ул...

Илзат миңа сәерсенеп карап куйды. Аннары елмаеп:

—Син дә шулай сөйләшерсең икән! Мин синең балык кебек дәшми йөрүеңә күнгән идем инде,—диде.—Синең туган көнең кайчан соң, Гөлкәй?

—Җиденче мартта.

—Кара, чынлап та, балык икәнсең бит. Су кызы, Русалка... Беләсеңме шундый әкиятне?

—Беләм. Мин Андерсенның бөтен әкиятен беләм. Әллә ничә кат укыдым инде. Русалка булсам, мин диңгеземне ташлап, кешеләр янына чыкмас идем.

—Ник?

—Кешеләр бер-берсенә бик күп авыр сүзләр әйтәләр. Авыр сүз ишеткәч, йөрәк авырта...

—Алай димә инде, матур сүзләр дә күп ич.

—Матур сүзләрне әйтергә оялалар. Дөньяда нихәтле җылы, матур сүз бар, ә барыбер ямьсезләрен, начарларын сайлыйлар...

—Кем рәнҗетте сине, Гөлкәй?

—Булды инде...

—Мин сиңа беркайчан да авыр сүз әйтмәм, беркайчан да рәнҗетмәм,— Илзат минем каршыма килеп чүгәләде дә, кулларымны җылы учларына алды:

—Синең күңелең тулы кояш, Гөлкәй. Шуны үзең беләсеңме?

—Илзат, син миннән көлмисеңме?

—Нигә?

Мин бер сүз дәшми аның күзләренә тутырып карадым. Ул үзе аңласын иде... Аңласын иде ул мине!

—Тотлыкканың өченме?

Аның өчен генә түгел, әлбәттә. Менә шулай җинел генә, ана ияреп шул буш йортка килгәнем өчен. Мин бит беләм, монда юкка гына килмәдек. Ләкин минем китәсем килми. Аның янында буласым, якты күзләренә туйганчы карыйсым, ягымлы назлы тавышын тыңлыйсым, киң күкрәгенә сыенып иркәләнәсем килә. Аңлыймы икән ул, үзенең минем өчен ни кадәрле якын, кадерле зат икәнен. Минем анардан башка бер көн дә, бер сәгать тә яшисем килмәгәнне аңлыймы икән?! Юктыр. Югыйсә, бу кадәр газапламас, бер күрергә тилмертмәс иде...

—Ышанасыңмы, Гөлкәй, тотлыгуың сиңа сабыйлык төсе бирә, сине ничектер... тагын да назлырак, сөйкемлерәк итә димме... Чынлап та шулай. Сине яклыйсы, саклыйсы килә башлый. Үзеннең хисләреңне сынар өчен еракка китеп карау кирәк икән. Мин сине бик сагындым, Гөлкәй, бик-бик сагындым!

Илзат мине кочагына алды, битемә аның кайнар сулышы килеп ягылды, янак-муеннарымны кайнар иреннәре яндырып үтте. Мин тоташ ялкын эчендә калдым. Бар дөньямны онытып, назланасым, иркәләнәсем килде. Үзем дә аны кочып, күкрәгенә сыендым. Иреннәр иренгә кушылды...

—Балык салкын була, диләр тагын... Тоташ ялкын бит син, Гөлкәем-бәгырькәем! Йөрәгемә хәтле пешерәсең!

Мин елмайдым гына, кичерешләремнән, гомеремдә беренче тапкыр татыган бу татлы хисләрдән тәмам исергән идем. Менә нинди була икән ул мәхәббәт! Менә ни өчен ирләр, хатын-кызлар бер-берсеннән башка яши алмый икән! Мин хәзер Илзатка җаным-тәнем белән бәйләнгән, әгәр ул мине ташласа, Халидә кебек тәгәри-тәгәри елаячакмын. Илзаттан башка бер көн дә яши алмаячакмын. Минем гел аның белән буласым килә, минем бары аныкы гына буласым килә. Илзатның китүеннән, югалуыннан курыккандай, мин ана тагы да ныграк сыенам, башымны күкрәгенә салып, йөрәк тибешен тыңлыйм. Җир йөзендә минем өчен шушы кешедән дә кадерлерәк, газизрәк зат юк. Йә Ходаем, аерма мине аннан!

Уйларымны сизеп, юатырга теләгән кебек, Илзат мине чәчләремнән иркәли, маңгаемнан үбә.

—Өшемисеңме?

—Юк.

—Әйдә, алайса, торып, ашап алыйк. Бүген төн безнеке, бары безнеке генә,— диде Илзат.—Син мич каршында, җылыда утыр, барысын да үзем әзерлим.

Ул торып киткәч тә, мин урынымнан кузгалмыйча мичкә карап яттым. Шул арада ут утыннарны «ашап» та бетергән, мичтә йолдызлар кебек күмерләр генә җемелди. Кайчандыр җирдән, судан, һавадан көч алып күкләргә омтылган агачлардан бары көл генә калачак... Никтер яшьлегем, августның йолдызлы бер төнендә мунча мичендә үткәннәрне яндырып утыруым искә төште.. Ул чакта миңа киләчәк юк кебек тоелган иде. Ә язмыш миңа нинди бүләк әзерләгән икән! Тормыш шундый кызык әйбер, көннәрне, айларны, елларны сүтә-сүтә, ни көткәнен үзе дә белми, һаман алга барасын. Сабыр итә, көтә белергә генә кирәк икән. Бүген минем иң бәхетле көнем. Мин бүген үземнең хатын-кыз икәнемне белдем. Хатын-кыз булу, яраткан кешеңнән яратылу бик зур бәхет икәнен белдем. Әлек мин, бер бичара теләнче кебек, мәхәббәт бакчасының капкасына гына сөялеп торганмын икән, шул серле бакчада

яңгыраган шат, бәхетле авазларны тынлап, бакчадагыларның нигә көлешкәннәрен, сөенешкәнен анларга, белергә теләп, койма ярыгыннан күзәткәнмен. Бүген Илзат мине җитәкләп шул гүзәл бакчага алып керде, хуш исле, әллә ничә төсләр белән балкыган мәхәббәт гөлләрен бүләк итте. Мохтар белән яшәгән елларымны тормышымнан бөтенләй сызып атсам да, мин берни югалтмас идем. Мохтар назлы хисләрдән мәхрүм бер бәндә иде шул. Яратуның нәрсә икәнен үзе дә белмәде, мина да берни бирмәде... Юлымда Илзат очрамаса, мин гомерем буе җансыз кешедәй, тере мәет булып яшәр идем дә яшәр идем... А-а-а, нинди бәхетле мин хәзер! Бәхетле!!! Шатлыктан бөтен эчем кытыклана, күкрәгемә генә сыймаган бу олы бәхеттән кычкырып көләсем, бөтерелеп биисем, канатланып очасым килә! Тик мин оялам. Оялам...

—Тор, тор, ялкауланып ятма! Әйдә мин сине бик шәп шәраб белән сыйлыйм. Кавышу көнен билгеләп үтәргәдер бит инде, әйеме, Гөлкәй-бәгырькәй!

Илзат яныма килеп, иреннәремнән суырып үпте:

—Әллә күтәреп кенә илтимме үзенне?—Шулай диде дә өстемдәге юрганны ачып җибәрде. Мин чырыйлап кычкырып, одеялны үземә тарттым.

—И ояла бирәү... Үземнеке булды да, хәзер оялган була.

—Көлмә миннән.

—Кызык син. Мәхәббәттән кем көлә инде?! Табигать үзе шулай кушкан бит. Бер-берсен яратсыннар дип, парлы итеп яраткан. Бездән генә калмаган. Син бик матур, Гөлкәй! Бер оялыр җирен дә юк, кадерлем. Алай оялгач, әйдә киендерим әле үзенне.

—Кирәкми. Мин үзем.

—Ярый алайса, син киенә тор. Мин утын алып кереп, мичкә өстим әле,—диде Илзат.

Төне буе урамда җил сызгырды, төне буе җир белән күкне тоташтырып карлар бөтерелде. Төне буе мин Мәхәббәт дингезендә коендым. Әгәр бу төн гомеремнең соңгы төне булса да, әгәр иртән күзләремне мәңгелеккә йомсам да, якты дөньяга бернинди үпкәм,үкенечем калмас иде... Илзат белән үткәргән шул төндә мин әллә ничә гомер яшәдем. Аның һәр минуты елга торырлык, һәр минуты бәхет нурына уралган иде.

Менә шулай, дәфтәркәем. Мин әле һаман айный алмыйм. Мин әле һаман Илзатның кайнар кочагында тирбәләм.

**28 ноябрь.**

Сәер, ул хәтта шалтыратмады да... Шундый төннән соң да... Хәлемне дә белмәде. Әллә соң мин аның өчен бер мавыгу гына булдыммы? Үзенекен алды да, киттеме? Безнең бүлектәге хатыннар шулай диләр бит, ирләргә бер генә нәрсә кирәк, алар хайван кебек, җан дигән нәрсә юк аларда, диләр. Илзатны очратканчы мин дә шулай уйлый идем. Ләкин Илзат бөтенләй башка! Нинди генә ягымлы сүзләр ишетмәдем, нинди генә назлар күрмәдем анардан. Юк, юк, көлмәгәндер ул миннән. Ә көлсә? Үкенер идеммени? Мин аны үзем яраттым, үзем теләдем бит, аның янында күпме бәхетле минутлар кичердем. Шуның өчен үкенимме? Юк, үкенмим. Яшерен мәхәббәт беркемне дә җылытмый, беркемне дә шатландырмый. Мина әти шулай дигән иде. Яратасың икән, хисләреңне сөйгәнеңнән яшермә, бар дөньяга кычкыр, кайнар мәхәббәтен башкаларны да җылытсын, дигән иде. Вакытында ачылмаган йөрәк дөрләп яна алмый, пыскый-пыскый кара күмергә әйләнә, дигән иде. Мин Зиннур турында сөйләгәч, шулай дигән иде ул. Ә мин аны тыңламадым, бәгыремне өтеп алырлык кайнар хисләремне куенымда саклад да саклад һәм алар чынлап та, көлгә әйләнделәр... Мин әтинең ялгышын кабатладым. Ул да шулай берәүне өзелеп сөйгән булган. Мәхәббәтен белгертергә кыюлыгы җитмичә, эчтән генә янып-сызып йөргән дә йөргән. Килгән шундый көн, бөтенесен берьюлы түккән, күз яшьләре белән бергә ничә еллар йөрәгендә сакланган мәхәббәтен бушаткан. Тик сөйгәненә түгел, аның каберенә... «Ул да сине яраткан, көткән иде бит,»—дигәннәр әтигә...

—Шулай, кызым, гомер үтә дә китә ул. Мәхәббәтне үзен белән кабергә алып китеп, туфракка күмәргә түгел, җирдәгеләргә—исәннәргә бүләк итәргә кирәк,—дигән иде әтием.

—Син шуна гел моңлы җырлар уйныйсың, аны сагынасың, әйе бит?

—Йөрәктәге ул моңнарны түгәр өчен гармун гына җитми шул, кызым, скрипка кирәк. Мәхәббәт артык нечкә хис ул. Гомерем буе скрипкада уйнарга кызыктым. Ичмасам син өйрән, кызым, миңа уйнар, күңелемне юатыр идең.

Мин скрипкада уйнарга өйрәнә алмадым, әтиемнең үтенече һавада эленеп калды... Шуларны искә төшердем дә никтер, чынлап та, скрипкада уйныйсым килеп китте. Әллә тәвәккәлләргәме, ә дәфтәрем? Өйрәнсәм, әтинең кабере өстендә уйнар идем, рухы булса да тыңлап сөенер иде. Илзатка да уйнар идем. Күңелем сизә, ул мине ташламаячак, юк, ташламаячак!

**5 декабрь.**

—Саумы, Гөлкәй!

Бу—ул. Тавышын ишетүгә тәнемә ялкын капты.

—Исәнме...

Мин телефоннан сөйләшергә яратмыйм. Миңа кешенең йөзен, күзләрен күрү кирәк. Ни гаҗәп телефоннан әйтелгән сүзләрнең мәгънәсе авырлык белән килеп ирешә. Шуңа күрә сөйләшүемнең рәте-чираты да юк.

—Хәлләр ничек?

—Яхшы.

—Иртәгә җыелыш, онытмадыңмы? Килерсең бит?

Оныттым, әлбәттә, оныттым. Нигә кирәк соң миңа ул җыелыш? Әгәр Илзатны болай да күрә алам икән, нигә миңа анда тилмереп утырырга? Илзат та... бигрәк инде... харап эшлекле сөйләшә.

Мин озак дәшми торгач, Илзат, кырыс итеп әйтеп куйды:

—Син—безнең партия әгъзасы, килергә кирәк.

Шул гынамы? Шуны әйтер өчен генә шалтыратканмы? Өстемә бозлы су сиптеләрмени, катып калдым. Ничә көннәр буе күңелемне җылытып торган хисләр гүя җилгә очты. Дөнья буш һәм шыксыз булып калды... Менә аптырап утырам хәзер, барыргамы ул җыелышка, юкмы. Киңәш бирче миңа, зәңгәр күзле акыллы дәфтәрем.

**6 декабрь.**

Бардым. Күрдем. Озатты... Боеклы тукталышында өшеп басып калдым. Ашыгып кына битемнән үпте дә, китеп барды. Әйтерсең безнең арада берни булмаган. Әйтерсең, төне буе миңа назлы сүзләр пышылдамаган. Әллә чынлап та бу ирләрдә йөрәк, җан дигән нәрсә юкмы?! Минем бәхетем шулай кыска гомерле булдымыни? И Ходаем, бу бушлыкны ни белән генә тутырырга? Скрипка алам! Скрипкада уйнарга өйрәнәм. Барсына да үч итеп! Менә шул.

**7 декабрь.**

Кочкә эзләп таптым. Базарда андый нәрсәләр сатмыйлар икән. Әллә ничә кибеттә булдым. Ә ул гел аулакта, кечкенә генә бер кибет икән. Шундый кысан. Скрипкаларның төрлесе бар. Бәяләре дә төрле. Артык арзанын да, артык кыйбатын да алмаска кирәк. Сайлап йөргән булам инде, кулыма гомердә скрипка тотканым юк, югыйсә. Өйрәнә алсам ярый ла. Әй, өйрәнермен әле. Кәтүк буе балалар уйнаганны. Акча алгач та, Халидә белән бергә барып алырбыз. Әлегә аңа әйтми торам, көләр, акчаң әтәч булып кычкыра башладымы әллә, дияр.

**11 декабрь.**

Илзат тагы «свидание»гә чакырды... Бигрәк йомшак холыклы шул мин. Каршы киләлмәдем, ризалаштым. Аның белән машинага утырып киткәнемне Халидә дә күреп калды. Без тагы шул йортка киндек. Өй учагында йолдызлар биеде. Шулар яктысында мин кадерлемне иркәләдем, үзем дә наз бишегендә тирбәлдем. Мин мәхәббәт колына әйләндем, Илзатның аяк астындагы туфракка әйләндем. Югыйсә горур буласым, ялындырасым, аны бераз газаплыйсым

килгән иде. Юк, миннән булмый икән. Яратам шул мин аны, өзелеп-өзелеп, үләр дәрәҗәгә житеп яратам. Ничек инде яратканымның назларыннан баш тартыйм? Кем инде үзенең бәхетеннән баш тарта? Кем инде мәхәббәттән туя?! Бәлки бу кадерле мизгелләр башка беркайчан да кабатланмас?

Наз-бәхет тулы татлы-гүзәл төн тагы кабатланды. Бәхет беркайчан да артык булмый икән ул. Күпме булса да, баштан ашса да, беркем дә: «Булды, житте» димидер, бәхеттән баш тартмыйдыр...

Мин һаман куркам. Анардан берни сорамыйм. Ә ул үзе сөйләми. Мин бит белмим дә, кем ул Илзат? Ялгыз кешеме, әллә өйләнгәнме? Минем белән ник очраша? Бу очрашуларның ахыры ни белән бетәр? Мин аның бердәнбереме, әллә... Әллә бишнең яки унның береме? Кая югала ул, каян кабат пәйда була? Мин сорамыйм. Чөнки аның ачуланып китүеннән, бәхетемне мәңгегә югалтуымнан куркам. Шул сирәк очрашулар да мина күпме шатлык, яшәү көче бирә! Илзат миңа кирәк, бик кирәк! Ул минем сулар һавама, эчәр суыма, тормышымның мәгънәсенә әйләнде.

...Таң атты.

—Мин сине эшенә илтеп куям,—диде Илзат.

—Кирәкми.

—Кешеләр күрер дип куркасыңмы?

—Без бит ир белән хатын түгел.

—Башкалар фикере синең өчен шулай әһәмиятлеме? Син аларга ярарга тырышып яшисеңмени?

—Юк та...Әллә ничек бит...

—Мин сине барыбер илтәм әле. Чөнки сина бер эш бар.

—Нинди эш?

—Чыккач әйтермен.

Урамга чыккач, ул миңа ике төргәк тоттырды.

—Менә, безнең партиянең халыкка мөрәжәгате кайтты. Шуларны таратырга кирәк булачак.

Мин калтыранып куйдым. Юк инде, мондый эшләр белән башка мәңге шөгыльләнәсем юк. Тәүбә иттем, житкән. Дәшми торуымны күреп, Илзат кашларын җыерды:

—Куркасынмы әллә?

Куркам, диясем килмәде, хәйләләргә булдым. Ярар, алырмын да, жилгә сибәрмен. Кем күрә дә, кем белә?

—Боларны Боеклыда таратыргамы?

—Юк, шәһәрдә. Газетлар эченә тыгасыз да, җибәрәсез.

—Алай булмый. Безне тикшереп торалар. Жыелышта да бик каты кисәттеләр.

—Кисәтә торсыннар, ә без үзебезнекен эшлибез. Без партизаннар хәлендә калдык хәзер. Алар курыкмаган бит, көрәшкәннәр.

Партизан сүзен ишеткәч, Боеклыдагы Хафиз абый искә төште.

—Юк, мин мондый эшкә алынмыйм.

Илзат каршыма килеп басты да, иңнәремнән кысты:

—Гөлкәй!

Мин аның күзләренә туп-туры карап баш чайкадым. Илзатның канәгатьсезлеге йөзенә чыкты:

—Шуна да ярамагач, ни дип керден син безнең партиягә?

—Синен өчен! Сине күрер өчен! Сине яратканга!

—Тиле! Партиягә кемнедер яраткан өчен түгел, инанып керәләр. Йөрәк белән түгел, баш белән уйлап!

Аның тупаслыгына хәтерем калса да, сүз көрәштереп торасым килмәде:

—Ярар, таратырмын,—дидем.

—Күптән шулай диләр аны, Гөлкәем-бәгырькәем!—Илзат шатланып мине күкрәгенә кысты, мин дә хисләнеп китеп аны яңагыннан, иреннәреннән үбеп алдым. Кадалып китсен партияләре, миңа мәхәббәт, бары мәхәббәт кирәк!

Язмышымның иң зур бүләге—мәхәббәтемне югалтмас өчен, хатын-кыз башым белән юкны бушка аударучылар арасында уралып йөрим ләбаса. Ниемә кирәк ул көрәшләр, минем яшисем килә! Яратасым, яратыласым килә!

Илзат мине эшкә илтеп куйды. Ике кулыма ике төргәк күтәреп кереп киттем.

Алар белән нишлисемне үзем дә белмим әле. Кием шкафына кертеп куйдым, торалар шунда. Аз-азлап үзем таратып йөрсәм генә инде. Газетлар эченә тыгып тарату турында сүз дә юк.

**14 декабрь.**

Кызык инде, чебеш тавыкны өйрәтә. Халидәнең кызы музыка мәктәбенә йөри, скрипкада уйный. Ял көннәрендә мин аның янына барып дәресләр алам. Көйгә охшаш тавышлар чыгара башладым инде. Скрипка бигрәк нәфис корал, нечкә билле, сылу кызлар кебек. Тавышы да нәфис. Илсөяр ярыйсы ук оста уйный, бишенче ел укый бит, концертларда да катнашканы бар. Минем Яңа ел житкәнче аз булса да өйрәнәсем килә. Яңа елны бәлки Илзат белән каршы алырбыз. Мин аңа скрипкада уйнап күрсәтер, мактаныр идем. Илзатның миңа үпкәләрлеге юк. Мин ул биргән өндәмәләрнең беразын тараттым инде. Һәр кич саен аз-азлап, үзебезнең тирәдәге йортларга кереп, кача-поса почта әржәләренә салып йөрим. Күрсәләр, Боеклыдагы кебек читен хәлдә калырмын дип куркам. Ярый ла ул чакта ансат кына котылдым. Ә шәһәрдә хәлләрнең катлаулырак та булып куюы бар. Бер өлешен поселокта почтальон булып эшләүче Надяга бирдем. Әйбәт хатын ул. Бер килгәч, үзе «Галеллек» партиясе турында, иренең шунда йөрүе турында сөйләп утырган иде, мин аңа өндәмәләрне күрсәттем. Алды, таратырмын, диде.

Ә Яңа елга бары ике атна вакыт калды. Элеккеләрен гел берүзем каршылый идем. Бу юлы Илзат белән буласы иде. Аның белән каршыласак, бәлки бергә булырбыз. Болай шундый авыр. Сагынам! Ә ул... Сирәк кенә шалтырата. Анда да бары жыелышка чакырып кына... Дәфтәркәем, сиңа язарлык бер шатлыклы хәбәр, бер күңелле яңалык юк әлегә.

**18 декабрь.**

Бүген эштә кызык хәл булды. Бүлек башлыгыбыз Зинаида Петровна барыбызны жыйды да, анкеталар таратып, шуны тутырырга кушты. Мин яза башлаган идем, карыйм, бу гариза икән. «Уртак Ватан» партиясенә керү турында гариза. Кызлар бер сүз дәшми тутыра башладылар, ә мин буш анкетаны кабат Зинаида Петровнага суздым.

—В чем дело?—диде ул.

—Мин берьюлы ике партиядә тора алмыйм. Чөнки «Галеллек»партиясенә кергән идем.

Житәкчемнең күзе шар булды:

—Что?!

—Нигә, бездә демократия бит, кайсына телисең, шунда керәсең,—дидем мин ике дә уйламыйча.

—Оныт, ул партия турында искә дә алма. Ничек кергәнсең, шулай чыгарсың. Яз гариза, тутыр анкетаны. Барыбыз да «Уртак Ватан» партиясе әгъзасы булырга тиеш.

—Мин алай итә алмыйм. Бу алдашу була.

—Милочка, безнең бөтен тормышыбыз алдашу. Нигә кирәк сиңа проблемалар? Теге партиядә булдың ни дә, монысында ни... Нинди аерма бар? Жүләрләнмә, монда эшлисең бар бит әле.

Шул чак Галина әйтеп куйды:

—Аңа барыбер түгел, ул листовкалар таратып йөри. «Галеллек»партиясенә керергә чакырып. Листовкалары ай буе безнең шкафта ята. Ышанмасагыз, үзегез карагыз, Зинаида Петровна.

Зинаида Петровнаның йөзе күгәреп чыкты.

—Ятмасын, чүплеккә чыгарып яндырыгыз, эзе дә булмасын,—диде.—Болай

булгач, милочка, сиңа не завидую. Бердәнбер шанс безнең партиягә керү. Ул чагында бөтен юләрлекләренне онытырбыз, кичерербез. Аңларга була, бик катлаулы заманда яшибез. Кем дә ялгышырга мөмкин.

Шул чак күз алдыма Илзат килеп басты. Ул мина рәнҗеп, гаепләп карап тора төсле тоелды. Партияне алдау минем өчен бер тиен тормаса да, Илзатны, яраткан кешемне алдый, аңа хыянәт итә алмый идем, шуна күрә: «Юк»,— диеп баш чайкадым...

**20 декабрь.**

Яңа елны үз фатирымда каршылыйсым килә. Илзат белән. Әйтермен, көн саен авылга кайтып йөрмәс өчен фатирга кердем диярмен. Аның белән әле сөйләшмәгән, ә мин инде ду килеп бәйрәмгә әзерләнәм. Өемне җыештырып чыктым, кичкенә генә чыршы да алып кайтып бизәдем. Скрипканы тәки алдым. Аңа бүләк ясыйсым килә. Мин аңа үземнең иң яраткан көемне уйнаячакмын. Хәер, башкасын белмим дә әле, шуны гына өйрәндем. Мин скрипкада кадерлем өчен «Минем иркә, назлы җанварым» киносындагы вальсны уйнаячакмын. Чөнки ул август аенда, арыслан йолдызлыгы астында туган икән. Бер очрашуда безнең арада шундый кызык сөйләшү булды.

—Син—балык, мин—арыслан. Алар бергә була аламы икән?—диде Илзат көлеп.

—Була ала. Әгәр арыслан су кырында йөрсә, ә балык ярга бик якын йөзсә,— дидем мин.

—Бик якын булгач, арыслан балыкны тотып ашамасмы икән соң?

—Арыслан балык ашыймыни?.

—Ач булса ашый. Шуңа күрә син ярга бик алай якын килмә әле, минем алтын балыккаем. Саграк бул.

—Балыкка кызыгып, арысланның да суга батуы бар.

—Ярый алайса, су кырыенда гына йөрербез.—Шулай диде дә, Илзат кабат мине кочагына алды. Шул чак бөтен батырлыгымны җыеп, беренче тапкыр сорадым:

—Илзат... Ә син мине яратасыңмы?

—Сорап торасың тагын!

—Юк, син турысын әйт.

—Яратам. Яратмасам, бу очрашулар булмас иде.

—Ә син мине ташламассыңмы?

—Яраткан кешене ташлыйлар димени?!

Бу сүзләрне ишеткәч, күңелемдәге шикле уйлар эреп юкка чыкты, йөрәгемә кояш булып шатлык тулды.

—Гөлкәй, синеңчә ничек, ут көчлеме, әллә сумы?—дип сорады никтер Илзат.

—Су! Ул утны сүндерә.

—Ут та суны киптерә ала.

—Диңгезне барыбер киптерә алмый, диңгез зур ул.

—Ә кояш? Син бит кояшны зур учак, ут дигән идең. Кояш җиргә төшсә, диңгезең парга әйләнә.

—Бөтен җирдә ут кына каламы? Алай кызык түгел.

—Ярар алайса, диңгезгә дә, балыкка да тимәбез. Яшәсеннәр,—диде Илзат.

Мин аның шаярып сөйләшкәнен яратам. Житди чагында ул миннән ерагая кебек. Житди чагында ул ничектер тупас. Карашы да, сүзләре дә авыр. Җыелышларда да гел ярсып, кемгәдер ачуы-нәфрәте бар кебек сөйли. Минем ул җыелышларга гел барасым килми. Илзатны ачулы итеп күрәсем килми. Ул «минем иркә, назлы җанваркаем» гына булсын иде. Ул партиянеке дә, башкаларныкы да түгел, бары минеке генә булсын иде!!!

**23 декабрь.**

Ни булды мина, ни булды?! Мәсхәрәгә калдым... Нигә шулай булды соң? Күп тә эчмәдем бит югыйсә, бер генә йотым кызыл шәраб эчкән идем.

Зинаида Петровна үзенен туган көнен үткәрде. Эштән сон табын корып утырдык. Мин эчмим, дигән идем, үгетләү, үпкәләүләр китте. Шуннан кабып куйдым инде. Шуннан мине башлык чакырды. Ник? Ул мине гомердә чакырганы юк иде. Тик мин аның янына барып житә алмаганмын, кабул итү бүлмәсендә егылганмын. Мина «ашыгыч ярдәм» чакырганнар, больницага алып киткәннәр...

Икенче көнне үк чыгарып жибәрделәр. Анда күргән мыскыллаулар, анда ишеткән сүзләр... Эшкә төштән сон гына бардым, кулда бернинди язу юк. Нәрсә диярга дә белмим. Ә анда сораучы да юк, мине инде эштән чыгарып ук куйганнар. «Үз теләгем белән» диеп гариза гына язасы калган... Яздырдылар, югыйсә, статья белән китәсен, диделәр. Документларымны алганда да, ышана алмыйча сорадым әле: «Ник? Нәрсә өчен?» Эш урынында исерек булганмын һәм сәбәпсез эшкә килмәгәнмен, менә шунын өчен икән. Нишләп исердем сон мин?! Нигә башкалар ап-айнык, ә мин егылганмын? Нинди хурлык! Нинди хурлык!!! Илзат күзенә ничек күренермен? Ничекләр генә яшәрмен?! Тизрәк, тизрәк ерагаясы иде бу көннән. Аны башка көннәр, бары тик шатлык, мәхәббәт, бәхет тулы көннәр күмеп китсен иде. Бу ямьсез, күнелсез көн ин аста, вакыт туфрагы астында күмелеп калсын, бөтенләй онытылсын иде. Бу көн минем йөрәгемне үтмәс пычак белән телә, жанымны каезлый. Мина шундый авыр!!! Ятасы иде дә, иртәгә уянмаслык булып, мәнгелек йокыга китәсе иде. Шулай тиз генә югаласы иде...

**2 гыйнвар.**

Яна елда берүзем утырдым. Илзаттан качам. Ул эшкә шалтыраткандыр, ана әйткәннәрдер. Мин аның күзенә күренә алмыйм. Оят, оят, оят. И Аллам, мин дә шундый көнгә калырмын икән... Мин нинди эчкече булыйм ди инде? Яна елда хәтта шампан шәрабы да капмадым. Табын да кормадым, төне буе телевизор карап утырдым. Телевизордагы кешеләр бик шат, бәхетле иделәр. Яна елда мине ни көтә? Кая барырга? Ничек яшәргә? Башым тулы сорау. Ә йөрәк әрнеп-әрнеп авырта. Бернинди дару ярдәм итми. Мин бөтенесен берьюлы югалттым. Илзатымны да, эшемне дә, киләчәгемне дә. Яна елга мин шәпшәрә керәм, жаным тулы бушлык белән.

**3 гыйнвар.**

Эч пошуга, ялгызлыкка түзә алмыйча, Халидәләргә киттем. Илсөярдән көйләр уйнаттым. Сагышланып, монга күмелеп тынладым. Күздән яшь таммаса да, жаным үкереп елый иде. Халидә мине ничек юатырга белми. Үзенен дә хәле хәл түгел, Данияры сөяркәсе янына күчеп киткән.

—Башы-күзе тонган, безне күрми дә,—ди Халидә.—Син, Гөлкәй, ялгыз башын ничек тә яшәрсен әле, ә минем өстә ике бала. Китүе бер хәл, акчасын да безгә бирми, теге албастысына ташый бит. Әллә бозганнар инде, шул хәтле бизмәс иде бездән...

—Халидә, син дә шунда идең бит, син дә эчтең, нигә мин генә исердем сон?—дип мин үземнекен сөйлим.

—Без үзебез дә аптырадык инде мона. Әллә берәр нәрсә бутап салдылармы икән? Сине барыбер ничек тә эштән чыгарасылар иде бит инде, Гөлкәй... Белеп, ишетеп тордык, үзенә генә сиздермәдек. Барыбер берничек булыша алмый идек. Ник кенә бәйләндең син ул кирәкмәгән партияләр белән?! Керергә иде алар кушкан жиргә. Безгә соң ни аерма? Аларның берсе дә халык өчен тырышмый, барысына да власть кына кирәк. Власть булгач, майлы бәлеш тә була,—ди Халидә.

Мин аның сүзләре белән килешмим. Илзатка майлы бәлеш, власть кирәкми, ул чынлап та халыкка жинеллек булсын дип тырышып йөри, гаделлек өчен көрәшә. Мин мона ышанам. Тик бу турыда Халидәгә сөйләп тормыйм. Ул Илзат турында белмәскә тиеш.

—Бардыр инде араларында, бәлки яхшылары бардыр,—ди Халидә.—Хәзер кемгә ышанырга да белмәссең. Кайсын тынласаң да, дөрес сөйли кебек.

Үзгәртеп, төзәтеп бетерә торган булмады инде бу. Ельцин вакытында рәхәтләнеп таладылар. Без генә авыз ачып карап калдык. Хәзер менә хаерчелектән баш чыкмый. Ә син кая барырга уйлыйсың инде, Гөлкәй?

—Бәйрәмнәр үткәч, эш эзли башлармын инде. Булыр әле,—дидем мин.

**11 гыйнвар.**

Булыр әле, дигән идем дә, бик булмады шул... Гаҗәп икән бездә хәлләр. Бер белдерү күреп барасың, анда инде егермеләп кеше өметләнеп килеп баскан була. Мал сайлаган кебек сайлыйлар кешеләрне. Күнел кимсенеп кенә кайта. Сораулары белән үзәккә үтәләр. Минем кебек курс бетерүчеләргә сан да юк, югары белем кирәк диләр. Эш эзләп килүчеләрне шулай сортларга аералар, исемлеккә кертеп өметләндерәләр дә, аннары танышлык белән бөтенләй бүтәннәрне, үз кешеләрен алалар икән. Йөри торгач, байтак нәрсә белдем мин. Тик белүем яхшы эш табу өметен сүндерә генә барды. Минем урынга Галинаның сеңлесе кереп утырган бит әнә. Алар да башта «конкурс» дигән булып, сайлау үткәргәннәр, тик килүчеләрнең берсен дә алмаганнар.

Ике атна шулай бер нәтиҗәсез, аяк киеме туздырып йөреп үтте дә китте. Хезмәт стажым өзелмәсен өчен эшсезләр биржасына барып бастым. Андагы кеше! Бөтен шәһәр эшсез икән диярсең. Илзат дөрес әйткән икән шул. Чиратта торганда гел зар-моң гына ишеттем. Эшкә урнаша алмыйча айлар гына түгел, еллар буе йөрүчеләр бар. Мине кочак җәеп каршылаучы булмады, документларымны тикшереп баш катырдылар. Ник эштән киттегез, имеш. Ирекле көннән кем эш ташлый? Мин киткәч, мөгаен, почтага шалтыратып сорашканнардыр да әле...

Урамда карак кебек кача-поса диярлек йөрим. Ак «Москвич» күрсәм, котым алына. Илзатны очратудан куркам. Аның күзенә күренергә оялам. Үзем аны өзелеп сагынам, күкрәгенә капланып елыйсым, күнелемне бушатасым килә. Ә үзем аннан качам. Аңлар идеме икән ул мине? Юк, юк, бу хурлыкларны ана мәңге белдерәсем юк.

Ә кичә тагы теге абыйны күрдем. Ул безнең каршыдагы йортта тора икән. «Хәлләр ничек, сеңел?»—дип дәшкәч, күнелем йомшарып китте, сөйләп бирдем. Минем хәлне белүче түгел, кызыксынучы да юк бит. Бигрәк ялгыз икән мин бу шәһәрдә. Менә шул абый әйтте: «Ә партия нәрсә өчен? Үз кешеләренә дә булышмагач. Җыелышка кил, хәлләреңне аңлат, эш табарга ярдәм итсеннәр. Безнең кеше бит син.»

Мина рәхәт булып китте. Чынлап та, минем үз партиям бар ич. Мин аларга көчемнән килгәнчә булышмадыммыни, кушкан эшләрен намус белән башкармадыммы? Ләкин... Ләкин бит анда Илзат бар...

**17 гыйнвар.**

Үзәккә билгеләнергә барган идем, эш тәкъдим иттеләр. Ишеткәч, аптырап та калдым. Нишләп һаман Боеклы тирәсендә әйләнәм мин? Шул хуҗалыкка кассир кирәк икән. «Барасыңмы?»—дип сорадылар миннән. Шатланып «барам», дидем. Чынлап та, шатландым. Бердән, Илзат белән очрашмаячакмын, икенчедән, анда минем танышлар бар! Берәр әбигә урнашырмын да яшәрмен тыныч кына. Үзәктән туп-туры вокзалга юл тоттым. Боеклы аша әллә ничә автобус йөри. Утырдым да киттем. Тукталышта төшеп калгач, «үземнең» яшел түбәле йортны эзләп таптым. Ничә тапкыр шул йортка карый-карый, менә шунда Илзат белән басып сөйләшеп тордык. Кызык, кемнәр яши икән ул серле йортта? Ә бит Илзатның анда мине эзләп килүе дә бар... Һәм минем ялганым беленәчәк, сөйгәнем каршында дәрәҗәм төшәчәк. Машинасы булган кешегә, мине табарга теләгән кешегә килергә була, әлбәттә. Тик ул мине табарга телиме икән соң, эзлиме икән мине? Эзләсә, күнеллерәк булыр иде. Читтән генә булса да бер карыйсы иде үзенә. Идарәгә житкәнче уйларым гел аның турында булды, очрашуыбызны күз алдына китердем. Каршыма килеп чыкса кочагына атылыр идем! Сагынам бит мин аны, үлеп сагынам! Икебез дә исән, икебез дә бер үк жирдә яшибез, бер үк юл-сукмакларда йөрибез югыйсә...

Иң кадерле кешенне бер күрергә тилмереп яшә, имеш. Авыр да соң ансыз! Күкрәгем тулы салкын боз кебек...

Авылда кар шундый чиста, шундый ак. Шул аклыктан хәтта күзләр чагыла. Рәхәт булыр иде монда яшәргә. Илзат белән бергә гомер кичерәсе иде шунда тыныч кына. Саф һава, тынычлык, иркенлек. Янәшәңдә яраткан кешең булса гына, дөнья ямьле, яшәү күнелле. Мәхәббәттән башка тормыш юк, ул үзе иң зур бәхетләр, мөгаен.

... Идарәгә ашкынып бардым. Ишегенә «Ватан» күмәк хуҗалыгы рәисе» дип язылган, теге кичтә Хафиз абый белән сөйләшкән бүлмәдә бөтенләй башка кеше хуҗа булып чыкты.. Олы гәүдәсе белән бөтен кәнәфине тутырып утырган кырык яшьләрдәге шакмак башлы, калын муенлы үгез кебек бер ир бугаз киереп акыра-бакыра телефоннан сөйләшә иде, ике сүз саен сүгенү. Мин ишек төбендәге урындыкта аның шул «матур»чыгышын тыңлап утырырга мәҗбүр булдым. Ул трубканы куйгач кына, каршына басып йомышымны әйттем.

—Син йөзенчесе,—диде ир, тәмәкесен кабызып.—Валлаһи, син йөзенчесе!— Аннары тәмәке төтенен туп-туры мина җибәрде дә, өстәп куйды:

—Нинди ахмаклар утыра соң анда?! Көн саен кеше җибәрәләр. Казан базарымыни монда?! Бернинди кассир кирәкми безгә. Чаптырып килгәнче, башта шалтыратып сорыйлар аны. Бар, бар, сеңлем, вакыт үткәреп йөрмә. Бернинди эш тә юк бездә. Теләсән, дуңгыз караучы итеп куя алам.

Әгәр аның урынында Хафиз абый булса, дуңгыз карарга да ризалашыр идем. Тик бу тупас, тәкәббер кеше янында эшләү түгел, бер минут та тоткарланасым килмәде.

—Юк, теләмим,—дидем.

—Шул, шул, теләмисен. Барыгызга да чиста эш кирәк. Ашарга яратасыз үзегез.

Мин аның белән сүз көрәштереп тормадым, үзәктән бирелгән кәгазьгә кул куйдырдым да, башымны иеп чыгып киттем.

Шул чак нәкъ каршымда чиләк белән ялкаулар таягы күтәргән Зөһрә апа пәйда булды. Ул мине танымады. Исәнләшкәч кенә, йөземә текәлеп карап торды да, хәтеренә төшерде.

—И-и, синмени әле бу? Тагы гәҗитләр таратырга килденме?

—Юк, башка эш белән. Ә Хафиз абый кайда соң?

—Китте ул, сеңлем. Төтенсез авылга китте. Яхшы кешеләр анда да кирәк шул...

Хафиз абый мина беркем булмаса да, никтер бик кызганыч, ямансу булып китте. Алай карт та түгел иде бит әле ул.

Күнелдә коточкыч бушлык. Бик авыр икән ул эшсез йөрүләре. Исәнлегең булсын, яшьлегең булсын, ә синең көчең дә, сәләтең дә беркемгә кирәк булмасын ди. Шулай ук артык, бер кирәксез кешемени соң мин бу илдә?!

**6 февраль.**

Бу юлы кирпеч заводына җибәрделәр. Андагы гыйбрәт... Ничек эшлиләр, ничек түзәләр анда? Юк, бармыйм мин анда. Баш тарттым. Эшсезлек буенча пособие һаман юк та юк. Кешеләрнең әйтүенә караганда, юри бирмичә торалар икән. Банкта яткач, процентлар җыела да, шуны кемнәрдер үзләштерә икән... Белмим инде, дөресме. Ә кешеләр нишләргә тиеш? Ә кешеләрдә беркемнең дә эше юк...

Мин баедым бит әле, базарда эшләүче үзбәкләргә диван белән шкафны сатып җибәрдем. Кулга акча керде. Шул шатлыктан үземне ит белән сыйладым. Нишләптер күңел болганып тора, гел ит ашыйсы килә. Пешкән ит күз алдыма килсә дә, авыздан сулар ага башлый...

**14 февраль.**

Бер килгәнгә килә икән... Акырып еладым. Кызганучы гына булмады. Бу караклар ник үз ишләрен талыйлар икән. Черек баеганнарга тимиләр, ә

хәерченең соңгы күлмәген булса да алып китәләр. Үзем дә гаепле инде. Башымны уй баскач, бик таркауга әйләндем. Белдерү буенча эш белешергә киткән идем, ашыгуым белән ишекне ачык калдырганмын. Эш тә булмады, кайткан җиремә менә шундый сюрприз... Телевизорны, скрипкамны алганнар. Башка алыр нәрсә дә юк инде миндә. Мин аларны соңгы чиктә сатармын дигән идем. Караклар миннән өлгеррәк булып чыкты. Утырам хәзер шыр бүлмәдә, күңелемне юатырга скрипкам да юк... Илзатыма яраткан көемне бер тапкыр да уйнап күрсәтә алмадым. Мин аны башка күрмәм дә инде.

**15 март.**

Без аның белән барыбер очраштык. Бер шәһәрдә яшәгәч очрашасың икән. Кибеттән кайтып барышым иде. Юл аша чыкканда чак машина астына барып кермәдем. Шундый инде мин хәзер, уйларыма кереп батам да, дөньямны онытам. Мине чак кына таптамый калган машина Илзатныкы булып чыкты. Тик ак «Москвич» түгел, куе яшел төстәге «Жигули». Яшел төсне яратам, дигән иде бит, үзе теләгәнне алган икән. Ә мин ак машиналардан качып йөрим...

—Гөлкәй! Син кайда югалдың?—Илзатның иң беренче сүзе шул булды.

Көтмәгәндә аны очратуымнан тәмам каушап калган идем, хәтта тавышым чыкмады.

—Югалмадым...—дип пышылдадым.

—Әйдәле, утыр машинага. Синең белән сөйләшәсе бар.

Мин аның күзләре белән очрашмас өчен, алга түгел, арткы утыргычка утырдым да, куркак куян баласы кебек почмакка сыендым. Юл буе дәшмәдем, аның киң аркасына, алкаланып торган коңгырт чәчләренә карап, тиле кебек: "Бу—Ул бит! Ул!!!"—дип сөенеп бардым.

Илзат мине тагы теге йортка алып китте. Монда бу юлы тагын да салкын иде. Кышкы җилләр, салкыннар үзенекен иткән, таш йортны эчтән дә, тыштан да суыткан. Мин Илзат бирәчәк сораулардан алдан ук куркып, куырылып бер сүз дәшми бүлмә уртасында басып торам. Ә ул мина шундый якын, каршыма ук килеп басты, күзләремә төбәлеп:

—Ни булды сиңа? Төсләрең гел калмаган. Ябыккансың. Авырмыйсыңдыр бит?—дип сорады. Шул чакта аның күкрәгенә капланып, елый-елый бөтен зар-моңымны түгәсем килсә дә, тыелып калдым.

—Юк.

—Әйдә, утырып сөйләшик әле.—Ул мине кочаклап диярлек диванга үз янына утыртты.

—Мин бит сине бөтен дөньяны айкап эзләдем. Туган көнең белән тәбриклисем килгән иде. Аптырагач, Боеклыга бардым. Бөтен авылны ду китереп сине таптырдым. Яшел түбәле йортта беләсеңме кем яши? Япа-ялгыз бер ир-ат. Хатыны үлгәч, фатирын улына калдырган да, авылга күчеп кайткан. Их син, Гөлкәй! Шулай алдыйлармыни? Нишләп кенә йөрдең соң син анда? Төнгә каршы шунда басып кала идең бит. Башыма сыймый, ничек шулай алдарга була?!

—Гафу ит. Шулай килеп чыкты инде.

—Анысы шулай да булсын ди. Ә эштән ник киттең?

—Белемең юк дип кыскарттылар.

—Хәзер кайда инде?

—Өйдә.

—Торыр урының бармы соң ичмасам?

—Бар. Фатирым бар.

Илзат гаҗәпләнеп баш чайкады:

—Фатирың бар?! Ну Гөлкәй... Син мине тәмам аптыраттың, дускаем! Шул гомер алдап, яшереп йөрергә кирәк бит, ә! Мин хәзер сиңа ничек ышаныйм, Гөлкәй?—Ул миңа таба борылып ике кулы белән битемне учлады.

—Үзгәргәнсең син. Ни булды? Тәмам суырылгансың. Ни кайгың бар, яшермә миннән.

—Мина эш кирәк.
—Эзләп карадыңмы?
—Әйе.
—Табалмадың, әйеме?
—Әйе.
—Моның сере бар, Гөлкәй. Без барыбыз да кара исемлектә. Синең арттан да шул кара койрык ияреп йөри. Бел, син монда эш таба алмаячаксың. Базарга чыгып бассаң гына.
—Нишләргә соң?
—Китәргә. Мин үзем Мәскәүгә китмәкче булам. Анда бездәге кебек кысулар юк. Мәскәү демократияне күреп калды.
—Нигә «калды»?
—Демократия безнең ил өчен артык зур күлмәк булып чыкты. Безгә кысан киемнәр күбрәк килешә.
Әллә ничек сөйләшә бу Илзат, аңлый алмыйм мин аны.
—Минем өстә дә кара болытлар куера, эшләр яхшыга бармый, Гөлкәй. Көрәш бик кискен, кысалар. Безнекеләрнең кайберләре «Гаделлек»тән чыгып, «Уртак Ватан»га керде. Аларны гаепләп булмый. Бер караганда, ул партия дә начарлык теләми кебек. Сүзләре бик дөрес. Тик анда һаман да шул ук кешеләр, күпчелеге үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүчеләр. Алар ничек тә властьтан китмәскә тырыша. Безнең илдә власть кына байлык һәм ирек бирә ала. Шуңа күрә барысы да югарыга омтыла.
Нигә сөйли боларны миңа Илзат? Миңа болар кызык түгел. Мине үз язмышым, үз киләчәгем борчый. Әгәр Илзат Мәскәүгә китеп бара икән, миңа нишләргә? Ул мине ташлый буламы? Ник бер сүз дә әйтми ул? Кем мин аңа? Нихәтле җавапсыз сорау... Боларга Илзаттан башка беркем дә җавап бирә алмый.
—Син кайгырма, Гөлкәй. Барып урнашкач та мин сине кайтып алырмын. Мин сине үзем белән алып китәм.
Илзат минем уйларны укыймы әллә?! Аның сүзләреннән соң бөтен күңелем яктырып китте. Елмаюымны сизми дә калдым.
—Сине менә шулай гел елмайтып кына торасы иде, Гөлкәем! Кызларга елмаю бигрәк килешә инде.—Ул мине кочып үбеп алды. Мин дә әнисенә сыенган сабыйдай аңа сыендым. Миңа шундый рәхәт иде, күңелем тулы җыр иде. Гүя бөтен кайгы-борчуларым иңемнән шуып төште. Зиһенем яктырып китте. Бу мизгелдә киләчәгем миңа ал нурларга күмелгән таң балкышы булып күренде. Сөенечтән күзләремә яшь тулды.
—Син миңа адресыңны бир, Гөлкәй. Башка югалтышмыйк инде без.
—Илзат, әйдә миңа барабыз. Мин Яңа елны синең белән каршыларга теләгән идем.
—Барыбер барып чыкмас иде, әни авырды. Мин аның янында булдым.
—Ә мин берүзем моңаеп утырдым.
—Син кайгырма. Алда Яңа еллар тагын булыр. Аларын инде бергәләп каршыларбыз.
Мин чакырсам да, Илзат миңа барудан баш тартты, адресымны гына сорап алды. Ул мичкә ягып җибәрде. Ялкын телләре, нидер пышылдый-пышылдый, карлы, салкын утыннарны үз кочагына алып, җылытырга- назларга кереште...
... Бу юлы без анда куынмадык.
—Үпкәләмә, Гөлкәй, миңа кайтырга кирәк. Әни авыру. Инсульттан соң һич җайга килә алмый,—диде Илзат.
Ул мине подъезд төбенә үк китереп куйды. Үрелеп яңагымнан үпте дә:
—Эшләмәгәч, акча якларың кыендыр, мин сиңа бераз булышыйм әле,—дип кесәсеннән чыгарып, миңа акча сузды.
Әллә нишләп киттем. Әйтерсең мин бер фахишә, тән сатып көн күрүче. Беләм, аңлыйм югыйсә, Илзат күңелендә бернинди начар уй юктыр, нияте дә

изгедер. Ләкин аның кулыннан акча алырга никтер кыенсындым, кимсендем.

—Рәхмәт, минем акчам бар, туганнарым булыша,—дидем.

—Кирәксә, әйт, кыенсынма,—диде Илзат.—Мин иртәгә кичен сиңа кагылырмын. Өйдә буласыңмы?

—Әйе.

—Ярый алайса, иртәгәгә кадәр, кадерлем. Тыныч төннәр, матур төшләр сиңа.

Илзат, машинасыннан төшеп, карашы белән мине озатып калды.

Бүген төнем шундый якты, шундый тыныч. Башымдагы бөтен авыр уйлар гүя мичтәге утыннар белән янып бетте. Күңелемдә илаһи бер тынычлык. Бернәрсә турында уйламыйча онытылып, изрәп, матур төшләр күрә-күрә рәхәтләнеп йоклыйсым килә. Минем яклаучым, терәгем—Илзатым бар!

**28 март.**

Ул юк... Инде ничә көннәр юк. Югыйсә мине эзләргә кирәкми. Мин гел үз өемдә, көннәр буе, төннәр буе аны көтәм. Ләкин ул юк... Нигә алдады ул мине? Киләм, диде бит! Ышандырды бит! Ул килә дип, мин тәмле ризыклар алып куйдым. Аның ярдәменә, мине ташламасына ышанып, пособиемне рәхәтләнеп туздырдым. Өч ай фатирга түләнмәгән иде, аны түләдем. Итегемнең табаны тишкән иде, аны ремонтлаттым. Бер айга житкерәсе акчамны атна эчендә туздырдым да бетердем. Ә ул юк та юк. Ни булды икән аңа? Әллә чирле әнисен калдырып китә алмыймы? Миңа әйтсә, мин аңа булышыр идем, әнисен дә карашыр идем. Үземнең дә хәлем яхшы түгел әле. Башым әйләнә, күңелем болгана, хәлем юк. Әни белән дә шулай булган иде. Әллә мин дә авырыйммы икән? Бигрәк авыр бу билгесезлек. Әллә апаларга кайтып китәргәме? Алай да булмый. Ул чагында Илзат белән тагы бер-беребезне югалтачакбыз. Өметемне өзмим, көтәм мин аны, барыбер көтәм. Ташламаячак ул мине, юк, ташламаячак! Әйе бит, дәфтәрем. Илзат намуслы, әйбәт кеше ул. Аңа да ышанмагач, тагы кемгә ышанырга соң?!

**2 апрель.**

Бүген төшемдә Илзатны күрдем. Имеш аның белән икәү кулга-кул тотынышып урманда йөрибез икән. Тар гына сукмактан атлап барабыз. Урман шундый куе, инде караңгы төшеп килә. Тик мин курыкмыйм, чөнки янымда Илзатым бар. Мин аңа сыенып диярлек атлыйм. «Жиләк ашыйсың киләме?»—ди Илзат. «Килә,—дим мин.—Тик караңгы бит, берни күренми». «Алда бер болын бар, анда жиләк күп. Ай булганда төн дә якты»,—Илзат шулай ди дә кулын минекеннән ычкындырып, кызу-кызу алга китеп бара. Мин аның артыннан чак-чак өлгерәм. «Ашыкма, калдырма мине! Мин куркам!!!»,—дип ялварам. Тик Илзат аның саен кызуырак атлый, ул инде күренми дә, бары тик ак күлмәге генә караңгылык эчендә байрак булып балкый, аннары ул да ерагайганнан-ерагая һәм куе булып үскән агач-куаклар арасына кереп югала. Ләкин Илзат бар әле, ерак булса да мин аның барлыгын тоям, шуңа һаман аңа дәшәм, аны чакырам. Тик жан авазым кайтаваз булып кире үземә кайта: «...зааат ... зааат! ...зааат!!!» Мин гүя бушлыкка дәшәм. Инде сукмак та күренми, берни күренми. Бар дөньяны караңгылык баса. Мин кай тарафка атларга белмичә, караңгыдан, ялгызлыктан куркып, Илзат китеп барган сукмакны табарга теләп, агачлар арасында бәргәләнәм... һәм куркып, шабыр тиргә батып уянып китәм.

Их, дәфтәркәем, болай булгач, бернинди өмет юк инде. Без бергә булмаячакбыз... Ташлый ул мине, ташлый... Бигрәк сәер сүз. Кешене ташлап буламыни? Ничек инде үзеңне яраткан, һәр сүзенә ышанган кешене ташларга була? Кешенең жаны бар бит!!! Бу йөрәккә ничек түзәргә соң?! Кайлардан гына көч, сабырлыклар алыйм икән?!

**22 апрель.**

Мине үзәктән дә «куып чыгардылар»—исәптән төшерделәр. Чөнки алар тәкъдим иткән эш урыннарына бармадым. Әгәр исәнлегем булса, кибетчелеккә ризалашкан да булыр идем. Аяк өсте басып тору авыр, башым әйләнә, хәл юк.

Мин эшли алырлык хәлдә түгел хәзер. Шулай дигән идем, инвалидлык артыннан йөрергә куштылар. Ул чагында пенсия билгеләнә икән. Иртәгә больницага барып карыйм әле. Тикшеренергә кирәк. Теге начар чир генә булмасын, ул чагында бернинди өмет юк...

**28 апрель.**

Ит ашыйсым килә! Умырып-умырып майлы сарык ите ашыйсым килә! Ник кенә теге чакта Илзат биргән акчаны алмадым икән?! Ул китте дә югалды. Хәзер көтмим дә инде. Көтү, өметләнү бик авыр. Башка берни турында уйлап булмый. Бөтен жанын-тәнен көтү газабы белән тула. Тамактан аш үтми, йокын йокы булмый, кулдан эш китә. Мин көтмәскә булдым. Үземә шундый боерык бирдем: «Ул килми, көтмә!»—дидем. Үземне анын килмәвенә ышандыргач, күнелдәге өметне сүндергәч, доньям бушап калгандай булды. Акылым аны югалтуга күнде бугай... Жылынын ни икәнен белгән-анлаган йөрәк кенә бу коточкыч салкын ялгызлыкка ияләшә алмый, әрнеп-сулкылдап аны, анын кайнар сулышын көтә. Ничек яшәп бетәргә сон бу гомерне?! Ничекләр түзеп бетәргә?!

**30 апрель.**

Мин больницага барып йөрмәскә булдым... Барыбер беркемгә дә кирәк булмагач, нигә яшәргә сон? Әгәр ашамыйча торсан, көчен бетә, әкрен-әкрен генә үләсен икән. Сугыш турында язылган бер китаптан укыган идем, кеше хәлсезләнеп ята-ята да, мәнгелек йокыга тала, үлгәнен сизми дә кала. Мин беркемгә ишек ачмаячакмын. Чөнки беркемне күрәсем килми! Хәтта аны да! Ул мина карата искиткеч рәхимсез булды. Киләм, диеп алдап китеп барды. Дөрләп янган учакка бозлы су китереп салды. Сүнде инде ул учак. Мәхәббәтнен очкыны да калмады. Шундый көчле учак та сүнәр икән... Үзен сүндергән учактан ялкын теләнмиләр. Хаер, теләнүче дә юк әле. Илзат хәзер күкрәк киереп Мәскәүдә йөридер, доньяда минем барлыгымны бөтенләй онытткандыр... Көтмим мин аны, көтмим. Бары аны—үлемне генә көтәм. Ул килер дә мине үзе белән мәнгелек тынычлык иленә алып китәр... Минем юклыгымны беркем дә сизмәс. Югыйсә мина бу жирдә күп тә кирәкми иде. Мин бик азга да канәгать идем. Доньянын матурлыгын күреп, үз хезмәтем белән акча табып, тыныч кына яшисем килгән иде. Яратасым, яратыласым килгән иде. Яраткан кешемнән балалар табып үстерәсем килгән иде. Мин кечкенә генә бер кеше, гади генә бер хатын, бу доньяда зур урын дәгъваламадым, азга да риза, азга да канәгать идем. Нәни генә шатлыкка да сөенә белдем, нәни генә бәхетне дә кояштай күреп кабул иттем. Ник сон мине күпсенде бу тормыш?! Ник сыймадым мин ана, ник сон үз илемдә дә шулай артык, үги баладай кирәксез, кадерсез булдым? Мин бу жиргә гариза биреп килмәдем һәм гариза биреп китмәм дә. Мәнгелек иленнән килеп алганнарын сабыр гына көтәчәкмен. Мин—мордар түгел, ә корбан. Мине сарык бәрәнедәй корбан итеп чалдылар. Рәнжеттеләр, алдадылар, кактылар да суктылар. Минем яшисем килми. Минем өчен кысан, салкын, карангы булган бу доньядан тыныч кына югаласым килә. Елга суына төшкән кош каурыедай талгын гына йөзә-йөзә, мәнгелек дингезенә китеп югаласым килә... Әй кешеләр, мине күрмичә, читкә тибәреп, таптап, кимсетеп киткән каты бәгырьле кешеләр! Сезгә бары бер соравым кала:

Нишләттегез Гөлкәйне?!

* * *

Көндәлекнен сонгы битен яптым да уйга калдым. Нигә шулай булды? Ин авыр, мохтаж көннәрендә дә Гөлкәй мина берни хәбәр итмәгән, ярдәм сорамаган. Һаман ялгыз булган. Туган апасына шул кадәр дә ышанычы юк микәнни? Ә мин? Мин үзем сон... Сенлемнән бернинди хәбәр булмаса да, анын язмышы турында борчылмаганмын, хәлен белмәгәнмен. Бер ата, бер ана балалары жиде ят булып, икебез ике якта яшәп ятабыз. Нигә шулай нечкә, чыдамсыз булды сон әле безнен туганлык жепләре? Әллә сон барыбызны

бергә җыеп торучы әти-әниле туган йортыбыз булмаганлыктанмы? Белмим, белмим...

Гөлкәйнең язмышы мине тетрәндерде. Ни генә күрмәгән,ниләр генә кичермәгән балакай. Әмма зарланмаган, безгә кайтып егылмаган, үз тормышын үзе җайга салырга тырышкан.

Эше дә, мәхәббәте дә баш ваткыч мәсьәлә түгел анысы, мине иң борчыганы сеңлемнең исәнлеге иде. Санаторийда аны тикшерми, күзәтми тормаслар. Дөрес диагноз куеп, дәваласалар, бик яхшы булыр иде дә бит. Берүк терелеп кенә кайтсын, калганы җайланыр.

Сеңлемнең йөрәк серләрен үз эченә алган зәңгәр дәфтәрләрне кабат үз урынына куйдым. Алып укыганны сизә күрмәсен берүк. Гомерлеккә рәнҗер, инде ялгана башлаган туганлык җепләре кабат шытырдап өзелер. Миңа Гөлкәйне югалтырга ярамый. Үткәннәрне кайтарып та, төзәтеп тә булмый, әмма калган гомерне без бергә үтәргә тиеш. Бер-беребезгә бик якын апа-сеңел булып.

Гөлкәй кайтырга атналап вакыт бар иде әле, беркөнне Яртаудан Халидә шылтыратты. Хәл-әхвәлләрне сорашты да:

—Нурсинә апа, Гөлкәйне сорап бер ир-ат шалтыратты. Мин әйттем инде сезгә киткәнен, адресыгызны, телефоныгызны бирдем, ачуланмыйсызмы?—диде.

—Исеме ничек соң аның?

—Сорамадым шул. Бик ягымлы, яшь тавыш. Гөлкәйнең очрашып йөргән кешесе бугай ул.

«Бу Илзат булырга тиеш»,—дип уйладым мин.

—Әйтеп дөрес эшләгәнсең. Киләм, дидеме?

—Алай сорагач, исәбе бардыр инде, юкка гына белешмәгәндер.

—Ярар алайса, көтәрбез кунакны.

Бу хәбәргә чынлап та шатландым мин. Гөлкәй өчен искиткеч зур бәхет булачак бит бу! Яраткан кешесе белән очрашкач, терелеп, күнеле күтәрелеп китәр, яшисе килә башлар. Мәхәббәт әллә нинди авыруларны да аякка бастыра ул!

Гөлкәй кайтты, тик ялгыз түгел. Аны нindидер бер ят ир-ат машина белән китереп куйды. Өйгә дә, Гөлкәйнең сумкаларын күтәреп башта ул, бөтен җире түгәрәк булган ни матур, ни ямьсез түгел ир гөрелдәп килеп керде. Аның артыннан гына кәтүк буе Гөлкәйнең бөдрә чәчле башы күренде.

—Менә, апасы, кызыгызны исән-имин кайтарып җиткердем. Пернимат итеп алыгыз,—дип бөтен өйне яңгыратып көлде таныш түгел кунак.

Аннан соң гына Гөлкәйнең нечкә, йомшак тавышы ишетелде:

—Апа, бу Салих абый була, минем танышым.

—Нинди таныш ди, киявем диген! Сөйләштек, килештек бит инде. Кыз сорарга кайттым мин, бирәсезме миңа сеңелне?

Бу кадәр көтелмәгән хәбәрдән миңгерәп калдым. Гөлкәйгә әти булырлык бу абзый нинди кияү булсын ди? Мин сораулы карашымны сеңлемә күчердем. Ул җавап урынына, тегенең сүзләрен җөпләп, баш кына какты.

Кунакларны ишек төбендә бастырып тоту килешми иде, түргә чакырдым. Үзем тизрәк табын корырга керештем. Гөлкәй дә өс киемнәрен алыштырып минем яныма чыкты.

—Нәрсә эшлим, апа, булышыйммы?

Ачуланырга әзерләнеп, бәрәңге кырган җиремнән ана төбәлгән идем, аптырап калдым. Минем алда эче-тышы балкыган бәхетле хатын басып тора иде. Гөлкәйне гүя алмаштырып куйганнар. Әгәр бу түгәрәк ир сеңлемне шулай шат күңелле итә алган икән, нигә әле мин аны ачуланыйм ди. Шуңа күрә әйтергә теләгән сүзләрне эчемә йоттым да:

—Суган белән кишер чистарт,—дидем.

Табын әзер булгач, бик вакытлы гына Атлас та кайтып керде. Ир-ат кунак

янына ир-ат хужа кирәк шул. Салих абый харап сүзчән кеше булып чыкты, әллә көлгәндә сөйли, әллә сөйләгәндә көлә, аера торган түгел, барысы бергә.

—Туганнар, ул бит болай. Насыйп ризык тешенне сындырып керә диләр. Менә бу чибәр сенелкәшне машинама утыртып кайткан идем. Ну күз төште, кызыктым бит мона. Ирем бар дигәч, бөтен өмет өзелгән иде. Их, мәйтәм, мина да шундый хатын белән гомер итәсе иде, дим. Ишеткән бит Ходай! Санаторийда очраштык та, анлаштык та, икәү бергәләп кайтып та төштек менә. Сез борчылмагыз, туганнар, Гөлкәйне абижат итмәм. Минем тормыш яхшы. Сенлегез нужа күрмәс. Бөтен нәрсәм бар. Йорт тулы мал. Патша кызы кебек яшәтәм мин аны!

Бу кешенен әллә нинди сөйкемле сөяге бар. Үзенә тартып тора. Гел көлеп, барсыннан разый булып торган, шат күнелле кешеләр янында жанга рәхәт, жинел. Гөлкәйгә бәлки нәкъ шундый ир кирәктер. Әнә бит ничек балкып, үзалдына елмаеп утыра. Гомеремдә дә мондый Гөлкәйне күргән юк иде. Бу кеше тәмам сихерләгән бугай аны. Әллә Илзатын бөтенләй оныткан да инде? Илзат дигәч, Халидәнен сүзләре искә төште. Шуна күрә, ирләр ишегалдына тәмәке көйрәтергә чыгып киткәч, Гөлкәй белән ачыктан-ачык сөйләшергә булдым:

—Яратасынмы бу кешене?

Гөлкәй мине тагын аптырашта калдырды, бөтенләй чит кеше язмышы турында сүз баргандай битараф кына:

—Юк,—дип әйтеп куйды.

—Мәхәббәтсез яшәп карадын бит инде. Ни икәнен беләсен. Бер утка ике тапкыр кермиләр. Яратмагач, нигә барасын?

—Яратканым үзем белән, апа. Ул гомер буе минем белән булачак.

Гөлкәй серле елмаеп, кулларын, кемнедер иркәләгән сыман, үзенен эч турысына куйды.

—Бала көтәм мин.

Мин «ах» иттем: менә нинди чир булган икән Гөлкәйдә! Шулай да белмәмешкә салышып сораган булдым:

—Салих абыйданмы?!

—Юк, яраткан кешемнән...

—Кайда сон ул синен яраткан кешен?

Гөлкәйнен йөзенә сагыш кунды.

—Анысы хәзер мөһим түгел инде... Минем балам ачлыкнын, хәерчелекнен ни икәнен белмәскә тиеш. Ә Салих абый бай. Анын яшел түбәле йорты бар... Анын бөтен нәрсәсе бар. Ул мине ярата, шулай булгач, баламны да яратыр. Ә мин ана яхшы хатын булырмын. Без авылда тыныч кына яшәячәкбез... Мин шулай телим.

Гөлкәй гомердә булмаганча сүзчән иде. Үзе генә белгән биниһая олы шатлыгы, сөйгәненнән бала табу бәхете, ана булу өмете гүя анын монарчы әллә ничә йозакка бикләп куелган күнел тәрәзәләрен якты дөньяга киереп ачкан иде. Ул бераз дәшми уйланып торды да, ниндидер мөһим эш башкарырга жыенган кешедәй, кинәт әйтеп куйды:

—Апа, мунча ягыйк әле, мунча керәсем килә!

—Сон бит инде.

—Булсын, төнлә керербез.

—Алайса бар, ут төртеп жибәр. Утыннары мичтә, суы керткән. Иртәгә иртүк ягып жибәрергә дип әзерләп куйган идем.

Бераздан мин дә, аулакта иркенләп сөйләшербез дип, анын артыннан киттем. Ни күрим, Гөлкәй мич алдына тезләнгән дә, кулындагы дәфтәрне умыра-умыра мичкә кәгазь битләре ташлый. Мин ул зәнгәр тышлы дәфтәрнен ни икәнен белә идем инде. Шулай итеп, Гөлкәй кабат үзенен үткәннәре белән хушлаша. Аларны утта яндырып, өр-яңадан тумакчы, яна тормыш белән яшәмәкче була.

Әйтергәме Илзат турында, юкмы?

—Гөлкәй, син Салих абый белән китмисеңдер бит әле, каласыңдыр.

—Китәм. Хәзер китмәсәм, аннары китә алмам дип куркам.

—Дөрес эшлисеңме икән инде, ялгышмыйсыңмы?

—Дөрес эшлим.

—Ә мәхәббәт?

—Мәхәббәт акылны томалый, яшәргә комачаулый. Кирәкми миңа ул. Арыдым инде... Тыныч кына яшисем килә.

—Гөлкәй, сине бер кеше эзләгән. Халидә шылтыратты.

Гөлкәй сагайды. Йөзенә ут капты, күзләренә курку тулды. Бераз дәшми торганнан соң:

—Кем ул?—дип сорады.

—Кем икәнен белмим, бер ир-ат, диде.

Көндәлек битләрен умыручы куллар һавада асылынып калды. Уй тулы сагышлы карашы мичтә биешкән ялкын телләрендә катып калган иде. Аңладым: Гөлкәйнең хыялында Салих белән икесе өчен тырыша-тырмаша төзегән ком сарае мизгел эчендә убылып, ишелеп төште. Ул, күнелендә бөтерелгән хискичерешләрен миннән яшерергә теләгәндәй, куллары белән йөзен каплады.

Мин исә, аңа карата рәхимсез булуымны аңласам да, һаман үземнекен сөйләдем:

—Халидә аңа безнең адресны, телефонны биргән. Ул, мөгаен, килер. Уйла, туганым, ялгышма. Китмә бу кеше белән. Яратмаган ир янында сулып-саргаеп яшәгәнче, ялгыз булуың мең артык. Гомер бер генә ул.—Мин үрелеп Гөлкәй алдында тузгып яткан дәфтәр битләренең берсен алдым һәм кычкырып андагы сүзләрне укый башладым: “Янәшәңдә яраткан кешең булса гына, дөнья ямьле, яшәү күнелле. Мәхәббәттән башка тормыш юк, ул үзе иң зур бәхеттер, мөгаен”.

Гөлкәй сискәнеп китте, кулларын йөзеннән алып, чык тамчыларына манылган карлыгандай дымлы күзләрен миңа төбәде:

—Моны мин язган идем. Ун гасыр элек...

Ул, йокыдан уянырга, икеле-микеле уйларын берьюлы коеп төшерергә теләгәндәй, кисәк кенә башын чайкап алды да, әкрен генә, пышылдап диярлек әйтеп куйды:

—Мин калам, апа... Мин аны көтәм...

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында саклаңган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**



Мөхәммәт
Мирза

## АДӘМ БАЛАСЫНА

БИШЬЮЛЛЫКЛАР

* * *

**...Таш кыя—вакытның**
**туктап калган хәле...**
**Адәм баласының**
**ташны ташка бәреп**
**ут чыгарган мәле...**

* * *

**Гарасаттан калды**
**хәрабә өеме...**
**Адәм баласының**
**ил-көне хәерле**
**догада идеме?!.**

* * *

**Тереклек суы,—дип**
**Шайтан сузган хәмер...**
**Адәм баласының**
**йотып җибәргәч үк**
**ирешкәне—кабер...**

* * *

**Садакта—ук җиде,**
**ян-якта—алмаш ат...**
**Адәм баласының**
**яулап алган җире**
**оныкларына ят...**

* * *

**Үзе таңнан эштә,**
**акылы төштән соң...**
**Адәм баласының**
**кайчан, кайда, ничек**
**авызы пешкән соң?**

* * *

**Күкләр сабак бирә...**
**Төшенгән төшенер...**
**Адәм баласына**
**тормыш—ватып алыр**
**чикләвек төшедер.**

* * *

**Бүредән курыккан—**
**урманга бармаган...**
**Адәм баласының**
**учак тергезерлек**
**чырасы калмаган...**

* * *

**Телнең сөяге юк,**
**кәгазьнең теле юк...**
**Адәм баласының**
**тел сындырып сөйләп,**
**язмаган көне юк.**

Мөхәммәт МИРЗА (1953)—*шагыйрь; «Турайгыр», «Киек каз юлы», «Тере су» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Телдән-телгә китә,
урап кайтып җитә:
Адәм баласының
«авызы әйткәнне
колагы»... ишетә!..

* * *

Тел яшергән кем дә,
телен болгаган кем?
Адәм баласының
тел тегермәненнән
онын урлаган кем?

* * *

Әдәп, әхлак—нидән,
мәдәният—кемнән?
Адәм баласының
шәрә гәүрәтенә
яфрак япкан көннән!..

* * *

Сый—хөрмәт асылы...
Сыйдан зур булмый тор...
...Адәм баласының
хөрмәтсез сыена
кулыңны сузмый тор...

* * *

Ярлы-ябагадан
ришвәт ала табип...
Адәм баласының
нәфсе-кәсебендә
рухы кала гарип...

* * *

Тормыш—тоташ базар:
гел алыш-бирештә.
Адәм баласын да
сатып-алып була
бәһасез килеш тә...

* * *

Авылда бер сәрхуш,
авылда бер тиле...
Адәм баласына
гыйбрәт алыр өчен
шулар җитә иде...

* * *

Кипкән чүл елгасы,
ярын какмый дулкын...
Адәм баласының
гомер дәрьясын да
күмеп китәр бу ком...

* * *

Язганы—аңар гел:
сүтәр дә, ямар гел...
Адәм баласының
ятлар йөген тартып,
гомере янар гел...

* * *

Саннар асылында...
галәмдә бүленеш...
Адәм баласының
җирдәге тормышы
иң серле күренеш...

* * *

Хәерле сәгатьтә
хәвеф-хәтәр чигәр...
Адәм баласына
саваплы гамәлдә
иман нуры иңәр...

* * *

Кайгысы китүгә
бәхеткә кинәнер...
Адәм баласының
биргәне—дөя дә,
алганы—энәдер...

* * *

Ятагыннан ары
берни яратмаган
Адәм баласына
Ай икенче ягын
бер дә каратмаган...

* * *

Тыйнакның тыны юк,
күкрәп чыкмас бер дә...
Адәм баласының
чынлап эш кырганы
күкрәк сукмас бер дә...

* * *

Сукмакны—бер кеше,
юлны—халык сала...
Адәм баласының
узган бар гомере
шунда ягылып кала...

* * *

Күк-Җир арасында
бернинди ара юк...
Адәм баласына
шул арасызлыктан
чыгарга чара юк...

* * *

"Син",—дигәндә тимәс...
"Мин",—дигәндә тияр...—
Адәм баласының
иреннәре әйткән
күңеленнән иңәр...

* * *

Сукырдан яшь чыгар—
чын-чынлап еласа...
Адәм баласы бай:
тумаган колыны
билен сындырмаса...

* * *

Уйдан уй туадыр...
Уйны уй куадыр...
Адәм баласының
уйлы тормышы да
уеннан торадыр...

* * *

Аһ! дигәнче күкне
айкап үтте яшен...
Адәм баласының
күзләренә багып
күк түкте күз яшен...

* * *

Намазга басмаган...
Сәҗдәгә китмәгән...
Адәм баласының
тәне тойган рәхәт
җанына җитмәгән...

* * *

Ходайдан бүтәнгә:
—Колыңмын!—димәгез...
Адәм баласына:
—Тәүбәгә килергә
"соңардың",—димәгез.

* * *

Яфрак селкенмәгән
тып-тын бу иртәдә
Адәм баласының
җиде күк катында
көнен хәл итәләр...

* * *

Буе җитмәгәнгә—
"өлгермәгән җимеш":
Адәм баласының
үткен балтасына
кагылмый бу "имеш"...

* * *

Ай—Җирнең күктәге
мәңгелек сәгате...
Адәм баласының
күк ихтыярында
холыгы-халәте...

* * *

Кәгазь дә саргая...
Вәгазь дә искерә...
Адәм баласына
Иблиснең өр-яңа
ялганы тиз кирә...

* * *

Гәүдәсенә күрә
шәүлә-күләгәсе...
Адәм баласының
салымы юк, шөкер,
шуңар түләнәсе...

* * *

Атына карап та
салына солысы...
Адәм баласының
үз урнын беләме
кечесе, олысы?..

* * *

Ярлы ятагында
ямьсез яры ятыр...
Адәм баласының
бары үз әнкәсе
матурлардан матур.

* * *

Дугасын бөккән дә,
тәртәсен күтәрткән...
Адәм баласының
тәү кат ат җиккәне
язмышын үзгәрткән.

* * *

Ташта сын-тамгасы...
Тузда сын-сурәте...
Адәм баласының:
—Асылың җуйма!—дип,
язган васыяте...

* * *

Яу—ау түгел, белми
кем кайчан кайтырын...
Адәм баласының
яуга киткән көннән
аулыйлар хатынын...

* * *

**Көләргә теләсәң,**
**бетәрме хөрәсән?..**
**Адәм баласының**
**һәрберсе эч катып**
**көләрлек бер әсәр...**

* * *

**Тиранны астылар—**
**хөкемдарга хөкем...**
**Адәм баласына**
**юкса күпме гасыр**
**кисәтелде бу көн!..**

* * *

**Соңгы барыш—зират,**
**соңгы кичү—сират...**
**Адәм балалары**
**сабыр итеп баскан**
**иң беренче чират.**

* * *

**Кылган бар гамәле—**
**эшендә, ашында...**
**Адәм баласының**
**иң соңгы хәбәре**
**кабере ташында...**

* * *

**Сылу—сокланырга,**
**түгел табынырга...**
**Адәм баласына**
**тигез юлда күпме**
**мөмкин абынырга?..**

*Хикәяләр конкурсына*

Әхәт Гаффар

# КОЕЛЫ ӨЙ

Бу хәл-әхвәл булганга әллә күпме вакыт узган инде. Шул кадәр дә узып киткән ки,—кичә, бүген, иртәгә дигәннең әһәмияте юк. Нигә икәнлеген карлар челтәрләнер-челтәрләнмәстән, гөрләвекләр агар-акмастан, әле туеныр жимен табар-тапмас чакта ук оя корыр вакытка ашкынып кайткан тургайлардан канатка-канат, жанга-жан оешканнан соң, туган, торган жирләре белән хушлаша-хушлаша киләсе язга кадәр басу-кырлар турысыннан очышкан сыерчыклардан сорыйсынмыни? Көндезге сәгать икедә шул сәгатенне көзгегә каршы куеп карасаң, иртәнге унны күрсәткән шикелле, үтеп барган вакыт арасында кичәгесе белән иртәгесе бутала, алаша, юкка чыга, күрәсең.

Өйгә—әнкәй янына кайтыр юлга чыгасың бар иде. Күктән боз, таш яуган шәттә дә. Яна елга керер кич, төн алдыннан. Ин кимендә—таңда. Әни янына, авылга. Ул андагы өебездә сыер, өч сарык, жиде-сигез тавык, әтәч, ике ана, бер ата каз тотып, япа-ялгызы яшәп ята. Йорт-жиребез ару гына таза, кешенекеннән ким түгел. Артыграк булмаса әле! Жәйләрен яшелчә үстерүендә әниебезгә житкәннәр сирәктер. Болай ул, кырык сигез яшеннән тол калган килеш, кош балаларыдай очкан-киткән, таралган тугыз баласын сагынып зарыкканлыгыннан ризасызлык белдерепме, зарланып, интизарлап, үпкәләпме искә-оска алмаган да шикелле. Тере, яшәмчән, елмайганда бөтен йөзе уылган кызыл кирпеч тузаны белән ышкып чистартылган жиз самавырдай балкып тора. Ә инде әнкәйнең, оныткандa дигәндәй, үзе дә сизмәстән тирәнтеннән уфтанып куйган чагында хәл-әхвәле, хәтмәле төстә ишелеп төшкән язгы ташу сыман, бәгырь үзәгенне басып киткән чаклар, аһ, булгалый. Ничек кенә булгалый иде әле! Әллә бу үткән дөнья сугышында алган ярасыннан соң, ары таба, өстәп, колхозда жан атып эшли-эшли тәмам ару-талчыгуларданмы илле алтынчы яшендә вафат булган һич онытылмас назыннан мәхрүм калу мәхшәреннән микән? Соравы, тәгаенләве унайсыз бит инде.

Менә шушы—сиңа укалы күлмәк, сатин чалбар кигезеп йөрткән, һәр баласына бирәр пар бияләй, оекбаш бәйләгән, трусик, майка теккән газиз әнкәң янына, катына дип, салкын, буранлы декабрь кичендә каршы юлга кузгаласың. Әнкән янына кайтасы юлыңның газабы, аның алдына куйган өч-дүрт кыстыбыйны ашаганың шикелле генә: фасыллардагы беренче иреньяргыч, көпшә, шомырт, жир жиләген капканың кебек, моның һич тә алыштыргысыз мәңгелек тәме бар.

Шулай итеп, син бүген чуен юл станциясендәге вагоннан алтмыш тонна чәчелмәле цемент бушаттың. Ничек итеп бушатканың кемгә хажәт: ин мөһиме сиңа дөнья пролетариаты юлбашчысының сурәте төшерелгән шәмәхә төстәге, шытырдап торган егерме биш сумлык кәгазь акча түләделәр; ул

Әхәт ГАФФАР (1949) – *язучы, публицист; «Әҗәт», «Бер йотым су», «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы», һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

жанкай-җанашны, студентларның тулай торагындагы шимбә кичендә бергә биегән хатыныңның нечкә, тыгыз билен сак кына кыскандай, урталай бөклисең дә чат тузан телогрейканның түш кесәсенә тыгып куясың; кайтышлый, якыныңның түш төймәсен беренче тапкыр ычкындырганнан соңындай итеп, капшап-капшап аласың әле: теге банкнотның кәбестә шикелле шыгырдап куйганына сөенәсең. Аннары инде тәнең, бөтен җирең әлеге кәгазь акча сыман кыштырдап торырдай итеп, беренче каттан түбән урында юынып чыгасың. Үзең кебек үк нык беләкле, тыгыз бәдәнле "цементташ" өч иптәшең белән бергә-бергә инде... Аларның кайтасылары юк—ерак шәһәрләрдән килгәннәр. Шәрабләре алып куелган, ә синең хәмер дигәнне иснәп карагаың да юк, өнәмисең; урам аша торган кибеттән ике бөтен икмәк, күмәч, ике кило алма, яртышар килодан кара җимеш, күрәгә, хөрмә, кадак ярым "Ласточка" дигән шоколадлы, "Лимонный" дигәнен өстәп, тагын көрән мендәрле конфетлар сатып аласың.Әзме-күпме тутырмасы да кирәк инде—кыскасы, нәкъ әлеге дә баягы егерме биш тәнкән исәбеннән. Юлга юк кеше генә буш чыга. Әзрәк өстәгәндә дә ярар дигәндә кысталып, тансыкка вактөяген дә өстисең әле. Кайтып килер юлга дигән әҗеренне чалбарыңның уң балак кесәсе төбенә җыйнап куясың, калган барчасын якыныңа биреп калдырасың. Алга таба да яшиселәр бар ич әле; җитмәсә, тегеннән-моннан аласы керемең дә юк.

Ә кайтып килергә кирәк. Кыш көне. Яңа ел төненә каршы кичтә. Әллә кайчан бабаң утырткан чагында әбиең тотып торган неп-нечкә үсентеләрнең ниһаять биш колачың да җитмәслек юан-юан кәүсәле тупыллар, таллар, атаң сугыштан исән-имин әйләнеп кайтканнан соң әнкәң белән бергәләшеп, тамырларын җәеп, таратып, туфракка индергән канәфер куаклары ышыгында тыныч-имин утырган, кайчандыр син елап дөньяга килгәч, бишегең тирбәлгән борын-борынгы нигезеңә таба.

Иртәдән үк йомшак, мамык-мамык аклы-кызыллы сыерыбызның абзарда бу чыгара-чыгара сулыш алганыдай тын, тыныч кар ява башлаган иде. Аннары төньяктан ачы җил исәргә керешеп, син автобуста кайтканда җәяүле буран кузгалды, асфальт юлга урыны-урыны белән көртләр дә себертеп куйган икән инде: чистарткычлар алгы тәрәзәләрне сөртеп алырга өлгермәскә әйләнде. Шуңа күрә син юлны тәгәрмәчләр арасына шуышып кергән тузбаш елан сурәтендә генә абайлыйсың инде. Ә җил себерткән җәяүле буран арыган күз керфекләреннән мизгел-мизгел ачылып-йомылулары гына булып тоела башлый. Мондый итеп: җәйге чиллә кояшы нурына туенган кыр, болын чәчәкләре генә үзләренең таҗларын каплап куючан. Һәрхәлдә бу мәлендәге әнге-мәңгедә шулай хис итәлә.

Минем йөгем пөхтә—чагыштырырга яраса, әз-мәз көмәнле бер-бер хатын-кызның әлегә сизелер-сизелмәс, бүлтәйгән кием-салымына тартым: күрәселәрен күптән күргән, заманында кыйммәт бәяле сары күн букчада иде.

Автобустан Масла авылы юл чатында төшеп калып, су күсесе тиресеннән тегелгән затлы бүрегемнең колакчынын төшереп бәйләгәч, букчамны аяк арасына кыстырган килеш биш бармаклы күн бияләемә ак брезент эш бияләе кидереп куйганчыга кадәр, җилдән ышыкланып, сигарет кабызгач, аркан ягыннан тын гына әйтелгән:

—Син күрмәдең дә,—дигәнне ишетеп аласың.

Шым гына керергә теләгәндә, кинәт сагаерга мәҗбүр итеп, көтмәгәндә ишек күгәне шулай тавыш биреп куючан. Бусы шыгырдап, тешеңне камаштырырдай чытырдап түгел, ә бәлки, әйтик, кышкы зәмһәрирдә өй җылысы белән тышкы суык чалт иттереп янакларына ябышкан ишекне дерт иттереп кенә ачканың шикелләме соң? Юк бугай: аркан яктан:

"Син күрмәдең дә",—дигән әлеге аваз миңа үзең белән ияреп керергә

аягың янында ясканып, атлыгып торган ак мәченең тыйнак кына, "минем дә кирәсем бар" дигәнедәй тын гына тавыш бирүе сыман тоелып китте.

Ә мин шул мәлдә сискәнеп куйдым. Нигәдер.

Әйтерсең лә әллә кайчан—күптән инде—әнкән иртән иртүк: "Тор инде. Вакыт",—дип, йомшак тавыш биргән көенчә синең инбашына өч бармагы белән кагылып узган.

Сискәнеп дип... һич юк анысы. Нигә дигәндә, мин бу аваз иясен тегендә—һәркем фәкать үз-үзен генә кайгыртКан автовокзалда күреп искәрмәсәм дә, хәзер исә ул ишетсен өчен каршы искән жил белән бураннан янтаебрак, мен дә бер елдан соңгы шикелле итеп:

—Күрдем,—дидем.

Ишеткәндерме,—тынымны, әйткәнемне кисәк жил бүлде.

Хәер, автобуста басып барганың чагында аркана тәрәлеп барган тыгыз түш, аягыңны алыштырырга да ирек бирмәгән чемоданның иясе шушы тавыш кешесе икәнлеген минем бүген унбиш тонна цемент бушаткандагы арыган тәнем, алжыган жаным сизми, белмиме соң инде, әйеме.

Кабызган сигаретымны бияләй ышыгында тотып, өстән аска—сул аягым кырыйлата карап алгач, мин аның теге чемоданы янәшәсендә шактый мул бүлтәеп торган рюкзагы барлыгын да күреп өлгердем инде.

Мин ана:

—Кузгалыйк,—дидем.

Ул:

—Әйдә,—диде дә шул йөкләренә иелде.

Шунда аның уң кул ягына үзеннең "йөкле" портфелеңне куясын да уң иненә аның яшькелт рюкзагындагы пар элмәкләрне эләсең, ә инде чемоданы тоткасына тотыныр алдыннан, үзеңнең брезент эш бияләеңне, берсен тешең белән, икенчесен болай гына алмаш-тилмәш салып, әкрен генә:

—Ки,—диясең.

Ул карыша. Тик инде мин бала чагымда ук озын бер пакус үләнне чабып куйганнан соң жиделе чалгым йөзеннән кайрагымны, аннары соң үткер кыргычымны алгы-артлы чажлап үткәнемдәге шикелле нык итеп:

—Ки!—дип кабатлыйм.

Нишләгәндер, мин ары таба атлап киттем. Аның йөген күтәреп, без автобустан төшеп калган аермадан ике чакрым да йөз сажин чамасы арадагы имән утыртмасына житкәнче борылып карамадым. Инде энгер-менгердән соңгы караңгылык тәмам инеп, йөзгә бәреп торган буранга каршы атлап киткән ике адәми затның ошбу юлда икәнлеген өстән дә бәргән, жәяүләп тә сызган буран белән жилдән гайре бу дөньяда һичкем белми иде.

Әй-й!—әйбәт этсә жиде чакрым ара юл мыни соң ул?

Дисең инде.

Ә син мамык шәл япкан, зәңгәрсу тукымалы кышкы палтә, аягына күн тышлы итек кигән, ә йөзенә килгәндә, кус кашлы, зуп-зур күзле—бөтен жирен кар сарган бер кыз кисәгенең сулыш алуын искәрә-искәрә аны шушындый төнгә каршы шул каләр дә кул йөге төяп кайтканын үз ихтыярың белән кулыңа алганыңа, күтәргәненә, шуңа мәжбүр икәненә күнеленнән сыкрый-сыкрый, аны әрли-әрли туган авылына таба барасың да барасың. Сукранмыйсың анысы: чөнки үз авылына таба кайтудан да якынрак, жиңелрәк бүтән юл юклыгын син ахырзаманга—әлмисакка чаклы яхшы беләсең. Сиңа әлеге юлда барышлый һичнинди юлдаш-әхрәт очрамаса да, мәшәкатеңне, рәхәтеңне, уеңны, сүзеңне уртаклашырдай, жан йөгеңне күтәрешердәй һичкем калмаслыгына тәмам ышанган сурәттә дә.

Сиңа аның рюкзагы белән чемоданы барыбер бүген өч иптәшең белән бушаткан алтмыш тонналы цемент вагоны гына түгел ул—күпкә авыррак кебек

тоела.

Мин атлыйм да атлыйм, әнә теге күтәрелештән соң Борынлы авылы каршындагы түбәнлек китә, аннан ары шактый озын тигезлек башлана, аның үренә житкәннән соң Корноухово авылы утлары ялтырар да, әз генә төшә торгач, безнекеләр күренер. Юлның яртысын узгансың икән, калганын ташбака булсаң да үтәсең. Иң мөһиме—җил белән буранга каршы барасы, юлга өелгән көртләрне зур-зур адым белән атлапмы, ерыпмы үтәсе дә үтәсе. Атлау кирәк, тик сүзсез-нисез генә.

Мин юлдаш кызның аяк атлавын ишетмәгәнемне искәртеп алдым.

Шул ук вакытта каршы буранның көчәйгәннән-көчәя барганын да. Будавыл. Кышкы. Сирәк нәрсә түгел. Күргән, кичергән бар. Ә исә шушы мәхшәр уртасында ике адәми зат бар бит әле. Шушы мәлдә аркан әйләнеп карыйсың да инде. Атлап китәр алдыннан аяк астыңны барлап алган шикелле итеп. Йә инде ул-бу хәтәр хәбәр ишеткәнеңнән соң (әйтик, таныш кемдер вафат булганын) госел коенып чыкканың шикелле. Моны атап, сурәтләп, әйтеп тору кирәкмәс тә. Мөэмин-мөселман икәнсен—шулай тиешле, шулай фарыз.

Әйе, бара-тора аркан борылып карыйсың. Чөнки син анын—һич тә теләмәгән ирексез юлдашыңның, аяк атлавын ишетмисең. Колагыңны гүя җил өреп тутырган буран мендәре каплаган.

Әнә ул: аны буран ташкыны аша чамалыйсың. Әле ярый күз үткер—югалтмыйсың. Шундук аны: "Ниме дип туры килден соң әле син?"—дип, әрләп атасы килгәнеңне басарга теләгән ниятең мизгелендә аның алты сажиннар чамасы артта калганлыгын, үзеңнең затлы портфеленә утырганын, ишетелер-ишетелмәс төстә тын гына итеп:

—Су,—дигән авазын ишетәсен.

Шунда шәйләп аласың инде: бактың исә ул синең йөгеңне юл кырыена трактор сөйрәтеп барганнан төшеп калган салам күченә терәтеп утырган икән. Шул чакны сине, аның тарафына чигенеп, янәшәсенә жайлашкач, сигарет кабызып тарту нияте биләп ала, тик син аның "Су!"—дигәненә каршы:

—Хә-зер!—дисең. Каршы ургым жилдән тыныңны коткаргач:—Хәзер,—дип кабатлыйсың.—Хәзер, эчертәм мин сина су!

Мин аның бала чагында үзебезнең йорт куяннарыбызның мамыгын йолыкканда чыелдап куйгандагы, йә әти безнең чәчебезне кул машинкасы белән китәргән чагында чәч бөртегебезнең өзелеп-өзелеп кенә чыккан мизгелләрдә кисәк авыртуга сискәнеп киткәндәгечә:

—Әй!—дигәнен ишетеп алдым. Аннары ул:—Нәрсә?—диде.

—Су түгел,—дидем мин.

—Ни?

—Арт сабагың. Типкәнче—тор.

Аңа таба борылгач, арка ягым унай жилдәге жилкән сыман ипләнде тагын. (Гәрчә жилкәнле көймәдә йөзгәнем булмаса да, тойгысы шулайрак иде булса кирәк.)

Ул:

—Тын аласы иде,—диде.

Мин тыныч кына:

—Юк инде,—дидем дә, йомшак кына итеп, портфельгә тибеп куйган булдым. Саллы булгандыр, күрәсен, чөнки аркамда—аның биштәре, ун кулымда—чемоданы. Өстәп, карлы бияләене ул оеган кыз затының битенә алмаш-тилмәш (уңлы-суллы) бәргәләп аласың әле. Шунда син кистереп:

—Тор!—дип боерасың.

—Утырып тор әле.

—Ярамый.
—Әзгә генә.
Мыегыма кунган бозны йолкып алткач, мин каттый төстә:
—Егерме бер градус. Цельсий буенча,—дидем.
Мин анын:
—Ә Фаренгейт белән?—дигәненә аны жәлеп итәр, игә китерер өчен дип көлеп жибәрдем дә мул кар кунган бүрегемне күтәреп куйдым, аннары салып, өч-дүрт мәртәбә тезем̇ә бәргәләп алгач, кигәч:
—Фаренгейтны белмим,—дидем.
Ул:
—Абсолютмы?—дип сорады.
Син бу сөйләшүнен аны арыганлыгыннан арындыру, аеру өчен кирәккә генә икәнен яхшы беләсен инде. Ә сүз алышуны дәвам итәр өчен:
—Зеро?—дип әйтеп куясын. Юри генә. Тынмаска. Сүз булсынга. Хәрәкәттә бәрәкәт өчен.
—Әйе. Әйе, әйе, нуль. Бүтән берни түгел. Син дә мин генә,—дип, ул муеным тирәли уралган яшелле-кызыллы жон шарфыма тотынды. Ныклап, сулыш алырга комачауларлык, хәтта буарлык итеп.
Мин, тоташлый жилне уздырырга теләп, кычкырмадым, ә бәлки пышылдап тагын:
—Тор!—дидем.
Ул минем шарфымны үзенә таба тартыбрак:
—Кочакла әле,—диде.—Суык.
Әйтерсен лә менә хәзер—бу салкын буранда, кайтыр юлымда мина шул гына житмәгән иде. Шулай да мин:
—Аннары,—дидем.
Ул:
—Кайчан?—диде.
—Беркайчан да.
—Син өйләнденмени?—дип сорады ул.
—Әйе.
—Балагыз да бармы?
—Бар. Балабыз да.
—Сөясенме?
—Кемне?
Ул:
—Мине түгел ич инде,—диде.
—Түгел,—дигәч, син кайтыр юлына каршы искән ургым-ургым жилне үзен аша Чулман елгасы тарафына озатасын да, тирән итеп бер сулыш алгач, күтәргәннәренне башта жилкәндә, аннары кулында кагынган шикелле барлап алгач, тагын бер—инде сонгы тапкыр, тик йомшаграк итеп:
—Тор. Бас. Әйдә. Киттек,—дип, ана буш сул кулынны сузасын.
Ул тора, баса, киерелеп, билен язып алган була. Боергач, тормыйча, басмыйча нишләсен соң ул: шунда утырып калса, аны иртәгесен бөрешеп катканы килеш узгынчы бер-бер юлчы табып алсынмыни. Яна елның беренче көнендә. Барчасының күнелләрен әллә нишләтеп. Нишләтеп дип, билгеле инде: өшетеп, ел буена тенкәп.
Торганы, аягына басканы шәпкә ун кулындагы мин кигезгән бияләйгә сарган карны авызына якынайтканы, иренен̇ә тидергәне мәлендә син анын кулына сугып аласын:
—Кирәкмәс.
—Тамагым чатнады.
—Кайткач.

Ул әле генә торган урынына борылды да, сине сискәндереп җибәреп:
—Монда йомшак иде,—диде.

Син аңа бүгенгедәй буранда, ургым-ургым искән салкын җилдә ул урынның иртәгесен нинди каты буласын, ә инде аннан кузгалгансың икән, язгы алсу-зәңгәр беренче чәчәкләрне, аннары сап-сары тавыкмы, казмы бәпкәләрен, тилгәннәрне—тагын әллә ниләрне һичшиксез күрәсеңне әйтеп тормыйсың инде. Ул үзе дә—кинәт исенә төшә—сигезьеллык мәктәбебездә миннән өч сыйныф түбән укыган "чебеш кызы" гына ич. Рәсимә бугай. Әйе, Рәсимә.

Аңа карамыйча, йөгенне, җилкәнне, кулыңны кагып иплләгәч, буранга каршы атлап китәсең.

—Әйдә,—дисең,—өйгә. Анда эш күп.

—Күп,—диде ул.

Шунда син кар дәрьясының кыл уртасында капылт туктыйсың да, өстән кигән мамык, җылы чалбарыңның каеш пряшкәсен ычкындыргач, аяк киемең аша гына салып, аңа сузасың:

—Ки.

Ул кия белми—булышасың: кызыңның трусигын алмаштырганың сыман гына итеп. Аның эчке киеменме, тагын нәрсәләрен бөтереп, җайлап, әлеге җып-җылы ыштанга тыкканда авылыбыздагы туган өебезнең җылы миченә тәнеңме, җаныңмы белән сарышасыңны гына уйлыйсың. Аннары инде барасың да барасың. Юл бер генә. Бүтәне юк.

Инде менә эндәшмичә-нитмичә, үзара һичбер сүз катмыйча, уңга борылып, таш күперне узасың, тып-тын (җил-буранны ис-оска алмасаң) авылына кайтып җитәсең, урамы буенча баргач, аны үз өйләренә хәтле озатып куясың. Ә бу мәлдә үз өендәге япа-ялгыз әнкән, ак мәче, абзардагы буаз сыер, өч сарык, тыннарын бүлеп, сине көтеп тормый ич әле. Көтеп дип... чамалыйлардыр, анысын кем белә. Чамаламасалар кайтып торасыңмыни ул?

Без аларның капка төпләренә килеп җиттек. Шундагы кар япкан коелары капкачын каерып ачып, чиләкне бияләем белән тыштан-эчтән сөрткәләгәч, чыгырны борганда да боларның этләре нигәдер өрмәгәнен искәреп куйдым. Өч-дүрт йотым су эчкәнемнән соң мин аңа:

—Хәзер ярый,—дидем.

Дөнья ап-ак иде. Тып-тын. Ә мин аның миннән соң голт-голт итеп су эчкәнен рәхәтләнеп тыңладым.

Ул:

—Тәмле,—диде.

—Тәмле, Рәсимә,—дидем мин.

—Мин исендәмени, Фәрхәт?

Җавап бирмәдем.

Син фәкать аның кое төбендәге рюкзагына, чемоданына, күтәреп кайтканыңны инде тәмам онытканың хәлдә ымлап, ишарәләп:

—Нигә болай авыр төялеп кайттың соң әле?—дип сорыйсың.

—Азык-төлек кирәк!—диде ул.—Иртәгә әнинең өчесе.

# Фирдәвес Галиева

## ТОЗАК

Рәфыйкъны Казан төзелеш институтын тәмамлап кайткан яшь белгечне, районлагы бер колхозга төзүче-прораб итеп билгеләделәр. Әлеге колхоз «Маяк» атлы, районда хәлле хуҗалыклардан булып, бирелә авыл хуҗалыгы өчен республика буенча әһәмиятле корылмалар төзү бара иде. Рәфыйкъны һәм аның гаиләсен колхоз үзәге Яктыкүл авылында яхшы каршыладылар—бакчасы, абзар-курасы булган шактый иркен бер йортка урнаштырдылар. Кечкенә Динәгә балалар бакчасында урын табылды, хатыны Мәдинә мәктәпкә укытучы булып эшкә керде. Рәфыйкъ баш-аягы белән эшкә чумды төзелеш планнарын ачыклады, төзелеш бригадаларына эш күләмен билгеләү, сметалар төзү, кирәк-яракларны кайгырту да аның вазифасы иде. Колхоз рәисе, кырык биш яшьлек таза, шәп гәүдәле Альберт Фәезович, Рәфыйкъка беренче көннән үк ачык йөз күрсәтте. Ул ана, үзенчә олылаптыр инде, Рәфыйкъ Сәлимович дип эндәште, эшендә һәртөрле ярдәмне күрсәтергә әзерлеген белдереп торды.

Көннәрдән беркөнне, дөресрәге колхозга төзелеш бианалары өчен түбә япмалары кайткач, колхоз рәисе аны үз бүлмәсенә чакырды. Кул биреп күрешкәч, утырырга ишарә итте.

—Рәфыйкъ Сәлимович, бер эш бар бит әле. Биш мен данә шиферны, яраксыз дип, акт белән рәсмиләштереп, «урнаштырырга» кирәк. Үзен беләсен, эш буенча төрле мәсьәлә килеп чыга, аларны хәл итәр өчен районда кирәкле кешеләрнең күнелләрен күрергә туры килә. Ну, үзенә бер 500 тәнкә акча керер, мина да. Эчне тишмәс бит?! Вакыты житкәч, төзелеш бианалары өчен кирәкле шиферны башка жирдән табарбыз. Әле бит, бианаларнын нигезе генә салынган...

Рәфыйкъ беравык дәшми торды. Аннан, дулкынлануын яшерергә чамалаптыр инде, тавышына аерым бер кырыслык биреп:

— Альберт Фәезович, төзелешкә кайтарылган шиферларның һәммәсе төзек, куллануга яраклы, саналган. Бары тик әлеге төзелеш өчен тотылачаклар.

—Ярый алайса,—диде Альберт Фәезович.—Мина, рәис кешегә, хуҗалык мәсьәләләрен төрлечә хәл итәргә туры килә. Кызганыч, мине анларга теләмисен.

Нәрсә бу? Рәиснен аны яна кеше буларак, сынап карарга теләвеме? Элеккеге елларда Рәфыйкънын колагына рәис турында «унган, булган житәкче» дигән сүзләр кергән иде. Дөрес, аннан сон байтак вакыт үткән үтүен... Әлегә кадәр бары тик эш белән мәшгуль булган Рәфыйкъ мондый сөйләшүдән сон тирә-юньгә бераз игътибар итәргә булды: кемнәр белән эшлисен, аралашасын белеп торыр өчен.

Мәдинә мәктәптә эшләрен әйбәт кенә башлап жибәргән иде, сонгы вакытларда мөдир белән аның никтер «борчагы пешми башлады», һәрхәлдә, ул берничә кат иренә мөдирнен начар мөнәсәбәтеннән зарланып алды. Бервакыт, Мәдинә, баласы авырып китү сәбәпле мәктәпкә бара алмаган иде. Шуны сәбәп итеп, дәресләрен үткәрә торырга кеше табылса да мөдир Мәдинәне тупас шелтәләгән. Имеш, Мәдинәнең календарь планында тәрбияви чаралар да сыеграк күрсәтелгән. Дәресләренә дә мөдир башкаларныкына караганда

ешрак керә икән. «Бәлки бу очраклы хәл түгелдер»,—дип уйлады Рәфыйкъ.

—Тупас бер кеше инде,—диде Мәдинә Рәфыйкънең бу турыда соравына каршы.—Олы яшьтәге укытучыларны үзе яныннан елатып чыгара ул. Берәү дә яратмый аны.

—Яратмаса яратмый инде,—дигән иде ул чакта Рәфыйкъ.—Әле шул авылда яңа мәктәп төзү мәсьәләсен күтәргән, рәис белән уртак тел табып, төзелешне башлаткан. Үзе дә килеп, төзелешне карап китә, киләсе уку елына әзер булырмы—кызыксына. Һәрбер кеше фәрештә булмас инде ул. Әгәр сиңа каныга икән, дәшмә. Бер кычкырыр, ике, аннан туктар. Иң әһәмиятлесе—эшеңне әйбәт алып бар, исәнлеген дә какшамас, җаның да тыныч булыр.

Мәдинә иренең эшләре җайлы гына бара дип уйлый иде, баксаң, аның эшендә дә каршылыклар җитәрлек ахры: төннәрен Рәфыйкъ тиз генә йокыга китә алмый, нәрсәләрдер уйлап, уфылдап чыга. Әллә Рәфыйкъне чит-ят күрәләрме икән бирегә?

Мәдинә кичке якта пәрәмәч пешерде, күршесе Хәлимә апаны чәйгә чакырды.Хәлимә апаның озак еллар авыл советында эшләве, барча авыл хәлләреннән хәбәрдар булуы Мәдинәгә билгеле иде.

—Хәлимә апа,—диде Мәдинә күршесенә чәй ясап,—кайчаннан бирле бирегә яшибез, сез әле безнең өйне кереп күргәнегез юк. Күрше, имеш...

—И-и, Мәдинә, бигрәк тәмле пәрәмәчләрең... Бик әйбәт урнашып киттегез инде. Эшендә ничек соң,ияләштеңме бераз?

—Үз кеше инде мин анда, Хәлимә апа. Әле, бергәләп мөдиргә каршы «көрәшәбез». Бик усал кеше икән, гаделлек тә чамалы үзендә. Берәүләрдә бик күп сәгатьләр, ә берәүләрдә бөтенләй әз. Минем нибары уникe сәгать, атна буена.Ә бит мин татар теле буенча да белгеч. Татар телен Нажия апа укыта, тарих укытучысы ул үзе. География буенча да аның сәгатьләре бар, атнасына егерме биш сәгать дәресе аның.

—Нажия бит колхоз рәисенең кардәше. Монда инде, Мәдинә сенелем, тәртипләр күптән билгеләнгән. Мөдир белән колхоз рәисе әшнәләр, шулай ук районлагы җитәкчеләр дә, бар да бер чыбыктан сөрелгән. Дөрес, күптән түгел районга яңа башлык килде, элеккесен, Госман Зариповны, кыңгыр эшләре өчен районнан кудырттылар. Хәзерге башлык, Гарифҗан Сабирович—Мөслим ягыннан килгән, чынында ниндирәк кеше үзе—ачыклап бетерә алганнары юк ди. Безнең районда шулай инде ул, сенелем—һәрбер килгән җитәкче тирә-юненә үзе белгән, ышанган кешеләрне җыя: районда һәммә җаваплы урында кем эшли дисәң, ул башлыкның һәрбер сүзенә «баш өсте» дип торучы кеше була. Бу районда гадел, белемле хезмәткәрләр озак тоткарланмый, аларга эшләргә юл бирмиләр. Шулай булгач, районда яхшы якка үзгәрешләрне кайдан көтәргә? Синең ирең Рәфыйкъ югары белемле төзүче, ә аның нәчальнигe—урта махсус белем белән. Элекке башлык Госман Закировның «үз» кешесе—бер куштан адәм. Тик шунысы ачык—әлеге тәртипне беркем дә үзгәртә алмаячак. Элек-электән шулай килә ул, шулай барачак та. Алай-болай каршы әйтеп, сүзгә килсәң, эшеннән куачаклар. Шуңа да, Мәдинә сенелем, барына риза булып, артыгын күрмичә, белмичә, эшеңә йөрe. Барыбер берни дә кыра алмаячаксыз.

—Хәлимә апа, әллә ни кырырга җыенмыйм мин, әмма олырак укытучылар кызганыч инде. Бер ишесенә озакламый пенсиягә китәргә, ә аларга сәгатьләрне кыскарталар. Эчегез әле, Хәлимә апа. Үзегез исән-сау яшисезме соң? Балалар ничек?

—Олы малаебыз Әлмәттә эшли, нефтьче, институт тәмамлады. Әле һаман гаиләсез. Кызыбыз Түбән Камада яши, кияүдә. Ике оныгыбыз бар. Абзыең гомер буе колхозда хисапчы булып эшләде бит инде. Быел язга, Ходай язса, пенсиягә чыга. Үземә дә «лаеклы ялга» китәргә күп калмады инде—ике ел.

Үзеннең әти-әниең, каенана-кайнаталарың исәннәрме?

—Рәхмәт, исән-саулар.Аллагы бәйрәмдә әти-әниләрнең хәлен белеп килергә ниятлибез.

—Ярый, Мәдинә сенелем, чыгыйм әле мин. Абзыең да мине югалткандыр. Кешедә озак торганны яратмый инде менә. Сиңа өчен бик зур рәхмәт, үзең дә безгә кереп утыр, чакырганны көтеп торма.

—Ярар, Хәлимә апа, бездән калмас,күршеләр ич без.

Кичке аш янында Мәдинә күршесе сөйләгән яңалыкларны иренә житкерде. Рәфыйкъ, «сүз җыеп йөрисең »,—дип хатынын ачуланса да, әлеге хәбәрләр аның шик-шөбһәләренә шактый ачыклык кертте. Ә рәис белән бүгенгә сөйләшү?

Альберт Фәезович, Рәфыйкъне бүген идарәдә күреп алып, бүлмәсенә чакырды.

—Кара әле,—диде ул,—миңа шундый сүзләр ишетелде: мәктәп мөдире Сәет Вәлиевич укытучыларны җәберли икән. Кыскасы, коллективта ызгыш-талаш... Тәрбиячеләр өчен килешкән нәрсә түгел инде бу. Район каршында да мәктәпнең абруен төшерә торган хәл. Синең хатын да укытучы бит?! Әйт үзенә, район мәгариф бүлеге исеменә жалу язсыннар. Озакламый яңа мәктәп төзелә, анда үзара тату, әйбәт тәрбиячеләр эшләсә иде дим мин.

—Соң, Альберт Фәезович, минем вәкаләт төзү эшләренә генә кагыла бит. Ничек итеп мәктәп эшләренә тыкшыныйм ди мин?! Укытучылар үз мәсьәләләрен ничек кирәк тапсалар, шулай хәл итсеннәр...

Рәфыйкъ әлеге хәлләргә хатынын катнаштырмаска, үзе дә читтә калырга карар кылды. Бер көнне, эштән кайткан жиренә Мәдинә өйдә юк иде, Рәфыйкъ борчыла калды: алай-болай, кинәшми-нитми үзлегеннән берәр ахмаклык эшләп куймагае аның хатыны. Бәлки, жалу кәгазе язылгандыр, ә Мәдинәнең имзасы анда беренче булып куелгандыр?

Ул хатынын көтә башлады. Мәдинә күренмәде. Рәфыйкъ кечкенә Динәне балалар бакчасыннан алып кайтты, ашатты, йокларга яткырды... Кичке сәгать сигез тулды, тугыз... Инде хатынын эзләп китәргә җыенганда, Мәдинә үзе кайтып керде.

—Нәрсә булды синең белән?! Дөньяны онытып кайда йөрдең?!

—И-и, Рәфыйкъ, ачуланма, элек тыңла.

—Ашап алыйк әле, көне буе ач йөрдем бүген.

—И-и, бәгърем, хәзер ашатам үзеңне.

Мәдинә кулларын юып, тиз-тиз өстәл хәстәрләде, ире ашаган арала ана яңалыкларын сөйли башлады:

—Укыту тәмамланып, өйгә таралышырга җыенганда, Рәкыя апа килде, һәммәбезне чәйгә чакырды. Без әлләни кыстатып тормадык, өеребез белән киттек—көн дә чәйгә чакырып тормыйлар ич. Анда табын корылган иде—сыйландык. Сәлимә апа Рәкыя апага мөдирдән зарланып алды, аннан китте шау-шу. Рәкыя апа чәйне ясап чыгара тора, без эчә торабыз. Альберт абый кайтып керде. Сәлимә апа анарга да «бездә шундый-шундый вакыйгалар»,—дип, хәлләрне сөйләп ташламасынмы. Янәсе, Сәет Вәлиевич безне соң чиккәчә житкерде, менә җыйнаулап жалу язарга булдык. Мин инде тыңлап кына утырам, мондый гаугa кубар дип кем уйлаган. Ә Альберт абый әйтә: «Сез дөрес эшлисез, кайчак, берәүләргә вакытында күргән чара әйбәт нәтиҗә бирә». Ә жалу язу эшен миңа йөкләделәр никтер. Мин риза булдым инде, бар да шуны теләгәч.

—Яздың дамы?

—Ю-у-ук. Шул көннәрдә язып, Сабир Дәүләтовичның үз кулына тапшырырга булдык.

—Их, кәмитчеләр икән үзегез,—диде Рәфыйкъ, хатыныннан көлеп.

—Ник алай дисең, Рәфыйкъ?!

—Соң, юләргә дә аңлашыла ич, район түрәләренә Альберт абзаң сине, мине әләкче, начар кешеләр дип күрсәтмәкче, хур итмәкче була. Рәкыя апаң да бәлеш ашатырга вакытны бик белеп чамалаган. Сиңа сүз шул: жалуны әзерләгез, әмма син язма, профком җитәкчегез дә, авыл киңәшмәсе рәисе дә, мөдиргә үпкәле укытучыларыгыз—барчасы кул куйсын, ә син ахырдан гына имзаңны куй. Башлык янына җыйнау керегез, кайдан килүегезне, ни өчен йөрүегезне аңлатыгыз, жалу кәгазен кулына үзегез тапшырыгыз.

Рәфыйкъ колхоз рәисенең үзенә карата тозак әзерләвен бөтен күзәнәге белән тойды. Җитмәсә, астыртын рәвештә.Тыштан ачык, рәхимле кеше булып сөйләшә, ә эчтән? «Ниндирәк буласы икән боларның алдагы адымнары»,—дип баш ватты ул көннәрдә Рәфыйкъ. «Ә ничек булса да үзләренең чын йөзләрен ачасы, хур итәсе иде». Уйлый торгач, Рәфыйкънең аңына барып җитте—бирелә район мәгариф бүлегенең дә «тырышлыгы» бар... Мәктәп хәлләре өчен ул җавап бирә, соңгы сүз аңардан чыга ич. Вакыйгалар, мөгаен, болай буласы: Мәдинә, хезмәттәшләренең үтенүе буенча район үзәгенә килә, башлык янына керә, үзенең кемлеген әйтә, нинди эш белән йөрүен сөйли. Башлык мәгариф бүлеге мөдирен чакырта, аңарга әлеге мәсьәләгә ачыклык кертергә куша. «Ә-ә,—ди Җәүдәт Зәкиҗанович,—тагын шул Гыйззәтуллинамы?! Гел оршыш-талаш тудырып йөрүче нәрсә ул! Туйган инде аның жалуларыннан! Аның ире дә, фәлән-фәләнеч, колхозда прораб булып эшли, юньле адәм түгел! Кеше котыртып, жалу язып ятучылар бит алар!»

«Соң,—ди беренче,—чара күрегез!» Җәүдәт Зәкиҗановичка шул гына кирәк тә! Шул сәгатьтә фәрман язып, Мәдинәне эшеннән куачак, билгеле. Соңрак, башлыкта шундый ямьсез фикер тудыргач, мине дә эштән селтәрләр. Колхоз рәисенең һәр сүзен җөпләп торучы прораб табылмасмени?!

Вакыйгалар, чыннан да, Рәфыйкъ уйлаганча башланып китте. Мәдинә һәм биш-алты укытучы дөрестән дә, жалу кәгазен алып район үзәгенә киттеләр. Тик, элек, жалу кәгазенә профком җитәкчесеннән дә, авыл киңәшмәсе рәисеннән дә, таләп итеп диярлек, кул куйдыртканнар. Район башлыгына, килгәч, мәктәп мөдиренең үз-үзен тупас тотуына чара күрүне сораганнар. Аның кайбер карарларын «гаделсезлек» дип атаганнар, әлеге жалуны да кычкырып укыганнар, барча кул куючыларны исемнәре белән атап, өстәлендә калдырганнар.

Аннан соңгы вакыйгаларны Рәфыйкъка хатыны Мәдинә, ә Мәдинәгә аның танышы—башлыкның сәркатибе сөйләгән. Кыскасы, алар чыгып киткәч, башлык мәгариф бүлеге мөдирен чакырткан. Тегесе нәрсәләр сөйләгәндер, тик беренченең йодрык белән өстәл сугуы, аты-юлы белән Җәүдәт Зәкиҗановичны сүгүе барча бүлмәләргә ишетелеп торган.

—Нинди Гыйззәтуллина!—дип кычкырган беренче.—Монда бөтен мәктәп хезмәткәре, колхоз вәкилләре булып китте! Бар, тиз ачыкла мәсьәләне, һәм чара күр!

Җәүдәт Зәкиҗановичның тирләп пешкән йөзен Мәдинәнең танышы үз күзләре белән күргән, имеш.

Икенче көнне, Рәфыйкъ хатыны белән өендә, төшке ашка кайткач очрашты. Мәдинә мәктәптән борчулы кайткан.

—Бүген кич җыелыш була бездә. Җәүдәт Зәкиҗанович үзе килә икән. Куркам мин, Рәфыйкъ.Ну, әләгер инде безгә!

—Курыкма... Сүз катма, ни әйтсә дә тыныч кына тыңлап тор. Иң ахырдан «ник бу эшне эшләдегез» дип сорар. Ә син тор да, гаепле тавыш белән «безгә Альберт Фәезович кушты» диген. Башка бер сүз дә әйтмә.

Кич, Мәдинә өенә кайткач, иренә көлә-көлә җыелыш хәлен сөйләде.—

Уф-ф,—диде ул,—вәт кыздырды безне Җәүдәт Зәкиҗанович!—Ул акырды, ул сүкте! Гомердә булмаган хәл,—ди,-—өйдәге чүпне читкә чыгарасыз,—фәлән-фәсмәтән... Ник үземә килмәдегез?!—ди.Тордым да урыннан, әкрен генә : «Безгә бит Альберт Фәезович шулай эшләргә кушты»,—дидем. Коелды да төште, чыгып ук китте, шуннан.

—Менә күрдеңме инде?! Үзләре ничек көлкегә калды! Ә без синең белән үз көебезгә, тыныч кына эшләп йөрибез, җан тыныч, андый-мондый борчылыр сәбәп юк.

—Ну, Рәфыйкъ! Ничек алдан күрә белден син бу хәлләрне?!

—Дөнья өйрәтә икән ул, матурым...

Әлеге хәлләрдән соң «Маяк» колхозында хәлләр тагын да кискенләште. Теге җыелыштан соң Җәүдәт Зәкиҗанович туры рәиснең өенә киткән, имеш, үзен пыр туздырып сүккән, орышкан ди, дөрес булса. Әле яна «мин кем?»—дип, күкрәк киереп йөргән Альберт Фәезовичне бер атна эчендә эшеннән азат иттеләр. Шул, мөнәсәбәтләр бозылу нәтиҗәседер инде.

Рәфыйкъ бу хәбәрне ишеткәч һәм идарәдә рәиснен үзен бик төшенке кыяфәттә дә күргәч, бер ара кызганып та куйды үзен. Шул ук көнне, кичен, эштән кайтканда күрше Закир абзыйлар капкасы буенда ул рәиснең машинасын күреп алды. Ул арада капка ачылды һәм Альберт Фәезович үзе күренде. Әллә Рәфыйкъның эштән кайтканын көтеп торган?...

—Рәфыйкъ, әйдә Закир абзыйларга керик әле... Бер ярты бар иде, сөйләшәсе сүзләр дә бар...

—Әйдәгез үзебезгә, Альберт абый. Минем үземдә дә бар ул.

—Әйдәле, әйдә... Әйдә инде...

Ул, кыстап, Рәфыйкъне күршесе өенә алып керде.

—Утыр әле, Рәфыйкъ.—Ул хуҗа ападан стаканнар сорап, үзенә һәм Рәфыйкъка аракы салды.

—Шулай хәлләр, туган. Дөньялар ничек үзгәреп тора, ә?! Бүген бар син, иртәгә—юк. Бүген кеше син, иртәгә—нуль. Бүген кирәк син, ә иртәгә, кирәгең калмагач... Ул аракысын «гөлт» итеп эчеп җибәрде.

—Селтәделәр... Көтмәгән идем. Ә бит шул ук Җәүдәт миңа муеннан бурычлы...

—Кая китәсез соң, Альберт абый?

—Бер туза башлаган колхозны йөкләделәр. Баулы районында. Рәфыйкъ, әйдә бергә китик, ә? Сиңа да эш бар анда, бар...

—Юк, Альберт абый, бер урынга ике кат тибә торган гадәт юк минем.

—?!

—Менә син, Альберт абый, мине берни аңламый дисең. Ә мин барын да күрәм, аңлыйм. Синдә кемнәргәдер үпкә, рәнҗү... Ә кем гаепле? Үзең үк түгелмени? «Кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең»,—дөрес сүз бит?...

Альберт Фәезовичның аңына Рәфыйкъ әйткән сүзләр яңа барып ирешә бугай. Ул күзләрен зур ачып, Рәфыйкъка карап торды. Аннан, кисәк урыныннан торып, өйдән чыгып китте. Машинасына утыругa, көчле газ биреп, тузан туздырып китеп тә барды.

Рәфыйкъ өенә кергәч, хатынына бер чиләк су җылытырга кушты. Кичләрен коенып тән сафлыгын тою ана рәхәт.



Фәрит
Габдерәхим

# АНТКА ТУГРЫ КАЛСАМ...

## Үзе сайлый

**Песнәккә охшаган—белмим
Исемен дә бу кошның.
Матурлыгы бер хәл әле,
Сайравы ала һушны.**

**Үзе сайлый ботагын да,
Көен дә үзе сайлый:
Табигатьнең җан авазы—
Цензор да тыя алмый.**

## Минме тузан?!

**Чак язмыйча калган акылыннан,
Үткән гасыр җитте ахырына.
Дөбер-шатыр ауды корылмалар—
Мәңге торачак дип корылганнар.**

**Китте очып тәхеттәге сүзләр,
Томалана төште шымчы күзләр.
Тын алгысыз әче тузан тузган,
Чәчи-чәчи иртәгәмә узам.**

**Килде бер өн: «Син үзең дә тузан!»
Минме тузан?! Юк, башкача түзмәм!**

## Тарихыбыз. Кыйпылчыклар

**Дала. Төркиләр. Каганат.
Балбал. Күлтәгин. Әманәт.**

**Итил. Урал. Болгар. Фазлан.
Аллаһ. Коръән. Мәчет. Азан.**

Монгол. Татар. Чыңгыз. Батый.
Алтын. Урда. Сарай. Балкый.

Мәчет. Чиркәү. Ярлык. Кодрәт.
Илләр. Сәүдә. Тәртип. Шөһрәт.

Тәхет. Мөлкәт. Ызгыш. Ваба.
Аксак. Тимер. Урда. Ава.

Ханлыклар. Күп. Казан. Ялгыз.
Кан. Яшь. Коллык. Иван. Явыз.

Империя. Тәре. Кяфер.
Чукыныгыз. Себер. Кабер.

Инкыйлаб. СССР. Алга!
Мохтарият. Ирек. Ялган.

Урысия. Сәмруг. Исән.
Татар. Богау. Игәү. Кисә...

## Шатланасы иде

Чит-ятлардан күрмик, империя
Үз явызлыгыннан шартлады.
Чит-читләре шактый җимерелде.
Кем—ничектер, ә мин шатландым.

Зур кисәге аның исән калды,
Империя инде барыбер...
Их, бакыйга китеп бармас борын,
Шатланасы иде тагын бер.

## Шаклар катарлык

*«Тотса Мәскәүләр якаң».*
Г. Тукай.

Гел бер төш күрәм соңгы айларда.
Урап кайтамын әллә кайлардан.

Явыз Иванны сагалап торам,
Каптырмак булып планнар корам.

Мине ерактан ала да күреп,
Бикләнә тизрәк кирмәнгә кереп.

Опричниклары капка төбендә.
Булган юк әле аның өнендә.

Казан бүреген бик еш кия, ди.
Без исән!—шуңа җаны көя, ди.

«Ошбу кавемнең саудым акылын,
Сүндереп тордым йөрәк ялкынын.
Баш бирмәс татар үрчегән кабат.
Татарвага дам последний сабак!»

Куак төбенә утырдым арып.
Тавык төшенә керә, ди, тары.

Чү! Кемдер килә, алартып күзен.
Сөйкемле Иван үзе бит, үзе!

Кысталган, ахры: төшеп атыннан,
Тиз-тиз атлады куак артына.

Җан дускаемны шунда каптырдым,
Өне чыкмасын—чүпрәк каптырдым.

Аты сыртына бәйләп салдым да
Китердем аны халкым алдына.

Акты каннарың, түктең яшьләрең,
Хөкем итегез, милләттәшләрем!

Шул чак Иваным сузды паспортын,
Тирә-ягына карый астыртын.

Паспортын алып укыйм: «Сталин...»
«Даһи атабыз, син гел истә!»—дим.—

Мөлдерәп карый яшьле күзләрем,
Кабатлыйм эчтән Тукай сүзләрен.

Коелып төштем—шаклар катарлык:
Юкмыни миндә гаярь татарлык?
Төштә булса да...

## Мөхәррир вә шагыйрь

Керде шагыйрь нәшриятка кыяр-кыймас,
Шигырьләре—папкасына сыяр-сыймас.

Мөхәррирнең шигърияттә теше төшкән,
Күз йөгертеп шигырьләргә өстән-өстән,

Алды сайлап арадан ул «Китмибез!»не,
Фикерләрен (белгеч ләса!) тиз-тиз тезде:

«Төркиягә беркем кумый, бу—чи ялган.
Дөрес, берәү кумак була монголларга...

Рифмаң белән ритмың бигрәк аксый, туган.
Шигыреңә гарәп, урыс сүзе тулган.

Белмисеңдер—нинди була шигъри сөйләм.
Һич югында, Ркаилдән[1] бераз өйрән!

Берлек әгъзасымы? Юк, түгелсең бугай:
Ул әгъзалар арасында юк Г. Тукай.

Нәшриятта эшләр безнең ифрат тыгын.
Өр-яңадан эшләп китер җыентыгың».

[1] Шагыйрь Ркаил Зәйдулла күздә тотыла.

## Буран әйтеп торды

Мин бу җирләрдә бәхетле идем.
Шуңадыр—монда мин кабат килдем.
Син бүләк иткән нурлы көннәргә—
Үткән бәхеткә башымны идем.

Озаттым инде җәйләр-көзләрне,
Кар күмеп киткән безнең эзләрне.
Котырды буран. Ул әйтеп торды,
Мин язып алдым ошбу сүзләрне.

## Кайсы тел?

Заманында ошбу телдә
Язганнар ярлык.
Ошбу телдә оран очкан
Һаваны ярып.

Бермәл катыйль ошбу телнең
Юк иткән илен.
Уйлаган: була үтереп
Иле юк телне.

Катыйль—кансыз, миһербансыз:
Аскан вә кискән.
Чукындырып та караган,
Тел һаман исән!

Сүгенә катыйль...

Бу тел кайсы тел?

## Шул җитә

Инде хәзер күп кирәкми миңа:
Антка тугры калсам—шул җитә.
Җир шарына ятып, көпә-көндез
Йолдыз күрә алсам—шул җитә.

Килер буыннарга мең шигырьдән
Бер шигырем калса—шул җитә.
Күзем йомылганда татарымның
Бәхиллеген алсам—шул җитә.

**Редакциядән:**
***Уфада яшәүче татар шагыйре, журналыбызның күптәнге авторы Фәрит Габдерәхимгә бу айда 75 яшь тула. Аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.***



Шамил
Маннапов

# ГОМЕР ҮРЕНДӘ УЙЛАНУЛАР

***

**Меңъеллыгын Казан бәйрәм итте,**
**Самолетлар очты күгендә.**
**Чечня хәле шунда искә төшеп,**
**Хәвефле уй килде күңелгә.**

**Очкычларның хәтәр тавышыннан**
**Күк пәрдәсе кат-кат киселде.**
**Кемдер безгә корыч бармак янап:**
**«Онытылмагыз!..»—диде шикелле.**

**Бәйрәмендә Казан кайнап торды.**
**Шатлык катыш хәвеф күңелдә:**
**Төрле телдә гөрләп торган кала**
**Минеке дә кебек, түгел дә...**

***

**Яшибез ярты-йорты Хаклык белән,**
**Яшибез ярты-йорты шатлык белән,**
**Яшибез шулай, ярты-йортыларга бай—**
**Урталай өзелгән еландай...**

**«Өметегезне җуймагыз шулай да,**
**Өметсез ул—шайтан гына»—дигәндәй,**
**Төнге күктән карый Җиребезгә**
**Яңа туган Ярымай...**

***

**Гомер узган саен күңел сүнә бара,**
**Шатлык-ямьнәр кими бара яшәештә.**
**Гомерем азагына җитәмме икәнни?—**
**Мәрхүм газизләрем бик еш керә төшкә.**

***

**Гаиләдә төпчек бала булу—**
**Әйбәттер дә...**
**Тик шунысы бәла икән:**
**Килә бер көн,**
**Барысы өчен ялгызыңа**
**Моңланырга кала икән...**

* * *

Элек пәйгамбәрләр, вәхи алып Ходайдан,
Өммәтләренә аңлатканнар яшәү мәгънәсен.
Бу изге эш—безнең заманда
Шагыйрьләргә калды микән әллә соң?

* * *

Бу дөньяның ачы-төчеләрен
Татыганнар шуны беләдер:
Аптыраган адәм кайчак елый,
Артык аптыраган—көләдер.

* * *

Аптырыйбыз: нигә безне язмыш
Аерып, төрле-яры тараткан?
Күр, Галәмдә йолдызларны да Ходай
Бер-берсеннән ерак яралткан...

* * *

Дөнья арбасыннан төшеп калып,
Көпчәгеннән аның тапталма...
Кайбер түбән, вак җаннарга карап,
Явызланма, җаным, вакланма.

* * *

Яшьлегеңдә югарыдан торып,
Яшәсәң дә хыял-уй корып,
Картлык баскач, башың җиргә иелә,
Язмышыңа инде буйсынып...

* * *

Кешегә ышанырга кирәк, дибез,
Бүген моңа шик бар шулай да:
Башына бәла килмәгәндә күпләр
Ышанмый бит... хәтта Ходайга!..

* * *

Үзен кече санавыннан беләм
Олы җанлы адәмне:
Йолдызлар да күренә ләса күктә
Бары тәңкә кадәрле.

* * *

Әй, замандаш,
Телең булсын безсез генә,
Безсез булмый икән, тик тор сүзсез генә.
Чәнчү-төртү җанны яралый бит,
Узмый әсез генә.

* * *

—Үзгәртеп кору дисезме?—
Ни ул—үзгәртеп кору?
—Үзгәртеп кору шул, кабәм,
Уртак йортны җимерү һәм...
Үзеңә ташып тору.

***

**Тормыш шундый:**
**Җил-давыллы**
**Дәрьядагы кебек,**
**Чиста агым тирәндәрәк,**
**Өскә чыга күбек...**

***

**Дөньяда талантлыларны**
**Бәяләүче ник сирәк?—**
**Талантны бәяли белгән**
**Талантың булу кирәк!**

***

**Тормасана миңа кырын—яның белән,**
**Әйләнсәнә, җаным, җаның белән...**

***

**Кем кычкырды:**
**—Мәхәббәт юк! Ю-у-ук, ю-у-ук!—диеп?**
**Сүзең хактыр, ләкин үзең өчен генә.—**
**Дөрестән дә, Мәхәббәт юк, була алмый,**
**Булмый икән ул нурлы хис үз күңлендә.**

***

**Нишлим инде,—**
**Назларымны**
**Алырга теләмәдең,**
**Мәхәббәттә януымны**
**Таныргa теләмәдең.**

**Белмим инде, кемгә генә**
**Син шундый тугрысыңдыр.**
**Үзең дә аңламый-нитми,**
**Син—минем заяга үткән**
**Гомремнең угрысыдыр...**

***

**Яши-яши хисләр кырыслана,**
**Иңгә баса төрле мәшәкать.**
**Игътибарым сиңа җитми икән,**
**Үпкәләмә инде, Мәхәббәт.**

***

**Наздан бозылмый хатын-кыз,**
**Ул бары тик яхшырачак.**
**Синең назны балаң аша**
**Киләчәккә тапшырачак.**

***

**Сине кире каккан тәкәббернең**
**Каршысына барып тезләнү—**
**Егетлекме? Юктыр, бу бары тик**
**Мәхәббәттән хәер теләнү...**

***

Мәшәкатьле борчулары белән
Тагын бер көн узды.
Уфтандым.—
Болай да бик кыска гомер җебе
Бер сапламга янә кыскарды...

***

«Бу тормышта усал булу кирәк»,—дисең,
Усаллыкны җанга ник салыйк?
Болай да бит инде Җиребездә
Яхшылык—аз, азды—усаллык...

***

Гаҗәпләнмә хөрт җырлар күбәйде, дип,
Каян чыгып тора, дип, халтурачылар?—
Җирдә дә бит әледән-әле булып тора
Адәмнәрне гарык иткән су басулар.

***

—Яшьрәк чакта ягымлы иде хатын,
Өлкәнәйгәч—шырпы телле нигә?
—Йомшак каен чуклары да көзен
Әйләнә бит... каты себеркегә.

***

Башкаларны гаепләве җиңел,
Ә бит, иркәм, әгәр аңласаң,
Башкаларны кичерү кыен булмас,
Үз хаталарыңны барласаң...

***

Сиңа ихлас гозерем шул, Ходаем:
Гомер юлым намус белән узаем,
Явызланмасын иде телем, күзләрем,
Ташка әйләнмәсә иде йөрәгем.

***

Газиз кешем!
Синең өчен даим
Мин Ходайдан шуны гозерлим:
Гомерләрең булсын бәхетле, дим,
Бәхеткәең булсын гомерле.

***

Мәхәббәттә хыянәткә барсаң,
Сөйгәнеңнән кичерү юк икән.
Ахирәттә тәмуг була, диләр,
Тәмуг бу дөньяда ук икән.

Хыянәт ярасы төзәлсә дә,
Әрнетүе аның һич бетмәс.
Гафу сораулардан файда булмас,
Тел кичерер,
Йөрәк кичермәс.

***

Башкалардан киңәш сораганчы,
Йөрәгеңне тыңлый бел генә:
Акылның бит уе төрле-төрле,
Ә йөрәкнең уе—бер генә.

***

Кыш башы бу,
Җанга салкын иңә...
Тәрәзәдә ап-ак абагалар.
Алар сүзсез генә: «Туңабыз,—дип,—
Өйгә кертегез...»—дип ялваралар.

***

Көздән—кышка таба
Көн кыскара бара,
Кими ул минутлап булса да.
Гомерләр дә шулай
Сиздермичә уза,
Туктатырга аны юк чара...

***

«Замананы авыр, диләр,
Кемнәр үлчәп караган?»—
Халкыбызның шушы җыры
Хәтергә кайта һаман.

Замананың авырлыгын
Үлчәргә була мәгәр:
Замананың авырлыгы—
Адәмнәрнең бер-берсенә
Дорфалыклары кадәр...

***

Төрлечә кузгатып була
Дулкынны агымсуда:
Җылы гына җил белән дә,
Һәм... таш атып та була.

Ә син күбрәк ташлар аттың
Күңелем дәрьясына.
Сак бул! Ярсытма дәрьяны,—
Гарык булырсың суда...

***

Әллә нигә эч пошуы алса,
Яшәү ямен җуйса бу җаным,
Искә алам халкым гыйбрәтләрен,
Һәм тыңлыйм мин халык җырларын...

***

Ходай адәмнәрне, бу Җирдәге
һәр җан иясе кебек,
Парлы-парлы итеп яралткан.
Моң-зарларны, кайгыларны күбрәк
Парсыз калганнарга тараткан.

Ялгыз кеше—ул җилкәнсез көймә,
Тормыш җиле аны
Кая тели—шунда сөрә...

***

Гомер озынлыгы, вакыт бирәмлеге—
Адәм аша узган ризык ул.
«Ризыгы беткән...»—диләр икән,—
Гомер чиге, соңгы сызык ул.

...Гомер юлың җиңел булмаса да,
Җирдә яшәп алу—кызык ул.

***

Дөнья көтү кыен икән,
Кемнәргәдер уен икән.
Уенның да уймагы бар:
Әле уйнап туймас борын,
Соңгы юлга җыен икән...

*2006-2007*

**Редакциядән:**

***Бу айда каләмдәшебез, элекке хезмәттәшебез Шамил Маннаповка 70 яшь тулды. Күркәм гомер бәйрәме белән ихлас котлап, аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.***

---

## Авторлар игътибарына!

**«Яңа дәвер кешесе» дигән хикәяләр конкурсы ахырына якынлаша.**

**Татарстан матбугатында барган үзгәрешләргә бәйле рәвештә, конкурсны үткәрү вакыты кыскарды. Җиңүчеләр 2008 елның май аенда, Татарстан язучыларының корылтаенда игълан ителәчәк. 31 мартка кадәр килгән барлык хикәяләр дә конкурста катнашачак.**

**«Казан утлары» редакциясе.**



Вазыйх Фатыйхов

## СИРАТ КҮПЕРЕНДӘ

### Чәчән сулышы

Нинди сулыш бу—кан исе килә?
Нинди язмыш бу—тоташ өермә.
Көн дә бер хәбәр—кемнәр соң алар,
Һәр киселгән баш җанны көйдерә?!

Нинди җилләр бу—тоташ тузанлы?
Атлар өченгә туры юл бармы?
Киселгән өмет тәнне өшетә,
Кая куярга белмим бу җанны.

Нинди карлар бу—тынмыйча ява,
Фәрештәләрнең күз яше тама.
Кара болытлар кояшны талкый,
Сулар да гүя кирегә ага.

Нинди сулыш бу—тыннар кысыла,
Энәдән атлыйм, аяк очында.
Афәт якадан ала түгелме?—
Күңел сырхаулы, йөрәк пошына...

### Яшерен сөю

Алтыдагы—алтмышта шул, диләр.
Утыздадыр, бәлки?.. Илледә?..
Нindидер бер яшерен сөю белән
Сөйдем бугай туган илне дә.

Бик сөйкемле булган өченме соң,
Бик ягымлы булган өченме?—
Яшерен сөю белән яныпсөйдем
Мин беренче укытучымны.

Яшерен янып тилмергәннәр саный
Яшьлек күкләренең йолдызын.
Яшерен генә сөеп йөрдем мин дә
Авылымның үсмер бер кызын.

Бездән соң да яңа яшьләр килсен,
Мәхәббәттә янып-көйсеннәр.
Яшерен сөюме ул, юкмы... әмма
Минем кебек чынлап сөйсеннәр.
Мәхәббәттә ян-көй
Кодрәтеңне синең күрсеннәр,
«Сөям!» дигән сүзне—кирәк чакта,
Яшермичә әйтә белсеннәр...

## Моңлы, диләр...

Нигә моңлы, диләр, синең жаның?
Бер моңлысы шул мин дөньяның.
Диңгезләрнең ялгыз дулкыны мин,
Бер бөркете ялгыз кыяның.

Нигә моңлы, диләр, синең жаның?
Юк, мин—канәгате дөньяның,—
Мин—әнинең чиксез куанычы,
Мин дәвамы газиз пар жанның.

Нигә моңлы, диләр, синең жаның?
Жырчы баласы мин таңнарның.
Жилләрнең мин иң-иң назлысыдыр,
Сердәшедер бөдрә талларның.

Нигә моңлы, диләр, синең жаның?
Гүя шуны аңлый алмыйлар:
Бу дөньяны чынлап яратканнар
Моңланмыйча кала алмыйлар...

## Гомер

Яшәгән саен—азая бара,
Азайган саен—күпне көтәсең.
Аз нәрсә һәрчак кадерле була,
Ходай бүләге—ни хәл итәсең.

Гомер йомгагың— бердәнбер бит ул,
Бер генә тапкыр аны сүтәсең.
Үзгәртәм димә, юктыр бер чара,
Ходай бүләге—шөкер итәсең.

Телисеңме син, теләмисеңме,
Йомгак очына берчак житәсең.
Бирелгәненә шөкер итә бел,
Ходай бүләге—ни хәл итәсең!

## Бушанулар кирәк

Әлсерәгән, ялын күккә чөеп,
Ак күбектә чаба Чулманым.
Ялкынсынган чагың күп күрсәм дә,
Мондый ярсу юктыр булганың.

Ярларыңа типтең кешни-кешни,
Аңлаганга сине, тыймадым.
Сиңа да бит бушанулар кирәк,
Һәрбер җанга кирәк, Чулманым!

## Сират күперендә

Кылдан нечкә, кылычлардан үткен
Сират күперендә мин бүген.
Алларымда намус офыгым бар,
Фәрештәле минем үз күгем.

Кемдер курка, кемдер икеләнә,
Шул күпергә аяк басарга.
Кемдер йөри, әнә, башын ташлап,
Яңабаштан аны ясарга.

Кылдан нечкә, кылычлардан үткен—
Куркытадыр кемдер йөрәген?!
Сынауларга калгач гына җаннар
Барлый башлый кемгә кирәген.

Сират күпереннән үтеп барыш—
Күпме җаннар китәр упкынга?
Ә мин атлыйм ныклы адымнарда—
Җаным намусыма тотынган...

## Касәмне күтәрәм...

Җидегән йолдыз ул—мәхәббәт касәбез,
Төннәрен икәүләп шәрабен эчәбез.
Шаһитка сүрелмәс йолдызлар сайлагыз,
Арага җиде ят кермәсен дисәгез.

Җидегән йолдыз ул—мәхәббәт көзгебез,
Аңарга карашлар сихерле тартыла.
Караңгы төндә дә, болытны аралап,
Шул йолдыз кабына мәхәббәт хакына.

Җидегән йолдыз ул—төнебез кояшы:
Вәгъдәләр күкләрдә эленеп калмады.
Шәрабләр кулда да, күктә дә чайпалды,
Тик алар читләргә таммады.

Җидегән йолдыз ул—
Уртаклык билгебез,
Югалтмый яшикче яктысын гомергә,
Мин бүген мәхәббәт касәсен күтәрәм—
Йолдызлы мәхәббәт яктырсын,
Нурлары агылсын күңелгә!

**Редакциядән:**

***Бу айда шагыйрь Вазыйх Фатыйховка 50 яшь тула. Каләмдәшебезне юбилее белән котлап, аңа яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.***

Рафаэль Мостафин

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗНЫҢ ИМӘН БАГАНАСЫ

### Әйдәп баручы

Аяз Гыйләжев иҗаты турында йөзләгән мәкалә, шактый саллы ике китап басылды, кандидатлык диссертациясе яклады (М. Сәхапов). Юбилей уңае белән шуларны карап утырганда, аптырап калдым. Боларга өстәп нинди яна сүз әйтә алырмын икән? Шуңа күрә мәкаләмне бәхәссез хакыйкатьләрдән башлыйм әле.



Татарстанның әдәби җәмәгатьчелеге Аяз Гыйләжевне талантлы һәм үзенчәлекле прозаик, хөр фикерле, кыю каләмле әдип, кызыклы драматург, кыскасы, зур язучы дип таныды. Бу әдипнең исеме Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Мәһдиев кебек классикларыбыз белән бер рәттә торырга лаеклы.

Аяз Гыйләжев татар әдәбиятын уй-фикерләрнең торгынлыгыннан коткарып, алтмышынчы-сиксәненче еллар әдәби агымын дәррәү кузгатып, хөрлеккә таба борып җибәрде, әдәби чараларны да кыю рәвештә яңартты. Аның «Өч аршын җир», «Язгы кәрваннар», «Әтәч менгән читәнгә», «Җомга көн кич белән», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», «Яра», «Балта кем кулында», «Йөгез, бер дога!», «Урамнар артында яшел болын» кебек проза әсәрләре, күп санлы пьесалары (алары кырыклап) бүгенге һәм үткән тормыш агымын тирәнрәк аңларга ярдәм итте, татар әдәбиятына яңача рух өрде, замандашыбыз образларын сәнгатьчә ача алды.

Шуңа күрә аны Язучылар берлегенең рәисе Мөхәммәт Мирза (Илфак Ибраһимов) «әдәбиятыбызның имән баганасы» дип атады.

Язучы илленче еллардан ук әдәбиятта үз сукмагын табып, беркемне дә кабатламыйча, рухи азатлык җырчысы буларак юл ярды. Аның төп теләге— хакыйкатьне яклау, гаделлеккә омтылу иде. Язучы әсәрләреннән тоталитар режимга карата ачы нәфрәт, шәхес иреген чикләү белән килешмәү, гади кешеләрнең азатлыкка омтылышы аңкып тора.

Гариф Ахунов, мәсәлән, Аяз Гыйләжевне тормышка үз карашы, әдәби-иҗат эшенә үз мөнәсәбәте булган, контраст бизәкләр белән эш итә, әсәр эченә укучыны язгы ташкындай шаулатып алып керә ала торган, җитлеккән язучы, җитмешенче-сиксәненче еллардагы әдәби агымны әйдәп баручы прозаик дип атаган иде.

«Аяз ага җаны-тәне белән милләтенә бирелгән, аның тарихи фаҗигасен, һаман да кыерсытыла килүен аңлаган, халкының, гореф-гадәтләренең иң тирән катламнарын күзаллап әсәрләрендә чагылдырган, татарның бәхетле милләтләр

сафына атлавын теләп, шунын өчен көрәш, ан, белем, мәгърифәт югарылыклары кирәклеген туктаусыз тәкрарлап торган әдипләрнең берсе иде»,—дип язды Тәлгат Галиуллин.

«А. Гыйләҗев әсәрләре—совет хакимияте чорынын сәнгатьчә тарихы, ахыр чиктә анын ни өчен җимерелеп төшүенең сәбәпләрен тирән итеп анларга ярдәм итә торган әдәби елъязма. Килер буыннар бу әсәрләргә еш мөрәҗәгать итәрләр әле, чөнки аларнын кыйммәте бүгенге көн белән генә чикләнми...» Монысы—тәнкыйтьче Фоат Галимуллин фикере.

Монын ише бәяләмәләрне шактый күп китереп булыр иде. Әмма, Туфан Миннуллин бик дөрес итеп әйткәнчә, татар әдәбиятында Аязнын урыны шактый төгәл билгеләнгән инде. Үзем исә анын зур язучы, талантлы, хөр фикерле әдип булуына беркайчан шикләнмәдем.

1995 елнын гыйнварында Аяз Гыйләҗев мина үзенең яна гына нәшрият тарафыннан чыгарылган дүрт томлык әсәрләрен бүләк итте. Беренче китапнын чиста битенә ул мондый автограф язып калдырды:

*«Рафаэль!*

*Менә—утыз биш еллык, тоташ хезмәтемнең бер өлеше. Газаплы, татлы йокыларны калдырган, мине берөзлексез тәртә арасында тоткан хезмәтемнен җимешләре... Тәнкыйтьчеләр—сәер халык, арадан бик сирәкләре генә яшел җимешләр ялраганын күреп, җимешләр пешеп өлгергәч нинди булачагын юрый ала. Минем кем икәнлегемне, иҗат биеклегемне, үз юлымнан тайпылмавымны шәйләгәнсеңдерме, юкмы, белмим, ә үзең анык кына бер чакта да әйтмәдең. Болай сиңа хөрмәтем чиксез зур. Кеше син!*

*31 гыйнвар, 95нче ел.*
*АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ. Казан».*

Минем Аяз Гыйләҗев белән беренче күрешүем 1949 елны, Казан дәүләт университетына укырга килгәч, булды. Мин—беренче, Аяз икенче курста укый идек. Базык гәүдәле, имән төбе кебек нык егет бер күрүдә үк үзенен түгәрәк күзлек пыялалары артындагы акыллы, үткер күз карашы белән җәлеп итте. Үз-үзенә бик нык ышанган, зур максатларга омтылучы, сәләтле кеше иде ул. Башка укучылар лекция белән генә канәгатьләнсәләр, ул исә профессорлар биргән белем белән чикләнмичә, кич саен диярлек китапханәләрдә казына иде. Тыелган, ул вакытта «халык дошманнары» дип исәпләнгән язучылар—Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан әсәрләрен әллә каян табып, аларны җентекләп өйрәнеп, алар турында үз фикерләрен туплый иде.

Әлбәттә, мондый «башбаштаклык» ул чорда җәзасыз калмый. Кемдер «чаккан», күрәсен. 1950 елнын мартында Аязнын ятагы кәтмәгәндә-уйламаганда бушап кала. Анын белән бер чорда Мәҗит Рафиковны, Гурий Тавлинны, тагы берничә кешене кулга алалар. Бу—ул чорнын ин өметле, ин сәләтле, башкалардан бер башка өстен яшь талант әһелләре иде...

Казанга Аяз биш елдан сон гына—шактый олыгаеп, житдиләнеп, ләкин мин-минлеген һәм үз-үзенә ышануын аз гына да югалтмыйча кайтты. Университетта укуын дәвам итте һәм жаны-тәне белән иҗат эшенә бирелде, иҗат ләззәтенә чумды. Юк, лагерьда үткән вакытын каһәрләмәде, беркемгә дә үч сакламады. Хәтта хәятынын сонгы көннәрендә дә: «Мин гомеремнен ин авыр елларын да сагынам»,—дип язды.

Әле аннан сон да Аязга шактый катлаулы тормыш һәм иҗат сынаулары үтәргә туры килде. Шулай да ул ин авыр, ин кыен чакларда да төшенкелеккә бирелмәде, сынауларны бөгелмичә-сыгылмыйча узды, усал тәнкыйтьчеләргә дә, обком «күкеләренә» дә бил бирмәде.

Каян шундый көч алды ул? Анын кыйбласын ачыкларга теләп, «Йәгез, бер дога!» исемле әсәрен ачып карыйк.

«Әдәбият нигезендә миллилек ята. Милли булмаган әдәбият—фальсификация ул.

Әгәр язучы татар халкының төбенә төшә алмаган икән, аның яшәеш рәвеше белән рухланмаган икән, татар халкына мәхәббәте юк икән—ул инде татар әдибе түгел».

Бу сүзләрдә, минемчә, Аяз Гыйләжев иҗатының төп мәгънәсе, рухи көченең сере. Әйе, ул чын мәгънәсендә татар әдибе, татар халкын тирәнтен аңлаган, аның өчен чын күңеленнән кайгырган, янган-көйгән язучы. Миллилек ягыннан аны үзе чиксез ихтирам иткән Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев белән янәшә куеп була.

Юк, ул халыкны мактап, аның алдында тезләнеп эш итми. Алай гына да түгел, кискен тәнкыйть итә: «Татар халкы соңгы вакытта аракы белән телевизорга сатылды»,—дип яза.

«Мин бераз төшенкерәк күңелле кеше»,—дип әйткән иде ул үзе турында. Әсәрләрендә дә ул күбрәк кайгы-хәсрәт, татар халкына тарих китергән бәла-казалар турында язды. Төрмә дә аның өчен үзенә күрә бер мәктәп булды. «Ул минем күземне ачты, тормышның ни икәнен аңлатты»,—дигән иде ул бер интервьюсында.

«Йөгез, бер дога!» әсәреннән тагын бер өзек китерәсе килә. «Милләтнең иң зур байлыгы—хәтер. Уртак хәтерсез милләтләр, милләт булудан туктап, гавам, халык төркеменә әйләнәләр... Милли хәтер бары тик үз җирендә бердәм булып яшәгәндә генә саклана ала һәм буыннар дисбесенең бөтенлеген, тулылыгын саклый...»

Хәтерне исә кем саклый? Матур әдәбиятның әһәмияте бу яктан искиткеч зур. Әдәби әсәр тарихи хәтерне образлы, тәэсирле рәвештә гәүдәләндерә, күңелләрдә тирән эз калдырырлык итеп тасвирлый.

Кайвакыт Аяз Гыйләҗевне уңай геройларның булмавында гаепләделәр. Янәсе, ул тормышның гел кире якларын гына тасвирлый, кара буяулар белән генә мавыга. Әйе, язучы тормышның авыр, хәтта куркыныч якларын бик ачык һәм тәэсирле итеп күрсәтте. Үз мәнфәгатен генә кайгыртучыларны, халык байлыгын туздыручыларны, кулга балта тотып башкаларга көн күрсәтмәүчеләрне нәфрәт белән тасвирлады. Карьера артыннан куучыларны, җыен торгашларны, җинаятьчеләрне җене сөйми иде.

Әмма шул ук вакытта аның әсәрләрендә төп урынны гади хезмәт кешеләре алып тора. Исхак белән Тәнзилә, Мирвәли белән Шәмсегаян, Җәүдәт белән Мөзәкир, Нәҗип белән Наилә, Арзу белән Хәбибрахман карт—болар барысы да саф күңелле, туры сүзле, тыйнак кешеләр. Алар чын мәгънәсендә уңай геройлар. Шул ук вакытта алар ниндидер дәрәҗәдә социалистик системаның корбаннары да.

Аяз Гыйләҗевнең иҗат колачы шактый киң булды. Без аны беренче чиратта күренекле прозаик буларак ихтирам итәбез. Ләкин шул ук вакытта ул үзенчәлекле драматург та, үткен каләмле публицист һәм журналист, таләпчән, ә кайвакыт усал телле тәнкыйтьче дә. Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин аның күпкырлы иҗатын җирдән бәреп чыккан кайнар чишмә белән чагыштырган иде.

Шулай да аның иҗатында иң зур һәм күренекле урынны повестьлар алып тора. Тема, проблема ягыннан алар төрле-төрле булса да, барысы өчен дә уртак булган сыйфаты шул: алар әзер штамплардан, соцреализм кысаларыннан азат. Моны «Өч аршын җир», «Әтәч менгән читәнгә», «Җомга көн кич белән...», «Язгы кәрваннар», «Яра» һ. б. әсәрләрендә дә күрергә була.

Тагын шуны да әйтергә кирәк: А. Гыйләҗев повесть-романнарының лирик агымы бик көчле. Язучы шактый нечкә психологик детальләр, бай, җор, халыкчан тел, үзенчәлекле сурәтләү алымнары белән эш итә. Әсәрләренең күпчелеге авыл тормышына багышланган. Аларда әхлак, тәрбия мәсьәләләре, мәхәббәт-гаилә, намус-вөҗдан каршында җаваплылык, яшәүнең мәгънәсе һәм максаты, яхшы белән яманның көрәше кискен драматик вакыйгалар, тирән психологик конфликтлар, бәрелешләр аша яктыртыла.

Тоталитар режимның иң авыр, цензураның рәхимсез котырынган елларында да ул халыкка туры сүз, хакыйкать сүзен алып килде, дөреслекне яклады. Шуңа да аның әсәрләре әле бик озак яшәр, автор үзе дә әдәбиятыбызда якты эз калдырган әдип буларак хөрмәт ителер.

## Дөяләр кемгә төкерә?

Халык тарафыннан танылган һәрбер олы язучы турында төрле мәзәкләр, кызыклы сөйләкләр тарала. Аяз Гыйләжев хакында андый сөйләкләр аеруча күп. Менә шуларның берсе.

Имештер, Аяз Гыйләжев бер төркем татар язучылары белән Каракалпакстанга бара. Нөкәс шәһәрендә аны колач җәеп каршы алалар, хөрмәтлиләр, мул итеп сыйлыйлар. Бер заман бай мәҗлестән соң кунаклар әзрәк җилләнеп алырга дип сахрага чыгалар. Шулай һава сулап, кояшлы дала-чүлләрне карап йөргәндә, болар мондый күренешкә тап була. Бер өтек кенә ишәк тау хәтле олы дөяне бауга тагып тартып бара, ди. Дөя теләр-теләмәс, иренеп кенә атлап бара икән. Бер заман ишәк туктый. Шуннан соң дөя ишәккә илереп-илереп төкерә башлый. Ишәк тагы кузгалып китә һәм үзе артыннан дөяне дә сөйри...

Кунаклар аптырап, исләре китеп, бу сәер күренешкә карап торалар.

—Нәрсә бу, парин, ыслушай?—дип сорый Аяз аларны озатып йөрүче каракалпак язучысыннан.

Тегесе мондый аңлатма бирә:

—Дөя кайвакыт белештермичә күп итеп пахта ашый, күбенә, эчләре кабара. Тик торса, үлүе дә мөмкин. Шуңа күрә аны ишәккә тагып, көчләп йөртәләр. Ишәк тезгеннән тарткач, дөя туктый алмый. Туктаса, ачуы чыгып, ишәккә төкерә. Шуннан соң тегесе тагы кузгалып китә. Шулай көннәр буе йөри бирәләр...

Моны ишетү белән, Аяз Гыйләжев, имеш, кычкырып елап җибәргән:

—Ыслушай, мин дә бит нәкъ шундый ишәк, татар әдәбиятының ишәге... Үзем иң авыр йөкне тартам, халыкның аңын алга өстерим. Обком дөяләре исә миңа төкерә дә төкерә...

Мондый мәзәкне үзе Каракалпакстанда булмаган, хәзер инде мәрхүм Мөдәррис Әгъләм сөйли иде. Мин Аяз белән бергә Нөкәстә булдым, әмма мондый вакыйганы хәтерләмим. Әллә булган андый хәл, әллә юк—анысы әллә ни мөһим түгел. Иң мөһиме—бу вакыйга чынбарлыкны бик дөрес чагылдыра. Чыннан да, Аязның үзенә дә, иҗатына да «дөяләр» күп төкерде.

А. Гыйләжевнең уңышлы, җитди, яңача язылган һәм зур шау-шу кузгаткан беренче әсәре «Өч аршын җир» повесте булды. Бу әсәрнең үзәк герое Мирвәли, көчләп күмәкләшү белән килешмичә, аңа мирас булып калган мал-мөлкәтне ярлыябага кулына бирергә теләмичә, затлы йортына ут төртеп, авылдан качып китә. Үзе белән аны яратып, атасының каршы килүенә дә карамастан аңа кияүгә чыккан Шәмсегаяnны да алып китә...

Бер яктан, Мирвәли—җаны-тәне белән җиргә береккән, теләсә нинди эштән дә чирканмый торган хезмәт кешесе. Икенче яктан, ул төрткән уттан үз өе генә түгел, бер очтан авылның шактый йорты да яна. Сөекле хатыны Шәмсегаянга да ул бәхет китерми, киресенчә, бәхетсез итеп, иртә гүргә кертә. Бүгенге күзлектән караганда, Мирвәли—шәхси милекне колхозга алып, кешене сыта, изә, кычкыртып талый торган иҗтимагый стройга каршы күтәрелгән зат, фетнәче. Әмма теге чор карашлары буенча ул—халык дошманы, социалистик реализм кысаларына берничек тә сыймый торган тискәре образ. Ничек инде аны уңай итеп күрсәтеп, аңа теләктәшлек белдерергә мөмкин булсын ди?!

Шуннан соң китә авторны һәм әсәрне дөньяга чыгарган мөхәррирләрне сүгү. Мондый карашны ул чорның рәсми тәнкыйтьчесе Флүн Мусин «Встречи с современником не состоялось» дип исемләнгән мәкаләсендә бик ачык чагылдырды *(«Советская Татария» газетасы» 1963 ел», 10 сентябрь)*. Мин Мусин фикере белән килешмичә, әсәрне яклап, аның тирән гуманистик идеяләрен аңлатырга тырышып, мәкалә яздым. Ләкин Казанда аны бастырып булмады. Минем белән килешкән очракта да, редакторлар, бармакларын түшәмгә төбәп, обком фикеренә ишарә итәләр иде. Имеш, обком секретаре Фикрәт Табиев бер чыгышында бу әсәрне зарарлы дип тапкан, Мирвәлине «вредитель», «кулак калдыгы» (подкулачник) дип

атаган, авторны исә житди идеологик хаталарда гаепләгән. Ничек инде партия фикеренә каршы киләсен ди?..

Шулай да мин үзәктәге «Литературная газета» аша әсәрне яклап чыктым *(«Плюсы и минусы», 1964 ел, 21 гыйнварь).* Мина каршы К. Фасеев чыкты *(«Полемизировать без приписок», шул ук газета, 1964 ел 2 апрель).* Аның фикере белән килешмичә, минем фикерне хуплап, Р. Фәизова чыгыш ясады. *(«Принципиальность и издержки критического азарта». Шул ук газета, 9 апрель).* Шулай итеп, бу әсәр турында ил күләмендә кайнар дискуссия булып алды. А. Гыйләжев әсәре «Дружба народов» журналында басылып, редакциянең икенче дәрәжәдәге премиясенә лаек булгач кына бәхәс берникадәр тынды. Әмма обком әһелләренең Аязга карата булган фикере барыбер үзгәрмәде.

Берничә елдан соң А. Гыйләжев бу әсәре нигезендә пьеса язды, Камал театрына илтеп бирде. Театр аны яратып кабул итте, рольләрне бүлешеп, репетицияләрне башларга әзерләнеп йөрде. Шул ук вакыта Туфан Миңнуллинның «Ат караклары» исемле пьесасын да куярга әзерлек бара иде. Шуннан соң булган вакыйгалар турында театрның баш режиссеры Марсель Сәлимжанов болайрак сөйли иде.

Берзаман аны уйламаган-көтмәгәндә обкомга чакырталар, идеология буенча секретарь Мирзаһит Вәлиев үзе дәшә. Ишектән килеп керүгә үк: «Нишләп әле син Миңнуллинның «Өч аршын жир» белән Гыйләжевнең «Ат караклары»н подпольно, понимаешь, куеп ятасың? Немедленно репертуардан алып ташлагыз!»—дип акыра. Марсель абый акланырга теләп, әсәрләрне яклап сөйли башлый, әмма ана авыз ачарга да ирек бирмиләр. Әңгәмә вакытында М. Сәлимжанов шуны аңлый: обком секретаре үзе бу әсәрләрне укымаган, авторларын да бутый... Күрәсең, кемдер килеп әләкләгән, шуңа таянып әмер бирә...

Әлбәттә, пьесаларны репертуардан сызып ташлыйлар. Ике пьеса да күп еллар үткәч, КПСС мәтәлеп калалгач кына, дөнья күрә.

Шундый ук хәл «Язгы кәрваннар» һәм «Күзгә-күз» повестьлары басылгач та кабатлана. Ә Аяз Гыйләжевнең «Өч тәгәрмәчле арба» хикәясен бастырган өчен «Азат хатын» журналының баш мөхәррире Асия Хәсәновага каты шелтә беллерәләр, эшеннән чак-чак кына алмыйлар.

Чыннан да, партия «дөяләре» Аяз Гыйләжевкә күп төкерделәр шул...

Шул ук ишәк турындагы мәзәкне Гариф Ахунов икенче төрлерәк сөйли иде:

—Хәтеремдә әле, Каракалпакстанда чакта Аяз чүл буенча башын иеп баручы ишәкне күрә. Янына килеп, ишәкне муеныннан кочаклап, елый-елый болай дип әйтә: «Синең дә, минем дә бер бүләгебез дә юк. Этләргә, хужасына ялагайланып койрык болгаган өчен муеннарына медаль тагалар... Синең белән мина исә—тот капчыгыңны.»

Чыннан да, бу вакытта Аяз Гыйләжевнең—йөзәр мең тираж белән басылган дистәләгән китаплар авторы, танылган прозаик һәм драматург, әдәбиятта үз сүзен әйтә алган, әйдәп баручы әдипләрнең берсе булса да, бернинди бүләге дә булмый. Шулай да вакыт узу белән гаделлек жинә, Аяз Татарстанның иң зур бүләген—Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен ала. Бу чакта, 1983 елда, Г. Ахунов Язучылар берлегенең рәисе булып эшли. Дүрт елдан соң ул бик хаклы рәвештә РСФСРның М. Горький исемендәге Дәүләт бүләген ала. Тагы берничә елдан, 1993 елның декабрь аенда, ана Халык язучысы дигән дәрәжәле исем бирелә. Әдип өчен шуннан да югары дәрәжә республикабызда юк! Язылган һәм куелган пьесалары өчен (ә аның куелганнары гына да өч дистәгә якын) ул Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе исемен ялады.

Үзе исә ул иң зур бүләге итеп башта дүрт томлык әсәрләр жыелмасын, соңыннан исә биш томлыгын исәпли иде. Чыннан да, мондый дәрәжәгә классик язучылар гына ирешә ала. Әмма монда да аның барлык әсәрләре кереп бетмәде. Ул бит, берничә роман, дистәләрчә повесть, йөзләрчә хикәя, кырыклап драма әсәре, санап бетергесез тәнкыйть мәкаләләре, ялкынлы публицистик чыгышлар авторы. Көндәлекләрне, хатларны, башка мөһим документларны да кертсән, утыз томга

да сыеп бетмәс иде. Бәлки киләчәктә чыгар да әле... Әгәр татар укучысы сакланса, башка халыклар арасында югалып, эреп бетмәсә...

## «Ач арыслан кебек усал»

Әдәбият тирәсендәге даирәдә Аяз Гыйләҗев турында «ул бик усал, хәтта явыз иде»,—кебек сүзләр йөри. Гамил Афзал бу турыда эпиграмма да язып калдырды:

*Син бик усал, ач арыслан кебек,*
*Усаллыгың җитәр йөз елга.*
*Юаш кына малай идең элек,*
*Усаллата икән бу дөнья.*

Чыннан да, Аязның пәке сыман үткен теленнән бик күпләр шүрләп йөрде. Теге яки бу әсәр ошамаса, ул ике уйлап тормыйча, үз фикерен турыдан-туры ярып сала иде. Халтурщикларны, урта кул язучыларны, ялагайларны җене сөймәде. Шул уңай белән аның турында мондый вакыйга булган дип сөйлиләр. Бер яшь язучы Аяз Гыйләҗевкә үзенең яңа гына табадан төшкән шактый калын романын биргән.

—Зинһар, укып чыгып, фикерегезне әйтсәгез иде,—дигән.

Аяз, романның беренче кисәген укыгач, авторга «Пүчтәк бу», дип, кире кайтарып биргән.

—Соң, беренче кисәген генә укыгансыз бит!—дигән автор.

—Калган өлешен дә син язгансыңдыр бит, парин?—дип китеп барган ди Аяз Гыйләҗев.

Шул ук темага тагы бер мәзәк бар.

—Кәрами туган, Аяз Гыйләҗ сине яратып бетерми, әсәрләреңне чүп дип атый, диләр. Шул дөресме?—дип сораганнар ди Рәфкать Кәрамидән.

—Дисәләр соң! Толстой да Шекспирны яратмаган!—дип җавап кайтарган ди Кәрами.

Чит кешеләр генә түгел, улы Искәндәр дә бер язмасында әтисе турында «ул холкы буенча шактый кырыс кеше иде», дип язды. Әмма шулай да сүзне бу очракта усаллык яки явызлык турында түгел, туры сүзле булуы турында алып барырга кирәктер. Катып калган алым, искергән фикерләр белән язылган әсәрләр авторларын Аяз Гыйләҗев беркайчан да җәлләп тормады.

Аяз урынсызга беркемне дә мактамый, ә инде халтурага тап булса—дөнья бетә, ул «кырыс теле белән уеп кына ала, кеше—бичара, үзенчәрәк әйткәндә, тәүбә догасын әйтеп өлгермәстән, тәһарәтен җуярга да мөмкин иде» (Гараф Шәрәфетдинов сүзләре).

Аязның тышкы кыяфәте дә бераз кырысрак иде, тәнкыйть тә аны «кырыс каләм остасы» дип атады. Әмма ничек кенә аны «пычак телле», «аяусыз», «усал» дип атамасыннар, чынлыкта ул бик нечкә күңелле, сизгер йөрәкле кеше иде. Янарак кына Татарстан китап нәшриятында Аяз Гыйләҗев турында истәлекләр китабы басылып чыкты. Бу китапта бик күпләр аны «олы йөрәкле остаз», «бик күп яшь язучыларга фатиха биргән әдип» дип атыйлар. Менә мисаллар да җитәрлек.

Казакъстанда яшәп иҗат иткән, гаепсез көе репрессияләр корбаны булган Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» романы Аязның әдәби эшкәртүеннән соң дөнья күрде һәм Тукай премиясенә лаек булды. Себердә яшәүче Якуб Зәнкиевнең «Иртеш таңнары» романы шулай ук Аязның таләпчән кулыннан узды. Аяз үзе әйтмешли, ул бу әсәрне башыннан ахырынача яңадан язып чыга, байтак эпизодларны, автор белән киңәшеп, өсти, тагы да күбрәген сызып ташлый. Бу әсәр дә Тукай бүләген алды. Кайвакыт Аяз, бераз шаяртып: «Мин өч мәртәбә Тукай бүләге лауреаты булдым»,—дип әйтә иде.

Шулай ук ул Әнәс Галиевка әдәбиятка юл ачты. Марат Әмирхановка беренче әсәрләрен эшкәртеп дөньяга чыгарырга булышты, башка бик күп язучыларга фатиха бирде.

«Әти юмарт кеше булды,—дип яза улы Искәндәр югарыда телгә алынган истәлекләр китабында.—Эшчәнлеге кебек үк, аның юмартлыгы да чик белмәде. Биредә мин юмартлык сүзенен киң мәгънәсен кулланам. Кунак кабул иткәндә дә, яшь язучыларга булышканда да аның юмартлыгы ташып торды»...

Бу турыда үз истәлекләрендә Якуб Зәнкиев, Миркасыйм Госманов, Марат Әмирханов һәм башкалар да яза. Әйтик, Разил Вәлиев Мәскәүдә әдәбият институтында укыганда Аяз белән очраша. Гыйләҗев аның бүлмәсендә була, яңа язылган повесте белән таныша, акыллы киңәшләрен бирә, Разилнең вак шрифтлы искергән машинкада басуын күреп, яңа машинка алыр өчен акча да калдырып китә.

Йә, шундый киң күңелле, юмарт кешене усал дип була димени?

Минемчә, мондый фикерне аның дошманнары таратты. Андыйлар исә һәр зур талантның, данга күмелгән кешенең житәрлек була. Шундыйларның берсе үз карашын ачыктан-ачык белдереп матбугатта да чыгышлар ясады. Мин Гурий Тавлинны һәм аның «Афәт» романын күздә тотам. Бу автобиографик әсәрдә автор Аяз Гыйләҗевне Риан образы аша гәүдәләндерә.

Рианның тышкы кыяфәте үк нәфрәт күзлеге аша бирелгән: «Аның жәенке кыска борынына атландырган зәңгәрсу калын күзлеге астында бака ефәге төсендәге күрәкарау бәбәкләре»... Риан үз-үзен «бик һавалы тота», «атлаганда башта үкчәләренә, аннары гына тулы табаннарына басып йөри». Әлеге «булачак классик» «кай ягы беләндер цирк шамакаен хәтерләтә», бөтен кыяфәтендә—«әйләнә-тирәдә мин генә бар!» дигәне күренеп тора.

Әлбәттә, Риан—әдәби образ. Башта мин аны шулай кабул иттем дә. Әмма Гурий Тавлин Язучылар берлегенең идарә утырышында «Риан—ул Аяз Гыйләҗев»,—дип турыдан-туры әйтте һәм аны үзе өстенә яла ягуда һәм төрмәгә утыртуда гаепләде. Менә ни өчен ул Аязны дошман күргән һәм аны «житлекми туган күзлекле ахмак», «тар күңелле кеше», «йөрәк урынына мүкле таш яткан адәм актыгы» дип атаган. Шундый дәгъва булгач, Язучылар берлеге идарәсе бу низагны тикшерү эшен миңа йөкләде. Һәм мин Черек күлгә барып, аларның тикшерү эшләрен архивтан алып, бу низагның асылы белән танышып чыктым.

1950 ел башында Казан университеты студентлары М. Рафиков, А. Гыйләҗев, А. Тимергалин, Педагогия институты студенты Г. Тавлин совет властена каршы коткы таратуда гаепләнеп, кулга алыналар. Аларның гаепләү эшләре белән танышу шуны күрсәтте—һәрберсе бер-беренә гаеп ташлаган, Аяз Гурий Тавлинны гаепләү өчен «показание» бирсә, Тавлин, үз чиратында, Аяз өстеннән сөйләгән.

Башта мин аптырап калдым. Соңыннан, тәжрибәле тикшерүчеләр белән сөйләшкәч, шуны аңладым. Кырыгынчы еллар ахырында өстән күрсәтмә килә—яшьләрне, аеруча студентларны, бераз «өркетеп алырга» кирәк, имеш. Янәсе, артык азындылар, кулдан ычкына башладылар. Эш шунда, безнең жиңүче солдатлар Европага бәреп кергәч, андагы мул тормышны үз күзләре белән күрәләр, бездәге ачлык-фәкыйрьлекләр белән чагыштыралар. Шуңа да яшьләр арасында партия һәм хакимият белән ризасызлык тарала башлый. Мондый күрсәтмә, күрәсең, Сталин авызыннан Бериягә бирелгән булса кирәк.

Шундый күрсәтмә нигезендә бер Казанда гына да һәрбер вуздан дистәләгән кеше кулга алына. Черек күл төрмәсе студентлар белән тула. Бу турыда Аяз Гыйләҗев үзенең «Йөгез, бер дога!» әсәрендә бик үтемле итеп, тәфсилләп яза.

Риясыз, бернинди жинаять эшләмәгән яшь-жилкенчәкне ничек инде тик торганнан төрмәгә утыртасың? Әмма, өстән күрсәтмә булгач, үтәргә кирәк. Шуннан Черек күл жәлладлары провокация алымнары куллана. Әйтик, Мәжит Рафиковны чакыртып алалар да, шундый күрсәтмә бирәләр. Имештер, Аяз Гыйләҗев—эчке дошман, советка каршы кеше. Әмма яшерен эш йөртә, серен бирми. Син аның янына бар да, үзең дә советка каршы сөйләгән булып, аның күңелендәге чын уй-фикерләрен белеп, безгә хәбәр ит. Хәтта дустының телен чишәр өчен аракы алырга акча да бирәләр... Аяз Гыйләҗевне чакыртып, үз чиратында Гурий Тавлин белән

сөйләшергә, аның чын уй-фикерләрен белергә кушалар. Менә шуннан инде тәҗрибәсез, НКВД хезмәткәрләренә тулысынча ышанган яшьләр бер-берсенә пычрак ягалар, үзләре дә баштан-аяк пычранып бетәләр. НКВД хезмәткәрләренә шул гына кирәк тә—барысын да җыеп, «дело»ларын әмәлләп, унар ел чәпиләр.

Кем гаепле, кем гаепсез—тикшерүчеләргә бусы әллә ни мөһим дә түгел. Әйтик, Аяз чыннан да совет строен, колхоз тормышын хурлаган. Әмма Мәҗит Рафиков җаны-тәне белән Сталин сәясәтен яклаган. Шулай да ул да, НКВД хезмәткәрләре кушуы буенча, советка каршы булып кыланган, аны да хөкем итәләр. Кыскасы, монда беркемне дә гаепләп булмый, тоталитар режим үзе гаепле.

Аяз минем белән сөйләшкәндә үз хаталарын таныды, олы абыйлар кулындагы курчак булуын аңлады. Шуңа күрә ул беркайчан да М. Рафиковны да, Г. Тавлинны да гаепләмәде. Тавлин исә моны соңгы көннәренәчә аңламады, күрәсең...

Нәтиҗә ясап, шуны гына әйтәсе килә. А. Гыйләҗевнең тормыш һәм иҗат юлы шомартуга яки бизәүгә мохтаҗ түгел. Аның әдәбияттагы урыны ачык билгеләнсә дә, иҗади мирасы әле чын-чынлап, тирән итеп өйрәнелмәгән. Моның сәбәбе бик гади: аның әсәрләре әзер кысаларга, кабул ителгән концепцияләргә сыеп бетми. Аның проза, драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть өлкәләренә керткән яңалыгын, иҗади ачышларын бәяләү, аңлау һәм аңлату киләчәк буын тәнкыйтьчеләре бурычы булып кала бирә.

---

Аяз
Гыйләҗев

# ГОМЕРНЕҢ БЕР ЕЛЫ

КӨНДӘЛЕК СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

**1993 ел, 2 гыйнвар, 1993ел, таң белән...**

Җаннарны изеп торган албасты-кәбисә елдан котылдык шикелле: Яңа ел төкле аягы белән килсен!..Теләк шул гына.

Бүген Зәй-Сарман тарафларына сәфәр чыгам. Кышкы юл, карлы авыл, шәһәрдә иркәләнеп күнеккән безләрне чак кына өркетсә дә авыл сагындырды. Татар теле сагындырды. Авыл теле сагындырды. Сарманнан җиде-сигез чакрым ераклыктагы Әлмәт дигән авылга йөз тотып чыгам юлга. Үзем белән эшмәшәкатьләрне, диабетны, борчуларны да алып китәргә туры килә. Нишлисең, күләгә болытлы көндә дә хуҗасыннан калмый...

**2 гыйнвар, көндез.**

Бүген сәфәр, Бигеш-Зәйләр аша Сарманга, аннан Иске Әлмәт дигән татар авылына кайтабыз. Нәкыя авылга кадәр мине озата бара. Юлга әзерләнеп машинкамның хәрефләрен юдым да лентамны алыштырдым, кул кычытып, берике сүз язып куярга ниятләдем. Ниһаять,кышкы авылга кайтырга булдым. Әгәр һава килешсә, урын үзгәләмәсәм, бик ныклап эшләргә исәп. Уйланганны тәмамлый алсам—олы бер җыю булыр иде[1].

**4 гыйнвар, Бигеш авылы, иртәнчәк.**

Аллага шөкер, икесендә үз вакытында кузгалып китеп, җитез генә тәгәрәп Зәй якларына кайтып җиттек. Казанда чалт аяз иде, монда төнге җәүле буран. Ярый әле Алмазлар машина белән Карман авылы турына килеп торган. Тизтиз «Уазик»ка күчендек. Алмаз тауда, куян куганда, егылып тагын дүрт кабырга-

---

[1] Йәгез, бер дога» дигән, төрмә-лагерь чорын да эченә алган роман-хатирәне язу күздә тотыла. Ред.

сын сындырган. Былтыр ике кабыргасының ныклыгын сынап караган иде. Егыла, кабыргалары сына, үзе сизми. Берничә көн сызлаштырып йөргәч кенә кинәт ясалган хәрәкәттән кабыргалар сынган төштә үз урыннарыннан кубып кузгалалар. Шунда гына рентгенга бара һәм....Ятып булмый ди, йоклап булмый, гәүдәне элеккеге рәвешенә китерә алмыйча газаплана икән! Алмазның тормышы көйле. Зарланмый. Йорт-җирне, ихатаны караган, абзарлар җиткергән, аранында кышлау бозау, "Җәмилә" исемле. Мал асрамасаң авылда ит табармын димә... Берәү дә сатмый икән...

И бу дөньяның хәлләре! Гап-гади ярты сүздән дә әллә ниләр белеп була. Борынгы дустым Гыйләҗетдиннең балалары Чаллыда яшәп, ел саен яңа ел тирәсендә кайтып йөриләр икән. Быел берсе дә юк, кайта алмаганнар, өйләрен ташлап йөрергә куркалар—басалар, талыйлар...

Бигеш мәчетле авыл, ниһаять, мин мәчетле авылда кунакта. Мәчет балкыпялтырап тәрәзәдән үк күренеп тора. Шунда гына хәзер энекәшемнең яңа шәп йорты мулла бабайның нигезенә менеп утырганын искәрдем. Мулладан калган йортны, каралты-кураларын хәтерлим ич мин! Өй ике катлы иде, аскы өйдә остазбикә кызлар укыткан, үзенә күрә аскы өй мәдәният учагы булган. Ул эре-эре ташлардан җитешлек белән салынган нык амбарлар, төз, биек кыеклы лапаслар, кар базы, келәтләр, алмалы-чияле янбакча... Йортның законлы төп хуҗалары кайларга китеп югалганнардыр да, Бигеш хәзрәтенең ак сөякләре кайсы җирләргә чәчелмәгәндер?.. (Аязның энесе ул авылга мединститутны тәмамлагач,1956 елда эшкә кайтып, шунда төпләнеп калган иде. Нәкыя*.) Мәчет ачканда Казаннан Мансур Хәсәнов та кайткан икән. (Мансур Хәсәнов шул авыл кешесе—безнең хөрмәтле галимебез, мәшһүр җәмәгать эшлеклесе. Н.) "Мәчет салырга нык булышты, бик тә күркәм кеше",—диде Гыйләҗетдин. Мәчет ачканда, элек балкып яшәгән, соңра югалган хәзрәтләрне искә төшереп телгә алучы булдымы икән? Юктыр, без, кабатлап әйтәм, кыска хәтерле халык. Мәчет авылны күккә күтәргән, мәчет Бигешне адәм балаларының бишеге—галәмгә якынайткан. Урамнан үтеп барышлый ирексездән гел шул якка кайрыласың, күңел җирси, әйтер сүзләр иманга манчыла. Акча җәлләмәгәннәр бигешлеләр, матур итеп бизәп, таш мәчет салганнар. Хәзерендә унсигез карт намазга килеп-китеп йөри, ара-тирә яшьләр дә күренеп кала икән...



*Авыл җирендә халык белән очрашулар.*

Күңелнең бөтен барлыгы белән мәчетне зурлый-зурлый үтеп киттек тә зиратка бардык. Азат, мин, Алмаз, Нәкыя белән Әлфия (энесе Алмазның кызы. Н.) әти-әни яткан изге җиргә баш иеп озак кына басып тордык. Тын кыш, дөнья апак, әрвахларның җаны кунган каен ботаклары иелеп-иелеп безгә сәлам бирде. Без, тезелешеп, җитмешкә бара торган өч Гыйләҗев, үзебезнең кайсы төбәкләрдә йокыга ятасыбызны уйлап моңсуландык... Безнең балалар шулай җыелып исемнәребезне яхшы сүз белән яд итәрләрме? Әллә дөнья аларны да изеп, сытып, җаннарын тишкәләп бетерерме?.. Әти белән әни безнең өчәүләп килүебезне сизгәннәрдер, сизми калмаслар, ләхетләре җылынып вә яктырып киткәндер. Амин, шулай булсын!

---

* Нәкыя Гыйләҗева—Аяз Гыйләҗевнең хатыны. Көндәлек сәхифәләрен ул әзерләп китерде. Алга таба кыскартып, Н. дип биреләчәк. Ред.

***

Гыйләҗетдиннән сораштым... Мыек Ярулланың фамилиясе Мөхлисов булган икән. "Шактый әшәке кеше иде!" диде Гыйләҗетдин. Инде Гыйләҗетдин булып Гыйләҗетдин, адәм балаларына бары тик яхшылык кына күрсәткән, җирдәшләренә гелән изгелек теләгән зат Мыек Яруллага шундый тамга салган икән...монда уйланырлык урын бар! Гомумән, сугыш елларында, сугыштан соң колхоз рәисе итеп әнә шундый "әшәке" бәндәләрне генә куймадылармыни? "Усал гына түгел, әшәке!" дип кабатлады Гыйләҗетдин.

Әшәкелекнең дә дәрәҗәләре бар... Усал, явыз, әшәке...

Бигеш, Бигеш ...ындырларны юа-юа, ярдагы талларны берәмтекләп санап Аулаш елгасы-инеш ага. Биек тау, Кый тавы... Мыек Ярулла белән шул тау өстендә йөргән идек бит. Тырмачы малайлар янында. Горчицаны колхоз үзе чәчкән икән. Бүтән иген-таруны сыпырып алып китеп бетергәннәр, ә горчица орлыгы калган. "Бөгелмәгә барырга туры килде,—дип сөйли Гыйләҗетдин,—ике кило гәрчис орлыгы бирделәр. Атка да шул, үземә дә шул. Әнкәй әүвәл гәрчисне кыздыра иде, аннан төя! Тәмле дә була торган иде! Соңыннан авыз эче яна!"

Бигеш үзгәргәннән үзгәрә, авылга яңа төс куна. Коймалар тыгызланган, капкалар биегәйгән, йорт урыннарында таш пулатлар кукыраеп утыра, тәрәзәләр челтәрле, тимер капкалы гаражлар ишәйгән, кая карама бөтенлек, төзеклек һәм байлык күзгә кереп тора. Тик җан нигәдер моңсулана, шушы бай ихаталарны, таза тормыш шаһитлары—таш пулатларны б е р б ө т е н  а в ы л итеп йомарлап тоткан төс юк. Баеган саен йортлар бер-берсеннән ерагайганнар төсле. Бер яктан сөенәсең, икенче яктан күңелне нидер кыра, борчый, авылның милли төсен аерып булмый, нинди зирәк булсаң да бу капка, койма артларына кереп бикләнгән адәмнәрне белә алмыйсың инде! Кунакка йөрешүләр кимегән, күршекүләнгә йомыш белән керүләр беткән, әгәр киләчәк авыллары кешеләрне шулай тарката торган булса, яшәү үтә күңелсез һәм суык булыр төсле.

***

ЖЗЛ сериясеннән Салтыков-Щедрин китабын карап утырам. Истә, Александр II патшаның резолюциясе истә: "И прекрасно; пусть едет служить да делает сам так, как пишет, то есть так, как желает, чтобы действительно делала хорошо".

**5 гыйнвар, Бигеш.**

Иртәнчәк.

Хәтер өзек-өзек чылбыр икән ул. Үткәннәрне тоташ юл-сукмак итеп һич кенә дә күз алдына китереп булмый! Вакыйгаларның урыны үзгәрә, вакытлары алмаша, үткәннәргә хәзерге мөнбәрдән торып бәя бирә башлавыңны сизми дә каласың. Никадәрле гадел, сак булырга тырышсаң да күңел-хуҗа язмышыңа якты бәя бирергә тели, кылган вак-төяк гөнаһлар, адымнарыңа чүп-чар булып ияреп барган кыек-мыек эшләр читкәрәк этәрелә, ни тырышсаң да үзеңә-үзең хак хөкемне чыгарып булмый. Күңелдә кат-кат тәүбәгә килсәң дә гөнаһларны тезеп салырга кул бармый, бәлки аларның кирәге дә юктыр, үз гомереңне синнән башка белеп бетергән җан иясе юк, нигә аларны дөньялыкта ук фаш итәргә, әле Ходай каршысына барып баскач та тулы һәм дөрес йомгак ясыйсы бар... Анда инде гамәл дәфтәреңнең сыңар сүзен дә яшереп кала алмыйсың! Адәм балалары бер-берләрен генә түгел, үз-үзләрен дә алдарга яраталар, юанып яшиләр, кешеләрнең әнә шул бәхетле юанычлары булмаса бераү дә гомеренең язмыш билгеләгән азагына кадәр барып җитә алмас иде.

Шушы Бигеш авылы язмышымда шундый зур, мөһим урын тотар дип кем уйлаган?.. Хәбир Зәйнуллин—гомерлек акыл биреп киткән егет. Мут, наян, күр күңелле Гәрәй Гәрәев. Зәйдә эшләгәндә Сабан туена кайткан идек. Бигеш Сабан туеннан Иштирәк авылына киттек. Молотов (Пермь) шәһәреннән кунакка кайткан Әминә белән танышкан идем. Ак күлмәк кигән сөйкемле кызыкай иде. Иштирәккә ат җигеп бардык, бәйрәмнән соң фатирга кайтсак, йөгәнебезне урлаганнар. Шулчак Гәрәй: "Сез бара торыгыз, мин куып җитәрмен!" диде, без атны чак-чак атлатып юлга чыктык. Элеккесеннән дә шәбрәк, җиз төймәләр

белән бизәлгән каеш йөгән күтәреп Гәрәй куып та җитте. Елгыр егет иде... Бигеш...Бигеш... Шәйхулла Зиннәтуллин, мәрхүм... Ниһаять, Алмаз монда утыз биш ел врач булып хезмәт итте. Әти-әнине шушы авыл зиратына җирләдек... Күпме кешеләр, нинди зур вакыйгалар белән бәйләнгән мин шушы борынгы татар авылына!..

**6 гыйнвар, Иске Әлмәт авылы.**

Кич.

Күз тотып чыккан авылга бүген таңда килеп җиттек...

Кичә иртәнге чәйдән соң Зәйгә юл тоттык. Таныш дөнья, таныш юллар, күңелгә якын манзаралар, хатирәле таулар, елгалар. Бу бормалардан, шыгырдап калган күперләрдән ничә мәртәбә үттем икән дә нинди уйлар уйламадым икән? Һәр авыл исеме мине яшьлеккә алып кайта, моңсуландыра. Зәйдә озак юанмадык, Тәлгатьнең (Аязның туганнан туган абыйсының улы. Н.) көндезге ашка кайтуын көттек тә, тамак ялгап алгач, Сарманга элдердек. Ял тәмам, кунак-кунак уйнауларны йомгакладык, урнашып, яңа урынга күнегеп эшкә тотынырга бик вакыт!.. Сарманда Әхнәф Гатауллиннарда (минем туганнан туган сеңлем Фәниянең ире һәм алар гаиләсе турында сүз бара. Н.) кундык. Озаклап сөйләштек, соң гына Сарман урамнарына чыгып "Архангел" дип сәер исем белән аталган яңа бистә тирәләрен урап, Сарманның зураюына гаҗәпсенеп, бизәлгән ятим чыршыны карап йокларга кайттык. Урамнар тын, ара-тирә машиналар уза да егет-җилән каядыр ашыгып үтеп китә. Элекке сыман авылларны бизәп, җанландырып торган уртак хәрәкәтләр юк. Һәр йорт, ихата борынгы крепостьлардай ялгыз, серле тынлыкта утыра. Сарман мин белгән почмак түгел инде, ул ят, андагы үзгәрешләрне күз әлдереп, бер ноктага җыеп бетерә алмыйм. Соңгы елларда Сарман төбәгеннән нык ук читләштем бугай, җанга якын кешеләр картайды, аларга картлык олылыгы сеңде, мин аларны, алар мине аңлап та бетермибез шикелле... Шуңамы Сарманда озак юанмадык, таң белән юлга чыктык. Текәй таулары өстенә менгәч офыклар ачылды, кырлар киңәйде, сыек алсу төскә манчылып дөнья ямьләнде.

Иске Әлмәттә безне көтәләр иде, куанып каршыладылар. Менә шушы байтак бүлмәләргә бүлгәләнгән җылы өйдә торырга кайттым мин. Урын сайлап, ары-бире караштырып йөргәч сул яктагы нәни бүлмәчеккә кереп утырдым. Каршымда юка боз белән челтәрләнгән тәрәзә. Ятсынып мине күзәткән куакларда песнәкләр шаярып-уйнап ала, бер-берсеннән һич аерылмас әрсез чыпчыклар очып-очып куна. Мин яңа тормыш башлап җибәрәм. Хәерлегә булсын!

**7 гыйнвар, Иске Әлмәт.**

Көндез.

Онытылганчы язып куйыйм әле...

"Юллар, юллар... Озын булса булсын, тик соңгысы гына булмасын!"

Зәйдән әңгер-меңгердә чыгып киттек. Әле Ирнә күперен үткәнче күңел кымылдап куйгаласа да тәмамысы уянмады. Урта юлга җитәрәк күкрәкне нидер кысты, күз төпләрем дымланды. Сулда карасу агачларын чайкап кашка тау шәйләнде. Без печән чапкан уйдыклар, без балык тоткан, кармак салган тугайлар, болыннар. Ятып суын эчкән чишмәләр! Ничәмә-ничә кат сез минем әсәрләремә кереп җанымны сүнмәс хатирәләр белән ураган, терелткән, җылаткан урыннар. Гомерем белән мин сезгә бурычлымын... Сезне—шушы гүзәл почмакны сездәй горур биеклеккә күтәреп дөньяга таныта алмаганмын икән, нишлисең, күпме еллар пышылдап кына сөйләштек шул, күкрәк киереп, бөтен тавышка кычкырып, данлап булмады... Урта Баграж зираты...Түбән оч. Машина тигез генә тәгәри, тәгәрмәчләр юлны урый, хатирәләрне сүтә. Менә Югары оч! Чуал ярларында карт өянкеләр. Баграж өянкеләре! Әти яратып утырткан агачлар! Әти вафатына унҗиде ел. Өянкеләре дә нык картайды. Алар да билләре муртаеп, ботаклары сынып берәм-берәм әз югалталар. Кем утыртканын белгәнгә, агачлар да кызганыч... Менә инеш аръягындагы тарлавык. Дөньядагы иң тыныч, иң тын урын. Тарлавыкны телеп тауга менә башласам колакларым чыңлый, дөнья таулар иңеннән минем иңнәремә күчә. Рәхәт! Чиксез рәхәт! Үләнчәчкәләрдән чыккан татлы исләр куерткан татлы һава адымнарны ашыктыра, гомерне бизи, җиңеләйтә вә озайта. ...Җир шарында шушы тарлавыктан да



*Сулдан уңга: Р. Батулла, Х. Гарданов, Ш. Бикчурин, А. Гыйләҗев.*

кадерлерәк почмак юк миңа. Өскә менәсең, уңда Кызыл яр. Улларымны Кызыл Яр таудан таш тәгәрәтергә алып кайта идем мин. Бәхетле мизгелләр! Дөнья бәясе торырлык уртак хатирәләр. Балалар да бу тауны хәтерлиләр, яраталар. Кызганыч, еллар үтү белән тау тәбәнәкләнә, аны ермачлаган чокырлар тирәнәяләр. Кар әз. Тау ала-кола. Беләм, хәзер анда җилләр уйный. Җилләр тарлавыкка ятып аска шуалар да Минәй чишмәсендә бөтерелеп, өскә, чуал буйлап әти утырткан өянкеләргә хәтле барып җитәләр...

Баграж... Керәшеннәр патшалыгы. Ягымлы, гади, юмарт күңелле кешеләр. Милли шикләнүләрдән азат яшәүче табигать балалары... Мин аларны шулай диеп белә идем. Янәшәдә, рәхәт итеп яшәдек моңарчы. Соңгы елларда милли бәрелешләрнең хәвефле, шомлы мисаллары җанны куырып, өркетеп тота башлады. Югославия таралды, анда сыенып яшәгән халыклар бер-берсен кыралар, асалар, суялар. Хорватлар, серблар мәңгелеккә дошманлашырга бурыч алган кешеләрдәй хәзер тыела алмыйлар. Бу кырылышны аларның милли лидерлары әзерләде. Тарих өчен, җир өчен, һава-сулар өчен, тагын әллә ниләр өчен үткәннәрдән канлы вакыйгаларны казып чыгардылар да халыкларны бер-берсенә каршы котырттылар. И китте суеш, и китте кырылыш. Милли чуалышлар тезгене милли лидерлар кулыннан бер ычкынса, аны авызлыклар көч юк, Алла кодрәте белән дә ул халыкларны ипкә китерә алмассың! Карабах өчен тарткалашкан әрмән-әзәриләр тиз генә туганлашырмы? Аның шаукымы йөз елларга барачак әле. Милли каршылыклар тарих төбенә салып калдырылган усал миналар алар, көне-сәгате җиткәч шартлап ярылалар да, дөньяга яңа корбаннар бүләк итеп, каршылык дулкыннарын һаман көчәйтәләр. Гөрҗиләр белән абхазлар тиз генә яраларын ямарлармы?.. Осетин белән гөрҗиләр... Милли күремсезлек—куенына мең вулканны яшергән серле тау ул. Аларның берсе генә уянса да тауны нигезенә кадәр тетрәтә... Бүген юлдан ерак та түгел тын гына йокымсыраган керәшен авылларына шигәеп карап барам: нигезләре тетри башламаганмы аларның?..

Китәр алдыннан нәшриятка, Фәрваз Миңнуллин белән саубуллашырга кердем. Максим Глухов белән кара-каршы килештек. Бүтән чакта күзен күтәреп карамаган, юри күрмәмешкә салышкан, исемемне атап эндәшмәгән кеше бу юлы туктады, башын чак кына кыйгайтып, миңа карады. Зәй төбәгендә булган икән. "Керәшеннәр тормышына багышлап бер китап та язмыйсыз" дип зәйлеләр нык үпкәли,—диде.—Шул бушлыкны тутырырга йөргән чак. Тырыша торгач зур гына җыентык әзерләдек. Дөрес, урыс телендә. Зәйдә Вениамин Демьянович Некратов (Максим тагын ике-өч керәшен исем-фамилиясен хөрмәт белән атады) китапны нык хуплыйлар, һәм матди, һәм рухи яктан ярдәм итәләр. Бик кызыклы, яңа фикерләр белән баетылган китап булачак". Максим татарча сөйләшсә дә, ул телдә сөйләшүенә авырыксынган кебек телен бозып, әллә ни-

чек кыланчык-божраландырып сөйләшә. Күзләре як-якка чәчеләләр, муены башын тик тота алмый... Аны-моны уйламадым: "Минем дә Баграж керәшеннәренә атап бер мәкалә язасым килеп кыжрап йөрим",—дидем. Минем сүзне Максим колагына да элмәде, китабының үтә мөһимлеген, Зәй тарафларында үз яраннары күбәюен кат-кат, байтак исем-фамилияләрне кабатлый-кабатлый, үз сүзләренә үзе гашыйк булып, арган ат сыман, аякларын алмаш-тилмәш күчереп сөйли бирде. Багражда да булган икән, "Гурий Тавлинны да, Мулла Гуриен дә беләм!"—диде һәм мактанган шикеллерәк итеп Гурийның әшәкелеге хакында багражлылардан байтак хәбәрләр төяп кайтуын искәртте. Ниятен ачык белмәгәнгә, бу серле-шикле кеше алдында Гурий хакында аны-моны куертмадым. Гурийның кушаматы "Мулла Гурие" икәнен каян белүенә гаҗәпләндем. Мулла?! Бу кушаматны белә идем, оныткანмын. Ни өчен һәр сүзен сергә, һәр ишарәсен тирәнлеккә манчырга тырышкан бу бәндә Гурийны яратмый башлаган әле?.. Ни өчен ул сәер хәбәрләрне миңа җиткерә? Шуның өчен генә туктаттымы мине?.. Мин үз ниятемне тагын кабатладым. Баграж керәшеннәренә багышлап хатирә язасым килә, дидем. Ул түшен миңа таба эшереп: "Ә син Багражның нинди мәгънә аңлатканын беләсеңме?" дип сорады. "Юк"—дидем. "Сары саз" дигән сүз ул", диде Максим. "Ә бездә Сарсаз Баграж" авылы бар", дидем мин, нигәдер сөенеп. Сүздә бу кешене өстен чыгарасым килмәде, бугай. Ул үзендәге үзгәрешкә мәгънә салырга тырышып:"Ә син ул хатирәләрдә кайсы якны яклыйсың? Керәшеннәр әүвәл татар булган, шуннан соң гына чукынып христиан диненә күчкән дип раслыйсыңмы?". Мин аны-моны әйтергә өлгермәдем. Югары Багражны, авыл-тыкрыкларын, кушаматларны җәһәт-җәһәт күңелдән үткәрергә тотындым. "Тугашлар тыкрыгы", "Микиләр тыкрыгы". Тугаш—борынгы татар исеме түгелмени? Мухановлар—Мөхәмнән алынган. Сарсазда Кондрабаевлар, "Кондырбай" түгелмени?.. "Юк,—дип ышаныч белән дәвам итте Максим,—без бер чакта да татар булмаганбыз, без—керәшеннәр. Керәшеннәр Идел-Чулман буйларында Грозный патшага кадәр үк булган, яшәгән. Мисалга, Сөембикә патшаның җансакчылары, гвардиясе бары тик керәшен яугирләреннән генә торган. Мөселман-татарлар хыянәтчеләр, алар христиан динен сатып татарга әйләнгәннәр". Максимның үзе әйткәннәргә ышанганы, бүтәннәрне дә шуңа ышандырырга тырышуы, киреләнгән ныклыгы һәр сүзеннән аңгырап тора иде. Ул миннән раслау да, кире кагу да көтми, мине дә үз ягына аударачагына, дөньядагы дөреслеккә бары тик үзе генә хуҗа икәнлеккә ышандырасына шикләнми иде. Газеталарда аның бу фикере, керәшеннәрне татарларга капма-каршы куюы, тарихтан шуңа дәлилләр табарга тырышуы күземә чалынган иде. Хәзер, аның шомлы хаксызлык китерәчәк өряңа теориясе белән кыска гына танышкач, мин куркып киттем. Китап дөньяга чыгар, Зәй төбәге вәкилләре керәшеннәрнең тарихи дөреслекне яклаучы аңлы төркем икәнен авыз тутырып сөйли башларлар. Милли корт иң нык агачларны да кимерә!.. Нәтиҗәдә, татар-керәшен каршылыгы үсеп чыгар. Тарткалашу башланыр. Башкорт-татар милли кискенлеге тирәсендә татар-керәшен каршылыгы ныгыр. Татарлар әзме-күпме җанлана, үзара аңлашып яшәргә омтыла дигәндә, тын гына оеп утырган Кашка тау күкрәгеннән вулканнар ут чәчеп дошманлык тарата башлар. Бар бит ул Максим Глухов сыңарлары, милләтнең кыска хәтерле катлауларын тиз-тиз котырта алган, күрәләтә ялгыш юлларга кертеп адаштырган шәхесләр...

**9 гыйнвар, Иске Әлмәт.**

—Җил. Ике көн, ике төн тоташтан җил. Басуда кар әз, аны да җил тыкрыкларга, читән ышыкларына, чокыр-чакырларга ташып бетерде. Тар тыкрыктан кар кикрикләре өстеннән бата-чума барабыз...

—Җил, җил. Алай да кошлар җим эзләп ихата тирәсендә туктаусыз очалар, әйләнәләр, тулганалар да йорт тирәсен, бакча читләрен сарган миләш төлгәшләре котырып атынган агач ботакларына килеп ябышалар. "Миләш ашарга каяндыр озынчарак, күгәрченнән чак кына ваграк кошлар килә. Быел урманда җим күп булды, кар озак яумады, миләш убырлары моңарчы күренмәде, әлерәк кенә яу булып безнең бакчаларга төштеләр. Бу вакытка элгәрге елларны бер чөм миләш тә калдырмыйлар иде. Быел соңардылар. Әмма хәзер миләш агачларына көн бетте: авыр гәүдәләрен көч-хәл белән күтәргән каргалар да таш-

лана аңа, әллә кай ярыклардан очып чыгып саесканнар да аны ботарлый, "безгә калмый, безгә калмый!" дип чыпчыклар да соры болыт булып миләшкә елыша, сак вә кыюсыз песнәкләр дә шул тирәдә пыр-пыр оча, чыда гына миләш", ди хуҗам Рәис. (Монда гына беренче мәртәбә телгә алынган Рәис абыем—ул кадерле әнкәемнең төп йортында яшәп гомер итүче, әнкәемнең энесе. Алар киң күңелле, мәрхәмәтле, йомшак телле Фәрхинур апа белән 1945 елдан бирле шушы хуҗалыкта бер тын булып, бер сулышта яшиләр. Аязны ул(1990-95) елларда иҗат итәр өчен сыендырыр урын таба алмыйча аптыраганда, алар чын күңелдән сыендырып яшәп алганнар иде. Аяз вафатына кадәр шушы кадерле көннәре турында җылы итеп искә алып сөйләде. Н.)

***

Караклык монда да килеп җиткән. Руша янындагы авыл очында, иң кырый йортта яшәүче берәүнең ябык абзарына төшәләр дә дүрт сарыгын суеп, тунап, эчен-башын ташлап, итләрен алып китәләр. Атна-ун көн үтүгә шул ук абзардан хуҗаның соңгы сарык малын—симез тәкәне йомдыралар. Эте була хуҗаның, бурлык алдыннан этне агулыйлар, эт исән калса да тавышы бетә, өрә алмый башлый.

***

Кичә телевизор аша Фәннүр Сафинның вафатын хәбәр иттеләр.

Монда сәфәр чыгар алдыннан гына нәшрияттамы, Комлев пулатындамы (хәзер Мөштәри урамы. Н.) очрашкан идек. Очрашуыбыз мәзәк диярлек булды. Фәннүр гел елмаеп, басымчак кына миңа карап торды. Мин аның учын кулымнан җибәрмичә, нигәдер тоташтан яхшы, ихлас сүзләремне әйттем. Хәзер хәтерләмим, сүзләре сеңеп өлгермәгәндер ахрысы, Фәннүр үзенең ялгызлыгын телгә алды. Машинага бәрелеп зиһене әз-мәз таралган бу һәйбәт, сәер шагыйрьне хатыны ташлаган иде шикелле... Ярым гариплеген, ятимлеген уйлыйм да...үз-үзенә кул салмаганмы Фәннүр дип сызланып, куркып куям. Безнең арадан ашыгып, үз ирекләре белән киткән каләмдәшләребез моңарчы да булгалады. Сөйкемле Җәгүр Уткин, тыйнак Ринат Рәхимов, моңсу Альберт Сафин, ...менә хәзер Фәннүрме? Тик без бер чакта да аларның ни өчен дөньядан туюлары хакында уйлап карамадык, баш ватып тормадык. Ләкин һәр ирекле үлем хөкем сөргән мохитка, чордашларына, фикердәшләренә протест ул, көчсезлек галәмәте генә түгел, һич, һәрбер һәлакәттә җәмгыятькә әйтелмәгән ачы нәфрәт, зар ята. Мин шулай уйлыйм. Фәннүр мине олы санап, гел елмаеп, йомшак сүзләр белән сөйләшсә дә аның тел төбендә чиксез моң, азагы юк зар, билгесезлекне сагыну, уйларының бәргәләшүе ята иде. Кайткач Нәкыягә дә бу хакта борчылып сөйләгән идем...

Иске Әлмәттә өч кич кундык. Бүген Нәкыя китәргә әзерләнә. Ялгызым торып калам. Әлегә хәлем әйбәт, иң мөһиме:тынычмын. Хуҗалар үтә эшчән, сабыр холыклы, кече күңелле кешеләр. Ашарга-эчәргә бик мул, һәр иртәдә яңа сауган сөт эчәм, ит ризыгы да күп, һич уйламаганда, көн туса миләш ашыйм. Әллә очар кошлар белән ярышка чыктым инде? Яратып, ясканып, рәхәтләнеп ашыйм миләшне. Салкын аның ачысын алган, аша да аша гына. Ашыйм икән—организм сорый дигән сүз. Бер-бер хаҗәте, файдасы булмаса корсак тәпсерләмәс, кабул итмәс иде. Әле төп эшемә басылып керешә алганым юк, моңарчы вак-төяк белән маташтым. Инде иртәгәдән эшкә...

Бүген һава тын диярлек. Җил, арып-талып рушадагы агачлар арасына кереп бөгәрләнеп, йокыгаятты. Бүген руша тирәсеннән әйләнеп тә кайттым. Алдагы көннәрдә йөрергә сукмак эзләдем. Бүген кар шул кадәр ак, аның кар булуына ышанасы да килми. Күзне кисә, күз чагыла. Дөнья безне чолгаган нәрсә-караларның төсен үзгәртеп бетерде, инде без ак чынлыкка да ышанмыйбыз.

Үзем торган хуҗаларның кызы Фәнҗияне озата киттем. Тап-таза гәүдәле, көче ташып торган гвардеец хатын. Балалар бакчасында мөдир булып эшли. Сөйкемле, игътибарлы, елмаюын артык тышка чыгармыйчарак сөйләшә. Шушы авыл очында йорт торгызып, хуҗалык корып, ире Таһир, карт әнкәсе һәм ике кызы белән яшәп ята. Сөйләшәбез: "Элек авылыбызда буш куралар ишәйгән иде, елдан елга арта иде буп-буш ихаталар, хәзер исә берәү дә калмады. Менә

безнең янәшәгә дә йорт салып куярга әзерләнәләр. Газ кергәннән бирле яшьләр авылга борылды. Су кергән, ут кергән, хәзер газ да керде. Шулар өчесе булганда авылга яшьләрне үгетләп торасы да юк. Алар үзләре кайтачак. Эш кенә табылсын".

Авыл очында, юл буенда өсте шалашлап капланган бәрәңге базлары. Әлмәтнең түбәнрәк урыннарында базга су керә башлаган. Юньле инеше дә булмаган, корылыктан интеккән Әлмәт базларында су каян килгәне дә мәгълум: нефтьчеләр җир астына туктаусыз кудырган су җир асты агымнары ясап, җир асты елгалары тудырган. Хәзер шулар астан гына кыймылдыйлар да, һич көтмәгән урыннардан килеп чыгалар. Алга таба ничек булыр. Җир асты тозларын, радиоактив элементларга бай катламнарны иген кырларына ташып куймасмы ул елгалар?!

**10 гыйнвар, Иске Әлмәт.**

Таң белән.

Төннәр шундый озын, ә күк гөмбәзенең нәкъ түбәсендә кич балкыган тулган ай таңда офыкка да тәгәрәп төшә алмаган. Чын кыш! Ап-ак, сап-салкын, җилсез, сәламәт кыш! Кичә Нәкыяне озаттык. Нигадер чиксез ямансу булып калды. Яңа урынга тәмам күнектем, ныклы тәртипкә кердем, яшим, эшлим дип куана идем. Нәкыя булганга икән. Менә аннан башка ничек булыр... Ничек яшәрмен дә, ничек эшләрмен?.. Бүген эшне һичшиксез дәвам итәргә кирәк...

Иртә чәйләдек, сигез тулып китүгә мин кичә йөри башлаган сукмакларга чыктым. Дөнья ап-ак, койма-капкалар, агачлар көмеш сыкыга төренгәннәр, чыгып килгән кояш нурлары баганаларны тоташтырган чыбыкларга сарган куе сыкы бауларындагы кристаллар аша үтеп, аларга сихри төсләр биргән. Чыбыкларны төргән кар бөртекләре нурланып елтыр-ялтыр киләләр. Урамны чыгып сулга борылдым, басу юлына төштем. Каршыма әкияти дөнья булып атаклы Әлмәт рушасы калкынды. Урман кырында бәсәргән куе нарат агачлыгы. Ак чал йөгергән наратлар авызларын ачып, шаккатып чыгып килгән кояшка текәлгәннәр. Алар артында ак нур таулары булып яшь кәләшләр—каеннар стена булып басканнар. Чаларган куе яшькелт наратларның иңнәренә басып акка төренгән каен-кәләшләр янына югарыга менәсе килә. Такыр юл да Әлмәтнең ындырларыннан башланып күккә иңә кебек. Мин онытылган хисләр дулкынында тирбәлеп шушы такыр юлдан, меңнәрчә күзләр елтыраган йомшак карларга басып ыгы-зыгылы бу дөньядан мәңгегә котылып каядыр китеп барам төсле. Мондый сихри манзараны, моның шикелле тоташ матурлыкны байтактан күргәнем юк икән. Әгәр юлны кисеп чыгып үткән куян эзләре булмаса бу дөньяны сихри бер төш дип уйлар идем. Куян эзләре дә күңелне күтәрә. Алар шушы тирәдә генә бәрәңге базларының өстен томалаган салам өемнәре янында уйнаклап йөргәннәр бит...

Көн шул кадәр матур булды. Иңнәрем шул матурлыкны тыныч кына күтәреп тора алмады, кат-кат утырып карадым, эш үрчемәде. Эш башлау—йөрергә тырышкан сабыйның беренче адымнары ул. Теләк зур, көч җитми, авып-авып китәсең... Әллә кыйналган тәнем белән газапланган җаным, шушы тынгысыз дөнья мәшәкатьләрендә, матурлык белән очрашканда хәлсезләнеп каламы? Ач заманда алабута кумәченә күнеккән кебек мин дә әшәкелекне генә кабул итеп, шуңа гына түзәргә гадәтләнеп киләмме?..

*Дәвамы киләсе саннарда*



Адлер Тимергалин

# СҮНМӘС УТ ЯНЫНДА УЙДА БЕЗ...

«СҮНМӘС УТЛАР БАЛКЫШЫ» КИТАБЫ ЧЫГУ УҢАЕННАН

«Еракка китеп кара!»—дигән иде Мөдәррис Әгъләм, Шагыйрь.

«Казан утлары» журналының меңенче саны чыгу унае белән 2006 елда нәшер ителгән «Сүнмәс утлар балкышы» китабы журналның сиксән еллык тарихына ерактан торып күз сала дисәк, хакыйкатьнең яртысын гына әйткән булырбыз. Чөнки бу мәһабәт Китап журналның үз эчендә кайнаучы кешеләр тарафыннан төзелгән һәм алар, әлбәттә, хиссиятле субъективлыктан арына алмаганнар. Юк, юк, алар моңа омтылмаганнар да. Һәм дөрес эшләгәннәр, югыйсә Китапның күңелебезгә тәэсир итү көче бермә-бер ким булыр иде. Кичәге кайгылар да бүгенгеләре белән аваздаш бит...

«Вакытлы матбугат—тактика, китап—стратегия» диләр. «Сүнмәс утлар балкышы» исә айлык журналыбызны дәвамлы тәэсир көченә ия булган стратегик коралга әйләндерә.

Китапны дөньяга чыгаручылар барысы да исемле-намлы затлар. Шунысын да әйтик, алар мактау-макталуга күптән инде мохтаҗ түгелләр.

Төзүчесе Рәфикъ Юныс, шеф-мөхәррире һәм проект авторы Равил Фәйзуллин белән мөхтәрәм редколлегия (Миркасыйм Госманов, Туфан Миңнуллин һәм Равил Фәйзуллин үзе) китапны гасырларга калачак әдәби һәйкәл һәм олы юлдагы маягыбыз итәргә тырышканнар.

«Татар әдәбияты тарихы»ның соңгы сәхифәләренә гаҗәеп матур иллюстрация килеп чыккан. Хәер, күмәкләшеп, кырыкмаса кырык төрле яки кырык төсле каләм белән язылган әлеге чуар күптомлык тарих һәм кулыбыздагы җанлы Китап арасында әсәрләрне бәяләүдә мөһим аермалар да бар һәм алар «Сүнмәс утлар балкышы» файдасына, ягъни тулаем журнал әһелләренең зәвыгы һәм гадел бизмәне файдасына сөйлиләр.

«Казан утлары»ның 2006 елгы 2 нче санында озакламый «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китапның дөнья күрәчәге игълан ителгән иде. Анда: «Мең сан эченнән иң шәп хикәяләр, шигырьләр, истәлекләр, юмор-сатира әсәрләре, әле дә кызыклыгын җуймаган, бүгенге күп кенә хәлләргә ачкыч булырлык мәкаләләр һәм документлар сайлап кертелгән бу китапны татар тормышының көзгесе дип атарга мөмкин»,—диелә.

Чыннан да, заманыбыз һәм язмышыбыз объектив чагылыш тапкан көмеш көзге бу Китап, әүвәлгечәрәк итеп әйтсәк,—Мирьат бу.

Әйе, хәтер көзгесе. Иннек-кершән сөрткән итеп, чибәрләп күрсәтә торган көзге түгел. Кәкре-бөкре көзге дә түгел. Булганын булганынча күрсәтә торган

гап-гади күзгә. Аның сихере дә шунда—чынлыкта инде, чөнки без житмеш ел буена бөкре көзгеләр дөньясында яшәп, кәкрене төздән аермас халгә калган идек бит.

Бу Китап—бөтен әдәбиятыбызга исән чагында ук куелган сәнгати һәйкәл, кабер ташы түгел! Кабер ташына гүр иясенең барлык эш-гамәлләрен теркәп калдырырга тырышканнар, ә сәнгати һәйкәл үз кануннары буенча торгызыла, барлы-юклы казанышларны ул кабул итми. Аннары бу Китап кемгә дә булса мәдхия җырлау белән дә шөгыльләнми.

Бу Китап—гадәти елъязма яки хроника-мазар түгел, әлбәттә. Ул чын маякларыбызны калку итеп күрсәтә, ә уртакулларга карашы—салкынча. Бу Китап «Казан утлары»ның йөзен һәм мәсләген чагылдыра дияргә мөмкин.




Киләчәккә хатыбыз ул безнең.

Пәйгамбәр Гаяз Исхакый алдан күргәнчә, «соңгы болгар» да вафат булгач, ерак оныкларыбыз «Сүнмәс утлар балкышы»н актарып, Исхакыйның болгарына җан кертә алырлар...

Әгәр дә мәгәр бер мәлне мине адәм заты яшәми торган утрауга озатасы булып, үзем белән ун китап алырга рөхсәт итсәләр, шуларның берсе һичшиксез «Сүнмәс утлар балкышы» булыр иде. Алай-болай ерак йолдызара сәяхәткә чыгып китсәм дә үзем белән алыр иде мин аны. Ул мине, зурдан кубып әйтсәк—туган планетама, тарихыбызга, рухиятебезгә, туган якларыма, кардәш-кордашларыма күзгә күренмәс рухи җепләр белән бәйләп торыр иде...

Кулыбыздагы «Сүнмәс утлар балкышы», төзүче вәгъдә иткәнчә, 1922 елдан алып чыгып килгән «Казан утлары» журналының төп-төгәл мең санының «каймагы», төше дип аталырга хаклы.

«Сүнмәс утлар балкышы» китабын, әйтик, авыру дәрәҗәсендә көнчел күршеләребез туздырган тузан кунмасын өчен, нәкышьле супертышлыкка киендереп чыгарасы калган. Ә бәлки аны, килешле күлмәк кидереп, «Казан утлары»ның әбүнәчеләренә, шул исәптән китапханәләргә һәм мәктәпләргә, почта аша (яздырып) таратуны оештырып буладыр? Китапның тиражы бүгенге көн өчен аз түгел (2 мең данә), аның һәр данәсен укучыбызга житкерәсе иде. Бусы инде стратегия.

Һәм менә мин бүген уртакул америкаң төрмә бинасына тартым «хрущоба»ның кысан фатир-мәгарәсендә, һава житмәгәндә тәрәзә ачкалап утырам. Тезәмдә кызыл мәрмәрдәй саллы том—үзе бер китапханәгә бәрабәр «Сүнмәс утлар балкышы».

Мин бу утларның саллы җылысын тезләрем белән дә, күңелем белән дә тоям. Тәрәз каршында ук үзебез—кооперативчылар утырткан каенлыкка ел саен сандугач килә инде. Быел икәү килде. Ханс Христиан Андерсен әкиятендәге кебек, адәмне савыктыра торган былбыл моны китабымдагы олпат татар шигырьләренә һәм хикәятләренә аккомпанемент булып үрелеп бара, сарылып бара...

Дөрес, сабый күңелле сандугач мин Ф.Мөсәгыйть ишеләрнең «җәүһәр»ләрен укыганда да тынып калмый-калуын, вәзенле чут-чутларын тезә бирә. Ялаяп Мөсәгыйтьләрдә эше юк самими кошчыкның, куркуны белми—Аллага шөкер, башы яшь, аны өркетүче булмаган һәм—өметләник—бәлки булмас та.

Фатих Хөсни «Казан утлары» журналы «безне үстергән «яшел бишегебез»

булды»,—дип язган иде. Бу сүзләрне һәр татар язучысы бүген дә кабатлый ала. Беләсезме, язучы гына түгел, Һәр милләтпәрвәр әйтәчәк сүз бу.

Нажар Нәжми «Казан утлары»н юкка гына «милли ут» дип атамый! Ул утта Нажар Нәжминең үзенең дә якты чаткысы бар.

Китапның чорларга бүленеше табигый, ул бүлекләрнең һәрберсенә, оригиналь үк янгырамасалар да, мәгънәле һәм килешле исемнәр (баш) табылган («Без тарихта эзлебез», «Ил корабын җил сөрә», «Болгавыр еллар», «Без сугышта юлбарыстай көчлебез», «Торыгыз, Мусалар!», «Язмышлар ярында», «Без яшәргә хөкем ителгән»). Хәер, бәлки, исемнәре үтә оригиналь булса, укучы, кирәксезгә, маңгаен җыерып уйлап торырга мәҗбүр булыр иде, андый башваткыч монда кирәк тә түгелдер.

Беренче бүлек Нурихан Фәттахның «Тарих сәхифәләрен актарганда» дигән мәкаләсе белән ачыла. Яшь Нурихан, гыйшкы төшеп, бу заман турында роман да иҗат иткән ерак Болгар чоры:

*Әтил суы ака торур,*
*Кыя төби кака торур.*
*Балык телим бака торур,*
*Күлең тәки кушәрир.*

Татар күңеленә аерата якын бу борынгы дүртьюллыкны Идел суы агып торганда без дә яшәп торырбыз, «Нурлы Казаныбыз» да яшәр дип аңлыйк.

Шигырьдәге соңгы ике юлны «Балыгының бакый бетәсе юк, Култыклары тулып торыр» дип яңача укырга җөрьәт итүемне бераүгә дә белдерергә ашыкмаган идем. Барча галим комментаторлар, тешләрен кысып булса да, кабул кылган прозаик җир-су хайваны баканы борынгы шигырьдән каерып алып атканым өчен, бәлки, әзрәк шүрләгәнмендер дә. Нурихан Фәттахтан, фәкать аңардан гына: «Афәрин!» дигән сүзне бик ишетәсем килгән икән...




*Җиде бүлекнең берсе шушылай башланып китә.*

Китапны Фәттах ачып җибәрә, дидек. Төзүче аны алга куйганда бу күркәм исемнең төп мәгънәсе «ачучы» булуын, бәлки, искәрмәгәндер. Искәрмәгән булса, тагы да әйбәт—ничектер серлерәк, бу хәтта илаһи бәхетле очраккa ишарәли төсле, чөнки Фәттах—Аллаһның мактаулы исемнәреннән берсе дә бит әле. Нуриханга янә нур өстәгәч, балкыш килеп чыга инде...

Китапны актарам.

Шулай ук гыйбранига тартым үҗәтлек (максатчанлык) иясе мәрхүм Тәуфикъ Әйдинең «Яшерен васыять» дигән язмасы да керә беренче бүлеккә. Мәгълүм булганча, «Петр патша васыяте»нең тексты Төркиядә чыга торган «Төрек культуры» журналының 1990 елгы 323 нче санында басылган. Аның Тәуфикъ Әйди эшләгән татарчага тәрҗемәсе «Казан утлары» журналының 1992 елгы 1 нче санында дөнья күрде. Васыятьнамә тексты «Сүнмәс утлар балкышы» мәҗмугасендә дә урын тапкан.

«Васыятьнамә»нең чын дөреслеге исбат ителмәгән булса да (күбәүләр аны фальсификация дип саный), Патша Россиясе һәм СССР империясенең тышкы (шулай ук эчке) сәясәте, аның нәкъ Петр патша «васыяте»нең бөекмәмләкәтчел принципларына тәңгәллеге бу хакта безне житди уйланырга мәҗбүр итә.

Бәләкәй генә белешмә.

Бөек фикер иясе Лев Толстой император Петр патша турында: «Һәйкәлләр кую түгел, аны тәмам онытырга кирәк»,—дигән. Ә чордашлары (мәскәүлеләр)

Петрны кеше дип түгел, «антихрист» дип атаганнар. Явыз Иваннан да кансызрак дуамал рус императорына төрекләр биргән кушамат дөреслеккә бик туры килә, алар бу залимне «тиле Петро» дип йөрткәннәр (моны Габделбари Баттал Таймас яза), чөнки ул патшалык иткәндә Рәсәйдә дар агачлары һәм җәллад балтасы ялны белмәгән... Татардан күзе кара булган өчен дә, җомга намазына йөргән өчен дә, инештәге яна бәке өчен дә өстәмә салым каера башлаганнар. Халыкның йөрәк өзгеч «Лашман бәетләре» Петр патша заманында чыккан. Менә шушы затка бүген яна һәйкәлләр торгызып, исемен диварларда кабатлыйлар инде.

«Ил корабын җил сөрә» дип исемләнгән икенче бүлектә Г. Ибраһимовның «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән әтрафлы мәкаләсе урнаштырылган. 1927 елда тезис-доклад итеп язылган бу мәкаләдә автор үзенең теоретик фикерләре белән уртаклаша, татар мәдәнияте үсешенең перспектив юлын, аның үсеш баскычларын, максудын билгели. Теориядә бик дөрес булган фикерләр белән янәшәдә без бөтенләй икенче Галимҗан Ибраһимовны да күрәбез. Кол-габид Ибраһимовны. «Минемчә,—ди ул,—моңа иң ачык һәм тулы җавапны И. В. Сталин иптәш бирде.» Сталин тоткан милли сәясәтнең нинди җимешләр җитештерәсен, миллионнарча корбан сораячагын Галимҗан Ибраһимов белмәгән әле... Боларны ул берничә еллардан соң «мөлдерәмә тулы җамаягы белән» татыячак.

Кулыбыздагы Мәҗмуганы төзүче бу вакытта Галимҗан Ибраһимовның капма-каршылыклы шәхес булуын (моңа мәҗбүр ителүен) күрсәтүне дә күздә тоткан шикелле.

Шушы ук бүлектә Рәмзи Вәлиев белән Мөхәммәт Мәһдиевнең «Болганчык еллар авазы» дигән мәкаләсен (1992) укучы кат-кат күздән кичерер дип уйлыйм. Бераз купшы беллетристикага тартымлыгы игътибарны тупларга комачауласа да, мәкалә укучыга нык тәэсир итә. Аны укыйсың да, аптырашка каласың. Әдәбиятчеләр әртилендә рәтле-башлы бер генә шәхес тә күренмәгән кебек... Киләчәктә байдә тоту өчен, «Черек күл» психологлары аларның һәркайсын нәҗескә буяп ташлаганнар. «Антисовет җидегәнче»ләргә нисбәтән язылган яла-әләкләр санап бетергесез һәм аларны шушы «җидегәнче»ләрнең могтабәр каләмдәшләре, көн саен кул кысышкан һәм президиумда янәшә утырган иптәшләре язган. Каләм ияләре арасында кыргый, хайвани паника куптан диярсең.

«Җидегәннең бөтен трагедиясе Г. Минский хаты аркасында дип уйларга тулы нигез бар»,—дип язалар Рәмзи Вәлиев белән Мөхәммәт Мәһдиев.

Авторларның фикере документлар белән дәлилләнә.

Мәкаләне укыгач: «Их, Минский, Синский»,—дисең.—Их, Такташ, Такташым... Их, Туфан, Туфанкаем...»

Әйе, документлар белән танышканнан соң, «Кальбемне һәм тәнемне шакшы-пычраклардан арула» дип, белгәненне укый башлыйсың. Такташның вакытсыз үлеме дә, Туфанның һәм зәгыйфьлек күрсәтеп җәзадан котылып калган Минскийның язмышы да аңлашыла төшә. Исхакыйны кайсыдыр бер пьесасында «Качкинский» дип сурәтләп, авыз ерган «кәбестә төсле беркатлы» Нәкый ага Исәнбәтнең дә.

Шулай да чорны онытуу ярап бетмәс. Черек күл буенда дәһшәтле төн үткәреп чыккан кешенең рухын совет җәлладлары какшаткан була инде. Андагы бөгелмәс билне сындыру осталарыннан урта гасыр инквизиторлары да көнләшерлек бит.

Кем әйтмешли, ул заманда җил-янгыр тимәгән һәр әдипнең өендә—кием шкафында—каләмдәшенең скелеты басып торган. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, Ф. Мөсәгыйть кебекләрнең фатиры скелетлар коллекциясе тупланган тәшрикханәгә—анатомия театрына әйләнгәндер.

Мөсәгыйтьнең «Җидегән» исемле шакшы мәкаләсен Китапта кыскартып басканнар. Гаҗәп тә соң, мәкаләнең тулаем сәвадсыз-грамотасыз кеше

тарафыннан язылганлыгы кычкырып тора. Күрәсең, бер кичтә әмәлләп ташланган нәмәрсәдер. Бәлки мона телефоннан әйтеп яздырганнардыр әле. Мисаллар китереп торуны кирәксенмим—вакыт әрәм. Һәм менә шундый лилипутның берничә еллар дәвамында әһле әдәбият гулливерларын дер калтыратып тора алуына күнел ышанмый.

Эзләп карыйсы иде, бу бәдбәхетләрнең шәхси архивы исән микән? Юктыр, исән түгелдер. XX съездда Хрущев ясаган докладтан соң күп кенә кәгазьләрен утка атканнардыр. Хәер, бу дөньяда могҗизага да урын бар-барын. Кем белә, бәлки берәр татар сексоты, шымчы, җасус, тарихка арт ишектән булса да кереп калу нияте белән, хатирәләрен язып баргандыр..?

Менә без бүген Сара Садыйкованың «Җидегән чишмә» җырын (сүзләре прозаик Гомәр Бәшировныкы) әсәрләнеп тыңлыйбыз. Бу чын милли көйдә— бүгенге «Әллүки»дә диясе килә—авторлар безнең белән хушлашалар, бәхилләшәләр. Ә теге заманнарда «Җидегән» дигән сүзгә табу салынган була, аны кабатлап әйтергә дә курыкканнар...

«Сүнмәс утлар балкышы»на кергән кайбер әйберләргә яңа күз белән, хәтта шикләнебрәк тә карыйсың, ләкин беренче тапкыр укыгандагы кебек үк тәэсирләнәсең.

Ибраһим Газиның «Тургай картаямы икән?» дигән ике-өч битлек кенә хикәясе шушы ук авторның биниһая сузылган каучук романнарыннан көчлерәк икән. Каләмнәре Әмирхан Еники белән уртакка булган диярсең.

«Юмор-сатира» дигән баш астындагы «Шаян җырлар» кайчагында безгә зур гына мәкалә сыйдырган кадәр мәгълүмат бирә:

*Кулымдагы йөзегемдә*
*Фатих Хөсни исме бар.*
*Булса да темалары тар,*
*Ошый торган име бар.*

*Кулымдагы йөзегемнең*
*Максуд иде исеме,*
*Элек язган нәсерләре*
*Хәзергесе ишеме!*

*Кулымдагы йөзегемнең*
*Исеме Әнәс Камал,*
*Дуэт-такмак язып кына*
*Йөрер микәнни һаман?*

Хакыйкать тә, усаллык та җитәрлек бу такмакларда.

Шәйхи ага Маннурның «Тартай арбасы» дигән әкиятен хәзер бик белеп бетермиләр. Беренче тапкыр «Совет әдәбияты» журналының 1947 елгы 4 нче санында басылган ул.

«Ике тартай, бер бытбылдык юлга чыкканнар...» Әкият шулай башлана иде. Болар ниндидер бер арбага җигелеп Каф тау артына ук—батман алтынга дип баралар. Юлда төрле хәлләргә юлыгып, арбалары ватылып, сазга батып иза чигә болар. Бытбылдык: «Хур булдык, хур булдык!»—дип сөрән сала имеш... Үзләре һаман баралар да баралар ди болар... батман алтынга.

«Инде коммунизм кыры күренә» дип, хыялый миражга алданган заман иде бу. «Тартай арбасы»н кайсы мөртәтедер «коммунизм арбасы» дип анлый да, әләк язып, терек-терек өлкә комитетына йөгерә. Бүген бу көнчел бәндәнең кемлеген, ихтимал, әлегә ачылмаган архивлар гына белә торгандыр. Әлбәттә, әкият идеологик яктан зарарлы дип табыла, аның турында партия өлкә комитеты бюросының махсус карары да булды шикелле. Авторны партиядән чыгарып маташканнар.

Шәйхи ага Мәскәүгә, ВКП(б) Үзәк Комитетына тикле барып житә, ничек итсә итә, әмма тәмам акланып кайта. Тешләгән жиреннән өзә торган зат иде ул. Нәселләре белән шундыйлар дип сөйли иде белгән кешеләр.

«Тартай—Коммунизм арбасы»—сугыш елларын күргәннәргә бик таныш «уфалла арбасы» кебегрәк «транспорт чарасы» була инде. Аны «Рәсәй арбасы» дип аңласак та әлләни ялгышмабыз. Шәйхи аганың туганнары гафу итсен, ләкин бу юлы Ялаяповлар гел дә юкка тавыш куптармаган дип уйлыйм.

Ш. Маннур күмәкләшүдән соң язып ташлаган «Гайжан бабай» кебек чат кызыл мәдхиянен (һәм аның дәвамынын!) бу Мәжмугага да, шигырь антологияләренә дә керергә хакы юк, әлбәттә.

Ә менә «Тартай арбасы»нын бар дияр идем. Һәрхәлдә «Сүнмәс утлар балкышы» китабында әлеге әкиятне кайбер аңлатмалар белән биргәндә укучы ул чорны яхшырак күзаллар, аның бумалы һавасын үзе сулаган кебек булыр иде. Текәлебрәк карасак, әдипләребезнең ижатында шулай ак белән караның чиратлашканын күрәбез. Мондый ала-кола (аклы-каралы) ижат, бәлки, әдипнең үзе дә аңлап бетермәгән эчке көчләр көрәшен чагылдыра торгандыр, кистереп кенә әйтүе кыен.



*Татарча язулы Мәскәү акчалары.*[1]
*«Мәсәлән, 1482—1505 елларда олуг князь тәхетендә утырган Иван Өченченең үз акчаларына «Мәскәү акчасы будыр, Ибан» дип татарча язу сугуы гына түгел, бәлки аңардан элеккеге олуг князьләрнең дә русча төзелгән васыятьнамәләргә «болай уң күрдек», «алтмышта янбар айында» дип татарча резолюция салулары безнең әлеге фикеребезне артыгы белән раслый...» (М. Госманов. Язма мирасыбызның күтәреләсе катламнары.)*

Бастилияләрне жимереп бетерәсе урында, без житмеш ел буе яңа зинданнар гыйммран итү белән шөгыльләндек. Ил такта-toktадан әмәлләгән бараклар һәм тулай тораклар белән тулды. Еллар үтеп, аларга панель «хрушевка»лар алмашка килгәч, халык ожмахка күченгәндәй булды... бер катка. Коммунист түрәләр, әлбәттә, кирпеч «сталинка»ларда яшәделәр.

Ә бүген илне кичәге Бастилия архитекторлары һәм назирләре идарә итмимени? Ил байлыгын өч тиен түләп хосусыйлаштыручылар шулар түгелмени? Фәнне күптән академик ялга китәсе партбилетлы тере мәетләр житәкләве дә жанга тигән иде... Алар бит фән арбасын, мәсәләдәге кысла шикелле, артка өстерәделәр. Әдәбиятны да.

Без, ватансыз чегәннәр кебек, һаман юлдабыз. Безне һаман шул «батман алтын» белән алдыйлар. Бурлак-буралгылар шикелле, ватык-жимерек «тартай арбасы»н тартабыз.

«Каф тау алтыны» үз жирендә кала бирсен. Ул безнеке түгел! Безнең дә кара алтыныбызга тимәсеннәр!»—дияргә куркабыз.

Китапны төзүче һәм редколлегия, шигырьләрне сайлаганда, саран кыланганнар, муен артларын кашый-кашый, барчасын жиз иләк аша үткәргәннәр, күрәсең.

Ихтимал, кайберәүләр нигә Китапка минем шигырь сыймаган? дип үпкәли дә торгандыр.

Алайга китсә, нигә даһилар даһие иптәш Сталин турында Мәжмугада бер генә шигырь дә кабатлап басылмаган? дип, яхшук «шаян» сорау китереп куя алам. Объективлык хакына. Әйтик, 1949 елны (Сталин бабана 70 тулганда)

[1] Рәсем-сурәтләр — «Сүнмәс утлар балкышы»ныкы. Алар авторның сүз сөрешенә бәйсез рәвештә, хронологик тәртиптә бирелә. *Ред.*

гәзит-журналларда номер саен юлбашчы турында шигырь йә җыр басылмый калмый, ә Сталин исеме бер санда йөзләрчә тапкыр кабатлана иде.

Бу шаукымга бирелмичә калган шагыйрьне белсә Әбрар Кәримуллин гына белгәндер. Менә шушында Шүрәлем килеп кытыкларга тотына: «Ә бүген?— ди ул.—Әгәр дә мәгәр Сталин золымы әйләнеп кайтса (тфү!), кайсы гына куштан рифмачы шушы кавказлы башкисәргә дан җырламыйча калыр иде?» «Пакь каләм ияләре икәү-өчәү генә булса булыр иде»,—дип җавап бирә Шүрәлем үз-үзенә.

Олысын, кечесен җен алмаштырган һәм саташтырган заманнар бит. Әткәсен сатучы Павлик Морозовның, үзен коллыкка бушлай тапшырган самими Павел Корчагинның рәсемен ызбаның кызыл почмагына тәре урынына элделәр. Коръәннәр, шамаилләр, Инҗилләр һәм тәре-иконалар яндырылган, мәчетләр «сөннәткә утыртылган» дәһшәтле еллар иде бу. Павел Корчагинны (Николай Островскийны) кызганам мин. Ә пионер Павликны кызганышлы түгел, соңыннан тәпченә башлагач, Урал якларында андый тиле малайның бөтенләй булмаганлыгы беленде. Кызык бит, Аркадий Гайдарның кызыл галстуклы Тимуры (һәм аның командасы)—авторның хыял җимеше генә, ләкин укучыны бу малай яраттыра һәм ышандыра, пакьлеге һәм самимилеге белән алдыра ул. Ә безнең Гариф Гобәй белән Роза Хафизованың кызыл галстуклы курчак малайлары һәм кызлары ышандыру көченнән мәхрүм, чөнки алар буш хыялдан да сыеграк «куян шулпасының шулпасы» гына иделәр.

«Халык рухы тәмам зәгыйфьләнгән чорлар була... Шул чагында әдәбиятның да биле сынып, ул җинүче сыйныфның мәгънәсез һәм канунсыз кыланышларына мәдхия җырларга тотына. Ә бит башка вакытта ул алардан җирәнеп йөз чөергән булыр иде.»

Революцион-демократ Добролюбовның әлеге сүзләрен яшь чагымда истә калдырган идем. Фикере искермәгән дә, картаймаган да. Хәтеремдә янартырга тырышып, шуны монда татарча язып куюым.

Журналыбыз тарихында караңгы сәхифәләр бар, чөнки сәяси зәхмәтләр берсе дә аны читләтеп үтмәгән. Ул берничә тапкырлар иманыбызга, динебезгә каршы көрәшкә кузгалып ала.

1963—65 елларда журналда җаваплы секретарь булып эшләгән Әхсән Баяновның «Хыялда туган калам» дигән автобиографик әсәрен заманында укымый калган булганмын. Аңардан бер өзек шушы Мәҗмугага да кергән. Өзектән Гариф Гобәйнең шул 60 нчы елларда дөнья күргән «Коръән серләре» дигән пасквиленең журналда басылу тарихын уку миңа да кызык тоелды. Урыны-урыны белән солдат анекдотына охшап кала торган бу әйберне, партиячел юнәлеш тоткан дәһри авторга күбрәк гонорар түләү өчен, журналның алгы өлешенә—нәфис әдәбият бүлегенә күчергән булганнар икән. Бу мәсьәләдә редакциядә әзрәк ризасызлык та булып алган.

Гариф Гобәйнең «Антикоръән»ен басу, һичшиксез, журналның хатасы иде. Соңыннан исә журналыбыз, бу ялгышын танып, үзен реабилитацияли алды дип әйтәсе килә. Моңа да көч һәм тәвәккәллек кирәк булгандыр.

Без инде монысына да канәгать.

Узган гасырның 70нче елларында, борынгы сугыш баһадирларының көбә күлмәге шикелле калай күкрәкле кашлач генсек Брежнев чорында, коммунистлар партиясенә беренче чиратта эшчеләрне алганнар. Норма буенча, тугыз эшчене кабул иткәч кенә унынчысы зыялы интеллигент булган икән. Чөнки шуны аермачык күрәләр: аена 120 тәңкә алып эшләүче зыялылардан диссидентлар чыга, эшче халкы исә, «артык» тиеннәрен арзанлы сыраханәдә калдырып, бөтен ачуын аты-юлы белән сүгенү кебек «зыянсыз» эшләргә тотып бетерә...

«Болганчык еллар авазы» мәкаләсенең авторлары: «Эшченең станок янында басып торасы, машина йөртәсе, урман кисәсе, күмер чабасы бар. Идеологиягә катнашырга аларның вакыты калмый—җитәкчелек өчен нәкъ менә шул кирәк

тә»,—дип язалар. Дөрес. Ләкин нечкәләбрәк карасак, монда милли мәсьәлә дә калкып чыга әле. Еврей мәсьәләсе. Урман егып яткан, ятып күмер чапкан, олау белән элеваторга икмәк ташыган, сабан сөргән еврей хезмәт иясен бик үк күз алдына китереп тә булмый. Һәм КПСС Үзәк комитеты әлеге сәясәте белән берьюлы ике куянны тота иде. 1917 елда большевикларны хакимияткә китергән зыялыларның милли составы беребез өчен дә сер түгел. Совет чорында идарә эшендә мондый зыялыларның керәге калмаган кебек иде. Ликбез курсларын үткән җирле кадрлар—уртакуллар диктатурасы башланды. Әлеге зыялыларның Израилгә качып бетмәгәннәре берәр директорның урынбасары яки киношчесе булып калдыкалуын, чөнки аларсыз эшнең алга бармаганлыгы һәм бармаячагы бик тиз күренде...

Ярар, кем әйтмешли, болары инде бөтенләй башка һәм, шик тә юк, берәүләр өчен бик кызыклы, берәүләр өчен бик тә кызыксыз тарих... Без монда юдофобиягә (ягъни йәһүдне сөймәүчелеккә) катнашы булмаган битараф кешенең дә чәчләрен үрә торгызырдай рәсми фактларны һәм саннарны китереп тормабыз, чөнки темабыз моны сыйдырмый, ә арзанлы сәясәтбазлык белән шөгыльләнәсебез килми.



*Рус армиясенең литва-татар полкы сугышчысы.*

Йөзәр меңлек тираж белән чыккан китапларга да кытлык булган вакытларны хәтерлисезме? Затлырак китаплар махсус исемлек буенча гына кибетләрнең арткы ишегеннән таратылды. Ә гавамгә дигән киштәләре большевистик макулатурадан сыгылып-сыгылып тора иде. Соцреализм ашаган кәгазь рулоннарын санап карасак, ул бөтен Җир шарын ничә кат кәфенләргә җитәр иде микән?

«Букинист» кибетенә еш йөрдем мин ул елларны. Кызыклы гына очраклар хәтердә. Шулай, бервакыт кибеткә яшел рюкзак күтәргән таныш кеше килеп керде. Моны без әле былтыр гына баш редакторлыктан «лаеклы ял»га озаткан идек. Капчыгы тулы марксизм-ленинизм классикларының әсәрләре... Атна-ун көн генә үтсә үткәндер, шул ук кибеттә бу юлы инде элекке нәшрият директорының кызыл тышлы китаплар тапшырып торуын күрдем. Монысының да ярты «байлыгын» кире бордылар—ниһаять, Карл Маркcларның базары төшә башлаган иде инде. Директор чыгып киткәч, кызыксынып, моның бер «классикасын» актарып карадым. Сталин чорында ук басылган шактый калын бу китапның битләре дә киселмәгән булып чыкты. Шул килеш саргайганнар... «Мәҗикнең мәҗиге» булган нәшрият директоры кайчандыр кунак залындагы шкафын «бизәп» торган бу китапны әллә 30, әллә 35 тиенгә тапшырган иде.



*Наполеон армиясендәге татар эскадроны атлысы. (Р. Таһиров. 1812 елгы Ватан сугышында Казан татарларының катнашуы тарихыннан.)*

Татар китабын дөньяга чыгару әнә шундый таш маңгайлы монафикълар кулында иде бит. Фаҗигаме? Фаҗига. Кәмитме? Кәмит. Сабакмы? Ала алсаң гына,—сабак.

Безнең буын татар укучысы бестселлер дип аталырга хаклы бер генә әдәби китапны да күрми үсте. Хөр әдәбиятка бай Көнбатышта исә бестселлердан да уздырган мегаселлер дигән термин барлыкка килеп өлгерде. Беренчесе миллионер булса, бусы миллиардер шикеллерәк инде...

Сатлык әдәбият кибет киштәләрендә сатылмыйча ятты.

Ә бит татар әдәбиятының олуг тарихы бар. Тик бүген ул үсештә артта калды, чөнки эчке сәбәпләр генә түгел, тышкы сәбәпләр дә әдәбиятыбызның үсешен тоткарлыйлар, аңа үсәргә ирек бирмиләр.

Татар әдәбияты—Ханс Христиан Андерсенның «Шыксыз үрдәк бәпкәсе» шикеллерәк. Без әдәбиятыбызның матур киләчәгенә—әкияти аккош булып житлегүенә өмет итәбез, татар әдибе шуның өчен каләм тибрәтергә тиеш дибез.

Моннан егерме ел элек зыялыларыбыз төштә дә күрмәгән зуп-зур исем йөртүче бүгенге голямаларыбызның корама тел белән көчәнеп язылган мәкаләләрен укыйсың да... җансыз җөмләләренең көпшәклеген тоеп, кәгазьгә төшкән арада искергән фикерләрен, урынлы-урынсызга кыстырган шәрык сүзләрен, шәкерт каләменнән туган зәвыксыз һәм күрексез чагыштыруларын укып гаҗәпләнәсең... Арада берсе бар, кырык ялгаулы дилбегә буе җөмләләр төзеп күрсәтергә маһир, аларның ахырына барып житкәнче башын үзе дә оныта.

Чын белгечнең төшенә академиклык дәрәҗәсе һәм акчасы кереп йөдәтми. Ак. Сергей Капица кебек хакыйкый галим яшь Рамзан Кадыйровлар әгъза булып торган әкәмәт академияне ташлап чыгу турында уйлап куйса гаҗәпмени?..

Хәзерге татар язучыларының күпчелеге оригиналь әдип түгел, алар—кучереп язучы хәттат кына. Маймуннарча тәкълид, башкаларга иярү хасияте көчәя генә бара һәм былтыргы «а»лар турында роман язучы әдипләр асылда милләткә аяк чалалар, аңа җәһәт атларга ирек бирмиләр. Деградация. Затсызлану. Токымсызлану.

Язып азаплanучылар буа буарлык, газапланып язучылар сирәк.

Бусын да Шүрәле-ярымтык «фөкере» дип кабул итегез.

Менә тагын Шүрәлемнең ифратчыл сүзе: «Әдәпсез әдипләрегез «Татар хатыны нилэр күрми» белән канәгатьләнмичә, «Татар хатыны нилэр күрсәтми» дигән роман язып яталар... Эстрада йолдызларыгыз бәллүр башмак турында гына түгел, пыяла күлмәк турында хыяллана... Хәдтин ашып шашканнары бөер-бөйрәкләрен үтәли күрсәтердәй крем уйлап табучы егеткә бүләк бирергә разый...»

Сыйдырыш ягыннан урта гасырлар фолианты белән чагыштырырлык бу Китап Зөлфәтнең «Яшәр безнең журналыбыз!» дигән шигыре белән тәмамлана.

*Исән безнең кәрван башы,—*
*Яшәр газиз журналыбыз!*

Нинди матур һәм мәгънәле сүз ул—«кәрван башы»! Бик борынгы заманнарда сәфәрчеләр кәрван башын имам дип йөрткәннәр,—шуны да әйтим әле. «Казан утлары»—безнең имамыбыз, һәм без аңа иярәбез, аңа ойыйбыз.

Нәфис әдәбият дибез.

Әдәби әсәрнең сыйфатын бәяләүдә төгәл критерийлар бармы соң? Гомуми критерийлар бар-барын. Аларның иң беренчесе—әсәрдәге яналык, беренчеллек, әлбәттә. Фәнни яки техник ачышка таныклык (патент) биргән вакытта беренче нәүбәттә аның яңалыгына игътибар ителә. Ләкин фундаменталь, әсасый фәндә яңалыкны билгеләү әлләни кыен түгел, һәрхәлдә мөмкин нәрсә. Монда тест дигән алымны да кулланып була торгандыр. Сәнгатьтә исә эш башка... Монда психологик фактор килеп кысыла. Монда яңалыкны замандашларының ничек

кабул итүе дә, аның нәкъ кирәкле мизгелдә игълан ителүе дә мөһим. Гениаль әсәр өстәл тартмасында озак ятса, ул сәнгать тарихына вакыйга буларак теркәлми кала һәм мондый әсәрнең авторын инсаният күрми үтә («прозеванный гений» дигән төшенчә бар). Ана тиешле урынны, бераз соңрак иҗат ителгән булса да, шундый ук кыйммәткә ия булган башка әсәр ала. Ә фәнни-техник ачыш ясаучы, беренчелекне дәгъва кылып, моннан соңгы тарихта танылырга да мөмкин...

Сәнгать прейскуранты исә үзгәрүне белми диярлек. Нефертити ... Венера Милосская ... Мона Лиза ... Дауд сыннары ... «Робагыйлар» ... «Илаһи комедия» ... «Гулливер сәяхәтләре» ... «Дон Жуан»... «Евгений Онегин» ... «Ревизор» ... «Безнең заман герое» ... «Шыксыз үрдәк бәпкәсе» ... «Чия бакчасы» ... Болар барысы да мәңгелек маяклар булып хисаплана. Ул маякларга тиң әсәрләр санап бетергесез күп югыйсә, тик болары, адәмнәргә хас каприз аркасында, күләгәдәрәк кала... Мәңгегә.


*Галимҗан Ибраһимовның 1919 елның җәендә Колчак тылында йөргән вакыты. (Ә. Сөләйманов. Революция елларында.)*

Сәнгатьчә сурәтләүгә бәя бирүдән дә нечкәрәк эш юктыр. Монда да субъективлык һәм кайчагында сәясәт хөкем сөрә. Әйтик, соцреализм әсәрләренең күпчелеге нинди дә бер вакытлы прейскурант бизмәненә салып үлчәнде. Сталин премиясе алган йөзләгән әсәрләрне, аларның каһарманнарын хәзер кем искә төшерә? «Язгы җилләр»не, мәсәлән? Татар хәтере ул чорның «көзге ачы җилләр»ен генә белә.

«Хәлвә, хәлвә диеп кенә авызга татлы тәм керми»,—ди таҗиклар. Дөрес, психологлар моның белән килешеп бетми. Ачы турында уйлаганда ук ачы тәм тою кебек физиологик күренеш нормаль санала. Әмма таҗик мәкале аш кайнатуда катнаша торган реаль татлылыкны күздә тота... Соцреализм—сахарин кебек ялган татлы әдәбият ул, алдавыч җим ул. Әйтәсе килгән фикерем шул гына.

Сүзгә саранлык, җыйнаклык—сәнгатьчәлекнең мөһим билгесе. Мин монда юл арасына яза белү осталыгын гына күздә тотып әйтмим. Анысына өйрәтеп тә, өйрәнеп тә була торгандыр. «Кеше, Сәнгать һәм Табигать сүзсез генә сөйли беләләр.» (Л.Сагдадзе-ханым, «Әбүгалисина»/«Ибн Сина» китабыннан.) Чиксез күп кырлы һәм күп мәгънәле сурәтең сөйләсен. Тыныш билгеләрең... «Күп сүз—юк сүз»,—ди бит халык та.

Кирпеч калынлыгы роман—егерме беренче гасырда казылма мамонтка тиң. Анда сусыл һәм төче ялган күп, фальшь күп.

Язучының базары төште хәзер. Чөнки күп язалар, әштер-өштер язалар. Кибет киштәләре «абыстай романнары», башваткыч детективлар, һәртөрле уйдырма «фикшннар», тарихи фэнтезилар белән тулды... Телевизорны ачуың белән сиңа алтатар көбәге карап тора... Әдәбиятны һәм сәнгатьне масскультура конвейерына әйләндерделәр—бөтен бәла шунда. Бу конвейер, «күмүшке аппараты» шикелле тамчылап, агуын берөзлексез җитештерә тора. Укучылар һәм тамашачылар нәрсәнең агу, нәрсәнең чәчәк балы икәнен аңламый башлады инде.

Кайбер китапны кулга аласың да бер-ике битен укып карыйсың. Шуннан ук авторның биографиясе сыек икәнлеге күренә: аяз күк, туп-туры юллары балалар бакчасыннан башлана да, әзрәк аң кергәч, ясле мисалындагы Мәскәү әдәби курсларыннан соң, алар, шомарган каләм һәм катыргы калкан белән яракланып, олы юлга, хөррият ярминкәсенә дан-шөһрәт дауларга чыгалар...

Мәскәү курсларына тел тидергәнем өчен яратмаслар да, бәлки. Бу курслар

безгә, кара гавәмнән күтәреп алып, Рәсүл Гамзатовны, Виктор Астафьев кебек хакыйкать сөючене бирде диярләр. Ә бит заманында Евгений Евтушенконы аннан кудылар, башта комсомолдан да чыгарып маташтылар бугай. Сүз дә юк, анда укып кайтучылар роман язу техникасын яхшы гына үзләштергән була. Шома техникасын гына шул! Ә романның рухы, җаны да булырга тиеш бит әле. Фатих Хөсничәрәк итеп әйтсәк, аның Наташасы истә калырга тиеш. Боларына Мәскәү өйрәтми, өйрәтә алмый, чөнки бусы мөмкин эш түгел. Болары чыннан да «алладан һәм балачактан килә».

Әйтик, Муса Җәлилнең «бригадир кыз Фәйрүзә»се истә калмый.

Ләкин һәр әдипнең үз «Моабит дәфтәре» булырга тиеш.

Дөрес, Моабит курсы үткән һәркемгә һәйкәл куймыйлар. Югыйсә бүгенге бурзай каләм осталары «Моабит дәфтәр»ләрен кочагы белән сатып кына алырлар иде.

Тукайныкы кебек үк булмаса да, һәркемнең үз Шүрәлесе булырга тиеш. Скептик Шүрәле. Ул синең тормозың һәм шәхси тәнкыйтьчең, таләпчән цензорың. Кайчак ул синең якын киңәшчең дә... Кәефе килгәндә ул синең каләмеңне очлап бирә... Ачуы килгәндә язганыңны ботарлап атарга йә яндырырга куша... Вөҗдан газабы—Шүрәлеңнең эше. Шүрәлең сине «әдәмчеккенәм» дип йөртерлек гади бул...

«Кесәңдә акча булсынга дип язмаска кирәк,—ди Шүрәле.—Югыйсә син кәсепче булып, Фатих Хөсниегез әйткән «су өстендәге күбек» булып калачаксың... Сыра кружкасындагы күбек... Буш куык...»

«Галимҗанны да, Хемингуэйны да өйрән, ләкин барыбер үзеңчә яз! Беркайчан да көчәнмә, күңелең ни тели, шуны яз! Фәкать шул вакытта гына яхшы әсәр чыгарга мөмкин»,—дигән иде өлкәнебез Гомәр Бәширов.

«Сүнмәс утлар балкышы» язучыга сыйфат планкасын һәм шул ук вакытта белем багажыңны күтәрергә боера.

Бездә Андерсен исемендәге «грамота» ияләре бар-барын. Беләсе иде, татар язучылары арасында Андерсенның «Тәрҗемәи хәл»ен, «Минем тормышым әкияте» дигән әсәрләрен укып йөрәген яралаган әдипләр ничәү генә икән? Ә бит аларны укыгач бөек әдипнең «Сандугач», «Су кызы», «Чыршыкай» кебек әкиятләрен кальбең белән дә аңлый башлыйсың... Элегрәк «аңладым» дип алданган үз кальбеңне дә аңлыйсың. Элек язганнарына үкенсән дә гаҗәп түгел.

«Адым-адым юл үтелер» дигән борынгылар. Атлыйк, көн саен бер адым булса да алга китик. Шуннан башка тәрәккъыять мөмкин түгел. Инкыйлаби үзгәрешләрне һәм мутацион шартлауларны да шундый әкертен, салмак тәрәккъыять әзерли.

Морза чыгышлы Әмирхан Еникиләр, тумыштан затлы Гомәр Бәшировлар киткәч, татар дөньясы рухи аристократларсыз—рульсез калды. Әдәбият көймәбез җилкәнсез... Боргалак җил һәм түбән таба агым иркендә без хәзер. Бөтендөнья туфан дулкыны басса нишләрбез?

«Нишләп җилкәнсез булыйк?» диючеләр табылмый калмас. «Безнең әдәбиятта милләтпәрвәрлек ничек көчле хәзер!»—диярләр. Ничәмә әдәбият белгече җиң сызганып эшли, диярләр.

Ә бит Сталинны һәм урыс колонизаторларын сүгү белән генә җилкән киерелми. Милләтпәрвәрлек тә, хәдтин ашса, башкорттагы кебек, буш шапырынуга, көнчелеккә йә төкеренүгә әйләнеп кала.

Җилкәнсезлек харап итә безне. Сыңарлы милләтпәрвәрчелек җилкәне чыпта җилкән кебек чыдамсыз ул. Бөтендөнья мәйданына чыгу өчен безгә инсанпәрвәрлек җилкәне дә корырга кирәк, аны сәясәт үзгәргән саен ямыйсы булмый. Безгә хыялый Александр Гринның «ал җилкәннәр»е кирәк, очыйк дисәк,—Акбарсның ак канатлары кирәк.

Зыялы, нәзберек әдәбият, интеллектуаль драматургия һәм җанлы телетапшырулар кирәк безгә.

Бераз катнашым бар дип уйлаганга, татар әдәбиятынын үги баласы булган фантастика жанры турында бер-ике сүз әйтсәм артык булмас.

Гадел Кутуйның «Совет әдәбияты»журналында сугыш елларында басылган «Рөстәм мажаралары», әлбәттә, чын фантастика жанрына карамый. Ул фэнтэзига тартым. Асылда Рөстәм—бүген дөнья шаулаткан әкияти Гарри Поттерның элгәре (ихтимал, Рөстәмнен башка элгәрләре дә бардыр, бәхәсләшмим).

«Рөстәм мажаралары» тәмамланмаган әсәр. Дөресен әйтсәк, ул языла гына башлаган һәм ... язылып та беткән дияргә мөмкин. Чөнки абага чәчәге кабып күзгә күренмәскә әйләнгән батыр Рөстәмне автор алга таба нишләтергә белмәс иде, совет чынбарлыгы анын хыялый каләменә богау салыр иде. Әйтик, «Хоттабыч карт»тагы Вова мажаралары да узган гасырнын 40нчы елларында мөмкин түгел иде әле. Гомумән, совет әдәбиятында фәнни-популяр мәкаләгә тартым беллетристика гына чәчәк атты. Беренче совет фантастларыннан Ал. Беляев юкка гына: «Мине электр лампочкасы турында фантастик әсәр язарга мәжбүр итәләр»,—дип зарланмагандыр.

Шулай да мин, әгәр «Казан утлары»на бүген «Рөстәм мажаралары» тәкъдим ителсә, анын басылып чыгу ихтималы ике сарылы дип уйлыйм.

Гасырлар буе жирдә мүкәләп йөрергә мәжбүр ителгән татар фантастиканы өнәми микән әллә? дисен. Ул түше белән шуышкан жирне генә күреп, югарыда йолдызлар жемелдәгәнен дә белми микән әллә? Мин моңа ышанмыйм. «Жөмжөмә солтан»нарны, «Кисекбаш»ларны, «Мен дә бер сәхәр»ләрне биргән хыял иялребез булган безнен.

Бүген фантастика жанры үсмәгән әдәбият тулы канлы була алмый. Әйе, кибет киштәләрен бихисап фантастик әсәрләр тутырды. Ныклабрак карасан, алар бер-берсен кабатлыйлар, күбесе ияреп язылган тәкълиди әйберләр. Реалистик әдәбияттан бушаган вакуумны шулар тутыра бугай.

Хәер, реалистик әдәбият киштәләрендәге макулатуранын да исәбенә чыгышлы түгел.

Фантастлардан берәү: «Әгәр сиңа сызыклы кәгазь тоттырсалар, сызыгына аркылы яз!»—дип кинәш иткән иде. Фантастларны менә шушы кыю фикер өчен генә дә ихтирам итү тиеш.

Ярар. «Казан утлары» журналына әйләнеп кайтыйк.

Журналнын тиражы 100 мең данәдән ашып киткән унышлы еллар да булган. Ә хәзер ул нибары 6—7 мең данә тираж белән чыгып килә. Артка китешнең сәбәбен журналда басыла торган әйберләрнең сыйфатыннан гына эзләү, әлбәттә, дөрес булмас. Үзәктә чыга торган русча әдәби журналларнын да тиражы шул нисбәттәрәк азайды. Рәсәйдәге башка халыкларда да эш шулайрак тора. Монда тормыш-көнкүрешкә телевизион тапшыруларнын тыелгысыз үтеп керүе зур роль уйный. Ямanаты чыккан телесериаллар, хатын-кызларыбыз, бөтен эшләрен калдырып, телеэкранга багынып утыра торган «сабын опералары»... Уртакул әдәбият хәтта болары белән дә ярыша алмый. Үкереплэр жыласаң да булмый.

Янә китереп, Интернет—Бөтендөнья гайбәт челтәре... Ләкин безгә барыбер шул челтәргә тоташырга туры киләчәк, чөнки акыл ияләре: «XXI гасырда кешелек дөньясы тормышындагы революцион үзгәрешләр Интернет белән баглы булачак»,—диләр.

Димәк, укучыбызны саклап калыйк дисәк, сыйфат планкасын нык күтәрергә туры киләчәк. Әдәбият артыннан театр да, журналистика да, телевидение дә күтәрелер иде.

Менә «Сүнмәс утлар балкышы»нда әдәби планканы югары күтәреп бик дөрес эшләгәннәр. Хәзер исә журналнын агымдагы саннарын оештырганда да планка шул югары кимәлендә торсын иде. Шул чагында... Шул чагындамы?! Әгәр сыйфат ун дәрәжәгә күтәрелә калса, журнал редакторынын дошманнары ун тапкыр ишәер дип бәхәсләшә алам.

«Әдәбият тапкырлау җәдвәле түгел, анда ике икең беркайчан да дүрт була алмый. Әдәбиятта бергә берне кушсаң, ике килеп чыкмый, зуп-зур берлек пәйда була.» (Шүрәле.)

«Татар поэзиясе антологиясе»нең соңгы басмасы ике томлы булып чыккан иде. Ләкин, абсолют зәвык бизмәненә салып үлчәсәң, чын поэзиябез барыбер бер томнан артмый. Зурдан кубып әйтсәк, гел җырлап, гел шигырь белән генә сөйләшә-аңлаша торган хыялый халыкнын да поэзиясе сыңар томга сыеп бетәргә тиеш. «Лучше меньше, да лучше»,—дигән Владимир Ульянов (Ленин). В. И. Ленин теленең фразеологик сүзлегеннән бу гыйбарәнең ничек тәрҗемә ителгәнен карадым: «Аз булса да, яхшы булсын». Белешмә-сүзлектә вариантлары да бирелгән: «Бер булсын, бәрәкәтле булсын; ике булганчы бер булсын да берәгәйле булсын.» Иллә мәгәр дөрес сүзләр.

Кыскасы, бу очракта чиктән тыш оптимист буларак, «Татар поэзиясе антологиясе»нең өченче басмасы өч том түгел, фәкать бер томлы гына булып чыгар дип өмет итәм мин. Олы юлда атлаган саен маяк кадамыйлар. Олы юл буена чакрым баганалары гына куела. Шәхесләрен атау өчен бер сүз житкән Тукай—Такташ—Туфан—Хәкимнәрнең вәзенле авазы бер баганадан икенчесенә ишетелерлек булса, шәт, адашмабыз.

Мөдәррис Әгъләм шигырь сөюче каршына баһадир егет булып килеп баса. Аның шигырьләрен укыганда ләззәтле пакьләнү тойгысы кичерәсең. Намаз укучылар тойгысы дип әйтимме? Заманында Аристотель бу халәтне катарсис дип атаган. Гомумән, чын шигырь кешегә эчке, рухи тәһарәт шикелле тәэсир итә дияр идем. Тукай әйткән-әйтүен: «Ни сәбәптән жир йөзендә тәңгә—мунча, җаңга—юк»,—дигән. Белмәгән шагыйрь: баксаң, аның шушы сүзләре үк адәмнәрнең җанын пакьли бит. Ихластан булса, тәүбә дә пакьләндерә безне... «Әллүки», «Карурман» кебек җырлар да. Һәр гүзәллек шулай. Ә сабыйларнын таң чыгыдай саф күз яше?

Бер томлык антологиягә лаек кандидат булган шагыйрьләрне атап тормыйм. Чөнки шигырь бәйгесендә гадел өлешсез калучылары да бар... Гомеренә бер, ләкин берәгәйле шигырь язган кеше дә шагыйрь ич. Их, шуныкы кебек бер шигырь язсаң иде! дисең.

«Шагыйрьнең тормышы вафатыннан соң башлана»...

Әгәр олы юлдагы әдәби маякларыбызга исем кушасы булса, мин түбәндәгеләрне тәкъдим итәр идем. «Туган тел». «Ике йөз елдан соң инкыйраз». «Алмачуар». «Тапшырылмаган хатлар». «Урман кызы». «Мокамай», «Туган ягым—яшел бишек». «Җәяүле кеше сукмагы». «Рәшә». «Өч аршын җир»... Болары әле ун-унбер чакрымлык тарихыбыз маяклары гына. Һәр чакрымыбызга лаек исемнәребез булганга горурланмый мөмкин түгел.

Чөнки татар әдәбияты—үсмер әдәбият, кәрлә әдәбият түгел.

«Сүнмәс утлар балкышы»нда ике генә битлек «Белешмә бүлек»тәге коры мәгълүмат та укучыны уйланырга мәҗбүр итә. Кайбер елларны карыйсың да, журнал редакторларының бик еш алмашынганын күрәсең, сәбәбен беләсе килә. Арада журналны озак кына житәкләүчеләр бар, ә кайберләре берәр санга гына кул куйган... «Казан утлары»ның хәзерге мөхәррире Равил Фәйзуллин—иң озын гомерлесе икән. Абсолют рекорд иясе буларак, ул Гиннесс китабына керергә лаек, алга таба да эше уңгыры. Ул—«менә дигән» шагыйрь генә түгел, җәмәгать эшлеклесе дә (Тукай, мактаныбрак, үзен «общественный деятель» дип тә атый, ул заманнарда әле «җәмәгать эшлеклесе» дигән сүз тумаган була).

Китап безнең күбебез өчен яна фотоиллюстрацияләргә бай булуы белән аерылып тора. Редакциянең фотоархивы булу—үзе бер казаныш. Китапта сурәтләр бизәү максаты белән генә бирелмәгән, әйтик, фотосәхифәләр ышанычлы тарихи мәгълүмат чыганагы булып та хезмәт итәләр.

Әдипләребезнең рәсемнәренә карагыз. Елмаюлы йөзләр. Нинди яшьләр, нинди чибәрләр... Аларнын кайберсенә картлыкны күрү насип та булмаган...

Ә менә болары—төрмә фотолары. Тетрәндергеч фас һәм профиль.

Ә монысы—төрмәнең үзе, казанлыларга бик билгеле пересылка (озату зинданы, мәхбүсләрнең мәнзиле). Гүзәл Кремлебезнең ак диварлары астында ук урнашкан баструк—бәләкәйрәк кальга, замок. Репрессияләр чорын чагылдырган, «Болгавыр еллар» дигән бүлектә күп кенә вакыйгалар шул төрмәдә бара инде.

Солдат Емельян Пугачевны, ять-яшь студент Володя Ульяновны хәтерләгән бу бинаны мин түбә-түшәмнәре бүселеп, реконструкцияләнеп яткан хәлендә дә күрдем. Аннары пересылкадан яман авырулы кешеләрне мәңгелеккә озата торган онкология хастаханәсе—«рак корпусы» ясадылар. Анын борынгы мөсафирханә (кәрван-сарай) кебек шәкеле дә, шакмаклы ишегалды да, тимер капкасы да «исән» калды...

Сиксәненче еллар ахырында, 9нчы май көнне, мин бирегә авыру туганымның хәлен белешергә дип килгән идем.

Кырыс дежур ханым килүчеләрнең пакетларын бушатып ук тикшерә башлады шикелле. Мин, бәладән башаяк дип, артын-артын гына чыгып киттем дә, элекке төрмә бинасының «кара» капкасына әйләнеп килдем. Көткәнемчә, ул ябык түгел иде. Бернинди тоткарсыз эчке ишегалдына үттем. Туганым—Карабаш асфальт-битум заводы директоры Ленар Зәйнуллин бер иптәше белән ишегалдында кояшта утыралар иде. Иптәше дигәнем Татарстандагы тагы бер кечкенә битум заводының җитәкчесе булып чыкты. Яман шешнең чыннан да сумала шикелле канцероген матдәләргә бәйләнеше табибларга сер түгел...



*Пугачевлар, Ф. Кәрим, Х. Туфаннар яткан төрмә бүген—Казан онкология хастаханәсе.*

Сөйләшеп утырдык. «Перестройка» дигән нәрсәнең башланган чаклары (перестройканың «атасы» Михаил Сергевич Горбачев әйтмешли, инде «процесс пошел») һәм, яшерен-батырын түгел, минем «зәңгәр өмет»ләрем шушы процессның уңышлы чыгуына бәйле бит. Туганым бу хакта әлләни әйтмәде, ләкин мондый үзгәртеп коруларга ышанып җитмәве анын кояш күрмәгәнгә аксыл маңгай сырларына язылган иде. Иптәше дә җилкәсен генә сикертеп куйды. Теманы алмаштырмак булып, сүзне Ленинның үзенә борып карадым. Коммунистлардан ерак ук торсам да, фиркале җитәкчеләр ленинчыл принципларның торгызылуын көтәләрдер дип уйлаганмын. Юк, алар моны көтмиләр икән. Яман шеш авырулы кешеләрнең өметсезлегеннәндер бәлки? Якты дөньяга тәмам кул селтәгәнгәдер? Алай да түгел. Алдынгы һәм хөрмәтле совет хуҗалык җитәкчеләре безнең системаның савыгуына ышана алмыйлар иде! Мин аларның сагышлы күзләрендә нинди-дер без белмәгән хакыйкатьне йөртүләрен күрдем. Системаның эчендә болганып, алар анын тамыры һәм бөтен кәүсәсе мурtaеп черегәнен аермачык белгәннәр... Дәшмиләр генә.

Озын-озак авырган кешенең уйланырга вакыты җитәрлек. Авыру кешеләр күп беләләр.

Бу бинада Володя Ульяновның төн кунуын гына түгел, күренекле татар язучыларының да шушы пересылка төрмәсе аша үткәнен белә иде алар. Хәтта миңа билгесез фамилияләрне дә атадылар, патша заманыннан ук калган бер-ике төрмә легендасын телгә алдылар... Бу легендалар төрмәнең өстө-өстенә буялы диварларына иероглифлар белән язылган да, алар, бер-берсенә

терәлгән тимер караватларында чалкан яткан килеш, күзгә күренмәс шул язуларны уку әмәлен тапканнар диярсең. Бәлки үлемдарларда шундый сәләт ачыла торгандыр... Кан юлларына турыдан-туры дару җибәрә торган система астында алар: «Там, там, тамчы там, тамуыңны яратам» дип батырайган булып яталар, чөнки бу җырның авторы Сирин дә шушы камераларның берсен үткән бит... Сириннең тамчысы калды, бу—аз түгел!

Китәргә кузгалгач, мин буаз портфелемнән берничә гәзит, тәм-томнар һәм энем тиешле Ленар («Ленин армиясе»!) сораган «тәгәрәткән бәрәңге», тозлы кәбестә һәм яшел суган белән шундый ук яшькелт шешәне чыгардым. Бәйрәм көне белән котлавым. Бәрәңгене күргәч, завод директорлары Мәхмүт Хөсәеннең бәрәңге турындагы җырын искә төшерделәр. Мин аларга бу җырның бик үк оригиналь түгеллеген, сугыш вакытында немес солдатларының бәрәңгене мактаган үз җырларын патефонда бик еш уйнатуын, бу җырның фронт сызыгы аша безнекеләргә дә ишетелеп торуын әйтергә базмадым...

«Хрущевка» тәрәзәмнән сандугачларның, бәйгедәге кебек, ярышып-ярышып сайраганы ишетелә. Минзәләбаш дип аталган туган авылыбызда Ленар Зәйнуллинны җирләгән көнне дә шулай чут-чут сайраган иде алар. Карабаш халкы соравы буенча Зәйнуллин исеме бирелгән стадион янында да сандугачлар сайрый. Чак кына үзгәрәк, бормалырак итеп...

Тоталитаризмга тугрылыклы эш башкаручылар, күндәм хәдимнәр һәм ялагай ялчылар кирәк, тәнкыйди фикер һәм вөҗдан ияләрен ул, лимон шикелле сыгып, җелекләрен суырып ала да, чәйнәп, бугазлап ташлый. Әйе, Зәйнуллин коммунист иде, фиркале коммунист иде. Ләкин ул барын да аңлап китте, «Ленин армиясе» дигән «мылтыклы исем»ен йөртә алмаячак иде инде ул.

Аның турында уйлаганда Әмирхан Еникинең «Саз чәчәге» искә төшә. Монда да саз—тоталитар система, ә сазда үскән чәчәк кем? «Казан утлары»ның әбүнәчесе, җыр-шигырь сөюче милләтпәрвәр Зәйнуллин үзе.

Зиндан бинасына әйләнеп кайтыйм әле.

Анда, Кальга-Кремль куенында, яман чир хастаханәсе булырга тиеш түгел!

Мин монда Рәсәй тарихында беренче төрмә тарихы музейханәсе ачар идем. Музей өчен искиткеч җайлы, кулай урын бу. Мәшһүр урын.

Хан заманы зинданнары—базлар. Җәллад балталары. Киселгән баш тәгәрәп төшә торган күн җаймәләр—сүрүкләр, натлар. Зынҗырлар. Эскәнҗәләр. Тырнак суырта торган кыскычлар. Газаплау кораллары. Дар агачлары. Картиналар. Документлар. Истәлекләр. Илне чуарлап бетергән ГУЛАГ картасы. Менә бу банкада гап-гади лагерь тузаны. Бу кара таш татарга да таныш Соловкидан кайтартылган. Бусы—ипи йомшагын чәйнәп, шул «пластмас»тан ясалган дивар сәгате. Менә бусы—корбаннарның һәм шәһит киткәннәрнең беркайчан да тутырып булмаячак күп томлы исемлеге.

Совет чоры юлбашчыларына куелган һәйкәлләр шушы зиндан ишегалдында урын тапсын иде. Ә совет чорында канлы вә кансыз репрессия конвейерына «добро биргән» яманлык даһие Владимир Ульяновның алагаем зур сыны, хәзерге урыныннан куптарылып, зиндан капкасы алдында, уйсу җирдән генә калкыбрак торырга тиеш. Бу гигантка пьедестал кирәкми.

Балавыз фигуралар (курчаклар) залы. Монда Гаяз Исхакый Галимҗан Ибраһимов белән, Туфан белән, Кутуй, әйтик, Минский белән очрашырлар... Курка-курка гына «Майт якасына!» дип пышылдап торучы Фатих Хөсни дә бирелә... Солтангалиев сыны да шушында булыр... Максим Горький белән Вл. Маяковскийга да урын табарбыз. Казанның бөтен дөньяга мәшһүр «таш капчыгы»—«психушка» мәхбүсе, Эстония президенты Пяц әфәндегә дә.

Зал почмагына, башкалардан тутык чылбыр белән аерып, Ф. Мөсәгыйть, С. Мортазин, М. Парсин, М. Даутов кебекләрнең һич югы берсенең шәкә

пәрие сыманрак кына сынын бастырасы иде,—калтыравык кулларына канлы язмаларын тоттырып.

Кавказ алдын кара канга батырган татар чыгышлы «башибузук» генерал Ермоловның, язмышы кыл өстендә торган чакта Рәсәйне коткаручы керәшен Козьма Мининның да балавыз фигурасы Казанда булырга тиеш, чөнки барыбыз өчен дә уртак «өтөрмән» булган Рәсәйнен тыелгысыз кинәюенә алар ифрат зур өлеш керткәннәр.

Ә зәңгәр бәрхет аркан белән аерылган хөрмәтле шәһитләр арасында Рәшит Әхмәтҗанны, Мөдәррис Әгъләмне, Зөлфәтне күреп тын калыр идек. Ничек чынлый, ничек чынлый ул салкын тынлык...

«Сандугачлар янган утта Җылынырга ярыймы соң?»

Беләсезме, суфилар үзләрен «идиот» (дивана, әл-балда) дип атарга яратканнар. Шәрык поэзиясе суфичылык фәлсәфәсе белән сугарылган. Чын шигърият—Пушкиннар, Тукай суфичылык идеяләренә бик якын төсле тоела миңа. Утыз Имәни шигырьләрен әйткән дә юк инде. Игътибар иткәнегез бармы икән, татар шигъриятенең чишмә башы дин әһелләре бит... Хәтта Шиһаб Мәрҗаниебез дә кәгазьгә шигъри юллар төшергәләгән, ләкин үзенең шагыйрьлек сәләтеннән мәхрүм икәнен дә яхшы аңлаган ул.

Соңгы вакытларда арабыздан чиратсыз китеп барган шагыйрьләребез иманлы гаиб ирәннәр иделәр. Ә бүген кайбер яшерен суфиларыбыз, үзләренең бөеклеген белмичә, гавәми безләр белән аралашып, зарланмыйча гына, тигезләшеп яшиләр.

Бер тәкъдимем әйтелми калган икән. Журнал архивында әдипләребезнең рәссам каләме белән ясалган кечкенә портретларын туплаганда ничек? Рәссам күзе фотообъективка караганда акыллырак, мондый портрет җанлырак, җылырак та килеп чыга. Гомерлерәк тә булыр иде.

Менә тагын «сайлау» көннәре якынлашып килә. Әгәр бирган булып, бу язмаларым басылып чыкса, ул вакытка инде хакимияткә янарак кешеләр менеп утырган булыр. Кемнәр? Нәрсәне «сайларбыз»? Мүкәләп йөрүнеме, әллә әнгерә сарык мәхлукатын һаман «по-пластунски» үрмәләргә өйрәтерләрме? Купшы ялганлау сәнгате яңа тамыр җибәрерме? Янә кеше саен икешәр «Волга» машинасы вәгъдә итәчәк яңа бакырбаш Чубайсларга ышанып, барлы-юклы демократик казанышларыбыздан колак кагарбызмы?

«Черек күл» тәрбия кылган бәндәләр демократия шытымнарын бүген икенче кат утап чыкты бугай инде. Кара җир генә ятып калды. Эшләр болай барса, тиздән аны тигәнәк басачак.

1991нең көзендә бер йотым хөррият һавасы сулап калган идек.

Олуг-кечек түрәләргә янә табына башларбыз дип кем уйлаган ул шаңлы көннәрне? Башлыкларның авызына карап торабыз, ни әйтсә дә «Афәрин!» дип кычкырырга әзербез.

Хәтердәге авыр йөктән күңел сыкрый.

Кайда соң ул моңлы курай өздерепме-өздерә?

Әллә кайда, кичәге көндә, кычытканлы тыкрыкларда онытылып калгангамы, җылый да җылый ун телле тальянка—олы күңелле нәни гандәлиб.

Ипекәй бәяләре арткач, ач үлемнән куркусыннан ярты ил җылыймы әллә? Гомер-бакыйга хаклык күрмәгән карт-коры инрәп, үксеп беткән инде...

Безгә бүгенге түрәләр политэкономиядәге «ачлык минимумы», «ачыгыр дәрәҗәдәге эш хакы» кебек төшенчәләрне өйрәтеләр. Ә берәүләр, «алланың кашка тәкәләре», Канар атауларында кенәриләр сайравын тыңлап сафа сөрә.

Кыйтгадан кыйтгага алыптай адымнары белән дөп-дөп атлап егерме беренче гасыр бара. Ул кичәгене таптап изәр дә, адәми затка ниләр калдырыр? Озон тишекләреме? Радиация базларымы? Ясалма вирусларынмы? Вакуум бомбаларынмы? Яңа хәшәрәт-миллиардерларын гынамы? Юк, миллионнарча яңа кабер ташларын да...

Без үзебез дә маймунләшеп һәм роботлашып бетәрбез дә, тарих башлангыч ноктасына әйләнеп кайтыр микәнни? Нуль ноктасына.

Соңгы удэгэ. Аннары Сахалинда теркәлгән бердәнбер айн кешесе. Исхакыйның соңгы болгары. Соңгы могиканнар... Нәсел-нәсәпләрен җирләп бетергәч, хәсрәтләре бик ачыдыр аларның, ай, ачыдыр... Милләтара золымның һич соңы булмас микәнни?

Гомере буе җилкәсе артында «Черек күл»нең хәсис сулышын тоеп, артларына поскан сексот пәриләрнең мышнавын ишетеп шом эчендә яшәгән кешеләр азмени? Микроскоп астындагы, яки пыяла аквариумдагы бәхетсез тормыш.

Билгеле булганча, акыл да бәхет түгел, бәла ул. Фикер ияләре юкка гына «Рухи юксыллар бәхетле» дип әйтмәгәндер. Мәхәббәт—бәхет, ләкин ул мантыйкка һәм гакылга каршы килә торган инстинкттан башка нәрсә түгел бит. Чеп-чеп килеп йөргән сары чебиләр йөз процентка бәхетле, сабыйлар да шулай. Еллар үтү белән бу процент кайчак нульгә кадәр кими. Шушы абсолют хакыйкатьне аңлагач, беркадәр ... тынычланасын.



*13 ел Японияда ирле-хатынлы Әнвәр һәм Хатыча Садыйклар булып яшәгән пар, ниһаять, чынлап торып язылыша. Инде үзләре—элекке совет разведчиклары полковник Шамил Хәмзин һәм Бибиһран Алимова булып... (Р. Мостафин. Татар Зоргесы.)*

Сагышлы ут яктысында мин болар турында да уйланам.

Илаһым!—дим.—Авыр, чамасыз авыр бит бәндәләреңә...

Бакчы: базар асфальтында сөякчел тезләре тузанга манчылган сәрхуш хатын биһуш ята. Ул инде беркайчан да ана булалмас. Ә дөньяда гөнаһсыз сабыйлар калмаса, без үзебезне кем белән үлчәштерик тә, кемнән үрнәк алыйк?

«Сабыйлар кебек булыгыз»,—дип өйрәтә безне дүрт Изге китапның берсе—Инҗил. Сәнгать кешесенең аерылгысыз хасияте—балалык сыйфаты. Шуңа күрә сәнгатькяр еш кына гадәти бәхеттән өлешсез кала, шуңа күрә сакаллы сабыйларның маңгаенда—шеш, күз төбендә «фонарь» күгәреп торыр, ә җаннарында—бетәшмәс яра. «Күңелләре пакь булганнар бәхетле» кебек сүз дә бөтен инсаният өчен уртак хакыйкать лабаса...

Ә сабыйларыбыз?... «Дедовщина» балалар бакчасында ук башлана диләр хәзер.

Чәнечкеле тимерчыбык белән уратылган зонаның чиге кайда? Ә кайда «нинди иркен минем туган илем»? Чик сызыгы юк, киртә юк бүген. Аны коммунистлар ук җир белән тигезләгән иде. Матурлыкны аяк астына салып таптаудан ләззәт ала торган җинаятьчел төркемнәр һәм аларны күпләп тәрбияләп иреккә чыгара торган төрмә университетлары барлыкка килде. Без моны коточкыч чүпләнгән сөйләм телебездән үк күреп торабыз.

Кайчагында бу җинаятьләр кемдер төзегән яман программа буенча тормышка ашырылгандай тоела.

«Кузгал, уян, ләгънәт ителгән...»

Туктал, туктал, мизгел! Алда кара упкын...

Акыл җитмәс ерак Галәм алысларыннан мен еллар элек вафат шагыйрьләрнең зары килеп инә Җиргә:

*Без бит бакыр тиен, без бер мискин казна,*
*Әрәм-шәрәм итә безне яман чор-замана!*

Тик менә Җир шарчыгында яшәп ятучы сәясәтчеләр мона бер дә пошынмый: «Гомер-бакыйга шулай булган, шулай булып калыр да»,—диләр. Чөнки алар башкалар өчен сызлануны белми торган тун йөрәкле динозаврлар. Аларны сез телевизорда еш күрәсез. Кызганыч, бу сәясәтчеләр арасында әдәбият әһелләре дә күзгә чалына,—димәк, әдәбиятыбыз ярлылана!

Болар Тукайның: «Кача күр, кош кеби, мактауларыннан, Хәбәрдар бул ки шунда ау барыннан» дигән сүзләрен иртәнге дога итеп укырга тиеш иде дә бит...

Бүген безгә бөтен дөньяны баскан гаделсезлек һәм ялган чорында гомер итәргә туры килә. Александр Солженицын үзенен «Ялган кочагында яшәмик!» дигән бер мәкаләсендә ялганнан «иң гади, иң ансат котылу чарасы—алдашуда шәхсән үзебез катнашмау» дигән иде. «Алдак бөтенесен томалап, бөтенесен яулап алган да булсын, ләкин шушы кечкенә генә гамәлебездә үҗәт булыйк: ялган минем аркылы башлык кылмасын!»

«Хөр заман ак кул белән күкләрдән йолдыз чүпләгән» Тукай совет режимы шартларында бик тиз һәлак булган булыр иде. Әлеге алдартазлар аның гаепләрен бик тиз табарлар иде: эмигрант Исхакыйга язган мәдхиясе... Романов-патшалар династиясенә дан җырлаган шигыре... «Кадер кичәсе»... Әхмәт Исхакмы соң, Фәйзиме, кайсыдыр бер шагыйребез мондый ялган тәнкыйтьчеләрнең «Гали белән кәҗә» шигырен эт итеп сүгүе турында оста пародия дә язган иде.

Ватан. Атам иле. Авыл саен диярлек Алып бабай чабатасын каккан кылганлы җирләрем. Хыялый Ак бүре белән Ак барс...

Башта ят тоелган барска инде ияләшеп барабыз. Дөрес, без аны Татарстан гербында гына күрәбез. Ниндидер ак күләгәне хәтерләтә ул, беренче карашка. Сәнгати деталь—ихтимал, бер-ике генә җанлы сызыкча җитенкерәми анар. Аны табасы калган... Менә әгәр берәр талант иясе затлы барсны бронзада яки мәрмәрдә сурәтләргә алынса, ана детальләр турында да уйларга туры киләчәк. Уйлагыз, уйла, сынчылар...

Анам теле... Бу сүз «туган тел» яки «әткәм-әнкәм теле» терминына тәңгәл үк түгел. Чөнки борында еш кына киленнәр башка каүм кызы булып, телләре дә үзгә булган. Ә баланың теле әнкәсенә ияреп ачыла... Бала аңында ике сөйләм керешеп, теле яңа сүзләр хисабына байый һәм камилләшә. Ләкин бүген инде без «ана теле» һәм «туган тел» сүзләрен тулысынча мәгънәдәш дип карыйбыз.

Русча язылып, соңыннан берәр тәҗрибәле тылмач ярдәмендә ана телебезгә күчерелгән мәкаләләр миңа әллә ничек «суррогат ана» карынында яралган бала шикеллерәк тоела... Ятсынам мин суррогат әйберләрдән, өнәп бетермим. Журналыбызда андый корама телле мәкаләләр күренгәләп ала.

Менә шушында мөхтәрәм Рафаэль Хәким иҗатына тукталмак булам.

Кем ничектер, ә мин Р. Хәкимнең мәкаләләрен һәм китапларын көтеп алучылардан. Дөресен әйткәндә, алар—минем рухи азыгым. Фикер иясе буларак, Р. Хәким миңа гадәттән тыш күп нәрсә бирә һәм аның һәрбер уңышы мине шатландыра.

Рафаэль Хәкимнең «Татар рухы» дигән гүзәл хезмәтен игътибар белән укып чыккан милләтпәрвәребез: «Яшә, Рафаэль! Яшим мин!»—диячәк.

Рафаэль Хәкимнең җәдиди фикерләренә популяр, гавәми матбугат тиешенчә җавап бирми, ихтимал, бирә дә алмый торгандыр. Ә татар фән әһелләре вакарьле тынлык саклаган сыман итенә. Кайтаваз юк дип әйтимме? Кайтаваз өчен дә кыюлык кирәк шул, ирдар тәвәккәллек кирәк. Аннары Хәкимдәгедәй белем һәм хәбәрдарлык.

Р. Хәкимнең туры сүзләре күбәүләргә ошамый. Мәсәлән, «Сүнмәс утлар балкышы» китабында да урын алган «Кем син, татар?» дигән күләмле мәкаләсендә ул: «Татар матбугаты... Ныклап карасаң, анда укыр нәрсә юк. Татар телевидениесе... Анда карар нәрсә юк»,—дип ачынып, әрнеп яза. Аның бу сүзләре театрыбызга да һәм, гомумән, әдәбиятыбызга, әдәбият белеменә, турыдан-туры әдипләребезгә дә кагыла. Әйе, Р. Хәкимнең каләме кайберәүләрнең тормыш идеалларын мәгънәсезгә әйләндерә.

Әлеге сүзләр, әлбәттә, гипербола инде, ләкин автор бу арттыру алымын махсус куллана, мүк баскан йөрәкләргә, чүпләнгән баш миләренә дә хакыйкать үтеп керсен өчен эшкә җигә.



*Шанлы Мәскәү «Спартагы» һәм аның данлы капитаны Галимҗан Хөсәенов (уңнан беренче). 1969 ел. (Җ. Мостафин. Бәләкәй генә булса да.)*

«Сүнмәс утлар балкышы»н актарганда мин тагын шунысын абайладым: икенче бүлеккә традицион Галимҗан Ибраһимовның тирән тамырлы мәкаләсе тон биргән булса, китапның ахырында Рафаэль Хәкимнең киң тармаклы җәдиди (бунтарь?) мәкаләсе игътибарны җәлеп итә. Иң нык уйландыра һәм чаң кага торган әйберләр—шушылар кебек. Башкалары һәммәсе шушы ике мәркәзне тоташтырган күчәр тирәсендә әйләнеп, шулар яктысыннан өстәмә балкыш-нур ала.

Соңгы гасырда рус теленә ашыгып һәм ничек кирәк алай тәрҗемә ителгән татар романнары да укучының күнелен генә кайтарды бугай. Бу тәкълиди кыйссаларның күбесе тәрҗемә ителергә дә тиеш түгел иде.

Русчадан татарчага әдәби тәрҗемәләр шулай ук эчне пошыра.

Адаптацияләнгән, җиңеләйтелгән, шоп-шома текст. Достоевскийның коточкыч тирән, аңлаешсыз кара психологик упкыннары уенчык канау гына булып кала торган үтә күренмәле җөмләләр... Автордан тәмам ераклашу. Тәрҗемәнең төп принцибын бозу. Күп кенә тәрҗемәләр оригиналның эчтәлеген сөйләүгә, ялгыш-йолгыш тәфсиргә әйләнеп кала.

Нәфис Чехов та юк хәзерге татар телендә. Горький тәрҗемәләре дә кичәге көннеке. Аның кичәге Казан рухлы «Фома Гордеев»лары, «Университетлары», «Страсти-мордасти»лары, «Тормыш төбендә»ләре бүгенге Казаныбызда да бик актуаль яңгыраячак түгелме? Пушкинның татарчага яңа тәрҗемәләре кирәк. Татарча яңа Лермонтов та юк. Ә бит соңгы 40—50 ел эчендә татар әдәби теле нык үсте, баеды, камилләште. Шигырь техникасы алга китте. Аннары хакыйкать шунда: Чеховны тәрҗемә итәргә алынган татар әдибенең каләме һәм сурәтләү чаралары һичшиксез байыячак. Ул, Чеховка өйрәнеп, үзенең сыйфат планкасын күтәрәчәк, күтәрми хәле юк. Кыскасы, биек планканы буйсындыру өчен безгә арткарак чигенеп, янә йөгереп киләсе һәм бар көчебезгә талпынасы булыр. «Һаваларда очкан кошлар»га иярик, шунда берәребез Киек Каз юлындагы Нобель йолдызын эләктереп кайтмасмы.

Ни генә әйтсәң дә, рус әдәбияты—безнең остазыбыз һәм мәктәбебез ул. Гаребтә булсын, Шәрыктә булсын, бүген XIX гасыр рус әдәбиятына үрнәк өлге итеп карыйлар. Кичәге әдәбиятка... Чөнки рус әдәбиятының да бүгенге көне—тирән кризис. Шүрәлем әллә кайчаннан колагыма тукып килә: «Олуг рус әдәбиятының гына түгел, татар яки, әйтик, башкорт әдәбиятының да бүгенге хәле мөшкел,—ди.—Сезнең дә олпатларыгыз дөнья кичте... Бүгенге әдәбиятта җим тапмагач, житди тәнкыйтьчеләрегез борынгы әдәбиятка кереп

чумарга мәҗбүр. Аптыраган үрдәк нишли..? Дөрес, шомарак белгечләрегез бүгенге әкияти шәрә корольнең күзгә күренмәс әдәби күлмәген мактаган, хәтта аерым кимчелекләрен тапкандай булып кыланалар... Күз буарга маташулары.»

Рус классикасын тәрҗемә итү эшенә татар каләм осталарының үзләрен тартасы иде, юкса инде менә ярты гасыр гына бардыр, бу эш нәшрият хезмәткәрләре кулына төште. Кәсепчеләр исә тәрҗемә эшенә акча эшләү ысулы дибрәк карыйлар. Хәер, әдәби тәрҗемә Язучылар берлегенә әгъза булып керергә юл ача—карьеристлар өчен, жим буларак, моның да роле зур.

Янә шунысы кызганыч, вакытлы матбугатта әдәби тәрҗемәләр турында тәнкыйди мәкаләләр юк дәрәҗәсендә аз. Чын, милли тәрҗемә мәктәбе бездә булмады. Бу факт кулыбыздагы «Сүнмәс утлар балкышы» китабының эчтәлеге белән дә раслана. Югыйсә бит заманында, «җепшек илленче еллар ахырында», Нурихан Фәттах американ галиме һәм фантасты Айзек Азимовка хат язып, үзенә килгән җавапны һәм, ялгышмасам, Азимовның неандерталь малае турындагы бер хыялый хикәясен үзе тәрҗемә итеп журналыбызда бастырган иде.

Кәбирләнүчән американнар өчен без-фәкыйрьләр неандерталь малае гына түгел микән? Әйттем исә кайттым.

Чит телдән турыдан-туры тәрҗемә итү мәсьәләсе һаман хәл ителмичә кала. Инглиз, француз, немес, испан һ. б. милләт язучыларын русчадан тәрҗемә итү оят безгә, оят. Гомәр Хәйямның президент Путинны да сокландырган мәшһүр робагыйлары татарчага, сайлап-сайланып кына, нигездә рус теле аркылы тәрҗемә кылынганнар... Бусы икеләтә хурлык. Татар әдибе үзенең элгәрләрен—гарәп-фарсы шагыйрьләрен һәм шәрык поэзиясен биш бармагын белгән кебек белергә тиеш. Үзбәкләрдән үрнәк алыйк. Безнең президент Гомәр Хәйямны татарча укысын. Өстәвенә, компьютерчы кыз бер-ике хәрефен алмаштырса, Гомәр Хәйямның башкортчасы да әзер булыр... Конкрет бу очракта, әүвәлдәге кебек, башкорт укучысы да безнең йогынтылы даирәбездә калыр.

Язучылар берлеге каршында һич югы гарәп телен өйрәнү түгәрәге оештырылсын иде. Шунда ук гарәп шрифты куелган компьютерда эшләргә өйрәтсәләр, тагы да әйбәтрәк. Гарәп теле сүзчән хәзрәтләребезнең кагылгысыз биләмәсе генә булып калмасын, әдип кеше дин әһеле белән тигез торып гәпләшә һәм, киреләксә, бәхәс кора алсын. «Коръән»нең татарчага югары сыйфатлы тәрҗемәсе юклыгы да гарәп телен белмәвебездән килә бит. Коръәннең башка төрки халыклар кызыгырлык һәм безгә ияререлек яхшы тәрҗемәсен булдырсак иде. Бу—әдипләр һәм галимнәр бурычы, бу эшне дин әһелләребезнең ялгыз гына ерып чыга алмаячагы күренә инде.

Борынгы төрки телебезне өйрәнсәк, күпләгән хакыйкатьләрнең ата-бабаларыбызга ук мәгълүм булганлыгын күреп, таң калыр идек. Ерак элгәрләребез хәтта һинди фәлсәфәсен белгәннәр, Кытай (Чин) ачышларыннан хәбәрдар булганнар, Юпитер (Айгыр) һәм Сатурн (Зөхәл, Туфрак йолдыз) планеталарының хәрәкәтен хисаплый алганнар, Бөек бозланыш чорына кадәр үк Ай фазаларын күрсәтә торган уч төбе хәтле генә таш календарь уйлап тапканнар, табигый таш «мөгезбака» сыртына йолдызлы күк йөзе картасын төшергәннәр... Борынгы элгәрләребезнең интеллектуаль казанышлары чыннан да искитмәле.

«Әйдәгез артка!» дигән өндәмәдән курыкмыйк, ул безгә җуйган максудыбызны табарга ярдәм итәр.

Сүнмәс ут янында хыялланып утырып, уйларымда әллә кайларга каерып кергәнмен, тарих карурманында яшьти Шүрәлем белән адашып, Сүзбашым истән дә чыккан бугай... Күңел төпкеленнән әллә нинди археологик катлам-сәхифәләрне актарып алды бу Китап.

Юк, юк, борчылмагыз,—бар да истә.
Шәмдәлләрдә генә утлар яна...
Дәрдле Мәнд кабызган шәм ялкыны
«Менә сүнәм...сүнәм»,—диеп леперди.

Утлар сүнәр. Хәтәр жилдән бигрәк, аны вакыт-патшаның битараф сулышы сүндерә. Шулай да күз алдыма котсыз яман сурәт килә: вәйран хәрабәләр арасында сүнгән учак көлен җен туеның салкын җиле бөтерә, тузгыта...

Утлы, тере күмер сүнгәч, аны үле күмер диләр.

Өмет кенә сүнми. Адәм күнелендә аның гәрәбә утыдай бәләкәй электр чаткысы барыбер саклана.

Кадими Болгар кирпечедәй саллы «Сүнмәс утлар балкышы» китабы гасырларга безнең гранит төсендәге чакматаш булып калыр—мәңгелек тарих нигезенә салынган татар кирпече...



*Буыннар берләшә.*
*Азатлык мәйданы. 1991 ел.*

Альберт Фәтхи сыман дәрдле бер яшь китап корты аны тузанлы киштәләрдән сак кына күтәреп алыр да, гранит чакматашын сызып, татарның балавыз шәм төпчегендә янә җанлы ут тергезер һәм шуның тыйнак балкышында, томанлы Акбарс белән янәшә, бүгенге моңлы фикер ияләребезнең кан җылысын саклаган шәүләләрен күрер.

Сәлам сиңа, Фәтхи-турун, сәлам сезләргә. Моны мин генә әйтмим, моны «Сүнмәс утлар балкышы» китабын дөньяга чыгарган кордашларым да әйтә.

Татар дөньясы бигүк караңгы түгелдер бит, кардәшем? Зольмәт түгелдер? Безне сагынасызмы?

Ә без сездән көнләмибез, юк. Тынгысыз Виссарион Белинский гына 1950 елда яшәячәк оныкларыннан көнләшкән бугай. Ялгышкан даһи, ялгышкан... Йөз елдан соң Рәсәйне замандашлары төзегән «Коммунистик партия манифесты» тудырачак ГУЛАГ пәрәвезе чорнап алыр дигән кара уй башына да килмәгән аның.

Һәркемгә үз заманы кадерле, бәс, шулай булсын! Матур киләчәк хакына яшим һәм эшлим дисәң дә, син бүгенге көнең өчен шәһит китәсең.

Безнең кордашларга шәһитләр буыны булырга язган.

Марс Гаитов

# ҖЫРГА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

## ШАГЫЙРӘ ГӨЛШАТ ЗӘЙНАШЕВА ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Безнен мөхтәрәм, яраткан Гөлшат апабыз турында язарга күптән жыенып йөрсәм дә, теләгемне хәзер генә башкара алдым. Менә бит җае чыгып тора: шушы көннәрдә аның туууына 80 ел тула.

Булачак шагыйрә Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Чаллы кантонының күрше Иске Теләнче авылында дөньяга килә. Гөлшат апа белән безнең туганлык болай. Аның әтисе Хисам абый белән минем әниемнең әнисе Фәрхисрур—бертуганнар. Дүрт бала атасы Хисам абый авылның урта хәлле крестьяны булып колхозга кергән булса да, 1930 елда кулак дип аны Архангельск өлкәсенә сөрәләр. Шуннан соңгы гомерен алдан күргән кебек, сөргеннән мондый җыр язып җибәргән абыебыз:

*Капчык астык иңнәргә,*
*Киттек ерак илләргә.*
*Әҗәл шушындадыр диеп*
*Җиттек Архангельләргә.*

Хәер, соңыннан, 1980 елларда, бер гаепсезгә иленнән сөрелеп, Архангель төрмәсендә ятып калган Хисам Зәйнашев репрессия корбаны буларак акланды. Хисам абыйның гомерен хөкүмәт 8 мең сумга бәяләде, балаларына шул кадәр акча бирде...

Берсеннән-берсе кече дүрт бала белән йорт-җирсез, ач, ялангач, хәерче хәлендә ялгыз калган әнисе ике яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче Маһруй апага асрамага илтеп бирергә мәҗбүр була. Чаллы—Минзәлә юлыннан ерак түгел урнашкан матур табигатьле бу авыл, балачак хатирәсе булып, Гөлшат күңелендә гомерлек якты эз калдыра.

*Нинди авыл ул, дисәгез,*
*Моңлы авыл Тәкермән.*
*Китсәң—сагынып кайтасың,*
*Мәңге чыкмый хәтердән.*

Бик күп еллардан соң, инде танылган шагыйрә Гөлшат апа "Моңлы авыл Тәкермән" дигән җырында (Ринат Гобәйдуллин музыкасы) авылын әнә шулай зурлый.

Ятимә Гөлшатның балачагы һәм яшүсмер чоры халык кичергән авыр елларга туры килә. Шул житмәүчелек, фәкыйрьлек шартларында да сәләтле, зирәк акыллы

кыз—белем алуга омтыла, бик күп әдәби китаплар укый. Башлангыч мәктәптәге сыйныфташы Хәсән ага Гәрәев (Казанда яши) "Гөлшат гел "бишле"гә генә укыды, һәрчак беренче рәттәге партада утырыр иде" дип искә ала.

Гөлшат апаның гомере буе су коенырга куркуы да Тәкермән белән бәйле. Әле йөзә белмәгән килеш, авыл уртасындагы буада бата язып калганын искә ала иде ул. Бәхеткә каршы, нәни кызчыкны коткарып калалар (рәхмәт яусын!).

Минзәлә педагогия училищесын уңышлы тәмамлап, 1945 елда ул Казан педагогия институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Бик яхшы билгеләргә генә укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша, сәхнәдә җырлый, кыскасы, менә дигән студентка була. Һәм менә бервакыт аны институт директоры Йосыф Туишев кабинетка чакыртып, тетрәткеч хәбәр әйтә: "Мин сезне институттан чыгарырга мәҗбүр, НКВД таләп итә",—ди. Гөлшатны кулак баласы ("халык дошманы" кызы) булуда һәм институтка кергәндә бу фактны яшерүдә гаеплиләр. Ике яшьтә әти-әнисеннән аерылуга дучар ителгән ятим бала әтисен бөтенләй хәтерләми, шуна карамастан, ул хакимият—совет власте өчен бик куркыныч җан иясе икән.


*Гөлшат Зәйнашева. 1959 ел.*

Бу вакыйганы яшь кыз, житмәсә комсомол әгъзасы, бик авыр кичерә, әмма югалып калмый. Шундук Казан театр училищесына укырга керә. Бераз вакыттан соң институт директоры аны эзләтеп таба һәм янадан үзендә укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирә (миһербанлы, бик тә әхлаклы кеше булган Йосыф ага). Әмма "халык дошманы кызы" дигән нахак мөһер Г. Зәйнашеваны гомере буе эзәрлекли. Инде 20 ел нәтиҗәле иҗат итеп халыкка танылса да, язучылар берлегенә аны 1969 елда гына кабул итәләр.

Гөлшат апа белән мин Казанда, авыл хуҗалыгы институтына укырга кергәч, 1953 елда күрешеп таныштым. Анын Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшләве турында әнием (авылыбыз мәктәбендә укытты) әйткән иде. Татар әдәбиятын ярату, язучыларга һәм китап чыгаручыларга хөрмәтем зур булу сәбәпле, минем шундый "зур урында" эшләүче Гөлшат апаны тизрәк күрәсем, анын белән якыннан танышасым килде.

Матбугат йортына бардым, коридорда очраткан ападан: "Гөлшат апа Зәйнашеваны ничек табарга?—дип сорауга, ул мине анын бүлмәсенә алып килде. Бәхеттән, Гөлшат апа үз урынында икән, мине бик җылы каршылады. Безнен гаилә, әтием Җамалетдин, әнием Маһруй, әбием турында сорашты, аларны яхшы белүе сизелеп тора иде. Аннан соң минем институтта кем булырга укуым, тормыш-көнкүрешем белән кызыксынды, мактау сүзләре әйтеп, күнелне күтәрде. Өенә килергә чакырып, фатир адресын бирде. Ул чакта алар: әле яшь бала—кызы Асия, ире Мөхәммәт белән өч кешедән торган гаилә—Некрасов урамында ярым подвалдагы бик кечкенә бүлмәдә яшиләр иде. Бүлмә кысан булса да, киң күнелле Гөлшат апа мине якты чырай белән каршы ала, тәмле чәй һәм ризыклар белән сыйлый иде. Аларга без мәктәп сабакташым, ул чакта консерватория студенты, сонрак мәшһүр җырчы Илһам Шакиров белән дә баргалый идек.

Шул еллардан башлап без Гөлшат апа белән гомер буе аралашып, дустанә,

якын туганнарча яшәдек. Гаиләбез белән без аны бик яраттык, ихтирам иттек. Ул да безне үз итә иде. "Марс энекәш, син мина тормышта—бер терәк",—дигән иде берчак. Мин ана зур терәк булдым дип мактана алмыйм, ә менә Гөлшат апабыз, чыннан да, безнең гаиләгә кояш кебек якты нур сибеп, рухыбызны баетып, авырлыкларга бирешмичә яшәргә, алга карап эш итәргә өйрәтте, акыллы киңәшләре белән ярдәм итте.

Мәктәп елларыннан әдәби әсәрләр укырга яраттым, татар әдипләренең китапларын, газета-журналларны даими укып бара идем. Күп укый торгач, яраткан әсәрләр, яраткан язучылар билгеле була, алар турында фикер туа. Шулар хакында Гөлшат апаның бәясен белү миңа бик кызык була торган иде. Гөлшат апа мине Матбугат йортындагы Г. Тукай исемендәге клубына җомга кичәләренә еш чакыра. Анда язучыларның үзләрен күрәсең, чыгышларын тыңлыйсың, җыр, моң, концертлар белән клуб без яшьләрне гел үзенә тарта иде. Мин анда мөхтәрәм язучыларыбыз Гомәр Бәширов, Мирсәй Әмир, Афзал Шамов, Фатих Хөсни, Әмирхан Еники, Хәсән Туфан, Ибраһим Гази, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һ. б.ларны күреп, чыгышларын тыңлау бәхетенә ирештем.

Бервакыт (50 нче еллар) Гөлшат апа язган "Рамай" пьесасын язучылар берлегенең драматургия секциясендә тикшереп фикер алыштылар. Ул җыелышка Гөлшат апа мине дә дәшкән иде, бик кызыксынып тыңлап утырдым. Җыелышны күренекле драматург Таҗи Гыйззәт алып барды. Әсәрне хупладылар, җитешсезлекләрен күрсәтеп, тагын да камилләштерергә кирәк, дигән теләк белдерделәр. Гөлшат апа ул әсәрне яңабаштан язып, театр сәхнәсенә менгерде.

Мин, ниһаять, 1958 елда институтны уңышлы тәмамлап, галим-агроном дипломы алып, үз авылыма (Яңа Юл районының Иске Дөреш авылы, хәзер Тукай районына керә) дәүләт сортлар сынау участогына мөдир булып эшкә кайттым. Гөлшат апа белән элемтәбез өзелмәде. Аның иҗади уңышларына шатланып, горурланып яшәдем. 1959 елның августында Гөлшат апа безнең авылга килде. Туган-тумачалары—безнең гаилә белән шатланып күрешкәч, хәл-әхвәл белешкәч, чәйдән соң әйтә куйды: "Марс энекәш, миңа басуларыгызны күрсәт әле". Без аның белән трантаска утырып басу-кырларга юнәлдек. Кояшлы, матур көн, игеннәрне урып-җыю бара, кызу эш өсте. Гөлшат апаны бөтен нәрсә кызыксындыра. Кара туфраклы, уңдырышлы басуларда күкрәп үскән бодайларга соклана, игенчеләрне мактый. Әбәткә туктаган комбайнчылар белән кыска гына әңгәмә дә булды. Мин шаяртып: "Менә, егетләр, сезнең ничек эшләвегез турында җыр язарга Гөлшат апа Казаннан кайтты, сынатмагыз!"—дим. Гөлшат апа бу "экскурсиядән" бик канәгать калды.

Ә менә бер мәгълүм җыры—нәкъ менә безгә килүе истәлеге. 1963 елда без хатыным Венера, шул елны туган кызыбыз Алсу белән Минзәлә янындагы совхозда яшәгәндә, Гөлшат апа, юл уңае дип, бер генә кичкә безгә килде. Дүрт чакрым араны ул кичен, кояш баеп караңгы төшә башлагач, юлы-ние белән яңа гына сөрелгән басу аша буразналар таптап, җәяү үткән. Зарланмады, уфтанмады, ә без аның килүенә бик шатландык.

Соңыннан үзе сөйләде, "Буразналар" җырының сүзләре аның күңелендә шул чакта басуда туган икән. Буразналарны ул гармун сыры белән чагыштыра, көмеш сабаннар җыры итеп тыңлый һәм хезмәт шавы, кошлар җыры белән баета:

*Буразналар, буразналар*
*Йөгерек дулкыннар.*
*буразнамда игенкәйләр*
*Күкрәп уңсыннар!...*

Күренекле композитор Җәүдәт Фәйзи бу сүзләргә дәртле, матур көй язды, оста җырчылар башкаргач, ул популяр җыр булып китте.

Икенче көнне без аны Минзәләгә озаттык. Минзәләгә ул еш кайта, Тәкермән авылында Маһруй апа янында була, Минзәлә драма театрына пьесалар язып алып килә иде. Ә аларны сәхнәгә чыгарып, тамашачыга күрсәткәнче режиссёр белән (Сабир Өметбаев, соңрак Мулланур Мостафин, Булат Бәдриев) бергәләп ул күп

эшли, текстны төзәтә, өстәмәләр кертә. Гөлшат апаның "Бәхет кошым", "Кем гүзәл", "Ирексездән әрәмтамак", "Рамай", "Яшел сумка", "Язмышлар һәм ялгышлар" пьесалары Минзәлә театры куелышында зур уңыш белән барды.

Гөлшат апа үз гомерендә шактый күп пьесалар: драмалар, комедияләр иҗат итте. Аларның күбесенә композиторларыбыз музыка язды. Спектакльләр сәхнәдә музыка, җыр белән үрелеп бара, нәтиҗәдә музыкаль драма яки комедия рәвешен ала, һәм тамашачы күңеленә хуш килә. Бу җәһәттән, хәтердә бер төен дә саклана.

1990 елда зыялы җәмәгатьчелек Галия Кайбицкая, Афзал һәм Салих Шамовлар, Әзһәр Абдуллин, Үзбәк Әхмәров, Фасил Әхмәтев һ. б. Казанда махсус музыкаль драма театры булдыру мәсьәләсен күтәреп чыккан иде. Шундый тәкъдимне нигезләп, 100дән артык татар зыялылары исеменнән хакимияткә хат юллана. Гөлшат апа бу башлангычны кайнар хуплый, хатны беренчеләрдән булып имзалый. Арада хатка кул куюдан баш тартучы әдәбият-сәнгать әһелләре дә була. Ә түрәләребез бу бик тә урынлы тәкъдимне игътибарсыз калдырдылар, мәсьәлә әле бүген дә хәл ителмәгән.

Гөлшат апаның яңадан-яңа китаплары чыга торды. Һәрберсен миңа, соңрак без өйләнешкәч (1962 елдан), гаиләбезгә җылы сүзләр язылган автограф белән бүләк итә иде. Радио, телевидение, концертларда аның сүзләренә язылган җырлар бик еш яңгырый иде, алар халыкның мәхәббәтен тиз яулады. Чөнки күренекле композиторлар иҗат иткән моңлы көйләр, Гөлшат апа язган тирән фикерле сүзләр бик халыкчан, аңлаешлы, җырчылар да аларны бик теләп, яратып, оста башкаралар, тыңлаучының күңел кылларын тибрәндереп җырга гашыйк итәләр. Ул җырларда чын мәхәббәт, дуслык, туган илгә тугрылык, аны ярату хисләре яңгырый, алар тыңлаучыны уйландыра, моңландыра, дәртләндерә, яшәргә көч бирә. Сәнгатькәрләр даирәсе көнчеләрсез булмый, диләр—бу дөрестер, күрәсең. Бер урта кул язучы, Гөлшат апаны кимсетергә теләп, ахрысы, аңа болай ди: "Син, Гөлшат апа, такмаклар язасың инде". Андый нахак сүзләрне акыллы, әдәпле кеше, уенда булса да, хатын-кызга әйтми, билгеле. Аннан соң, татар җырына битараф булмаган кеше шуны истән чыгармаска тиеш: Гөлшат Зәйнашева "такмакларына" Татарстан һәм Башкортстанның иң күренекле композиторлары моңлы көйләр иҗат итеп, татарлар гына түгел, гомумән төрки халыклар ярата торган популяр җырлар тудырдылар. Аларны без зур ихтирам белән атыйбыз: Р. Яхин, Ж. Фәйзи, А. Ключарев, М. Мозаффаров, С. Садыйкова, А. Монасыйпов, Б. Гайсин, Б. Мулюков, Р. Еникеев, И. Мәҗитов, М. Имашев, М. Шәмсетдинова, Р. Ахиярова, З. Гыйбадуллин, Ф. Әхмәдиев, И. Хисамов һ. б.

Мин доцент вазифасында 24 ел эшләгән Казан авыл хуҗалыгы институты (хәзер Аграр университет) коллективына, бигрәк тә студентларга үзенең иҗаты белән ул бик таныш һәм якын булды. Күпчелек студентларыбыз авыл җирләреннән килгәнгә күрә, мәктәпләрдә татарча укып үскәннәр, татар әдәбиятын, сәнгатен, бигрәк тә җырларын кечкенәдән беләләр, яраталар. Гөлшат Зәйнашева җырларын алар аерата яраталар, аларны үзләре дә җырлыйлар.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, режиссёр, актёр Роберт Галиев җитәкчелегендәге "Тургай" халык (студентлар) театры Гөлшат апаның драма әсәрләрен сәхнәләштерде, алар үзебездә һәм авылларда, телевидениедә уңыш белән барды.

Ул елларда институтта бик күркәм гадәт яшәп килде—студентлар белән очрашуларга әледән-әле язучылар, артистлар чакырыла иде. Шундый кичәләргә Гөлшат апа бик теләп килә, кичәне бик оста итеп, юмор белән үзе алып бара, тамашачыларны көлдерә дә, уйландыра да иде.

Студент халкын бар нәрсә кызыксындыра, кичәне алып баручыга сорау язылган кәгазь кисәкләре килә тора, ә Гөлшат апа аларга юмор белән, көлдереп җавап бирә, әмма зыялы буларак тирән эчтәлекле, тәрбияви мәгълүмат та өсти. Әйтик, әле яшь-яшь Зилә Сөнгатуллина ифрат моңлы итеп җырлагач, сәхнәгә уч төбе кадәр кәгазь очып төште. Гөлшат апа сорауны залга карап укый: "Кем ул Зилә Сөнгатуллина?" Һәм бик җитди җавап бирә: "Зилә әле консерватория студенткасы, җырчы булырга әзерләнә, бик өметле, перспективалы кыз, киләчәктә мәшһүр җырчы

булачак!" Аллага шөкер, нәкъ шулай булды! Зиләбез, шагыйрәнең бу фаразын артыгы белән аклады! Чыннан да, Гөлшат апа яшь, өметле, талантлы жырчыларны бик тиз һәм оста таный белә, аларга зур сәхнәгә чыгара ярдәм итә иде. Шуңа күрә аны жырчылар бик яраталар, ана омтылалар, киңәш-табышка еш киләләр иде. Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Рафаэль Ильясов, Флёра Сөләйманова, Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхәбиева-Бигичева, Гөлзадә Сафиуллина, Хәмдүнә Тимергалиева, Фердинанд Сәләхов, Искәндәр Биктаһиров һ. б. бик күп жырчылар белән озак еллар дәвамында ижади дуслыкта булды Гөлшат апа.

Гөлшат апа үзе дә моңлы, матур тембрлы тавыш белән жырлый иде.

Яши торган бүлмәсе тар булса да, күңеле киң иде аның. Ямская урамындагы бер бүлмәле коммуналь фатирда өч кеше яшәгәндә алардан кеше өзелмәде. Язучылар, композиторлар, жырчылар еш кына килә иде. Ул чакта ире композитор Зиннур Гыйбадуллин белән бик актив ижат иттеләр—моңлы, күңелгә хуш килердәй, эчтәлекле жырларны күп яздылар Гөлшат апаларның бу кечкенә фатирында. Ана кадәр бу фатирда ике баласы белән язучы Әминә Бикчәнтәева яшәгән булган. Ул бик еш килеп йөри иде. Хәл-әхвәлен сорагач: "И-и Марс, бик борчулы чагым әле",— дия иде. Мин куркып китәм: "Нәрсә булды, Әминә апа?". Ул җавап бирә: "Акча беткән вакыт әле, акча юк". Даими хезмәт хакы алмыйча, барлы-юклы гонорарга берүзе (ул шагыйрь Нури Арсланның беренче хатыны) ике бала тәрбияләүче Әминә апаның "борчулы вакытлары" күп булгандыр шул.

Гөлшат апаның игелекле кеше булуын раслаучы йөзләгән мисалдан бер мисал китерәм. 1964 елда мин Татарстан авыл хужалыгы тәҗрибә станциясендә өлкән гыйльми хезмәткәр булып эшли башладым. Башта Гөлшат апаларда туктадым, фатир алганчы берничә ай Әмәт тавы итәгендәге Агрономическая урамында үз йортында яшәүче пенсионер карчыкның кечкенә бүлмәсендә тордым. Менә бервакыт Гөлшат апа миңа: "Марс, бер өметле яшь шагыйрь, университет студенты, Равил Фәйзуллин исемле бик тәүфыйклы егеткә бүлмә кирәк, синең янга кертмәс микән йорт хужасы, сорап кара әле",—ди. Хужабикә белән минем сөйләшү уңай хәл ителде. Равил шул йорттан үзенә аерым, минеке шикелле кечкенә бүлмәгә килеп урнашты. Ул миннән баерак булып чыкты: ике зур чемоданга шыплап тутырып китапларын алып килде. Соңрак бөтен бүлмә ул жыйган китаплар белән тулып, китапханә рәвешен алды. Советлар Союзының төрле төбәкләреннән шагыйрьләрдән килә иде аңа, шигырь басмалары. Дуслары, танышлары күп, элемтәләре, дөньясы киң булып чыкты Равилнең. Үзе бик күп укый, яза, аның зур шагыйрь буласы шул чакта ук сизелә иде. Соңрак бу йортны аның әти-әниләре сатып алып, үзләре дә Казанга күчеп килгәч, ул яшь шагыйрьләр "оясына" әверелә. Р. Гаташ, Р. Мингалим, Г. Рәхим, Р. Харис бирегә еш килеп йөри башлый, биш егет шигърият дәрьясында йөзәләр, шигырьләрен укыйлар, бәхәсләшәләр...

Янадан авыл хужалыгы институтына, студентлар янына кайтыйк әле. 1990 елда чираттагы очрашу кичәсендә бер кыю студент аягүрә басып әйтеп салды: "Шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваны институт коллективы исеменнән Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим итик әле!" Залдагылар хуплап кул чапты, ә икенче көнне шул премияне бирү комитеты рәисе М. Хәсәновка хат язылды, ана институт житәкчеләре, укытучылар, студентлар кул куйды. Тәкъдим бик вакытлы булып чыкты, 1991 елда Гөлшат Зәйнашева ул мәртәбәле премиянең лауреаты булды. Жырлар жыентыгы өчен Г. Тукай исемендәге бүләк тапшыру (бигрәк тә шагыйрәгә) тарихта беренче тапкыр иде һәм әлегә кадәр берданбер вакыйга булып кала бирә.

Татарстан һәм Башкортстан шагыйрьләре, язучылары, сәнгать әһелләре, галимнәре Гөлшат Зәйнашева ижатына уңай бәя бирделәр. Шигъриятны яхшы белүче тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин Г. Зәйнашева ижатын "бөтенләйгә диярлек жыр жанрына багышланган һәм идея-эстетик планда зур тәрбияви әһәмияткә ия",— дип бәяләде.

Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәжми Г. Тукай бүләгенә лаек булган "Илле жыр" китабы турында "Илле шатлык" дигән мәкалә язып чыкты, ана югары бәя бирде, авторның үзен "жырлаучы шигырьләр остасы" дип атады *(Шәһри Казан, 1991, 12 апрель).*

Гөлшат апа искиткеч образлы фикер йөртә, үзе уйлап тапкан куптөрле шул образларны иҗатында һич котмәгәндә, әмма бик урынлы файдалана иде. Бу мәсьәләдә аны аңламаучылар да, яклаучылар да табылып торды. Яклаучыларның берсе—халык язучысы Гариф Ахунов: “Гөлшат җырлары тирәсендә әледән-әле бәхәс куера, кылычлар чыңлый”, “кайберәүләр җырның эчке рухын аңламыйлар”, дип язды. Һәм нәтиҗәдә ясады: “Гөлшат Зәйнашева татар җыр поэзиясенә үзеннән лаеклы өлеш кертте” (1988). Ә кайбер тәнкыйтьләрнең нигезсез булганлыгын тормыш, вакыт раслап килде.

1950 еллар ахырында шагыйрәнең “Менәргә иде Урал тауларына” шигыре басылып чыккач, бер хәсрәт тәнкыйтьче: “Урал таулары биек түгел бит ул, аларга менү турында хыялланырга кирәк микән?”—дип язды. Җырның сүзләрен пессимизмда гаепләде. Тирән мәгънәле, туган илгә мәхәббәт тәрбияләүче бу шигырь сүзләренә күренекле композиторыбыз М. Мозаффаров кабатланмас моңлы көй иҗат иткәч, нинди матур җыр туды! Легендар җырчыбыз Илһам Шакиров аны иң беренче булып, консерваторияне тәмамлаганда диплом җыры итеп, тыңлаучыларның күңел кылларын тибрәндереп башкаргач, әсәр халкыбызның яраткан җырына әверелде, ана тауның «тәбәнәклеге» һич комачауламады.

Икенче бер гыйбрәтле мисал. Гөлшат апа иҗатташ дусты, мәшһүр композитор Сара Садыйкова турында гаять саллы өч китап бастырып чыгарды. Берсен ул үзе иҗат итте. *(Гөлшат Зәйнашева, Сара Садыйкова (Җырга багышланган тормыш һәм иҗат юлы турында)—К., 1987).* Әлеге документаль повесть кызыклы, мавыктыргыч, җиңел укыла, татар сәнгате тарихыннан күп мәгълүмат бирә. Рецензентлары—халык шагыйре Сибгат Хәким һәм композитор, дирижёр, галим Әзһәр Абдуллин.

Соңгы ике китапның төзүчесе булды Гөлшат апабыз. *(«Сагыналар сине якын дуслар». Сара Садыйкова турында истәлекләр—К., 1991; «Калфаклы сандугач». Сара Садыйкова турында истәлекләр, язмалар, шигырьләр, фоторәсемнәр.—К., 2002).* Бу китапның тышлыктагы буш битендә Гөлшат апа язган: “Кадерле Марс! Кадерле Венера! Сара апабызның җырларын, моңнарын сез дә бик яратканны беләм. Бу китапны Сара апаның һәм минем истәлегем итеп саклагыз. Бик зур көч куеп, авырлыклар белән дөньяга чыгардым бу китапны. Сез минем эшләремнең нинди кыенлыкларны җиңеп алып барганымны беләсез инде, һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торасыз. Рәхмәт шулай якын итүегезгә! Сезне яратып: Гөлшат апагыз. 29 октябрь, 2002”.

Үзе төзегән соңгы басмада композиторны ул “калфаклы сандугач” дип атый һәм китапка да шундый исем куша. Нәшриятта бу исемгә каршы кешеләр табыла. Имеш, сандугач калфаклы булмый. Гөлшат апага бу исемнең шагыйранә бер охшату, символик образ икәнен исбатларга, бәхәсләшергә туры килә.

Аналарга багышлап 1960 елда язылган һәм тиз арада җырлана башлап, популяр булып киткән “Кояш гомере” җыры да тәнкыйтькә эләгә. “Кояш гомере дигән сүз юк бездә, халыкта булмаган сүзне кертеп җыр язмыйлар”,—дип чыгыш ясый язучылар җыелышында бер тәнкыйтьче. Ярамыйга карамый: җыр күңелләрне яулады, аны балалар гына түгел, олылар да җырлый.

Гөлшат апа бөек композитор Салих Сәйдәшев иҗатын бик ихтирам итә һәм ярата иде. Аның сүзләренә музыканы, гаҗәеп моңлы көйләрне нәкъ менә С. Сәйдәшев традицияләрен дәвам итүче композиторларыбыз иҗат итте. Без аларны бу язмабызда атадык инде. Кайбер композиторларга шагыйрә үзе мөрәҗәгать иткән, шулай ук җырчылар үтенече белән язылган көйләр дә бар. Әле музыка язылмаган шактый нәфис шигырьләре бар шагыйрәнең, композиторларыбыз аларны игътибарсыз калдырмас, шәт. С. Сәйдәшевның 100 еллык юбилеена, аның иҗаты һәм тормышы турында документаль фильм төшерү зарурлыгы килеп баскач, Г. Зәйнашевага мөрәҗәгать итеп, сценарий язуын үтенделәр. Ул бу эшнең бик җаваплы булуын, андый олпат шәхеснең, татар профессиональ музыкасына нигез салучының, тормыш һәм иҗатын тулы итеп бирүнең кыен икәнен тирәнтен аңлап, шундук ризалыгын бирмәгән иде. Әмма кабат-кабат үтенеп сорагач, күнде. Сценарий язу үзе бер бик җаваплы иҗади хезмәт булса, фильмны тудыру тагын да катлаулырак

эш булып чыкты. Алар кинорежиссёр Идмас Үтәгәнев белән бик кыен шартларда "Салих Сәйдәшев" дигән документаль фильм иҗат иттеләр. Гөлшат апа сөйләвенчә, кыенлык шунда икән: алар телестудиядә аппаратлар буш вакытта, бары төннәрен генә эшләргә мәҗбүр. Ниһаять, кыенлыкларны җиңеп, озак, җентекле эзләнүләр аша кирәкле материалларны табып, фильм эшләнеп бетә, телевидение экраннарында нәкъ юбилей көннәрендә тамашачыга күрсәтелә, унай бәяләнә. Гөлшат апа Сара Садыйкова турындагы "Моңсара" (1996), "Моңнар дөньясына сәяхәт" (2006) документаль фильмнарына да сценарийлар язды.

Гөлшат апа үзе иҗат иткән шигырьләренә, җырларына, пьесаларына, китапларына әле ишетелмәгән, бик күркәм, нәфис исемнәр куя белә иде. Берничә җырны искә алыйк: "Китмә, сандугач" (шушы исемдә соңрак Хәйдәр Бигичев ядкаре басылып чыкты, 1999 ел), "Мин бит кара карлыгач" һ. б. Шигырьләр: "Тургай гөле", "Адашкан мәхәббәт", "Кояшлы җыр" һ. б. "Җырчы миләш" (китап исеме, 1982 ел).



*Гөлшат, Алсу, Венера, Марс.*

1970 елларда булган бер вакыйга истә калган. Бервакыт Матбугат йортына, нәрсәдер салынган тартма күтәреп, "Кызыл Шәрык" сыра заводы хезмәткәрләре килеп керә һәм ул чакта нәшриятның кадрлар бүлеге мөдире Гөлшат апага мөрәҗәгать итәләр. Йомышлары шул икән: ширкәт, кукуруз оның файдаланып, махсус технология кулланып, өр-яңа алкогольсез эчемлек эшләп чыгара башлаган, ана исем кушарга кирәк икән. "Сезнең хезмәткәрләрдән берәрсе ярдәм итмәс микән?" Гөлшат апа үзе алына бу эшкә, әмма завод өчен әһәмиятле мәсьәләне чишәргә: "Ачып күрсәтегез әле шешәгезне!"—ди. Пластик бөкене тартып алу белән бу эчемлек шампан шәрабы кебек ургылып шешәдән чыга башлый, бокалларга бүлеп салгач кына тына. Тәме дә ярыйсы икән, эссе көндә сусынны да басарга мөмкин. Эчемлек хуҗалары шагыйрәгә текәлеп карап, аның сүзен көтәләр. Ул бераз уйлап торгач, әйтә куя: "Шаян чәкән!" Кунаклар табышмакның бик тиз һәм отышлы хәл ителүенә куанып, рәхмәтләр әйтеп, заводка ашыгалар. Ширкәт ул елларда 100 мең декалитрдан артык шул исемдәге эчемлек эшләп сатуга чыгара; бәясе кыйммәт булмый, кулланучылар аны яратып өлгерә. Кызганыч, халык күңеленә матур исем белән кергән бу эчемлек соңгы елларда, ниндиләптер, җитештерелми.

Гөлшат апаның җыр сүзләренә катгый үз таләпләре бар иде. Аныңча, җыр тирән фикерле, мәгънәле, заманча ягымлы һәм халыкчан, тыңлаучыга аңлаешлы булырга, әхлаклылык хисләре тәрбияләргә тиеш.

Гөлшат апа бик тыйнак, хәтта артык тыйнак кеше иде. Үзенә, иҗатына багышланган шау-шулы тантаналарны яратмады. Ә концертларда, радио, телевидениедә, төрле кичәләрдә үз җырлары, шигырьләре яңгыраса, сәхнәдә спектакльләре уйналса, чын күңелдән шатлана иде. Минем берничә мәртәбә әйткәнем булды, Гөлшат апа, үзең турында китап яз әле, дип. Гөлшат апа Әлфия Афзалова турында "Үзем турында" дигән китап язды, әмма авторлыкны аңа бүләк итте. Үзе турында китап язарга унайсызланды, тыйнаксызлык була, диде. Әмма күңел биреп укысаң, аның биографиясен язган әсәрләреннән, шигырь-җырларыннан белеп була.

Гөлшат апа тормышта нык, көчле ихтыярлы, оптимист кеше иде. Тормыш аны төрлечә, ә кайчак аяусыз сынады. Әмма ул бөгелмәде, бөтен авырлыкларны җиңеп, урман эченнән чабып баручы зифа боландай алга омтылды. "Үзем турында" дигән

шигырендә ул үзенең бөтен гомерен күздән кичерә, яшәвенең юкка түгел икәнен әйтә:

*"Булды эш, хезмәттә җиңеп,*
*Данга ирешкән чакларым.*
*Якын дуслар белән шатлык,*
*Бәхет бүлешкән чакларым...»*

Гөлшат апаның тагын бер матур ягы—ул бик өлгер, житез, кыю иде. 55 яшендә жинел автомобиль сатып алып, аны йөртергә өйрәнде, 70 тә компьютерны үзләштерде, әсәрләрен шунда татар телендә яза иде. Бу нәрсә язучы өчен бик унайлы, текстны төзәтү жинел, дип мактый иде. Дөнья малына, байлыкка кызыкмады. Аның байлыгы—таланты, сәламәтлеге, гаиләсе һәм дуслары, халык мәхәббәте булды. Васильево бистәсе тирәсендә, Идел буенда башка сәнгатькәрләр белән бергә жир кишәрлеге алып, бакча булдырды. Чәчәк үстерергә ярата иде, бигрәк тә хуш исле, ак төстәге сиреньнәрне. Ул бакчада кызыклы бер вакыйга булган иде. Бакча өчен 6-шар сутый жир бүлеп биргәч, бакча ширкәте рәисе Гөлшат апага мөрәҗәгать итә: "Гөлшат апа, фәлән кешегә жир кирәк иде, син бит берүзең, эшкәртергә авыр булыр, кишәрлегеннен яртысын бир ана!" Мәрхәмәтле Гөлшат апа шунда ук риза була, жиренең яртысын үзе дә белмәгән шул кешегә бүләк итә. Еллар үтә, кызы Асия кияүгә чыга, бер-бер артлы оныклары Дания һәм Камил дөньяга килә. Гөлшат апа бик куанып аларны үстерергә ярдәм итә, җәйне шул бакчада—дачада үткәрәләр, су коеналар, рәхәтләнеп ял итәләр. Анда без дә баргаладык, миңа алма, карлыган агачларына "хирургик операцияләр" ясарга да насыйп булды. Бервакыт әлеге күршеләре: "Бакчамны сатам, аласызмы?"—дип, аларга керә. Уйлаша, киңәшә торгач, Рафаэль кияү Гөлшат апаның "бүләген" сатып ала, бакчаны тәүге, тиешле мәйданда торгыза.

Гөлшат апа бик бала жанлы кеше иде. Кызы Асияне тәрбияләп үстерү, укыту өчен барсын да эшләде. Асия Казан консерваториясен тәмамлап, дирижёр белгечлеге алды, телестудиядә, соңрак татар музыка мәктәбендә эшләде. Ә өзелеп яраткан оныклары университетны тәмамлап, юрист булдылар, әтиләре юлыннан киттеләр. Кияве Рафаэльне ярата иде, минем кияү чын кеше ул, дия иде. Балалары, оныклары әниләрен, әбиләрен бик яраталар, хөрмәт итәләр иде, аны Гөләни дип йөрттеләр.

Гөлшат апа безнең балаларны һәм онлыкларны да үз итә, ярата иде. Кызыбыз тугач, ана без Гөлшат апа хуплавы белән Алсу исеме куйдык. Кызыбыз яхшы укыды, кечкенәдән рәсем ясау белән мавыкты. Казан сәнгать училищесын уңышлы тәмамлагач, Харьков сәнгать-сәнәгать институтында укып, рәссам-дизайнер белгечлеге алды.

Гөлшат апа Алсуны нәшриятка эшкә килергә, рәссам буларак, китаплар бизәргә күндерде. Башка авторларның китаплары белән беррәттән, Алсу Гөлшат апабызның "Мәхәббәт һәм жыр" исемле шигырь һәм жырлар жыентыгының рәссамы булды (2000 нче ел).

Гөлшат апа үзенең һәм туганнарының гына түгел, гомумән, барлык балаларны яратты, аларга игътибарлы, ягымлы булды. Гимназияләрдә, мәктәпләрдә укучылар белән очрашу кичәләрендә бик тиз уртак тел таба, бергәләп хор белән жырлауларына, сорау-табышмакларга җавап бирүләренә ирешә, көлдерә, сөендерә. Кызык була балаларга, алар шатлана, канатлана. Гөлшат апа балалар өчен шактый әсәрләр иҗат итте, китаплар чыгарды: "Асия" (1973), "Кояш гомере" (1975), "Бөҗәкләр концерты" (1984), "Гимназиядә дуслаштык" (1996), "Әбиемне яратам" (1997) һ. б. Вафатыннан соң, 2007 елда"Көмеш тавышлар" дөнья күрде. Казан курчак театрында берничә пьесасы күрсәтелде, алар тамашачы балаларга ошады.

Гөлшат апа гомер буе үз милләтенә, Татарстанга бар талантын жигеп, вакытын һәм көчен кызганмыйча армый-талмый хезмәт итте. Язучылар берлегендә актив эшләде, жәмәгать эшләрендә катнашты. Татарстанның киләчәге өчен янып яшәде. Азатлык өчен көрәш кызган 90 нчы еллар башында бераү, уйламыйча, аңа: "Гөлшат

апа, мәйданда күренмисең, азатлык өчен көрәшмисең",—дигән. Шагыйрә җавап биргән: "Минем иҗатым, җырларым көрәш түгелмени?" Әйе, милләттәшләр-кардәшләр шаһит—гомер буе үзенең халыкчан иҗаты белән ул бу көрәшнең алгы сафында булды. Ул иҗат иткән "Азатлык" җыры (Ә. Шаһиморатов көе) бигрәк тә көчле яңгырады:

*"Тарих шаһит: без бу җиргә хуҗа,*
*Бик тирәннән килә тамырлар"...*
*...............................*
*"Газиз халкым ирек яулый бүген,*
*Иркен сулыш алсын Идел дә.*
*Яңа тормыш, иркен, азат тормыш*
*Тәзик бүген туган җиремдә".*

Ә инде "Идел суы ага торыр" җырын (С. Садыйкова музыкасы) Хәйдәр Бигичев җырлаганда кемнәр генә битараф кала икән? Шулкадәр көчле тәэсир итә ки, тетрәндерә бу җыр, күңелнең иң түренә үтеп, сине үз җиреӊ, үз илеӊ өчен көрәшкә чакыра, азатлыкның янадан кайтачагына ышаныч тудыра.

Аның янына татарлар яшәгән башка төбәкләрдән дә киләләр иде. Әйтик, Башкортстанда аның иҗатташ дуслары күп булды. Татар-башкортның легендар җырчысы, саекмас моң чишмәсе Фәридә Кудашева белән алар гомер буе дустанә яшәделәр, бер-берсенә кунакка йөрештеләр. Ф.Кудашеваның ире, мәшһүр композитор Бәхти Гайсин да килә иде, Гөлшат апаның "Кичегеп килгән мәхәббәт" һәм "Кара мыек" шигырьләренә матур көйләр язды, нәтиҗәдә популяр җырлар туды.

Гөлшат апаның 70 яшьлек юбилее күңелдә якты хатирә булып калды (бу аның соңгы бәйрәме булды, 75 яшь тулган көнне ана инсульт булып, каты авырып китте).

1998 елның 28 февралендә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт Драма һәм комедия театрында аны хөрмәтләү кичәсе узды. Татарстанның Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлеге, театр җитәкчеләре, Минзәлә, Сарман районы хакимият җитәкчеләре һ.б. юбилярны кайнар тәбрикләделәр. Тантаналы бүлектән соң, Гөлшат апа иҗат иткән, озак еллар сәхнәдә уңыш белән барган "Гайфи бабай, өйлән давай!... комедиясе күрсәтелде.

Шул юбилей көннәрендә Гөлшат апаны Кремльдә Президентыбыз М. Шәймиев кабул итте. Берәүгә дә сер түгел, кайберәүләр мондый очрашу форсатыннан оста файдаланып, үзләренең шәхси проблемаларын хәл итәргә тырышалар. Гөлшат апа исә Президентка әдәбият һәм сәнгать әһелләренә, шәхсән үз иҗатына игътибары өчен рәхмәтен әйткәч, татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре С. Сәйдәшев, С. Садыйкова, Ф. Ильская, Г. Болгарская, Г. Камская, Ш. Әсфәндиярова, В. Шәрипова һәм башкаларның истәлекләрен мәңгеләштерү зарурлыгы, өлкәннәр тәрбиясеннән читтә калучы балалар язмышы өчен борчылуын белдергән. Президент бу фикерләр белән килешкән.

1990—2003 елларда Гөлшат апа драматург буларак бик актив эшләде. Аның комедияләре К. Тинчурин театрында уңышлы барды һәм әле дә репертуарда. Әмма шушы театр җитәкчеләре белән бәйле булган һәм Гөлшат апаны гомеренең соңгы елларында бик нык рәнҗеткән бер күңелсез хәл турында әйтми кала алмыйм.

Дистәләрчә еллар бик кысан, бернинди уңайлыклары булмаган артык тузган торакларда көн күреп җәфа чикте Гөлшат апабыз. Тузган торактан күчкәндә дә (1970 еллар уртасы) ана Октябрьская урамында бер бүлмәле "хрущевка" бирелә. Анда ул 20 елга якын яшәде, иҗат итте, зарланмады. Иң кызыгы, Мусин урамындагы ике бүлмәле "хрущевкага" күчәргә җыенып йөргәндә, таныш түгел бер ир кеше килеп, Гөлшат ападан бушаячак фатирны күрсәтүен сорый. Озак еллар төрмәдә утырып кайткан бу адәмне район башкарма комитетыннан җибәргәннәр икән. Фатирны карагач: "Юк, мин мондый фатирга риза түгел",—дип чыгып китә бу. Ә иҗат кешеләре ничек кенә риза әле!!

Тормышта халык белән бергә атлаучы, аны борчыган проблемаларны һәм

куандырган шатлыкларны уртаклашып яшәүче, бик сизгер, зыялы Гөлшат апа тузган торак мәсьәләсенең уңай чишелешенә битараф кала алмады, шуңа багышлап "Тузган тораклан күчкәндә" дигән пьеса язды. Пьесаны К. Тинчурин театры баш режиссёры Рәшит Заһидуллин укып чыга һәм авторга аны сәхнәләштерергә вәгъдә бирә. Гөлшат апага аның 12 вариантын эшләткәннән соң, һичшиксез куябыз, инде репетицияләр башланды, дип белдерсә дә сүзендә тормады. Үзе вәгъдәсен төгәл үти торган шәхес булганлыктан, ир кешенең мондый ямьсез гамәлен Гөлшат апа авыр кичерде, гафу итә алмады. Сонрак бу әсәр Татарстан Яңа Гасыр телевидениесендә, режиссёр Нурания Җамали куелышында, күп серияле фильм итеп күрсәтелде һәм тамашачыларның уңай бәясен алды. Президентыбыз М. Ш. Шәймиевка да бу фильм ошаган булып чыкты, аның исеменнән сценарий авторы Гөлшат Зәйнашевага 50 мең сум бүләк тапшырылды.

Гөлшат апабыз ике елдан артык каты авырды. Хастаханәдә дә, санаторийда да булды, әмма табиплар ярдәм итә алмадылар. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр аек акылында иде, кыенлык белән булса да сөйләшеп ятты. Янынннан кеше өзелмәде, балалары, туганнарыннан тыш бик күп дуслары аның хәлен белергә, кизү торырга килделәр.

Барчабызны тетрәндереп, якыннарын, чын дусларын тирән кайгыга салып, Гөлшат апабыз 2005 елның 1 нче апрелендә арабыздан китеп барды. Ул матәм көнне Татарстан радиосы иртәнге тапшыруларын Гөлшат апаның "Китмә, сандугач" җыры (Рөстәм Яхин музыкасы) белән башлап җибәрде һәм кайгылы хәбәрне халыкка житкерде. Мәрхүм белән хушлашу, матәм җыены, Г. Камал театрында уздырылды, театр шагыйрәне соңгы юлга озатырга килгән халык белән тулы иде.

Гөлшат апабыз арабыздан үзе китте, әмма аның мәңгелек җәүһәрләргә әйләнгән моңлы җырлары калды. Үзе вафат булгач, 2006 елда аның сайланма әсәрләре дөнья күрде, Казанда Гөлшат Зәйнашева музее булдырылды Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтында анын иҗатына багышланган фәнни хезмәт— диссертация якланды. Чаллы педагогика институты укытучысы Дания Нигъмәтҗанова професоор Нурмөхәммәт Хисамов житәкчелегендә шагыйрәнен ярты гасырлык күпкырлы иҗатына тирән анализ ясаган, лаеклы якты бәя биргән.

Татар сәнгате, мәдәниятенең киләчәге турында ихлас кайгырткан шагыйрә исеме кадерле ядкарь булып чор хәтерендә уелып калыр дип ышанасы килә.

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

Мансур
Вәли-Барҗылы

# НАМУСЛЫ КЕШЕЛӘР

*"...Аны кемнәр генә нинди генә хурлыклы сүзләр белән тамгаласалар да, кемнәр генә нинди генә ачулы күз карашлары белән чәнчесәләр дә, Нуриасма үзенең алар өчен буй җитмәс биеклектә торуын аңлады".*
Ф. Садриев, "Таң җиле".

Бу язмабызга исем итеп алынган "намус" төшенчәсен күргәч бәлки күпләр, бигрәк тә яшь буын вәкилләре, сәерсенеп китәр, аптырашта калыр. Чөнки соңгы елларда без ул сүзне, ул төшенчәне онытып ук барабыз бугай инде. "Яңа икътисади һәм сәяси шартларга бәйле рәвештә", ягъни җәмгыятьтә капиталистик мөнәсәбәтләр урнаша бару сәбәпле, без хәзер үзебезгә яңа юнәлеш, яңа кыйбла табарга телибез, ахрысы.

Ләкин ныклап уйлаганда бу мөмкин эшме икән соң? Без монарчы озак еллар буе үз күңелләребездә йөрткән рухи идеалларны тиз генә бүтәнгә алыштыра алабыз микән?

Танылган прозаик Фоат Садриевнын романнары һәм повестьлары безгә бу хакта уйлану өчен гаять мул азык бирә, чөнки аларда җәмгыятебезнең соңгы егерме елдагы тормышы үзенең бик тә типик чагылышын таба.

Язучының "Казан утлары"нда басылган "Таң җиле" романы турында 1993 ел буена журнал битләрендә зур сөйләшү барды. Бу сөйләшүгә инде унбиш еллап гомер үтсә дә һәм шул сәбәпле байтак фикерләр онытылган булса да, аның бөтен барышын, эчтәлеген хәзер яңартып торасы килми. Бары тик безнең белән хәзерге тормыш, бүгенге әдәбият өчен ул әсәрнең һәм шуңа бәйле рәвештә әлеге сөйләшүнең әһәмиятен генә ачыклап китәсе килә. Ул рухи-әхлакый яктан "искермәде" микән? Хәзерге тормыш, димәк, капиталистик мөнәсәбәтләр урнашкан яңа яшәеш өчен, әлеге романның әһәмияте нәрсәдә? Унбиш ел вакыт узганнан соң без ул романга ничек карыйбыз, аны ничек аңлыйбыз, ничек кабул итәбез?

"Читтән караганда аны фәрештә дип кабул итәргә мөмкин иде: кардай ак озын күлмәк, кардай ак яулык астыннан кардай ак чәчләр күренеп тора... Әнә ул, ак фәрештә сыман, ямь-яшел Ык буена килеп басты, чыкка юешләнгән чүәкләрен янәшә китерде, йөзе илаһи кыяфәткә керде..."

Романның иң беренче юлларында ук укучыга әнә шундый фәрештә сыман тәкъдим ителгән Нуриасма, чыннан да, әсәр дәвамында да шул югарылыкта торып кала. Уллар һәм оныклар үстергән гап-гади бер авыл әбие Нуриасма әсәрдә ялганга, аллауга, хәйләгә каршы куела. "Ә ялган үзе, аңа төртеп күрсәтеп торуга карамастан, кимемәде, көчәйде генә. Ялганлаучылар тагын да хәйләкәррәк була бара... Мизхәте дә шундый булыр микәнни?"

Ләкин Нуриасманың үзенең ныклы карашы менә мондый. Безнең хәтергә бик озакка сеңеп калачак әлеге җавап аның килене Мәдинәгә әйткән сүзләрендә чагыла:

—"Их, кызым, кызым,—диде ул аның бирчәеп беткән кулларын сыпырып.— Күзгә күренмәс әйберләр җимерелә шул... Син бүген бернинди начарлык эшләмәдем дип уйлыйсың. Булса да, әз генә, энә очы кадәр генә гаебем бардыр дип

уйлыйсың. Ялгышасың, кызым. Өрфия калынлыгы гына түбән төш—син беттем дип уйла. Ә өрфия калынлыгы күтәрелү өчен кайчакта бер кеше гомере дә җитми. Кем белә, моның өчен берничә буын тормышы кирәктер..."

Нуриасма холкы-табигатенең асылын ачып салган бу сүзләр әлеге әңгәмәдә шактый урынлы килеп чыга чыгуын, ләкин шулай да, без укучылар аларда күбрәк авторның фәлсәфи уйлануы чагыла дип саныйбыз. Һәм моннан романга һич тә зыян килгән дип булмый. Чөнки образлы фикерләү шартлылыгы иҗатчының моның ише алымнарына киң юл ача ул.

Әйе, кешелек җәмгыятенең рухи-әхлакый үсеше бик тә акырын бара. Үтә дә авырлык белән бара ул. Ә кайсыбер чорларда—мисалга без яшәгән елларны алырга мөмкин—ул үсеш тукталып ук кала, җәмгыять аска таба да тәгәри башлый. Мондый елларда акча һәм тамак колына әверелгән кешеләр "намус", "иман", "гаделлек" дигән иң төп ориентирларны—яшәеш кыйбласын бөтенләй оныталар, кирәкмәгән нәрсәгә санап аларны юл читенә үк атып бәрәләр.

Андый вакытларда Нуриасма кебек намуслы кешеләр күңелендә менә мондый кичерешләр туа:

"...Әйтерсең лә аның өстенә коточкыч стена акрын гына ава иде. Аны аудармый калу мөмкин түгел, ул берүзе, янында ярдәмгә беркем дә юк иде... Дөрес, бу күренмәс стенаның теге ягына чыгып, үзенне сытылудан коткарып була. Бәлкем шулай итәргәдер?"

Колхоз рәисенә каршы бармас өчен роман геройларының барысы да диярлек милиция тикшерүчесенә ялган күрсәтмә биргәч, "бу якта" бер ялгызы торып калган Нуриасмада әнә шундый уйлар туа.

Әйе, "Таң җиле" романы героинясы Нуриасма бүтәнрәк холыкка ия шул. Ул көтүдәге малларның берсе кебек кенә түгел. Ул—олы хәреф белән Кеше дип язылa һәм горур итеп әйтелә торган зат. Шуңа күрә Нуриасма күңеленә килгән менә бу уйлар әсәрнең бөтен барышы белән аклана. Аннан соң алар без күрергә, без ишетергә теләгән уйлар да бит әле:

"Юк, диде ул үз-үзенә. Стенаны аудармыйча тотып торучылар кирәк. Нуриасма ак нур булып аларны чакырачак. Ул үзе хәзер кирәкми. Бөтен өмет аларда, аны күрүчеләрдә, аңа иярүчеләрдә..."

"Фәрештә кебек" дигән чагыштырудан башланган романның уртасындагы "ак нур булып" дигән сүзләр, чыннан да, Нуриасма образының бөтен әһәмиятен, рухи-эстетик кыйммәтен ачып сала.

Сүз уңаенда әйтеп китсәк, Нуриасманың әлеге фикере безнең моңа кадәрге әдәбиятыбызның да асылы, төп максаты иде бит ул. Чыннан да, моңа кадәр иҗат ителеп халкыбыз күңеленә яткан, аның күңеленә хуш килгән иң яхшы әсәрләребез алар нәкъ менә шундый "ак нур" кебек көчле тәэсир итүләре, аклык-пакьлек, сафлык, гаделлек үрнәге булулары белән көчле һәм кадерле иделәр. Нәкъ шушы мәсьәләдә үткән гасырның җитмешенче елларында әдипләр арасында фикер каршылыгы да килеп чыккан иде. Бер иш язучылар әдәби әсәр геройларының укучыга үрнәк булырга тиешлеген хуплады (Г. Әпсәләмов һ.б.), ә икенчеләре исә образлар гыйбрәтле язмышка ия булса яхшырак дигән фикер үткәрде (А. Гыйләҗев һ.б.).

Аннан соң күп еллар үтте. Әдәбиятыбызда гыйбрәтле геройлар шул кадәр күп үрчеде ки, хәтта хәзер әдәбиятыбызның тәрбияви көче турында сүз йөртүе дә авырлашты. Тулаем әдәби әсәрләр, бигрәк тә проза әсәрләре, тормышка шулкадәр дә нык якынайды, хәтта аларны күп чагында чынбарлыкның турыдан-туры копиясе дә дип карарга мөмкин кебек. Ягъни әйләнә-тирәдә без нәрсә күрсәк, әдәби әсәр дә еш кына шуны тәкъдим итә башлады. Бу хәл соңгы елларда бигрәк тә уртакул талантка ия язучылар иҗатында күзәтелә.

Әнә шундый әсәрләргә каршы итеп Фоат Садриевның икенче бер әсәрен—1987 елда язылган "Шаһзаманов эше"—повестен куясы килә. Бу әсәрнең башланып китүе үк инде бүтән рухта, башка аһәңдә:

"Мондый хәл килеп чыгар дип колхозда беркем дә уйламаган иде..."

"Илһамның дөп-дөп басып, бик сәер кыяфәттә килүен күреп, барысы да аңа таба борылдылар. Бригадир Латыйпов, үңга тайпылып уртадан юл бирде. Илһамның

йодрыклары гына түгел, иреннәре, күзләре дә ачу белән кысылды, ун як янагы дерт-дерт тартышты. Яхъя, нәрсәдер сизенеп, көлүеннән туктап калды, аның күзләре киерелеп ачылды. Ләкин инде соң иде: Илһам тимердәй йодрыгы белән аның янагына китереп кундырды. Бу шулкадәр тиз, шулкадәр көтмәгәндә булды ки, барысы да аяз көнне яшен сукгандай катып калды. Яхъя мәтәлеп китте һәм чәчәк түтәлен әйләндереп алган тимерчыбык рәшәткәгә башы белән төртелеп, туктап калды. Читтәрәк торучылар да бу якка борылдылар, идарә алды "аһ" итте".

Юк, без хәзер экраннарда һәм китапларда күпләп очрата торган чираттагы "боевик" түгел бу. Повестьның башына ук урнаштырылса да ул—әсәрдәге берданбер шундый күренеш. Ә аның бөтен калган өлеше әнә шул вакыйганы тикшерүгә багышлана. Әсәр иң тәүге биттә үк житди интрига тудырып, укучыны соңгы битләргә кадәр киеренке халәттә, кызыксыну, җавап табасы килү халәтендә тота.

Ә җавап ул чынлап та нинди соң?

Матур гына гаиләсе булган, хатыны белән бергәләп балалар үстергән, колхозда да алдынгы саналган, яхшы колхозчы һәм әйбәт кеше буларак партиядә торган Илһамның әлеге гамәленең сере бик тирәндә ята. Ул сергә бару дәвамында без, укучылар, баштарак ялгыш (яисә тулы булмаган) җавапка да килеп юлыгабыз. Чөнки Илһам яшь чагында әлеге Яхъя исемле агрономның хатыны белән йөргән була. Чын сөю утында яна-яна! Тикшерүче башта Илһам әнә шуның өчен Яхъядан үч алган дип тә уйлый. Әмма Илһам мондый җавапны расламый: "Юк, мин аның өчен сукмадым!"—ди.

Бу уңайдан повестьтагы бер бик хикмәтле эпизодны искә алмый үтү һич мөмкин түгел.

Илһам белән бик яратышып йөрсә дә, Гөлзада Яхъяга кияүгә чыккан бит инде, алар бергә яшәп яталар. Күпмедер вакыт үткәч Илһам да өйләнергә була һәм нәрсә эшли дисез? Ул шушы адымга рөхсәт сорап Гөлзада янына килә. "Син рөхсәт итсәң, мин өйләнер идем..."—ди!

Белмим, бу эпизодны язучының иҗади фантазиясе тудырдымы икән, әллә автор чыннан да тормышта булган шундый бер очракны күреп, ишетеп алганмы—әмма ул Илһамның холкын, табигатен, аның бөтен барлыгын шуның кадәр төгәл ачып бирә—шаклар катарсың! Менә шуннан соң инде син Илһамны алдагы роман героинясы Нуриасмага иш түгел дип әйтеп кара!

Әйе, алар икесе дә—Нуриасма да, Илһам да—намуслы кешеләр. Беренчесе колхоз рәисен яклар өчен генә ялган сөйли алмый, ялган адым атлый алмый, ә бусы—үзен ялганга этәргән агроном Яхъяга сугып җибәрә. Чөнки Яхъя, төнлә тракторчы Илһамның басуны бик үк төгәл күрмәвеннән файдаланып, анда үскән менә дигән борчакны юк иттергән! Тикшерергә киләсе түрәләргә үзе яхшы булып күренер өчен! Әнә шундый пычрак максат белән!

Яхъяның әнә шул әшәке ялганын, үзенең бик тә нык алданганын иртән көн яктыргач кына аңлаган Илһам инде нәрсә эшләргә дә белмичә, ярсый-ярсый авылга кайта, өенә кереп тынычлану өчен дип байтак кына хәмер каба. Әмма алай да тынычлана алмагач, идарә янына килә... Ә анда Яхъя исә, үч иткәндәй, рәхәтләнеп көлә-көлә басып тора! Шул вакыттагы Илһамның халәте безгә бик тә аңлашыла: тегесе вакытта аның сөйгәнен тартып алган әлеге нахал Яхъя аны тагын бер мәртәбә алдады бит! Әле житмәсә, хәзер Илһам килгәндә, башларын артка ташлый-ташлый көлеп тора! Тантана итә!

Шуңа күрә әсәрдә намуслы Илһамның Яхъяга саллы гына итеп берне кундыруы, тегесенең исә мәтәлеп үк китүе—укучы көткән, теләгән гамәл буларак кабул ителә.

Илһамны партиядән чыгарырга теләүләре һәм шуның өчен аның бик нык борчылуы уңаеннан биредә мәрхүм әдибебез Тәуфикъ Әйди фикере искә төшә. "Партиядән чыгарылу—шундый зур кайгымыни соң ул?"—дигән шик белдергән иде ул бер язмасында. Аның бу фикере белән килешәсе килми. Чөнки бит Илһам партиягә чын күңелдән ышанып кергән. Иң намуслы кешеләр партиясе дип кергән. Һәм андый кешеләр партиядә чыннан да бик күп иде алар! Менә шундый дип уйланылган партиядән чыгарылу, ул—әлбәттә—рәхәт түгел! Конкрет чор һәм намуслы, ихлас кеше табигате эченә кереп карый алсак—без моны яхшы аңлыйбыз. Шул ук вакытта, Илһамның әлеге хис-кичерешләре, "искергән" һәм безнең чор

өчен һичнинди дә әһәмияте булмаган кичерешләр дә түгел. Чөнки бирегә үзенә күрә бер коллективның, бер җәмгыятьнең аерым шәхесне читкә тибәрүе, үзеннән кууы турында бара. Ә бу хәл теләсә кайсы чорда да кешегә зур психологик киеренкелек алып килә.

Югарыда телгә алынган "Таң җиле" һәм "Шаһзаманов эше" әсәрләре турында сүз алып барганда, бу реалистик проза әсәрләрендәге романтик агымның да көчле булуын әйтмичә мөмкин түгел. Ә романтик-күтәренке хис-кичерешләргә аеруча игътибарлы булу һәм аларга әсәрдә зур урын бирү—белгәнебезчә укучыга тәэсир көчен бик тә арттыра.

"Алар җир куенындагы бөртекләрнең шытуын, карындагы баласының тәүге тибүен ана кеше ничек сизсә, шулай сизәләр. Шушы басуларда талгын җил кайнар рәшә белән кочаклашып, иген басулары өстендә ауный-тәгәри уйнаса, аларга артыгы кирәкми. Алар башаклар белән талгын җилләрнең кыз белән егет кебек серле пышылдашканын аңлыйлар, шуны җыр итеп күңелләрендә йөртәләр, мирас итеп балаларына тапшыралар...

Илһам белән Габделхәй шушы уйларны уйлап утырдылар да утырдылар. Сүзләр кирәкми иде, һәммәсе—авыл урамнары, ындырлар, бакчалар, басулар, болыннар, сулар, әрәмәләр—аларның аяк астында җәйрәп ята, төсләр булып күзгә, исләр булып борынга тула, җил булып битләрдән сыйпый, кыскасы, табигать үзе сөйли, ул сөйләгәндә сүзләр артык, дәшмичә тыңларга гына кирәк иде. Бөтенесе садә, аңлаешлы, саф, ачык, якты, гади, матур, моңлы һәм тантаналы иде. Бернинди тавыш та, сүз дә, дәшү дә, кушу да, кисәтү дә, әйдәкләү дә кирәкми; шушылай тып-тын, дәшми аңлашудан да ләззәтлерәк һәм бөегрәк нәрсә юк иде..."

Без югарыда сүз алып барган әсәрләрдән тыш Ф. Садриевның тагын биш повесте бар. Иң элек аларның "Көлми торган кеше" исемлесенә тукталыйк. Әсәрнең төп герое—шулай ук авыл кешесе, шулай ук механизатор һәм шулай ук үтә дә намуслы кеше.

Әмма биредә инде автор үзенең героен бүтәнрәк яссылыкта, башкарак мөхиттә күзәтә. Гаилә мөхитендә.

Газизҗан яшьлегендә яратып өйләнгән чая һәм чибәр Һаҗәр сонга таба авылның "яңа татары"—халыкка ялган аракы сатып баеп киткән Халит белән чуала башлый. Армиядә авариягә эләккән, аннары авылда эшләп йөргәндә "Беларусь" тракторы белән кышкы салкын төндә юлда кунган һәм үпкәсенә салкын тидергән Газизҗан исә еш кына авыргалап ала...

Менә шушындый хәлдә калган намуслы ир... Күргәнебезчә, ситуация бер дә гади түгел. Хатынын аерып кына да мәсьәләне хәл итәм димә: чөнки Газизҗанның яраткан малае да бар, аннары соң ул хатынын чынлап та көчле сөю белән сөя.

Алайса ул нишләргә тиеш соң?

Менә шушындый авыр хәлдә калган, бик күпләрнең (бигрәк тә авылда) аннан чыгу юлын таба алмаенча иң соңгы адымга барулары—үз-үзләренә кул салулары—мәгълүм. Әмма Газизҗан алай эшли алмый. Бу чактагы геройның психологик халәте повестьта менә мондый тәэсирле юллар аша бирелә:

"Малаен өзелеп яратмаса, аны ятим итмим диеп җан атмаса, ул ике дә уйламас, йә Һаҗәрне аерып җибәрер, йә үзе өйдән чыгып китәр иде. Боларның берсен дә эшли алмаганлыгын аңлагач, ул коточкыч карарга килде. Бу карар үзенең хурлыклыгы белән төрмәдән дә хәтәррәк иде: малаен кеше иткәнчегә кадәр хатынының хыянәтен күтәреп йөрергә, төртеп күрсәтеп көлсәләр, мыскылласалар да—түзәргә.

Бу хурлык Газизҗанның төн йокыларын качырды, яшәү ямен суындырды, аны төртмә теллегә әверелдерде, бөтенләй елмаймас-көлмәс итте. Ул хәзер авылда берүзе бөтен кешедән аерылып торучы түбәнсетелгән зат иде. Ләкин Газизҗан, ир буларак түбәнсетелсә дә, баш иярга теләмәде, эштә өстен калды, алдап-йолдап, селәгәй белән майлап йөрүчеләрне, кемнең кем булуына карамастан, усал быжан кебек рәхимсез чакты, кайчакта якаларыннан алды".

Ф. Садриев үзенең менә шушы намуслы героеның тормышын бик күп төрле ситуацияләрдә күзәтә. Менә Газизҗан, Казанга дәваланырга дип килгәч, авылдашы, ялгызы гына яшәп ятучы Фирдәүсәне очрата. Алар Фирдәүсәнең фатирына кайталар.

"—Синең өчен мина кыен бит, Газизҗан.
—Нишләп?
—Шулкадәр куркып, куырылып утырасың..."

Автор төзегән менә шушы кыска гына сөйләшү үзе тулы бер күренешне күз алдына китереп бастыра. Биредә гомер буена авылда яшәгән кешенең яп-якты һәм чиста-пөхтә (ялгыз хатын бит!) бүлмәдә бөтенләй югалып калуы да, Фирдәүсәнең исә үз авылдашын һәм чордашын чын күңелдән кызгануы, ана бу моментта ярдәм итәргә теләве дә, соңгы араларда үтә күп хәлләр кичергән Газизҗанның байтак еллар очрашмаган кыз алдында үтә кыенсынуы да—һәммәсе дә күренә, чагыла.

Ә инде бергә утыра-утыра аралар җылынып киткәч, Фирдәүсә аның җырлавын үтенә—чөнки ул аның яшь чакта матур җырлаганын белә. Шул чакта Газизҗан җырлаган җыр аның бар язмышын ачып сала:

*Җәйгә чыксам, бар йөргәнем*
*Урман белән кыр гына...а-ай...*
*Нигә миңа җырламаска,*
*Бар шатлыгым җыр гына-а-ай...*

Ә җырлаучы шушы ирне язучы менә болай тасвирлый: "...аның һәр күзәнәге агып торучы кайнар моңга әверелгән. Бу моң кеше гомеренә йомгак ясый, адәм баласының чиксез газиз нәрсәдән мәңгегә аерылу ачысын сөйли, бер үк вакытта аны нииндидер илаһи бөек җиһан белән куша..."

Шушындый шигъри юллар, чыннан да, прозаик Ф. Садриев каләменең үтә тирән, үтә четерекле халәтләрне дә психологик яктан төгәл итеп, ә без укучылар өчен хисле, тәэсирле итеп ача, җанландыра алуын раслый.

Бу повестьны укыганда без төп герой Газизҗан белән Фирдәүсәнең бергә булуын, кавышуын өмет итә башлыйбыз. Һәм бу табигый да булыр иде кебек. Әмма... әмма Газизҗан барыбер намуслы Газизҗан булып кала шул! Әсәрнең иң ахыргы битендә—Фирдәүсә машина белән аны алырга дип авылга кайткач: "...Ул Фирдәүсәнең күзләренә ярдәм сорагандай төбәлде, теле әйләнмәде, яргаланган иреннәре кызганыч дерелдәп бер ачылды, бер ябылды, тамак төбе белән еш-еш сулап алды. Ахырда ул бөтен барлыгы белән этеп бер сүз чыгара алды:

—Бул... мый..."

Үзенең ни өчен Фирдәүсә белән бергә яшәргә шәһәргә китә алмавын Газизҗан сүзләр белән әйтә алмый. Әмма биредә язучы икенче бер отышлы алым куллана—ул Фирдәүсә күзләре белән Газизҗанны күзәтә: "Газизҗанның кулы коточкыч авыр, имән кайрысыдай кытыршы иде, анардан туфрак, май һәм җир исе килә иде. Әйтерсең лә бу кул түгел, ә бәлки мәңге шушы җирдә үсүче, ләкин күзгә күренмәс пәһлеван агачның бер тере тамыры иде".

Әйе, биредә Газизҗанны авылда калдырып автор һич тә конъюнктур гамәл кылмый, ягъни әсәр герое әйбәт адымнар гына ясасын дип тырышмый. Биредә образның объектив эчтәлеге, асылы шундый. Газизҗан—чынлап та шәһәр җирендә яши дә, түзә дә алмас иде. Без үзебез дә—кичәге миллионлаган авыл кешеләре, бүген шәһәрдә яшәп ятучылар—хәзер янадан җиргә тартылабыз түгелме соң?! Димәк, Газизҗан—безнең күңелебез теләгәнне чынга ашыручы әдәби герой, әдәби образ ул.

Алдарак карап үтелгән өч әсәрнең геройлары: Нуриасма, Илһам Шаһзаманов һәм менә Газизҗан... Алар соң тормышчан образмы? Әйе, без моны бик тә ышанычлы итеп раслый алабыз—чөнки бу персонажларда реаль чордашларыбызның байтак сыйфатлары, типик яклары күренә. Һәм шул ук вакытта әлеге образлар безнең реаль тормыштагы байтак шәхесләрдән күпкә калкурак булып, югарырак та торалар. Бу хәл аларның тормышчанлыгына һич тә зыян китерми. Чөнки, беренчедән, әйләнә-тирә яшәешебездә сирәк булса да андый көчле рухлы кешеләр дә очрый, ә икенчедән, әдәби образ, унай образ логикасы биредә аларга киң мөмкинлекләр тудыра. Әдәбиятның тәрбияви роле турында сүз алып барганда без нәкъ менә Нуриасма, Илһам, Газизҗан кебек көчле рухлы һәм шул ук вакытта намуслы, кешелекле шәхесләргә таянабыз.

Фоат Садриев язган роман һәм повестьлар арасында үзенең тәэсир көче белән аеручa күзгә ташланып торган бер әсәр бар. Ул—"Рәхмәт, әтием!" повесте. Күләм ягыннан алып карагaнда арада иң кечкенәсе булып саналырга лаек әлеге әсәр тәүге юлларыннан ук үзәк өзгеч аһәңнәрдә башланып китә.

"Кеше! Мин моны синең өчен язам, син ялгышма, минем фаҗигане кабатлый күрмә, дип язам... Бу аклану өчен язылмады, мин беркемнән дә гафу сорамыйм, минем моңа бернинди хакым да юк. Кичерергә теләүче табылса да, мин ул кешегә нәфрәтләнер генә идем... Ник дисәң, мин үз-үземне күрә алмыйм, ә андый кеше гафу ителергә тиеш түгел".

Шулай гафу итә алмаслык нәрсә булган икән соң? Повестьны укый-укый алга таба киткәч, безгә очраган менә бу юллар инде күпмедер дәрәҗәдә серне ача төшә: "Минем дөньядагы барлык нәрсәләрдән дә ныграк яраткан улым—куанычым һәм юанычым—корып кипкән хәлдә диспансер баскычында басып тора".

Әсәрдә "мин" дип сүз алып баручы кеше үзе колхоз бригадиры, хуҗалыкның бөтен эше-мәшәкате аның өстендә, аның җилкәсендә. Бу яктан карагaнда ул алда карап үткән әсәр геройлары язмышын дәвам итә дә кебек. Әмма биредә әлеге эш кешесен яңа төрле сынау көтә...

Үзе көн-төн колхоз эше белән мәш килеп йөргән ата кеше иртән малаена ишек алдындагы саламны арбага төяп куярга кушып китә. Көне буе нервланып йөреп кич ачуы да басылмаган көе ишек алдына кайтып керсә—салам һаман төялмәгән! Үч иткәндәй, нәкъ шул чакта бер бәйләм тал чыбыгы күтәргән малае да кайтып кермәсенме!

"—Ник төямәдең?—дидем, ярсуымны көчкә тыеп.

Аның мине беренче мәртәбә шушындый хәлдә күрүе булгандыр. Йөзендәге елмаюы качты, бер сүз дә әйтә алмады. "Без... малайлар белән..."—дип нидер әйтмәкче иде, мин аны кинәт этеп җибәрдем. Әллә таллары авыр иде, ул тигезлеген саклый алмады. Ничектер борылып китте дә, сырты белән арбаны тракторга тага торган кырлы тимергә барып төште. Башыннан бүреге очты, талчыбыклары чәчелеп китте... Мин Сәгадәтнең сынсыз булып катуын күрдем..."

Баштарак бу вакыйга эзсез генә узган сыман тоелса да, бераздан Сәгадәтнең хәле бетә, ул җитди авырып китә... Сонга таба исә ата кешенең яраткан малаенда әлеге каһәр суккан яман чир килеп чыгуы мәгълүм була.

Повесть беренче битеннән алып ахырына кадәр ата кешенең тирән психологик кичерешләренә багышланган. Гүяки без—әсәрне укучылар—баштан ахырга кадәр бер моңлы скрипканың үзәкләрне өзгеч сызлануын, сыкравын, әрнүен, газаплануын ишетәбез, шул фаҗигане кат-кат үз бәгыребез аркылы үткәрәбез.

Әсәрдә күздән яшь китерердәй күренешләр бик күп. Чөнки ата кеше үз малаенын тиздән, бик тиздән якты дөнья белән хушлашасын белеп тора.

Менә шушы күренешләрне тасвирлаган вакытта язучының бер ук вакытта нечкә күнелле кеше дә, оста психолог та булуына һәм геройларның халәтен-портретын чын рәссамнарча күрсәтә алу сәләтенә дә шаһит булабыз. Менә диспансердагы бер күренеш:

"Шул чак аның кулы дерелдәп китте, ул күз яшьләренә буылып, минем муенымнан кочаклап алды. Мин аның ябык аркасын сыпырдым, икебез дә мышык-мышык еладык.

—Әтием... китмә әтием...—диде ул бертуктаусыз".

Соңгы елларның күбрәк бандитлар белән тулган әдәби әсәрләрендә менә мондый тәэсирле, күнелне кузгатучан күренешләр бик аз очрый шул.

Ф. Садриевның әле тагын "Зөбәйдәнең күңел дәфтәреннән", "Кыргый алма әчесе" һәм "Адәм әүлиясе" дигән повестьлары да бар. Аларның беренчесе бүгенге шәһәр тормышы шартларында яшь йөрәкләргә бер-берсен табу кыенлыгын төрле-төрле язмышларны, шәхесләрне күрсәтү аша тасвирласа, икенчесе яшь артистка Әнвәрәнең мәхәббәт газапларын гаять тә тирәннән ачуы, укучыга көчле тәэсир итүе белән кыйммәтле. "Бер секунд эчендә рәнҗеш-үпкәләрне кубарып, каяндыр төптән әче өзгәләнү бәреп чыга, йөрәгенне тибүдән туктата, зиһененне ала, тәненне көйдерә башлый, дөнья юкка чыга, нибары икәүдән-икәү—син һәм өзгәләнү генә кала..." Әнә шундый киеренке психологик халәтләр байтак ул әсәрләрдә.

"Адәм әүлиясе" исә безне үзенең сатира көче белән сокландыра, аны укыганда

без күпләгән комедияләр язган һәм сәхнәдә куйдырган драматург Фоат Садриев талантлы белән янадан очрашабыз.

Әле бит бу авторның көндәлек матбугатта һәм китапларында басылган байтак кына хикәяләре дә бар. Аларнын кайберләре ("Авыш басу икмәге") "Казан утлары" уздырган конкурста җинүче булды, ә кайсысы ("Гадәти иртә") матбугатта сүз кузгатты.

Мисалга "Гадәти иртә"не алыйк. Бу әсәрнең үзәгендә дә эш кешесе тора. "Эш кешесе" дигән төшенчә совет чорында безне шактый куркыта иде. Чөнки житештерү, производство процессы турында кайберәүләр редакцияләргә калын-калын кульязмалар күтәреп килделәр дә әнә шуны "Эш кешесе турында роман" дип укучыга тәкъдим итмәкче булдылар. Аларның кайберләре басылып та чыкты, әмма укучы йөрәгенә үтә алмады. Ни өчен? Чөнки аларда тере, җанлы кеше юк иде.

Ә "Гадәти иртә" хикәясенең герое Вәли Гаязович—никадәр генә эш филакаре булса да, ул барыннан да бигрәк—кеше.

Ул иртән урыныннан кузгала алмыйча да азаплана, эшкә барыр вакыт җиткәч, йоклап яткан хатынын иркәлисе дә килеп китә аның, кешеләргә карата фикердә дә кайчак ялгышкалап куя ул...

Әмма, барыннан да бигрәк ул—совхоз директоры, әнә шул зур йөкне тартып баручы. Үз урынбасары, беркайчан да бернәрсәгә дә исе китмәүчән Гайнетдиновка карата үз фикерен менә нинди ялкынлы сүзләр белән белдерә ул:

"—Мин синең илне сатарына да ышанам. Чөнки синең өчен бернинди дә изге нәрсә юк. Һәм соңгысы: бәлкем син бездән егерме ел артыграк яшәрсең. Тик шуны бел: үз чордашларың белән яшәп, алар күргәннәрне күреп, алар белән бергә елап, бергә үлмәгән кешедән дә бәхетсез кеше юк... Кызганыч кеше син!"

Әйе, талантлы каләм игътибарына эләксә тормыш-яшәешнең байтак күренеше истә калырдай тәэсирле мизгелгә әйләнеп китә. Укучылар бүген юкка гына үткән сугышка, яисә разведчикларга багышланган әсәрләрне мавыгып укымыйлар шул! Киеренке мизгелләр күп булганга шулай ул! Югарыда күренгәнчә, намуслы хезмәт процессы да еш кына әнә шундый ситуациягә—кешеләрне сыный торган киеренке мизгелгә—әверелеп китә ала икән.

Фоат Садриевның югарыда без күзәтеп узган проза әсәрләренә карата гомуми фикер рәвешендә шуны билгеләп үтәсе килә: алар, һичшиксез, татар реалистик прозасының соңгы еллардагы үсеш-үзгәреш юлында истә калырдай казаныш булып торалар. Образларның-характерларның әсәрләрдә күпьяклы һәм тулы канлы итеп, укучы күз алдына тере кеше кебек килеп басарлык дәрәҗәдә, үтә дә көчле тәэсир калдырырдай эстетик энергия белән сурәтләнүе дисеңме; конфликтларның реаль тормыш үзәгеннән "суырып" алынуы һәм бүгенге көн өчен дә, ерак перспектива өчен дә гаять мөһим һәм актуаль булуын әйтәсеңме; табигать күренешләрен тасвирлаганда әдипнең иң оста пейзажчы булган рәссамнар сыман төгәл һәм ачык буяулар-сүзләр таба алуы дисеңме; әсәр геройларының күңел-җан карурманнарына кереп киткән очракларда әдипнең иң нечкә һәм сизгер күңел кылларында уйнавы һәм шул чагында кешенең үзәгенә үтәрдәй аһәңнәр тудыруын искә аласыңмы—менә болар барысы да Фоат Садриевның әдәбиятта "реализм" дигән ышанычлы юлдан баручы прозаик буларак зур талантын, күп еллар буе дәвам иткән иҗади хезмәт нәтиҗәсендә ирешелгән осталыгын раслап торалар. Һич шикләнмичә әйтергә мөмкин: аның әсәрләре XX гасыр ахырында татар прозасының югары дәрәҗәсен күрсәтүче ышанычлы дәлил алар.

Ул әсәрләрнең кайберләрен хәтта талантлы шагыйрь тарафыннан иҗат ителгән драматик поэмалар дип әйтергә дә мөмкин булыр иде кебек. Тел-стиленең үтә дә нәфислеге, нәзакәтлелеге, нечкәлеге; хис-кичереш дөньясының мәгърур музыкаль симфонияләрдәге шикелле бөек бер гармония һәм драматизм белән агышы; вакыты-вакыты белән югары романтиканың, ә кайчак иң-иң трагик аһәңнәр өскә калкып кеше рухиятенең гаять киң диапазонда һәм тирәнлектә-биеклектә чагылу—болар барысы бергә проза әсәрләрен шигърият белән якынайта, алар арасындагы чикне җуйдыра. Хәер, әдәбиятта "нәсер" ("стихи в прозе") дигән жанр да бар бит әле!

Фоат Садриев прозасының кайбер урыннары (бигрәк тә геройларның эчке кичерешләрен биргәндә, яисә табигать күренешләрен тасвирлаганда, яки автор

үзе хисләнеп лирик чигенешләргә кереп китсә) нәкъ менә шундый—зур күләмле әсәрдән аерып алып шигъри әсәр кебек кулланырлык дәрәҗәдә сәнгатьлеләр.

Русның атаклы язучысы М. Шолохов гомер буена Дон буенда яшәп иҗат иткән шикелле безнең Фоат Садриев та әле дә булса үзенең Мөслимендә яшәп ята (сүз уңаеннан мәрхүм шагыйребез Мөдәррис Әгъләмнең бу яктан чыккан талант иясләренең күплегенә сокланып: "Уңдым мин Мөслимнәремнән!" диюе искә килеп төшә). Һәм бу авторыбыз шулай ук Шолоховтан һич калышмыйча роман арты роман, повесть арты повесть биреп бара. Яңа гасырга кергәч инде ул "Бәхетсезләр бәхете" дип исемләнгән һәм саллы-саллы өч китаптан торган трилогия бастырды.

Бу трилогиянең журнал варианты белән безнең укучылар яхшы таныш, әсәр турында аерым фикерләр дә булды. Шуңа күрә биредә әлеге трилогиягә тулаем бәя бирү, аның әһәмиятен ачыклау белән генә чикләнергә туры килә.

Кыскача гына әйткәндә, бу трилогияне безнең җәмгыятьнең бер иҗтимагый формациядән икенчесенә күчү чоры панорамасын чагылдыра дип әйтергә мөмкин. Чыннан да, трилогиянең бик тә уңышлы табылган исеме үк—"Бәхетсезләр бәхете"—шуңа ишарә ясый түгелме соң?!

Юк, трилогиянең исеме генә түгел, ә андагы геройларның исемнәре дә тирән аллегорик мәгънәгә ия. Мәсәлән, төп герой—Ирек. (Безнең Азнакайдагы бер авторыбызның әле соңгы елларда гына "Кол Ирек" псевдонимы куеп республика матбугатында кызыклы гына язмалар бастыруын да искә алып үтик). Ходай тарафыннан иҗатчы итеп яратылган бу егет партия райкомы аппаратында эшли башлагач үз-үзен тәмам югалта, механизмдагы бер шөрепкә әйләнеп кала. Ә бит ул партиянең үзенә ихластан ышанып кергән иде! Партия аппаратында эшләгәндә аның үз сөйгәне Зәнфирә белән бозылышуы да юктан гына түгел. Чөнки Зәнфирә хатын-кыз күңеле белән Ирекнең бөтән төрле затка әверелеп баруын, алар арасында зур упкын килеп чыкканын тоя, аңлый башлый.

Татар халкы өчен изге булган Сөембикә исемле героиняның язмышы да укучыны тирән уйга сала. Бердән, ул яшь Ирекнең башын әйләндереп, аны чын мәхәббәтеннән аерса, икенчедән, Ирекка кияүгә чыккач та ул райком түрәләренә наз өләшүдән туктамый. Трилогияне укыганда бу героиняның исеме һәм җисеме арасындагы кискен аерма һәрвакыт искә төшеп тора.

Ирекнең абыйсы Мэлска бәйле сюжет сызыгы да истә кала. Аның исеме (Маркс, Энгельс, Ленин, Сталиннан алынган) әтиләре Хәйретдин агайның чын большевик булуын, тормышта бөтен кешедән намуслы, гадел эшләр, гамәлләр генә таләп итүен искәртсә, совхозга һәм хатыны Нәфисәгә бәйле күренешләр исә аны шул ук вакытта эшкә чумган яңа заман эшлеклесе буларак та ача.

Райкомның беренче секретаре Арсланов, аның азгын малае Рашат образлары шулай ук чорыбызның байтак "күренекле" әһелләренең тормышын гәүдәләндерә.

Фоат Садриев үз трилогиясенең өченче китабында шундый бер кызыклы алым куллана: бүтән әсәрләрендәге геройларның уллары, оныкларын (Нуриасманыкылар, Илһам Шаһзамановныкылар һ.б.) бергә очраштыра. Аларны бергә туплау укучы күз алдында "Намус" дигән дәүләт көчләренең бергә оешуы, үзара берләшүе кебегрәк тойгы калдыра. Әйе, бу—намуслы кешеләрнең, намуслы нәселләр вәкилләренең бер сафка басуы.

Трилогиянең башында Ирек саф мәхәббәткә һәм кешеләргә, партиягә ихластан ышанган булса, ахырда да әсәр тормышка, намуслы кешеләргә, мәхәббәткә зур ышаныч белән тәмамлана.

"Бәхетсезләр бәхете" трилогиясе—әлбәттә, прозаикның чираттагы уңышы, кин колачлы эпик жанр мөмкинлекләрен үзләштерүдәге яңа бер иҗади казанышы. Трилогия дөнья күрү уңаеннан вакытлы матбугатта басылган язмаларда да әлеге фикер хаклы рәвештә билгеләп үтелде.

Ләкин, шул ук вакытта, авторның яңа әсәре уңаеннан күңелгә килгән бер уйны да әйтми үтү мөмкин түгел. Әлеге трилогиядә соңгы еллар тормышының үзенә күрә бер чиренә әйләнеп киткән телесериаллар шаукымы үзен шактый ук сиздереп ала кебек. Ягъни бу—тормыш күренешләрен аларның табигый дәвамчанлыгында һәм бераз чама хисен оныта төшеп, озак һәм күп итеп күрсәтү дигән сүз. Болай эшләгәндә инде сәнгатьчәнлек һәм образлылык шактый кими, тормыш күбрәк

үзенең натураль хәлендә ага, геройларның хис-кичереш киеренкелеге дә йомшара. Кыскасы: нәкъ телесериаллардагы кебек—кара да кара, укы да укы.

Әнә шул ягы белән "Бәхетсезләр бәхете" авторның югары сыйфат дәрәҗәсендәге "Таң җиле", "Шаһзаманов эше" кебек әсәрләреннән бераз аерылып тора.

Ә Фоат Садриевның проза әсәрләре турында тулаем фикер йөртүгә күчсәк һәм аның роман-повестьларындагы геройларны барысын бергә күздән кичерсәк шуны күрербез. Алар—яшәештә гаделлек тантана итсен өчен көрәшүче, ихлас күңелле, намуслы кешеләр. Соңгы елларда тормышыбызның "капитализм" дигән дөньяга барып керүе андый геройларның, әйләнә-тирәбездәге андый кешеләрнең бөек миссиясен үзгәртә аламы соң? Һәм иң мөһиме: безнең аларга мөнәсәбәтебез үзгәрә аламы?

Юк, алмый!

Чөнки "капитализм" инде ул кешелек җәмгыяте өчен бик тә таныш күренеш. Әдәбият һәм сәнгать өчен дә үтә таныш дөнья ул. Классик әдәбияттан О. Бальзак, В. Гюго, Д. Лондон, А. Чехов, М. Горький, үзебездән Г. Ибраһимов, Ш. Камал һ.б. язучыларның геройларын гына алып карагыз. Алар бит—шул ук акчага гына табыну җәмгыятендә яшәгән геройлар. Алар да үзләренең саф күңелле, ихлас, намуслы булуы белән көчлеләр һәм алар әйләнә-тирәдә гадел мөнәсәбәтләр булсын өчен көрәшәләр. Әнә шундый бөек миссия башкарулары белән алар кешелек дөньясының прогрессив көчләре ихтирамын казанды, соклану белән үзләренә баш идерделәр!

Безнең танылган әдибебез Фоат Садриев геройлары да дөнья әдәбиятындагы әнә шундый саф күңелле, көчле рухлы унай геройлар плеядасын дәвам иттерә. Алар җирдә матди мәнфәгатьләр белән генә, акчага табынып кына яшәп алашкан җаннарга якты бер маяк кебек булып балкыйлар. Җирдә байлык туплау өчен, яки хакимлеккә ирешү өчен төрле ялганнарга барган һәм ахыр чиктә, барыбер, шуның пычрак эш икәнен тоеп, шул пычраклык, шул әшәкелек кортын үз психологиясендә, үз эчендә сиз башлаган җаннар янәшәсендә алар, барыбер, әллә ничә башка югарырак күренәләр. Әнә шунлыктан алар—намуслы кешеләр—кешелек җәмгыяте өчен гаять тә кадерле. Алар—үзләренчә бер рухи юлбашчылар кебек, алар—рухи үсеш юлының маяклары.

Һәм мондый геройлар, тормышыбыздагы әнә шундый кешеләр турындагы уйлануларыбызны йомгаклый төшеп тагын шуны да әйтәсе килә.

Әйе, алар—әлеге геройлар, әлеге кешеләр—хәзергә "капиталистик мөнәсәбәтләр" һәм әнә шул иманга, шул кыйблага баш июче кешеләр чолганышында яшиләр. Ләкин шунысы да бар бит әле: ә соң җирдә бары тик акчага табынган җәмгыять кенә озын гомерле дип, ул гына җирдә мәңгелек дип кем кистереп әйтә ала?! Үзара ызгыш-талашны, сугышны һәм басып алуларны гадәти хәл дип санаган, әнә шул бәла-казалар килеп чыгуга үзе үк сәбәпче дә булган әлеге җәмгыять, андый мөнәсәбәтләр мәңгелек була аламы? Акыл дәрәҗәсе үсә барган саен кешелек җәмгыяте бу хәл белән килешә алачакмы?

Кешеләрдәге рухи омтылышларның матди мәнфәгатьләргә караганда өстенрәк булуын, рухилыкның беренчел булуын соңгы елларда без инде аңлый, тоя башладык бугай. Шулай икән, димәк киләчәк тормыш та рухи яктан көчле кешеләр, рухи яктан матур кешеләр ягында булачак дигән сүз!

Намуслы кешеләр бүген әнә шуңа бик тә ышаналар.

**Редакциядән:**

***1981 елдан бирле «Казан утлары»нда эшләүче Мансур Вәли-Баржылыга 60 яшь тулды. Ул әдәби тәнкыйть мәйданына әле студент чакта ук, шау-шу тудырып килеп керде. 1976-81 елларда «Идел» альманахында эшләгәндә ул татар яшьләр журналы ачу өчен көрәшүчеләрнең берсе. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлегенең Җ. Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты М. Вәли-Баржылы бүген — проза һәм әдәби тәнкыйть әсәрләреннән тупланган 12 китап авторы.***

***Хезмәттәшебезне юбилее белән котлыйбыз, аңа яңадан-яңа тормыш һәм иҗат казанышлары телибез.***

Айдар
Юзиев

# МИЛЛИ ИДЕОЛОГИЯГӘ НИГЕЗ САЛУЧЫ

XIX гасырның икенче яртысында татар җәмәгатьчелегенең рухи үсешенә зур йогынты ясаган шәхесләребезнең берсе, әлбәттә, күренекле дин белгече, фәлсәфәче, тарихчы, дини реформатор һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани булды. Шул чор татар дини-фәлсәфи фикере өлкәсендә ул—иң алдынгысы. XIX гасыр башында мондый дәрәҗәгә аның рухи остазы Габденнасыйр Курсави ия иде. XIX гасыр татар җәмәгатьчелеге өчен Ш. Мәрҗани—заман таләпләренә йөз тоткан талант иясе, Яңа тарихка нигез салучы.

Без европачыл протестантизм мисалында иҗтимагый үзгәрешләр аң, рухи кыйммәтләр өлкәсеннән башлана дигән концепцияне алга сөргән М. Вебер карашын хуплыйбыз һәм әлеге концепциянең тулысы белән Мәрҗани эшчәнлегенә дә каравын билгелибез. Мәрҗани, Яңа чор идеологы буларак, татар милләте аңында чынбарлыкны яңача аңлауга юл ача, Исламны да яңача шәрехләү кирәклегенә басым ясый, ә диннең хезмәткә мәхәббәт, намуслылык кебек гүзәл сыйфатларны тәрбияләүгә караган нигезләмәләре татар җәмгыятен алга җибәрүгә булышачагын ассызыклый. Гомумән алганда, XIX гасыр азагы—XX гасыр башы татар тормышында Мәрҗанинең дөньяви һәм дини башлангычны тыгыз бәрләштергән өндәмәләре яңарыш программасы ролен үти.

Мәрҗанинең тормыш юлын һәм эшчәнлеген шартлы рәвештә ике этапка бүлеп карап булыр иде: дини-реформаторлык этабы (XIX гасырның 70 нче елларына кадәр) һәм мәгърифәтчелек этабы (XIX йщзнец 70-80нче елларда).

Шиһабетдин Баһаветдин бине Сөбхән бине Габделкәрим әл-Мәрҗани 1818 елда Татарстанның хәзерге Әтнә районындагы Ябынчы авылында туа. Аның әти-әнисе ягыннан бабалары танылган имам-мөдәррисләр нәселенә карый. Башлангыч белемне әтисе укыткан Ташкичү мәдрәсәсендә ала, үзлегеннән өйдәге китапханәдә дә белемен арттыра. Унҗиде яшендә исә шушы мәдрәсәдә укыта башлый һәм, фарсы теле дәреслегеннән канәгатьсезлек белдереп, үз дәреслеген яза.

Белемгә сусаган Мәрҗанине авыл мәдрәсәсе генә канәгатьләндерми. Ул чагында татар җәмгыятендә яшәп килгән гадәт буенча, Мәрҗани 1838 елда белемен дәвам иттерү өчен Бохарага китә. Тик Бохара элеккеге данлы Бохара булмый инде. Һәм схоластик дин галимнәре тарафыннан ятлауга корылган укыту алымнары яшь егетнең күңелен кайтара. Ул мөдәррисләр алдына мәдрәсәдә реформалар үткәрү мәсьәләсен куя һәм, шушы максаттан чыгып, «Игълам-әбна-әд-дәһр би-әхвәли әһли Мәвараэннәһр» (Мавераннахр кешеләренең хәлләре турында замандашларга җиткерү.—Кульязма сакланмаган.) исеме белән зур булмаган трактат яза, ләкин яклау тапмый. Мәдрәсәдәге белем бирү системасыннан риза булмыйча, ул, нигездә, белемен мөстәкыйль рәвештә күтәрә, кыйммәтле кульязмалар сакланган китапханәләрдә шөгыльләнә башлый. Бай балаларын укытып, көн итү өчен акча таба.

Бохарада уку канәгатьләндермәсә дә, Мәрҗани өчен бу эзсез югалмый: ул биредә шул чорның алдынгы карашлы галимнәре белән таныша, мөселман белем бирү системасын үзгәртү зарурилыгы турындагы фикерен тагын да ныгыта.

1843 елда Мәрҗани Урта Азиянең борынгы мәдәни үзәге булган Сәмәрканд шәһәренә китә. Биредә ул «Ширдар» мәдрәсәсендә укый, танылган тарихчы, казый Әбү Сәед ас-Сәмәркандый (1848/49 елларда үлә) белән очраша. Әлеге галим Мәрҗанигә тарих фәне белән шөгыльләнергә киңәш итә. Сәмәркандта билгеле бер дәрәҗәдә

белем өстәгәч, Мәрҗани, ватандашы һәм рухи остазы Габденнасыйр әл-Курсави фикерләре белән якыннан танышу теләгеннән, аның «Мәҗмуга» хезмәтен кулына ала. Беренче мәртәбә ул Курсави кулъязмасын 20 яшендә укый һәм әлеге әсәр Мәрҗанинең реформаторлык һәм фәлсәфи карашлары формалашуына нык тәэсир итә (аерып әйткәндә, «иҗтиһад ишекләрен ачу» концепциясенә һәм мөтәкаллимнәр идеяләрен тәнкыйтьләвенә).

Мәрҗани үзенең беренче басма хезмәтен «Гыйрфат әл-хавакин ли-гыйрфат ал-хавакин» *(«Хаканнарның танып-белүләре турында уч төбе кадәр мәгълүмат».)—Казан, 1864).* Урта Азия төркиләре тарихына багышлый. Бу вакытта Мәрҗани, иске карашлы руханилардан аермалы буларак, мәдрәсәләрдә укыту системасына яналыклар кертергә омтыла.

Унбер елдан соң Мәрҗани, яна белем, яна фикерләр үзләштереп, туган ягына кайта. 1850 елның 30 мартында аны Казанның җамигъ мәчетенә имам-мөдәррис итеп билгеләү турындагы указга кул куела. Әмма бу хәл Казан бае Ибраһим Юнысов җитәкчелегендәге бер төркем көнче муллаларга ошамый. Алар аның өстеннән Мөселман Диния нәзарәтенә шикаятьләр яза башлыйлар, аның исеменә пычрак ягарга омтылалар. Шушы әләкләр аркасында Ш. Мәрҗани берникадәр вакытка вазифаларыннан азат ителә—1854 елда тугыз айга, 1874 елда ярты елга эшеннән китеп тора.

Татар сәүдәгәре Ибраһим Юнысов белән Шиһабетдин Мәрҗани арасындагы киеренке мөнәсәбәт турында да әйтеп узарга кирәк. Мәчет һәм аның каршындагы мәдрәсәнең матди хәле күп яктан Казан шәһәре Думасында мөселманнар башлыгы Ибраһим Юнысовка бәйле булуын да истән чыгарырга ярамый. Аз гына каршы әйтүне дә кабул итәргә күнекмәгән И. Юнысовка Мәрҗанинең бәйсез, горур табигате баштан ук ошамый. Хәлбуки, Ш. Мәрҗани Юнысов мәчете имам-мөдәррисе итеп нәкъ менә аның хуплавы буенча билгеләнгән. Югарыда телгә алынган ике «отставка»дан соң да Мәрҗанинең холкын үзгәртә алмаган Юнысов җимерелә башлаган мәдрәсәне сипләү өчен акча бирми. Үз чиратында, Мәрҗани дә Юнысовка бил бөгәргә теләми, яна бина төзелешенә мәчеткә йөрүчеләрдән акча җыя [хәзерге Мәрҗани мәчете]. Ул үзе төзеткән шул мәчеттә гомеренең ахырына кадәр укыта.

1867-68 елларда Идел буе һәм Урал мөселманнарының Диния нәзарәте Мәрҗанине Казанның ахуны һәм мөхтәсибе (төбәктәге абруйлы вазифаларның берсе) итеп билгели. Мәрҗани рәсми хакимият белән дә тыгыз элемтәләр урнаштыра. Ул Казан губернасы хакимиятенең кайбер йомышларын үти: Казан типографиясендә Коръән басылуына күзәтчелек итә (соңрак ул Рәсәйдә Коръән басылуга багышланган «Китаб әл-фаваид әл-мөһиммә», «Файдалы һәм мөһим [эшләр] китабы» дигән хезмәт бастырып чыгара.—Казан, 1879), җир тетрәүдән зыян күргән Каф тавы арты халыкларына ярдәм итү өчен акча җыюны оештыра. Дәүләт учреждениеләре өчен мөселманнарның тууы, никахы һәм вафаты турындагы мәгълүматларны яза, мөселманнар ант иткәндә мәхкәмә утырышларында катнаша, мөселманнарны җәнлек-хайваннарга карата мәрхәмәтле булуга чакырып, «Китаб ан-насаих» (Нәсихәт китабы.—Казан, 1869.) өндәмәсен яза.

Тора-бара Мәрҗанинең даны читләргә дә тарала. 1870 елда ватанында һәм мөселман Көнчыгышында ана шөһрәт китергән, дини реформаторлык идеяләре белән сугарылган «Назурат ал-хакк...» хезмәте дөнья күрә. Ш.Мәрҗани, үзенең рухи остазлары Утыз Имәни, Г.Курсави традицияләрен яна тарихи шартларда дәвам итеп һәм тирәнәйтеп, дини реформаторлыкның күренекле идеологына әйләнә. Мәрҗанинең үзгәрә барган чынбарлыкка диннең үзенчәлекле рәвештә яраша баруын чагылдыручы дини реформаторлык карашлары үз эченә, «иҗтиһадның ишекләрен ачу» теоретик концепциясе белән бергә, исламны «сафландыру» максатыннан Мөхәммәд пәйгамбәр яшәгән чорга мөрәҗәгать итүне (Коръәнгә, сөннәткә, мөштәһидләр сүзләренә) һәм мәдрәсәләрдә укыту реформасын да ала. Мәрҗани, мөселман ортодоксаль традиционалистларыннан аермалы буларак, Мөхәммәд пәйгамбәр вакытларына кире кайтуга өндәүне «динне янарту» төсендә күзаллый, бу юнәлештә нәкъ менә «тәҗдид» атамасын куллана да.

«Мөкатдимә»сендә Мәрҗани мөселманнарда рухи тормыш янарышы Гомәр бине Габделгазиз (VII гасыр) идарә иткән чордан башлана, гасырлар буе дәвам итә һәм диннең төп нигезләренә, телгә, фәлсәфәгә, фикъһына, хәдисләргә, тәфсиргә кагыла, дигән карашын уздыра. Динне янарту тезисын раслау йөзеннән, ул түбәндәге хәдисне китерә: «Пәйгамбәр сүзләреннән күренгәнчә (Аллаһ аны ярлыкасын һәм сәламләсен),

Аллах һәр гасыр башында мөселман җәмәгатенә дингә янарыш кертүче җибәрә». Һәр дәвернең иң күренекле галимнәрен аерып алып, Мәрҗани «иҗтиһад ишекләрен ачу» концепциясенең (VII йөздән алып XIX йөзгә кадәр) буыннан-буынга күчеп, тапшырылып килүен раслый. Сөнни исламында XII гасырдан соң «иҗтиһад ишекләре» ябылмаган дигән нәтиҗәгә килә ул. «Назурат ал-хак фи фардият әл-аша ва ан лям ягиб-аш-шәфак» (Энгер-менгер төшкәнче кичке намазның зарурлыгына күзәтү.—Казан, 1870, гарәп телендә) хезмәтендә Мәрҗанинең дини реформаторлык карашлары ачык чагыла. Биредә ул, Казан төбәгендә кичке намазның үтәлешен катгый таләп итүнең дөрес түгеллеген аңлатудан бигрәк, үзенең дини өйрәтмәләрне ничек күзаллавы турында яза (фикъһ, хокукый мәктәп, хәдисләр, кәлям, иҗтиһад нигезләре). Бу китап нәшер ителгәч, дин галимнәре һәм зыялылар арасында каршылыклы кискен бәхәсләр чыккан һәм фанатик муллалар тарафыннан Мәрҗанигә һөҗүм итүләр башланган.

Мәрҗани «Назурат ал-хакк...» хезмәтендә Курсави тарафыннан алга сөрелгән идеяләрне тәгаенли, тирәнәйтә, үзенең дини мәсьәләләргә карата булган шәхси уй-фикерләрен, төрле мисаллар китереп, нигезли. Китабының теге яки бу бүлеген язганда, галим Коръәннән өзекләргә, пәйгамбәр сүзләренә таяна һәм, күп очракта, үзенең шәхси мөнәсәбәтен белдерми. Аның уенча, укучы, әлеге мәгълүмат белән танышкач, нәтиҗәне үзе ясарга тиеш. Мондый «киная» ысулы аша Мәрҗани, моңа кадәр гомум кабул ителгән ортодоксаль аңлатулардан үзгә буларак, дини өйрәтмәләрне үзенчә тәфсирле, аңлатып бирергә омтыла. Руханилар тарафыннан Ислам дине хаким сыйныфны яклаган һәм татар җәмәгатьчелегендә өстенлек иткән бер чорда шушындый алым белән китап язу мөселман традицияләреннән, дини кануннардан читләшү, алласызлык дип бәяләнә, кабул ителә.

Барлык мөҗтәһидләр арасыннан Мәрҗани хәнәфи мәзһәбенә нигез салучы Әбү Хәнифәне (767 елда үлә) һәм аның эшен дәвам итүчеләрне аерып, сайлап ала. Әгәр аларның әйткәннәре белән ул үзендә фикри уртаклык тапса, аларга таяна; әгәр инде мондый охшашлык юк икән, ул теге яки бу мәсьәләгә карата үз карашын тәкъдим итә. Мәрҗани иң кыйммәтле чыганаклар буларак Коръән, сөннәт, иҗма, кыяс һәм мөҗтәһидләрнең сүзләре, кылган гамәлләренә һәр даим мөрәҗәгать итә, мөселманнарны шуңа чакыра. Аларда фикер уртаклыгы тапмаган очракта, белем дәрәҗәннән чыгып, үзенә нәтиҗә чыгарырга кирәклеген күрсәтә.

Мәрҗани билгеләвенчә, кешедә теге яки бу мәсьәләгә карата үз карашы һәрчак булмаска да мөмкин; әгәр бу шулай икән, ул әлеге очракта тәкълидкә мөрәҗәгать итәргә тиеш була. Ләкин шулай да, Мәрҗани, кайбер галимнәр раславынча, традиционалист түгел. Билгеле ки: традиционализмның тоткасын тәкълид, ягъни Коръәнгә, сөннәткә, дини абруйга тулысынча иярү тәшкил итә. Мәрҗани исә, тәкълидкә иҗтиһадны каршы куя, фәлсәфә фәнен югары бәяли һәм моңа каршы чыгучы тәкълид тарафдарлары Ибн Ханбал (855 елда үлә), аш-Шафии (820 елда үлә), Ибн Таймияләрнең (1328 елда үлә) карашларын кире кага.

Мәрҗани мөселман хокукын XIX гасырның икенче яртысы татар җәмгыяте ихтыяҗларына һәм таләпләренә яраклаштыра. Ул әлеге хокукның инде бүгенге чынбарлыкка туры килми торган кайбер өлешләрен яңача аңларга, мөселманнар тормышының гражданлык-административ һәм хокукый өлкәләрен XIX йөзнең икенче яртысында барлыкка килгән социокультура халәтенә яраклышлы итәргә кирәк дип саный. Ортодоксаль галимнәр (фәкыйһләр, имамнар, хәдис белгечләре), Мәрҗанидән үзгә буларак, социаль-сәяси теорияләр булдыруны кирәксез дип табалар. Алар фикеренчә, барлык иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрнең чишелеше шәригатьтә әйтелгән һәм аларны яңача күзалларга мохтаҗлык юк.

Мәрҗани үзенең социаль-сәяси карашларын традицион мөселман формасы аша белдерә. Хокук белгече буларак, ул пәйгамбәр чорындагы идеаль Ислам дәүләте һәм аның гадел дүрт хәлифе нигезләмәләренә таяна; шулай да сөнничелек хокукының аерым өлешләрен XIX йөз Казан төбәгенең чынбарлыгына яраклаштырырга омтыла. Ул үзенчәлекле мөселман тормышы тәртипләрен, милли мәдәниятне сакларга чакыра. «Бу максатка ирешер өчен мөселманнарга үз араларыннан аларга акыл бирә һәм хаким була алырлык, халыкны берләштерү көченә ия имам сайлап кую тиеш»,—ди Мәрҗани. Фикерен дәвам итеп ул, дәүләтнең иҗтимагый тормышында мөселманнар катнашсын һәм аларның ихтыяҗлары канәгатьләндерелсен өчен дәүләт аппаратына үз араларыннан булдыклы кеше кую кирәген дә әйтә.

Галим, китап бастыруда көчле цензураның булуын истә тотып, «мөселманнар»

исеме астында татар халкын күз унында тотуын ачыктан-ачык яза алмый. Мәрҗани әлеге фикерен барлык мөселманнарга таратса да, беренче чиратта татар халкын күз алдында тота. Киная юлы белән ул үзенең социаль-сәяси карашларын белдерә һәм, шул рәвешчә, татар тормышын заман чынбарлыгына яраклаштырырга омтыла.

Икенче этапта (XIX гасырның 70-80 еллары) Мәрҗанинең дөньяга карашында мәгърифәтчелек төсмерләре дини реформаторлыктан өстенлек итә башлый. Дөрес, ул дин эшләрен, мөселман теологиясенә караган тикшеренүләрен ташламый, аерым хезмәтләрендә иҗтиһад мәсьәләләренә, ислам өйрәтмәләренә карата булган күзәтүләрен дәвам итә *(Хак әл-мәгърифә вә хөсн ел-идрак.—Казан, 1880; Китабел-хикмәтел-бәлига әл-җәнния фи шәрхел-гакаид әл-хәнәфия.—Казан, 1888).* Әмма аның иҗатында галимнең мәгърифәтчелек идеологиясенә авыша баруы үзен шактый сиздерә башлый. 70-80 елларда ул татар мәгърифәтчелек хәрәкәтенә кушылып китә.

Бу чорда Мәрҗани рус мәдәнияте, Казан университетының көнчыгышны өйрәнүче галимнәре белән таныша. Ул профессор И. Ф. Готвальдны, академик В. В. Радловны, профессор А. Казембекны, хатын-кызлар арасыннан беренчеләрдән булып көнчыгышны өйрәнүче галимә О. С. Лебедеваны һәм күп кенә бүтән рус галимнәрен якыннан белә, шәкерте Х. Фәезханов аркылы Петербургның Көнчыгышны өйрәнүче танылган галимнәре В. Вельяминов-Зернов һәм шәех ат-Тантави белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыра. Әмма Мәрҗанинең барлык галимнәр белән дә мөнәсәбәтләре бертөрле булмый. Мәсәлән, Мәрҗани, И. Ф. Готвальд белән дустанә мөнәсәбәттә булса да, соңгысы аның китапларын бастыруда каршылык күрсәтә.

Күпләрне Мәрҗанинең көнчыгыш телләрен югары дәрәҗәдә белүе һәм көнчыгыш мәдәнияте турында яхшы хәбәрдар булуы сокландыра. Шуңа да, профессор И. Готвальд Казанга килгән чит ил галимнәрен татар укымышлысы булганы өчен Мәрҗани белән таныштыра. 1873 елда Казанга Кашгария илчесе килә һәм Татар бистәсендә Мәрҗанидә туктый. 1876 елда Мәрҗани үз йортында дөньякүләм танылган галим, «Хайваннар тормышы» дигән хезмәт авторы А.Бремны кабул итә.

1887 елда Казанда Санкт-Петербург Археология җәмгыятенең IV Бөтенроссия съезды уза. Аның эшендә илнең күп кенә шәһәрләреннән һәм өлкәләреннән 300 ләп галим катнаша. Съездда 13 август көнне академик В. В. Радлов рус телендә Мәрҗанинең 1884 елда съезд материалларында рус һәм татар телләрендә Болгар һәм Казан тарихына багышлап басылып чыккан «Гыйлаләт аз-заман фи тарих Болгар вә Казан» *(Болгар һәм Казан тарихы буенча вакыт пәрдәсе—Казан, 1884)* докладын укый. Мәрҗани мөселман галимнәреннән беренче буларак әлеге съездның хәзерлек эшләрендә һәм үткәрелүендә катнаша. Ак чалмалы, яшел чапан кигән бу зыялы шәхес Археологик җәмгыять әгъзаларының игътибарын еш җәлеп итә.

Мәрҗанинең мәгърифәтчелек өлкәсендәге эшчәнлегенең тагын бер ягы булып аның укытучылык хезмәте тора. 1876 елның 13 сентябрендә Казанда башлангыч сыйныф татар мөгаллимнәре әзерли торган дүртъеллык Казан татар укытучылар мәктәбе ачыла. Мәрҗани, татар мөселман руханилары арасыннан беренче буларак, анда дини тәгълимат укытуга алына һәм бирелә 10 ел дәвамында эшли, укытучылар советына керә. Ләкин инспектор һәм кайбер укытучылар белән үзара каршылыкка керүе нәтиҗәсендә (мәктәпкә татар мәдәнияте белән бәйле булмаган рус-татар училищеларыннан укучылар ала башлыйлар), ул мәктәптән китәргә мәҗбүр була. Галим үз мәдрәсәсендә үзе төзегән программа буенча укыта һәм аның педагогик концепциясе нигезләренең берсе булып укучыларны мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтү тора. Мәрҗани Россиядә җәдитчелек хәрәкәтенең алхәбәрчесе була, нәкъ менә ул аның нигезләрен сала: мәдрәсәләрдә уку-укыту реформасы, татар халкын дөньякүләм алдынгы мәдәни һәм фәнни ачышлар белән якыннан таныштыру, шуларны үзләштерергә ярдәм итү.

80 елларда Мәрҗанинең фәнни эшчәнлеге киң колач ала. Беренче планга фәлсәфи һәм тарихи фәннәр белән шөгыльләнү чыга, ә дини реформаторлык мәсьәләләре арткы планга күчә. Мәрҗанинең бу чакта язган хезмәтләрендә көнчыгыш традицияләренең Яңа чор европача белем белән синтезда бирелүе күзәтелә һәм бу зур әһәмияткә ия була. Мәрҗани фикеренчә, татар җәмгыятенең киләчәк үсешен тәэмин итү өчен мөселман кыйммәтләренә мөрәҗәгать итү генә җитми, татар милли үзаңын һәм иң мөһим милли мәсьәләләрне формалаштыру Яңа чор рухында барырга тиеш. Ул татар халкының тарихи үткәненә, мәдәниятенә һәм әдәбиятына мөрәҗәгать итеп, тарихи чагыштырулар аша татар милләтенең дөньяда алга киткән халыклар арасында тоткан урынын күрсәтергә омтыла.

XIX йөзнең икенче яртысы татар рухи мәдәнияте үсешендә яна бер чор иде. Бу— татар халкының милли үзаны уянган, эшкуарлары үзләрен татар милләтенең аерылгысыз бер өлеше дип санаган дәвер. Әлеге вакытта татар руханиларының күпчелеге, татарны аерым мөстәкыйль милләт итеп карамыйча, бердәм мөселман милләтенә кертә. Икенче төркем исә (нигездә татар меценантлары) Казан татарларын «чыңгызлар» белән тиңдәшлектә карый, татарны шул юл белән югары күтәрергә омтыла.

XIX гасырның икенче яртысы рус матбугатында да татар халкының этногенезы мәсьәләсенә карата бердәм фикергә килү күренми. Рус елъязмаларында, аерым әйткәндә «Никон елъязмасында, Идел буе татарларын Алтын Урда татарлары варислары төсендә карау белән бергә, Казан татарларын болгарлар белән бәйләү дә чагылыш таба. Мәсәлән, танылган рус мәгърифәтчесе Н. Г. Чернышевский татарларның килеп чыгышын болгар теориясенә кайтарып калдыра.

Шул рәвешчә, вакыт үзе татар мәгърифәтче галимнәреннән әлеге мәсьәлә буенча үз карашларын белдерүне таләп итә. Татар халкының тарихи үткәнен өйрәнү хәрәкәте башында торган Мәрҗани, әлбәттә, үз халкының этногенезын өйрәнүгә татар галимнәреннән беренче булып алына. Төрле мәдәниятләр, Көнчыгыш халыклары турында киң мәгълүматлы Мәрҗани бу мәсьәләне төрле яклап тикшерә һәм «Мөстафад Әл-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» исемле Болгар дәүләте, Казан ханлыгы тарихына багышланган хезмәтен яза *(1885)*. Биредә ул Идел Болгары һәм Казан ханлыгы арасындагы дәвамчылык идеясен алга сөрә һәм, язма чыганакларга, археологик һәм этнографик мәгълүматларга таянып, татарларның Идел болгарларыннан килеп чыгуын фәнни дәлилли.

Мәрҗанинең әлеге хезмәте татар иҗтимагый фикере өлкәсендә беренче тарихи тикшеренү була. Биредә галим «татар» атамасының монголларның бер өлешенә каравын, ә XVI гасырда бу исемнең Казан татарларына (болгарларга) тагылуын күрсәтә һәм, шулай итеп, тарихи дөреслеккә юл ача. Ләкин ул «татар» атамасыннан баш тартырга чакырмый, ә киресенчә, татарларның, барыннан да элек, татарлар булуын ассызыклый. « ... рус халкының аларны кимсетү, хурлау рәвешендә татар дип әйтүләреннән кайберләре татар булуны бер кимчелек санап, ул исемнән чирканып, без татар түгел, без «мөселман» дип, тавыш-җәнҗал чыгаручылар да бар. Нинди кызганыч хәл, бу исемнәр (татар белән мөселман) арасында Нил белән Евфрат елгалары арасында ераклык кадәр зур аерма бар бит! И мескен! Татар булмасаң, гарәп, таҗик, нугай түгел, кытай, рус, француз һәм немец та түгел, инде кем булырсың?—дип яза ул.

Казан ханлыгы мәдәниятенең Идел Болгары мәдәниятеннән барлыкка килгәнлеген исбатлап, Мәрҗани татарларны үз мәдәни мирасын өйрәнергә чакыра, шул юл белән ул татар халкының үзаңын уятырга, аны дөньякүләм мәдәни уңышлар һәм кыйммәтләр белән таныштырырга омтыла.

Татар милли концепциясен эшләп, Мәрҗани татар милли идеологиясенә нигез сала. Ул татарларны Идел-Урал төбәгенең төп җирле халкы дип саный; биредә, кыпчак, фин-угыр һәм чыңгыз компонентлары белән бер рәттән, мәдәни, этник һәм лингвистик үзенчәлекләргә ия булган болгар компоненты да чагылыш таба, башкалардан өстенлек итә, дип күрсәтә.

Мәрҗанине татар милли концепциясен эшләүгә татар халкы бердәмлеген какшатуга юнәлдерелгән россиячел сәясәт тә этәргеч бирә (мәсәлән, миссионер Ильминскийның чуашларның болгарлардан килеп чыгышлары теориясе). Шулай ук аңа бу эшендә милләтнең берләшүенә комачаулый торган «типтәр», «мишәр», «керәшен» кебек этнонимнарның һәм җирле атамаларның татарлар арасында киң таралуы да тәэсир итә. Халкында, зур хөрмәт казанган Мәрҗани татарны аерым милләт дип саный башларга, аны язмышын татар тарихы, татар мәдәнияте белән бәйләп карарга инандыра.

Бу чорда ул шулай ук мөселман Көнчыгышының 6057 галиме, язучысы, философы һәм сәясәтчеләрнең биографиясен кертеп, «Вафийәт әл-әсләф вә тәхият әл-әхләф» (Бабаларыбыз һәм аларның киләчәк буыннарга сәламнәре турында җентекләмә) дигән био-библиографик сүзлек өстендә дә эшли. Ибн Халдунның «Мөкатдимә» хезмәтенә ияреп, «Вафийәт ...» әсәренә «Мөкатдимә» дигән кереш яза һәм аны 1883 елда бастырып чыгара. Көнчыгыш рухи мәдәниятенең төрле мәсьәләләрен һәм якларын ачып бирүгә багышланган бу хезмәт һәм тарихи, һәм фәлсәфи үзенчәлекләргә ия.

Мәрҗани билгеләвенчә, мәгърифәтчелекнең төп сыйфаты—тарихи-мәдәни процессның шәхес аңы үсешендә чагылуында. Әлеге фикер «Мөкатдимә»дә дә, энциклопедиядә дә үткәрелә, бу җөмләдән, Көнбатышның тарихи-мәдәни традицияләре Көнчыгыш традицияләренә «буйсындырылып», үзенчәлекле бербөтенлек һәм берлек хасил итүче күренеш буларак чагылдырыла.

Мәрҗанинең мәгърифәтчелек карашларын аның 80 нче елларда Россия, Якын һәм Урта Көнчыгыш илләренә кылган сәяхәтләре тагын да кинәйтә. Тарихи тикшеренүләре өчен мәгълүматлар туплау максатыннан, ул Болгарның борынгы харәбәләренә бара, татар, рус, чуаш, мордва авылларын йөреп чыга. 1880 елның 31 августында Мәрҗани хаҗ кылырга китә.

Галимнең сәфәре Түбән Новгород, Мәскәү, Курск, Киев, Одесса шәһәрләре аша үтә. Одессадан ул, корабка утырып, Якын һәм Урта Көнчыгыш илләренә юл ала: Истамбул, Измир, Искәндәрия, Каһирә һәм мөселман мәдәниятенең башка үзәкләрендә була. Сәяхәте вакытында шул заманның күренекле галимнәре һәм дәүләт эшлеклеләре белән очраша, китапханәләрдә күп эшли. Сәфәренең һәр мизгеле турында җентекләп язып, көндәлек алып бара. Бу вакытта аның китаплары Көнчыгышның күп кенә галимнәренә билгеле була инде.

Мәрҗанинең даны Көнчыгыштан тыш, Европа, Америкада да тарала башлый. «Мәрҗани ике мәртәбә фотосурәткә төшә (бер тапкыр Америка консулы өчен, икенчесендә—Лондонда чыга торган энциклопедик сүзлек нәшире үтенече белән)».

Мәрҗанинең хөр фикерләве мөселман тәгълиматын кире кагуга кадәр барып җитми, әлбәттә. Ләкин шуңа да карамастан, консерватив руханилар галимнең эш-гамәлләре дин нигезләрен какшатуга китерә дип саныйлар. 32 мулланың мөфти М. Солтановка Мәрҗани өстеннән рапорт юллаулары—моның ачык бер дәлиле.

XX гасырның 70-80 нче елларында Мәрҗани тараткан мәгърифәтчелек идеяләре татар иҗтимагый тормышын яңарту өлкәсенең төрле якларын иңли. Бу үз эченә яшь буынга дөньяви белем бирү, үткәннән калган алдынгы (антик, гарәп-мөселман фикере) мирасны һәм бүгенге (рус һәм көнбатыш европа) мәдәниятләрен үзләштерү зарурлыгын ала. Галимне татар халкының милли үзаңын тәрбияләү мәсьәләләре дә, милләтнең көнкүреш, социаль-икътисади һәм сәяси хәлләре дә нык борчый. Татар тормышындагы һаман да урын алып килгән урта гасырчылык күренешләрен Мәрҗанинең җене сөйми. Анны хакыйкатькә ирешүнең төп чарасы һәм мәгърифәтчелекне милләтне прогресска илтүдә иң көчле корал дип санап, ул үз халкын «йокыдан» уятырга тырыша. Схоластиканы, уку-укыту һәм тәрбиянең, тормыш итүнең урта гасырчылык ысулларын тәнкыйть уты астына алу Мәрҗани иҗатының һәр ягына да кагыйл.

Кеше турында тәгълимат теләсә-нинди мәгърифәтчелекнең үзәген тәшкил итә. Әгәр бу күзлектән тормышының соңгы дәверендә Мәрҗанинең дөньяга карашын ачыкларга тырышсак, татар фикер иясенең җитлеккән мәгърифәтчелек антропоцентризмы юлында гаять зур юл үткәнен күрербез. Традицион Исламның катгый теоцентризм һәм провиденциализмына ул мәгърифәтчелек концепциясен каршы куя. Аның фикеренчә, барлык халыклар да фәннәрне, сәнгатьне өйрәнүдә бер үк сәләткә ия һәм бу сыйфат аларга табигать тарафыннан бирелгән; «фәнгә һәм сәнгатькә тартылу—кеше табигатенә цивилизация барлыкка килгән вакыттан бирле хас нәрсә»,—ди ул.

Мәрҗанинең дөньяга карашындагы көчле антропоцентрик төсмер аның гуманизмын да билгели. Йөрәгенә якын алып, үзенең хезмәтләрендә халыкның аяныч хәле турында яза, салымнар җыйганда, солдатка алганда күрсәтелгән кыерсытулар, суд даирәләренең мәрхәмәтсез эш-гамәлләре аның хөкеменә тартыла.

Мәрҗанинең зур казанышы, һичшиксез, дини фәлсәфә өлкәсендә була. Бу җәһәттән, 70-80 нче елларда аның аеруча танылган хезмәтләре басылып чыга: «Китаб-ал-азб-ал-фурат ва-л-ма аз-зулал ан-накия ли-асрар шарх ал-Джалал» (ал-Җәлал комментариесе серләренә төшендерүче, төче, сафландыручы, ачкыч бирүче китап.—Истамбул, 1875), «Хакк ал-марифа ва хусн ал-идрак» (Танып-белү хакыйкате һәм аңа ирешү гүзәллеге.—1880 ел.); «Китаб ал-хикма ал-балига ал-джанния фи шарх ал-акаид ал-ханафия» (Хәнәфиләр тәгълиматын аңларга ярдәм итүче төпле фәлсәфә турында китап.—1888 ел.); «Би-т-тарикат ал-мусла ва-л-акидат ал-хусна» (Лаеклы иярү юлы һәм иң яхшы инану белән.—1890 ел.). Мәрҗанинең дини-фәлсәфи карашлары татар мәдрәсәләрендә өстенлек иткән спекулятив теология—каламне тәнкыйть итүдә чагыла. Ләкин ул, каламне тәнкыйтьләсә дә, күп кенә мәсьәләләрдә

шул ук карашларда кала.

Мәрҗани, фәнни белемне югары бәяләп, аны дини белемгә каршы килә дип санамый, ә бәлки икесен бергә янәшә куеп карый. Шул заманның дин галимнәре һәм мөдәррисләр дини мәсьәләләрне чишкәндә фәнни белемне инкарь итсәләр, ул дин белән фәннең тыныч янәшә яши алуын исбатларга омтыла. Мәрҗани фәнни белемне халык арасында тарату зарурлыгын алга сөрә. Аның фикеренчә, фәнне зурлау, дөньяви фәннәрне өйрәнү җәмгыятьнең социаль-икътисади, матди ягы үсешенә ярдәм итсә, динне өйрәнү җәмгыятьнең рухи яктан камилләшүенә китерә. Фән, ди ул, абсолют камиллеккә һәм хакыйкатьнең асылына төшенеп, өстенлеккә ирешү.

Мәрҗани дини белемне фәлсәфи белемгә каршы куймый, бары тик аларның куллану өлкәләрен генә аерып күрсәтә. Анынча: «Ислам дусларыннан бер надан, фәнне кире какса, дин чарасыз җинә дип уйлап, фәнни белемнәрне тулысынча инкарь итә. Ул хәтта Ай һәм Кояш тотылуы сәбәпләрен дә танымый һәм бу сәбәпләрне белү шәригатькә каршы килә дип раслый. Чынлыкта исә, алар аподейктика өлкәсенә карыйлар һәм, бер асылларына төшенгәч, аларны инкарь итәргә ярамый. Геометрик исәпләүләр бу сәбәпләрнең барлыгын дәлилилләр һәм шикләнерлек урын калдырмыйлар. Диндә моңа каршы килерлек бернәрсә дә юк».

Мәрҗани, диннең асылы рациональ дәлилләр белән исбатланмый, дип яза. «Рациональ фикер йөртүләргә килсәк, диннең һәм ана ышануның дөреслеге аларның асылларына төшенүгә һәм карауга нигезләнми. Киресенчә, алар турында фикер йөртү, аларны тикшерү—исбатлау өлкәсенә карый һәм шулай булганда гына алар яши». Нәтиҗәдә, Мәрҗани өчен фәлсәфә (фәнни белем) чынбарлыктагы дөньяны акыл аша аңлата алырлык төшенчәләр белән эш итә, ә дин—бары тик аның барлыгына ышану белән генә. Моңа охшаш фикерне галим «Назурат ал-хак» әсәрендә дә үткәрә: « Дин фәлсәфәгә, ә фәлсәфә дингә каршы килми, чөнки алар икесе дә бер-берсенә игезәкләр, бер үк хакыйкать чыганагыннан агып чыгалар һәм чынбарлык тормышта кулга-кул тотышып баралар».

Мәрҗани диннең заман таләпләренә җавап бирмәгән урыннарын гына тәнкыйтькә ала. Чөнки ул диннең күп мәсьәләләрен рациональ дәлилләр белән аңлатып булмый дип саный һәм аларны анга таянып түгел, ә ышанудан чыгып аңлата да.

Ш. Мәрҗани, үзеннән соң бай фәнни мирас калдыру белән генә чикләнмичә, шәкертләрен һәм үз эшен дәвам иттерүчеләрне дә тәрбияләде. Алар арасында Петербург университеты укытучысы Хөсәен Фәезханов та бар. Ул—Ш. Мәрҗанидән гыйлем алуы белән үк абруй казанган шәхес. Төрле елларда Каһирәдәге «Әл-Әзһәр» университетында көнчыгыш фәлсәфәсен укыткан Камалетдин бине Сәйфетдин һәм Әбубәкер бине Яһүд кебек шәкертләре исә гыйлемнәре белән чит илләрне дә таң калдырды.

Бертуган Мөхәммәтҗан һәм Шәрифҗан Кәримовларның нәшерлек эшчәнлеге дә Ш.Мәрҗанинең даими йогынтысы ярдәме белән башланган иде.

Ш. Мәрҗани Рәсәйдә татарлар арасында милли идеологиягә нигез салучы һәм җәдитчелек хәрәкәтенең алхәбәрчесе иде. Анын дини-фәлсәфи карашлары, педагог, дини реформатор, мәгърифәтче, тарихчы, фәлсәфәче сыйфатындагы эшчәнлеге, татар тарихына гына түгел, бөтен Рәсәй һәм дөньякүләм мөселман иҗтимагый фикеренә дә зур өлеш кертте.

*Ринат Таҗетдиновка 70 яшь*

Луара Шакирҗан

# БЕР СӨЙЛӘШҮ—БЕР ГОМЕР...

Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдиновны кем генә белми икән? Театрыбызның 100 еллыгына багышланган төрле конкурс сорауларына килгән сокланырлык җаваплардан хәтта мәктәп балаларының да Ринат Таҗетдинов иҗаты белән яхшы таныш булуы күренде. Аның Чүпрәле ягыннан, Кече Чынлы авылыннан икәнлеген дә, Мәскәүнең Щепкин исемендәге Югары театр училищесында татар студиясендә укыганын да, сабакташларының «щепкинчы»лар—Р. Шәрәфиев, Ә. Шакиров, Н. Ихсанова, Н. Дунаев, Г. Исәнгулова, Ф. Әхтәмова, Ф. Хәмитова, Ә. Зарипов, драматурглар Т. Миңнуллин, Р. Батулла икәнлеген дә беләләр икән. Муса Җәлилне, Нурихан Фәттахның «Кол Гали»ендә Гали кебек шагыйрьләребезне, Идегәй, Мулланур Вахитов кебек тарихи шәхесләребезне уйнаганын да, соңгы еллардагы күренекле эшләре—«Кара чикмән»дәге (Г. Хугаев) Чабар, «Баскетболист»тагы (М. Гыйләҗев) Сократ, «Шулай булды шул»дагы (Т. Миңнуллин) Нургали рольләрен бик яратуларын да язалар алар. Ә татар театрының даими тамашачылары—артистны беренче адымнарыннан ук якын итеп, һәр эшен карап, күзәтеп барганнары Ринат Таҗетдиновның «Хуш, Назлыгөл»дәге Искәндәрен, «Диләфрүзгә дүрт кияү»дәге Җәмиле дә, 29 яшендә «Гүзәлем Әсәл»дәге Ильясы өчен Г. Тукай премиясе, 1985 елда Муса, Илфат («Моңлы бер җыр», «Монда тудык, монда үстек» Т. Миңнуллин), Карандышев («Бирнәсез кыз» А. Островский) рольләре өчен СССР Дәүләт премиясе алуын да яхшы хәтерлиләр.



**—Ринат абый, сезне һәрвакыт бик бәхетле йолдыз астында туган кеше итеп күзаллыйлар, шулай язалар. Сез үзегезне ничек сыйфатлар идегез?**

—Күпләр—танышлар, башка театрдагы коллегалар, хәтта сабакташлар да миңа барысы да җиңел бирелде дип уйлыйлар. Бәлки анысы да бардыр, каршы килмим, әмма ләкин бу «бәхетле язмыш» ничек килгән, ничек бирелгән соң? Бу «җиңеллек» артында роль буенча никадәр эш, хезмәт, уйлану-газаплanулар, эзләну, уку, йокысыз төннәр, шикләнү, борчылулар бар бит. Әле юньле торыр урын да булмаганда, тар фатирда кечкенә балалар үстергәндә, ванна бүлмәсенә кереп роль текстлары өйрәнеп утырулар—алар чит күзләргә күренми, артта кала, артист эше җиңел тоела. Тамашачы өчен шулай булырга тиештер дә инде ул. Ә иҗат—бик газаплы эш. Артист бит теләгән ролен генә уйный алмый. Режиссер ни тәкъдим итә, шуның буенча эшләргә

тиешсең, ошыймы ул сиңа, юкмы, туры киләме ул синең тышкы һәм эчке сыйфатларыңа. Күп вакыт бит ышандырырлык итеп, табигый итеп бөтенләй «яңа халәт»кә керергә тиеш буласың. Кыскасы, минем һәр образым тир түгеп эшләнгән.

**—Ә уйныйсы килеп калган роль булдымы?**

—Минем кайбер артистларның, шушы рольне уйныйсым килгән иде, бу рольне уйный алмадым, диюләре белән бик килешәсем дә килми. Бөтен рольләрне уйнап бетереп булмый, беренчедән. Ә икенчедән, режиссер сине үзеңнән күбрәк күрә, ул синең алдагы эшләреңне белеп, шуннан нәтиҗә ясап рольне бирә. Мин Шекспирның Ричард III не уйнарга бик хыялланган идем. Марсель Хәкимович «аны сиңа, һичшиксез, уйнарга кирәк» дип, ничектер вәгъдә дә иткән иде, матбугатта да язулар булды, интервьюлар бирдем бу хакта. Әзерләнә дә башлаган идем инде. Ләкин ничектер туры килмәде. Бу—Шекспирның бик катлаулы әсәре. Марсель Хәкимович шикләнә, курка иде бераз бу автордан, ул аңа тотынмады.



*Г. Фигейредоның «Эзоп» спектакле. Клея—Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Эзоп—Ринат Таҗетдинов.*

**—Ни өчен шикләнә иде икән?**

—Бу кызыклы сорау, шундый талантлы, оста режиссер ник Шекспирны куймый икән дип, мин үземә дә күп тапкырлар сорау биргәнем булды. Үзе ул бер вакыт болай дигән иде: «Әгәр мин шундый зур классик әйберләр куеп, зал буш булса, миңа ул кирәк түгел, кызык түгел». Һәм мин аны бик хаклы булгандыр дип уйлыйм. Залда тамашачы булуын тели иде ул. Шунлыктан кайчак аңа уртакул әсәрләр дә куярга туры килде; ә классиклардан ул безнең тамашачы өчен А. Островский әсәрләренең якын булуын аңлады,аңа еш мөрәҗәгать итте һәм алар бик уңышлы булды.

**—Татар сәхнәсендәге рус классикасы турында бәхәсләр куерган чаклар була, чөнки безнең тамашачы бик кабул итеп бетерми шул аны...**

—Кайсы халыкныкы булса да, классикамы яки заман әсәреме, алар безнең тамашачыга якынрак булсын, аны тетрәндерсен ул. Шул чагында уңышлы булачак. Мин, мәсәлән, А. Чехов әсәре буенча безнең Фәрит куйган «Өч сеңел»не карагач, әлбәттә, котладым. Ул интеллигенция өчен, сәнгатьне аңлаган зал өчен искиткеч әйбәт эшләнгән спектакль, чынлап та андый профессиональ эшне тапмассың. Канәгатьлек алып утырасың анда. Шәхсән, үземнең тәэсир шундый. Театрны, артистлар талантын үстерүгә ул, һичшиксез, бик кирәк, мөһим эш. Фәрит, заман режиссеры буларак, моны бик яхшы аңлап эш итә. Спектакль турында Мәскәүнең тәнкыйтьчеләре, театр белгечләре дә әйбәт фикердә, әмма андый әсәр ул безнең авылдан килгән «абзый-апайларыбыз» өчен түгел. Алар аны аңламый, хәтта студентлар да аңламый. Шуңа күрә, минем фикеремчә, безнең күпчелек гади халыкка якынрак булган әсәрләр эзләргә, табарга, шулар белән үстерергә кирәк безнең тамашачыны.Без классиканы болай да сирәк куябыз, ә инде куелганы халыкны үзенә тартсын.

**—Празат Исәнбәтнең бер әйткәне истә: «Ниндидер спектакль карап кайткач, әтинең (Нәкый Исәнбәт) «йә ничек?» дип соравына, мин «ярый инде бистә халкына» дип җавап бирдем, һәм әти миңа шунда гомерлек сабак ясап, нык «пешерде», тәнкыйтьләде. Син шул халыкның малае, синең «шедеврларың» беренче чиратта халыкка ошасын, дигән иде.»**

—Әйе, нәкъ шулай. Мольерның «Суган суфые»н куйган иде Празат абый. Ул

спектакльне шундый халыкчан, аңлаешлы итеп куя алды, бернинди мөгез чыгармадык без анда. Мин әле яшь идем,миңа Тартюфны бирде. Бу роль мине иҗади яктан шундый үстерде, халык та йөрде бит, мәгънәсе барып җитте тамашачыга. Яисә менә «Эзоп»ны куйды ул. Мин бу спектакльгә әллә ни халык йөрмәс дип уйлаган идем.Ә бит ничә сезон барды спектакль, тамашачы агылып йөрде. Шундый әсәрләрне куярга кирәк. Шекспирның да безнең тамашачыга шактый якын әсәрләре бар. Мәсәлән, Отеллоны да рәхәтләнеп карарлар иде, яисә Шиллерның «Нәфрәт һәм мәхәббәт»ен дә. Артистлар гына булсын. Безнең милли театр башкорттагы кебек саф романтикага корылмаса да (без бит җирдә йөрибез), барыбер бераз күтәренкерәк хисле әсәрләрне дә ярата халык. Һәр бөек драматургта андыйларны табарга була, хәтта Чеховның прозасын сәхнәләштереп тә, татар күңеленә якын спектакль эшләргә мөмкин дип саныйм.

**—Хәзер инде киңәшергә худсоветлар юк. Сез 50 елга якын сәхнә тоткан олы артист, театр әһелләре берлеге рәисе, бу юнәлештә фикерегезне, үз сүзегезне әйтеп сөйләшкәнегез бармы баш режиссер белән?**

—Сөйләшкән бар. Өйрәтү кебек кабул итмәсен дип тә уйлыйбыз шул без. Ничек кенә булмасын, Отелло, Гамлетлар театр оешканнан бирле куелган, кайберсе аның бик аз уйналган, әмма шулар белән артист та, тамашачы да үскән.

**—Сез Отеллоны уйнар идегезме?**

—Мин студент елларында уйнадым бит.Ул миңа яки мин аңа шундый туры килә идек.

**—Ә бүген?**

—Уйнап булыр иде, билгеле, режиссер куйса. Бөтен рольләргә тиешле артистлар табылса, ник булмасын.

**—Элек театрларның репертуарлары буенча киңәшмәләр, җыелышлар була иде Актерлар йортында. Үзебезнең һәм Мәскәүдән тәҗрибәле театр белгечләре чакырыла иде. Хәзер хәлләр ничек?**

—Минем андый уем бар. Режиссерларны җыеп фикер алышу бик кирәк.

**—Сезне, укып бетергәч, Мәскәүнең Кече театрына калырга үгетләгәннәр, имеш, дип ишеткән идем, дөресме ул?**

—Юк, дөрес түгел. Чегән театры Роменга барып кара, дип киңәш итүчеләр булды. Мин Мәскәүдә калырга теләмәдем, мин бит татар артисты. Безнең бит авылда үскән малайларның рус теле дә шәптән түгел. Мәскәүдә генә өйрәндек сөйләшергә.

**—Сугыш елларына туры килгән малай чактан нинди тәэсирләр калган?**

—Сугыш ачысын, ачлыкны без, Аллага шөкер, бик алай тоймадык. Сыер бар иде безнең, бәрәңге утырта идек. Күршеләргә дә сөт биреп, ярдәм итә идек әле. Гаиләдә бер генә кыз булганга, без, биш малай, бөтен өй эшләрен эшләп үстек.Беләсең килсә,мин токмачны кайбер хатын-кызлардан остарак та кисәм әле! Шулай үстек.Әти-әни барыбызга да югары белем бирде: беребез табиб, беребез химик, беребез укытучы, беребез әти юлыннан китте—механизатор.

**—Берегез артист... Әйтегез әле, Ринат абый, сезне чын артист итеп тоярга көч, ышаныч биргән аерып әйтерлек роль булдымы? Әллә инде беренче рольдән ук (ул А. Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләр»ендәге Хәнҗәр иде) сездә икеләнүләр беттеме?**

—Юк, беренче рольдән түгел, рольләр баштан ук бик күп булды, әлбәттә. Аларның күбесе минем үз табигатемә, яшемә туры килә иде. Темперамент, интуиция белән бара идем, әмма «О, булдырдым!» дип әйтү юк иде. Ә менә «коры» артист табигате, йөрәк, талант белән генә түгел, нәкъ осталык белән уйнарга кирәклеген мин «Бирнәсез кыз»да Карандышев ролендә тойдым һәм аңладым.Классиканың кыйммәте дә шундадыр шул. Бөтен күзәнәкләр белән аңлап, тулысынча үзеңне җиңел, рәхәт хис итеп уйнаудадыр. Монда әнә шул «мастерство», «мәктәп» кирәк. Ул «Гүзәлем Әсәл»дә дә табылды. Тәмам рольнең эченә керсәң, йөрәк анда әйтеп тора нишләргә кирәк икәнен һәм төгәл яшәү табыла. Аннан тәҗрибә белән килә күп нәрсә: роль белән залга нәрсә җиткерергә тиеш икәнлегемне—безнең телдә «сверхзадача» диләр аны—мин инде бик ачык беләм хәзер, бу турыда күп уйланам. Гади автор сүзен генә җиткерү түгел, үзем буларак та һәр спектакльгә үз сүзем бар.

**—Сәхнәгә чыкканда дулкынлану, ниндидер бер эчке туплану, ырымыгыз бармы?**

—Бисмилланы әйтеп башлыйм. Дулкынлану барыбер һәрчак була, әзер икәнеңне йөз процент ышаныч белән белеп чыкканда да.

**—Бик моңаеп аерылган әсәрләр, рольләр булдымы?**

—Булды. «Сүнгән йолдызлар»ны 500 тапкыр уйнадык, һаман да уйнар идем. «Гүзәлем Әсәл»дәге Ильяс күңелгә бик якын иде, халыкның йөрәгенә үтеп керә идек. Ильяс бит әле гел уңай образ да түгел, ләкин барыбер тамашачы аны аңлый, кичерә иде. Йөрәкнең зал белән бергә типкәне сизелә иде. Бик кызганыч булды аерылу.

**—Сез бик мәгънәле, төпле акыллы кеше. 70 яшь инде аксакаллар яше, диярлек, уйнаган рольләрдәге гыйбрәтле язмышлар да эссез үтми бит—рухи баета, тәҗрибә бирә. Яши-яши инанган, йә үзегез тапкан фәлсәфә, мәкаль, нәтиҗә бармы?**

—Олыгайган саен кешегә начарлык итү түгел, начарлыкны уйларга да ярамый икәнлеген аңладым—ул синең барыбер үзеңә начар булып килеп житә. Бер көн табибка чиратка бастым. «Барыгыз, чиратсыз керегез»,—диючеләр дә бар иде. Юк шул, алай итәсе килми—дөрес булмаган эшләрдән тыелу бар хәзер.

**—Сәхнәдәшләрегезнең уңышы сезгә ничек тәэсир итә?**

—Миндә, Аллага шөкер, көнләшү юк. Бу минем бәхетем. Сәнгать өлкәсендә, гомумән, көнләшү бар бит инде. Исем яки премия бирсәләр, нигә миңа түгел, дип уйлаучылар бар. Мин аны үземә карата да сизә идем. Сәхнәдәшләремнең уңышы, һөнәри осталыгы мине шатландыра гына. Яшь буын сокландыра. Искәндәр Хәйруллин гаҗәеп көчле артист булып бара.

**—Татар мәктәпләре ябылып беткән заманда милли театр һәм сезнең кебек милләтпәрвәр артистларыбыз туган телебезне саклап калырга ярдәм итүче бер терәк иделәр, ләкин замана шаукымын сез гаиләдә, өйдә җиңә алмагансыз, ахры. Бу четерекле соравыма ни диярсез? Кызларыгыз ана телен сезнең кебек белми, ә үзләрен татар итеп сизәләрме?**

—Бу соравың, әйе, четерекле, ләкин бик кирәкле сорау.Безнең заманда Казанда татарча сөйләшү юк иде. Ишетсәләр, кырын карый башлыйлар... Онытасым юк, берзаман абый белән трамвайда үзебезчә сөйләшеп барабыз. Бер юан марҗа килеп колагымнан тартып торгызды: «Сидишь тут, болтаешь по татарски»,—ди. Хәзер инде, шөкер, андый хәлләр юк. Кызларыбыз Руфина, Айсылу, әлбәттә, татар җанлы балалар, татарча аңлыйлар, эти дип дәшәләр. Балалар үскәндә мин көне буе эштә идем: көндез репетиция, кич спектакль, айга 32 спектакль уйнаган чаклар була иде. Мин кайтып, «татарча сөйләшегез» дип әйтә идем дә бит, тагын китә идем. Хатыным Рәисә Мәскәү кызы, татарча бөтенләй диярлек белми иде әле, гомер итә-итә генә өйрәнде. Өйдә балалар белән русча сөйләшкәннәр инде, билгеле. Хәзер мин үзем дә моңа үкенәм, кызларым да миңа үпкәли, өйрәтмәгәнсең дип. Ә менә оныкларым—ике бәләкәй кызым татар телен мәктәптә дә өйрәнеп, аңлап үсәләр, минем белән татарча сөйләшәләр, хатасыз язалар, гәрчә аларның әтиләре татар кешеләре түгел. «Миңа түгел, сезгә кирәк, балалар, байлык бит ул—тел белү, дип аңлатам инде. Спектакльгә килгәч, мине, бабагызны аңлап карап утыру кирәк»,—дим. Олы кызым Руфина сәнгать һәм мәдәният институтында укыта, культурология буенча диссертация якларга җыена. Татар теле белән бик кызыксына хәзер.

**—Әйтегез әле, сез, гади авыл малае, ничек һаман Европа джентельменнары шикелле елмаеп яши аласыз? Һаман якты чырайлы, кояш кебек балкып торасыз? Тормышта сез бар нәрсәдән канәгатьме әллә? Башкалар кебек һәр нәрсәдән зарланганыгызны ишетмим. Сезне борчыган, чыгырдан чыгарган нәрсә бармы?**

—Якты чырай күрсәтү безнең канга сеңгән ул. Без алты бала үстек. Биш малай, бер апабыз, барыбыз да шундый. Бу—тәрбиядәндер инде. Әти авыр эштә эшләгән кеше, бераз кырысрак иде. Тракторчы булган, сугыш вакытында бронь белән калдырганнар аны, кайтып елаган. Өч класс белеме белән сугыштан соң аны инженер-механик итеп куйдылар. Сәясәт белән кызыксына иде, колхоздан бер бөртек урламады, чын коммунист булып яшәде. Шулай да мине авылдан озатканда: «Син, улым,

партиягә кермә инде»,—дигән иде. Ә мине чыгырдан чыгарган нәрсә—ул битарафлык. Борчыган нәрсә—бүгенге пенсионерларның матди хәле, бәяләр һаман күтәрелә. Ә иң эчемне пошырган нәрсә—чисталык сакламау. Безнең татар халкына чисталык хас бит. Без авылда үстек, анда чисталык иде. Бакчаларга барганда чүп өемнәрен, пычраклыкны күреп шаккатам инде. Алып килгән әйберләрен һәркем үзе белән алып кайтып чүп оясына ташлый ала бит югыйсә.

**—Ә нишләргә бу яман чир белән? Чит илләрдә зур штрафлар түләтәләр, ди...**

—Белмим инде, безгә дә шулай итәргәдер, бәлки? Ничектер бу гадәттән биздерергә, тәртипкә өйрәтергә иде. Һәр гаилә балаларын кечкенәдән өйрәтсен иде.

**—Ник әле без сезне депутат итеп сайламыйбыз икән? Төпле, мәгънәле сүзегезне әйтер идегез югары мөнбәрдән...**

—Минемчә, чын сәнгать, чын иҗат кешесе депутат була алмый, ул чакта сәхнәдән китәргә кирәк.

**—Ә театр кешеләренең мәнфәгатьләрен кем кайгыртыр?**

—Депутатлардан көтәбез инде. Табиб, укытучы, китапханәчеләр турында сүз кузгалды, бәлки, безнең турында да кайгырта башларлар.Бюджет,сәнгать мәсьәләләре буенча иҗат берлекләре җитәкчеләрен җыеп сөйләшкәндә, мин һәрвакыт артистларның хезмәт хакы турында әйтәм.



*Н. Фәттахның «Кол Гали» спектаклендә Гали ролендә.*

**—Бүген милли татар театрына караш нинди?**

—Халкыбыз, тамашачыларыбыз тарафыннан театрга булган мәхәббәт инде гасыр белән үлчәнә. Бик театр җанлы безнең татар халкы.Концертлар күбәйсә дә, театр сөюче аерым тамашачыбыз бар безнең. Җитәкчелектән дә без хөрмәт күрәбез, шөкер. Республикабызның президенты премьераларыбызга килә. Минтимер Шәрипович Шәймиев театр тормышын, артистларыбызны яхшы белә. 20 елдан соң театр бинасына ремонт ясалды хөкүмәт ярдәме белән, гастрольләр оештыруга да булышлык күрсәтелә. Ә менә театрга караш дигәннән, мине борчыган бер хәл бар. Бөтен җәмәгатьчелек милли театрның 100 еллыгына, зур бәйрәмгә әзерләнгәндә, кайберәүләрнең матбугатка чыгарган мәкаләләре турында әйтәм. Тел, милләт дип йөргән кешеләребез, театрны яратучылар да уйламыйчарак эш итәләр. Ошап бетмәгән әсәрләр була инде ул. Бәйрәм алдыннан күп нәрсә гафу да ителә, әмма театр турында шундый әшәке телле мәкаләләр язу мине шаккатырды. Мин бу турыда радиодан да әңгәмәдә әйттем инде, язып чыгарга минем алай осталыгым юк. Йөзек кашы саналган театр, аның искиткеч талантлары, гаҗәеп бай тарихы турында сөйләшер алдыннан мондый мөнәсәбәт күрсәтү, үз укучыңа, үз тамашачыңа театрны хур итеп язу,үзеңнең театрыңны үзең бетерү—театрга йөрмәгез дип әйтү белән бер бит ул.

**—Әйе, әгәр театрны, спектакльне чынлап та яхшыга үзгәртү буенча ниндидер төпле фикер, йә профессиональ теләк бар икән—режиссер белән аерым очрашырга да мөмкин бит, югыйсә...**

—Әлбәттә. Кил театрга, сөйләш. Мин мондый эшләр начар холык билгесе дип уйлыйм. Йә әсәрен куймаганга үчлек. Бер дә килешми, әлбәттә. Без бит барыбыз да театр өчен тырышабыз, халыкка хезмәт итәбез. Аннан соң «татар, татар» дип йөреп кенә булмый, андый сүзләр артында синең матур эшләрең торырга тиеш.

**—Бүген безнең туган телебезгә игътибар кими түгелме? Глобальләшү белән мәшгуль дөнья, шуның шаукымы микән?**

—Әйе, шундый процесс бара шул, кызганычка каршы. Ләкин, минем уйлавымча, бар нәрсәне бер казанга салу да дөрес түгел. Россиянең бөтен матурлыгы, байлыгы

милли төрлелектә, милли фольклорда. Нинди генә төс юк анда. Болын да төрле төстәге чәчәкләре белән матур. Шуңа күрә мөмкин түгел милләтләрне, татарны бетерергә.

**—Кими бит татарлар, урыслаша...**

—Безнең татарлар, кая гына барсак та, бик күп, шөкер. Аның телне белмәгәне дә спектакльләргә килә, тәрҗемә аша булса да тыңлый, тәэсирләнә, татар моңын ишетүгә аның йөрәге башкача тибә башлый, күзләре яшьләнә. Без бит күрәбез, беләбез. Театр белән төрле якка гастрольләргә баруыбызның төп максаты да шулдыр—татарлыктан читләшкән, рус дөньясында яшәгән милләттәшләрнең күнеленә моң салу. Менә Вильнюста, мәсәлән, русча сөйләшүче татарлар килеп, елап утырдылар. Канга сеңгән үз аһәңен, үз моңнарын алар барыбер тоялар. Гастрольләр элекке кебек еш булмаса да, барыбер менә Самарага, Әстерханга, Чиләбегә, Оренбургка, Бакуга, Мәскәүгә барабыз. Зал тулып килә татарлар. Менә шул гастрольләрне бетерә күрмәсеннәр инде. Бөтен татар театрларына да йөрергә мөмкинлек булып торсын иде. Бу безнең халкыбызны баетыр иде, театрның ролен дә үстерер иде.Соңгы вакытта әле, шөкер, хөкүмәт ярдәм итә.

**—Театрда үзгәрешләр булып торырга тиеш, диләр. Сез эшләгән 47 елда театр нинди үзгәрешләр кичерде?**

—Әйе, мин 1961 елда Ширияздан абый Сарымсаков чорында кайттым театрга. Искиткеч шәп артистлар иде. Әмма ниндидер бер җансыз, катып калган хәлдә, музей кебегрәк иде театр. Бизәлеш-сценография дә бик ярлы булды. Театр дөньясындагы яңа алымнар юк иде әле. Артистлар да, театр да артык олыгайган иде булса кирәк. Аннан директор булып Рәшидә апа Җиһаншина килде, Марсель Сәлимҗановны чакырды. Гаҗәеп зур яңару чоры башланды. Классик әйберләр: «Сүнгән йолдызлар», «Миркәй белән Айсылу»—алар бар да башкача, яңача куелды.

**—Ул яңалык нидә иде?**

—Мәскәүдән укып кайткан Марсель бөтен яңа алымнарны кулланды. Декорацияләр дә заманча эшләнде. Режиссерның башкаруга, уйнауга, артистларга карашы, таләбе башка иде, ул фантазиягә мөмкинлек бирде. Спектакльләргә җан керде, яши башлады. Бу, әлбәттә, төптән борылыш дигән сүз түгел. Яшь буын артистлар килү дә зур ачыш иде. Гомумән, сәхнә яшьләрне ярата, халык аларны карарга килә бит, гәрчә театрда өлкәннәр дә кирәк. Инде менә Марсельдән соң ниндидер бер үзгәреш кичерә театр. 35 елдан артык вакыт узган иде бит, тагын да шулай яңа бер сулыш кирәк иде, һәм ул Фәрит Бикчәнтәевнең спектакльләрендә сизелә. «Кара чикмән» спектакле Россия күләмендә үткән «Музыкальное сердце театра» фестивалендә өч приз яулады бит. Иң яхшы спектакль, иң яхшы режиссер, иң яхшы уйнаган ирләр роле номенацияләрен дә. Театрыбыз яши, ул һаман хәрәкәттә, үзгәрештә, үсештә—бу бик куандыра.

**—Сез инде 20 еллап Татарстан театр әһелләре берлегенең рәисе вазифасында. Заманалар үзгәрде, элек без ярты хезмәт хакына шушы берлек аша юллама алып, Кара диңгез буенда иҗат йортында ял итә ала идек. Хәзер берлек әгъзаларына юллама алу өчен ярты еллык хезмәт хакы кирәк. Беләм, бу сездән тормый. Иҗади берлекләр ни өчен кирәк соң? Мәскәүдәге киңәшмәләрдә ни сөйлиләр?**

—Әйе, бу турыда сүз күп бара. Мәскәүнең театр берлегендә дә шул ук хәл. Алар безгә ярдәм итә алмый хәзер, үз көнегезне үзегез күрегез, диләр. Хәл авыр булуга карамастан, мин бу берлек яшәргә тиеш дип саныйм. Гомерләрен сәхнәдә уздырган ветераннарыбыз өчен бер туган йорт булып тора әле ул. Киләләр, аралашалар. Иҗат кичәләре уздырабыз. Бик кыен хәлдә калганнарга без матди ярдәм дә күрсәтергә тырышабыз. Идел буендагы ял итү урынын да ремонтладык. Җәен анда халык бик күп була. Әлбәттә, Сәлимҗанов исемен йөрткән Актерлар йортын гөрләп торган иҗат учагы итеп күрәсе килә. Тырышабыз.

**—Нәрсәне дә булса түземсезләнеп көтәсезме, балачактагы шикелле?**

—Алай балачактагы, яшьлектәге кебек көтү юк инде ул,чөнки вакыт, гомер болай да бик тиз уза! Сизмисең дә атнаны, айны! Премьераларны дулкынланып көтү бар. Ничек булыр, халыкка ошармы, аңларлармы, дисең, образың турында уйлыйсың, нинди характер табарга. Нидер барып чыкмаса, мин бик борчылам.

Берәр деталь табылса, өйгә очып кайтам. Җәйне, яшел үләннәрдә йөрүне котәсен инде, без бит авылда үскән. Онықларымның үсеп житүен көтәм, аларның балаларын да күрергә иде, дисең...

**—Характер дигәннән, йөздән артык персонажның эчке, тышкы халәтен кабатланмыйча күрсәтер өчен никадәр генә бай күңел, зур талантның да, кем әйтмешли, запасы җитмидер. Бу процесс ничек бара? Ничек эзлисез,каян табасыз? Тирә-яктанмы?**

—Әлбәттә! Артист булгач—ул инде канга сеңгән—урамда болай гына йөрмисең, һаман күзәтәсең. Бакчаларга барганда, юлда нинди генә кызык характерлар очрамый. Атлавын да, хәрәкәтен дә, сөйләү манераларын да отып каласың, үзләштерәсең, әлбәттә, эзләнәсең һәм тормышта табасың. Тартюфның йөрешен мин шулай бер кешедән күреп калган идем.

**—Нинди образлар ошый сезгә?**

—Дөресен әйткәндә, кире, тискәре образларны уйнарга яратмыйм. Аларны уйнау җиңел. Бик эзләнәсе, иҗат газаплары кичерәсе юк. Уңай образларны эшләү авыр. Миңа «Дивана» спектаклендәге ролем бик кызыклы. Минем әле андый роль уйнаганым юк иде.

**—Ринат абый, бер әңгәмәдә әтиегезнең «беркайчан да кешенең дәрәҗәсен төшермә, түбәнсетмә, үзең масайма» дигән киңәшен гомер буе истән чыгармавыгызны әйткән идегез. Балаларыгызга, оныкларыгызга сезнең киңәшегез нинди?**

—Мин аларга әти сүзен дә әйтәм. Аннан өлкәннәргә, картларга хөрмәт күрсәтегез дип тәрбиялим. Сезгә дә ул көн киләчәк дим.

**—Кайсы шагыйрьне күбрәк яратып укыйсыз?Җәлилнеме?**

—Муса Җәлилне уйнаганда мин аның һәр шигырен ятладым диярлек.Күңелгә Зөлфәт шигърияте бик якын. Гомер узган саен Тукайны ешрак укыйм.

**—Театрда берничә кат яратып караган спектаклегез бармы?**

—Мин Туфанның «Әлдермештән Әлмәндәр»ен искиткеч әсәр дип саныйм. Ул спектакльне бик күп караганым бар. Караган саен карыйсы килә. Шәукәт абыйның уены да гаҗәеп, әлбәттә. Бу спектакль—безнең горурлыгыбыз ул.

**—Ә Казанның кайсы урынында йөрергә яратасыз, күңелгә бик якын җир бармы? Күптән түгел Казан шәһәренең Мактау кенәгәсенә керттеләр бит әле сезне.**

—Әйе шул. Укып бетереп кайткач та, Мәскәүне юксынган идем башта.

Хәзер инде мин Казанны туган шәһәрем кебек күрәм. Кая барсак та Казан сагындыра. Мин Эрмитаж бакчасын бик ярата идем. Казансу буенда Фукска һәйкәл куелган бакчада булырга яратабыз. Бутлеров урамындагы иске йортлар да бик ошый иде, кызганыч, аларны сүттеләр. Бик күпләр әйткән фикер белән мин дә килешәм—тарихи иске йортларны мөмкин кадәр саклап калырга иде.

**—Сезнең байлык нидән гыйбарәт? Матди якны күздә тотуым түгел.**

—Мин гаиләм, балаларым белән бай! Йөземә кызыллык китергәннәре юк. Укыдылар, урнаштылар. Иң мөһиме—мине гаиләмдә яраталар. Миңа хәзер тынычлык, көч кирәк. Саулык белән аяк өстендә йөреп, мөмкин кадәр балаларга ярдәм итә алсам—шул зур байлык миңа.

Миркасыйм
Госманов

# ТАРИХЫБЫЗНЫҢ ТУТЫКМАС БЕР КӨЗГЕСЕ

Узган 2006 елда «Казан утлары» журналының Меңенче саны чыгуын билгеләп уздык. Бу вакыйганың гыйбрәтле әһәмиятен аңлар өчен кайбер фактларны кыскача гына тезислар рәвешендә искә алу да җитә.



Хәзерге Русиядә, хәтта туфрагы, халык саны буенча бүгенге Русиядән күпкә зуррак СССРда басма сүзе, милли телдәге матбагасы 150-200 елдан артык булган халыклар бар икән.

Милли татар телендәге матбугатның дөньяга чыга башлавына, 1905 елдан исәпләсәк, нибары 102 генә ел...

Яңа дәвер, ягъни совет хакимияте урнашкач, төгәлрәк әйткәндә, XX гасырның 20нче елларыннан чыга башлаган төрле милли телләрдәге «калын» журналлар арасында бары бер «Казан утлары» гына 2006 елның февраленә үзенең 1000 нче санын чыгаруга ирешә алган икән.

«Безнең юл»дан башлап даими рәвештә чыгып килә торган «Казан утлары», төрле сәяси басымнарга, сугыш елларындагы авырлыкларга карамыйча яши алган булса, димәк, моның үзенә хас сәбәпләре дә бар дигән сүз.

Әйе, сәбәпләр, һичшиксез, бар. Шулардай мин иң элек икесен атар идем. Беренчесе милли матбага өчен озак еллар көрәшү дәвамында ирешелгән нәтиҗәләрне саклау омтылышы булса, икенчесе, әлбәттә, инкыйлабка кадәр тупланган тәҗрибәнең дә билгеле күләмдәге әһәмияте иде. Мәсәлән, «Аң», «Әлгасрел-җәдит», «Шура» журналларын чыгаруда тупланган бай тәҗрибә. Бу журналлардан эчтәлегенең байлыгы, басма сүз культурасының югарылыгы, ниһаять, гомеренең озынлыгы буенча иң саллысы, иң кыйммәтлесе, һичшиксез, «Шура» журналы иде. Шуңа күрә аның чыга башлавына 100 ел тулуны бераз киңрәк һәм махсус билгеләү очраклы түгелдер.

Татар телендә гәзит-журналлар чыгаруга булган барлык омтылышлар Русия хөкүмәте тарафыннан эзлекле һәм катгый рәвештә тыела килде. Бу—тулысынча расланган бәхәссез факт. Ләкин халыкның үз ана телендәге вакытлы матбугатка булган ихтыяҗы, омтылышы моңа карап кына яшәүдән туктамады. Шуңа күрә XIX гасырның өченче чирекләреннән башлап Каюм Насыйри һәм башкалар тарафыннан чыгарылган төрле календарьлар, җөмләдән мәгълүм Рәшид казый—Габдерәшид Ибраһим тырышлыгы белән озак еллар дәвамында нәшер ителгән «Миръат» альманахы һәм шуның ише гайре басмалар халкыбызның вакытлы матбугатка булган ихтыяҗын өлешчә канәгатьләндерүгә, ягъни «сусауны» беркадәрле басуга булышкан иде.

1883 елдан Бакчасарайда мәшһүр реформатор Исмәгыйль бәй Гаспралының нигездә кырымтатар телендә чыгарган «Тәрҗеман» гәзите Русия империясендәге төрки халыкларның, җөмләдән татарларның да укымышлырак катламнары өчен

дистә еллар дәвамында бердәнбер көндәлек басма сүз үрнәге булып хезмәт итте. Билгеле сәбәпләр (теленен беркадәр авырлыгы, шул чордагы коммуникацион мөмкинлекләрнең начарлыгы) аркасында «Тәрҗеман» таррак даирәләрдә таралса да, аның иҗтимагый һәм психологик тәэсире гаять зур булды. Ул, бер үк вакытта, булачак татар журналистларына тәҗрибә туплар өчен зарурый мәйдан, тәҗрибә мәктәбе буларак та хезмәт итте. Шулай ук дистәләгән еллар буена халыкның үз телендә газит-журнал булдыруның әһәмиятен, зарурлыгын тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итте. Һәр халыкка аның үз ана телендә сөйләп, һәр конкрет кавемнең үз мәнфәгатьләренә, үз омтылышларына җавап бирә торган милли гәзит-журналы кирәклеген күрсәтте. Ләкин гасырлар буена чын-чынлап халыклар төрмәсе була килгән Русиядә мондый табигый ихтыяҗ да канәгатьләндерелмичә кала бирде.



*Ф. Кәрими (сулдан уңга), Р. Фәхреддин, З. Рәмиев (Дәрдмәнд). 1909 елгы фотодан фрагмент.*

Мәсьәлә уңай хәл ителсен өчен империянең нигезләрен какшатырлык зур социаль-иҗтимагый зилзилә кирәк булган икән. Бары патша тәхетен дер селкеткән һәм, Тукайча әйткәндә, халык «бер таң белән» уянган 1905 елдан башлап, йөз ел чамасы сузылган әзлекле көрәш нәтиҗәсе буларак, татарларның үз милли матбагачылыгы мәйданга чыкты. Аз вакыт эчендә ул киң колач җәйде: империянен татарлар яшәгән төрле төбәкләрендә—төрле шәһәрләр һәм почмакларда бер-бер артлы татарча гәзит-журналлар чыга башлады.[1]

Социаль-иҗтимагый тигезлеккә, рухи азатлыкка омтылу нәтиҗәсендә һәм милли-азатлык өчен көрәш дулкыннарында дөнья күргән бу гәзит-журналларның күпчелегенә, нигездә, фикердә хөрлек, гамәлдә гаделлек, бер сүз белән әйткәндә, табигый халыкчанлык сыйфатлары, ахыр чиктә шуларга омтылу теләге хас иде. Алардагы фикер төрлелеге, ачыктан-ачык сөйләшергә, шул рәвешчә аңлашырга омтылыш күренешләре шуны раслый. Әлбәттә, мондый теләкләрнең тормышка ашуында аларны кемнең нәрсәне ничегрәк аңлавы, нинди чаралар белән гамәлгә кертүе һәм шушы юнәлештәге тәҗрибәнең булуы, яисә житеп җитмәве дә үзен сиздергәндер, һәрхәлдә, ничек кенә булмасын, 1917 елга кадәр чыккан күпсанлы гәзит-журналлар арасында либерал-демократик, яисә сул карашлы басмалар белән янәшәдә идея-фикерләре шактый буталчык яки консерватив эчтәлектәгеләре, хәтта клерикаль рухлы дип әйтерлекләре дә бар һәм житәрлек иде. Мондый хәл исә шул чор татар җәмгыятендә табигый плюрализм, ягъни фикерләү хөрлеге күренеше урнаша башлавына, иң кимендә аның орлыклары сибелүенә ныклы дәлил булса кирәк.

Менә шул төрле юнәлештәге күпсанлы татарча гәзит-журналлар арасында тоткан юлының киңлеге, эчтәлегенең байлыгы, полиграфик эшләнешенең дә югары сыйфаты һәм плюрализм рухының эзлеклелеге белән аерым урын биләгән басмаларның берсе һәм иң абруйлысы, һичшиксез, «Шура» журналы иде. 1908 елның башыннан ук 1917 елның ахырына кадәр тәртипле рәвештә айга икешәр мәртәбә чыгып килгән, шул дәвердә барлыгы 240 саны дөнья күргән бу журнал бер

[1] Гасыр башы һәм, гомумән, XX йөз татар вакытлы матбугатының барлыкка килү, үсү һәм торгынлыкка төшү үзенчәлекләре хакындагы гомум күзәтүне, шулай ук 1905–1924 еллар арасында чыккан 312 гәзит һәм 89 журналның тулы күрсәткечен карагыз: Гайнанов Р., Марданов Р., Шакуров Ф. Татарская периодическая печать начала XX века: Библиографический указатель. – Казань: Милли китап, 2000. – С. 316.

татар мохитендә генә түгел, бәлки бөтен Русиядә, хәтта аннан тыштагы башка мөселман төркиләре арасында да киң таралган популяр басма иде.

Журнал, мәгълүм булганча, күренекле татар сәнәгатьчеләреннән бертуган Шакир һәм Закир (шагыйрь Дәрдмәнд) Рәмиевләрнең өзлексез һәм тотрыклы рәвештә тәэмин иткән чыгымнары исәбенә Оренбург шәһәрендә нәшер ителә. Ул 1906 елдан шул ук меценатлар нигезләгән һәм мәгълүм мәгърифәтче әдип Фатыйх Кәрими редакциясендә чыгып килгән абруйлы «Вакыт» гәзитенен кушымтасы сыйфатында барлыкка килә.

Беренче санынннан алып соңгысына кадәр «Шура»ның баш мөхәррире, 1906 елда ук Уфадан Оренбургка махсус чакырылган Риза казый—шул чордагы иң абруйлы әдип, тарихчы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддин (1859—1935) була. Журналның югарыда кыскача күрсәтелгән уңай сыйфатларга (эчтәлектәге байлыктан тыш рухи хөрлеккә, киң популярлыкка) ирешүен чынчынлап тәэмин иткән, итә алган зат һәм наширләрдән гамәлдә, фикердә тулы ирекleккә хокук, хәзергечә әйтсәк, «карт-бланш» ала алган шәхес тә, һичшиксез, шул ук Ризаэддин Фәхреддин иде.

Баш мөхәррирнең нинди басма булдырырга теләвен һәм нәрсәгә омтылуын журналның беренче санында беренче биттә басылган «Мәсләк вә максад» исемле кереш сүзеннән—программасыннан күрергә мөмкин:

«Шура» милләтне гыйлемле, мәгърифәтле итмәк хакында, мәшавәрәт мәҗлесе [б]улачактыр. Эстәдеге кемсә ошбу мәҗлестә сөйләр вә эстәдеге адәм дә тыңлар. Шәхсияттән вә гарызлардан (дәгъваләрдән—М.Г.) саф [б]улмак шарты илә, милләт мәнфәгате арзусы илә (теләге белән—М.Г.) язылмыш мәкалә вә фикерләр өчен «Шура» битләре һәрвакыт ачыктыр. Кагыйдәсе илен улан интикадларны (булган тәнкыйтьләрне—М.Г.) «Шура» тәшәккер илә кабул итәр вә бәйлә хокуктан көндисе дә мөстәфид улыр (үзе дә файдаланучы булыр—М.Г.)»

Бу кечкенә өзекнең төп мәгънәгә ия сүзләре «мәшавәрәт мәҗлесе» дигән гыйбарәдер; ул «киңәш мәҗлесе, фикер алышу урыны» дигәнне аңлата (гарәпчә «шура» сүзе дә шул «мәшавәрәт» белән бер үк тамырдан һәм ул да «киңәш» мәгънәсендә). Димәк, югарыда журналга хас дип билгеләгән төп сыйфат—фикерләү ирекlеген тану, ягъни плюрализм принцибын яклау сыйфаты очраклы күренеш, яисә мәсләксезлектән килеп чыга торган башбаштаклык нәтиҗәсе түгел икән. Ул, һичшиксез, наширләр һәм җаваплы мөхәррир гамәлгә ашырырга теләгән, мөмкин кадәр тормышка да ашырылган программа җимеше иде. Әйтергә кирәк, Риза казый житәкләгән журнал редакциясе үзенең вәгъдәсенә ахыргача тугрылыклы булып кала алды. Ахун һәм миллионердан алып авыл хәлфәсе белән эшче-наборщикка кадәр, киң танылган мәгълүм әдипләр, галимнәр янында өйрәнчек шәкертләр дә журналда актив катнаштылар.

Авторлар арасында Идел-Урал һәм Себер ягы татарлары күпчелекне тәшкил итсә дә, алар белән янәшәдә Кавказ, Кырым һәм Урта Азия, хәтта Шәркый Төркестан, Төркия, Сүрия, Мисыр кебек ераграк илләрдәге каләм ияләренең дә чыгышларына киң урын бирелгән иде.

Ә журналда басылган материаллар арасында ниндиләре генә юк! Зур проблемаларны күтәргән иҗтимагый, икътисади фәлсәфи, дини темаларга багышланган тирән эчтәлекле хезмәтләр белән янәшәдә чын сәнгатьчә язылган әдәби әсәрләр—шигырьләр, хикәяләр булыр. Мәктәп-мәдрәсә, тәгълим-тәрбия һәм, гомумән, мәгарифчелекнең катлаулы мәсьәләләрен күтәреп чыккан актуаль мәкаләләр янында төп мәгънәсе белән кирәклеге шул чорда ук чамалы булган, ләкин укучыларның активлыгын чагылдыра торган язмаларны да күрәсең.

Сораулар артыннан сораулар куелса, аларга бирелгән җаваплар да төрлечә, житди уйланырлык итеп язылган. Вакыт-вакыт күптән узган чорларны сагынган моңлы яки идеаллаштырып мактаган тантаналы язмалар очраштыргаласа, киләчәкне кайгырткан борчылулар, якты өметләр белән өртелгән хыяллар да аз түгел. Милли тарихны яктырту, милләтнең бүгенге хәлен кайгырту эзлекле рәвештә чагылыш тапкан шикелле, башка илләр, халыклар, аларның күренекле вәкилләре хакында ихтирам белән язылган материаллар да, кем әйтмешли, артыгы белән житәрлек.

Баштарак «Тәрҗеман» гәзите тәэсирендә «уртак тел» идеясе белән мавыгу, шуна күрә «корама телле» язмаларга урын бирү күзәтелсә дә, әдәби тел халык сөйләшенә якын булырга тиеш дигән караш журнал уздырган «Тел ярышы» нәтиҗәсендә җиңеп чыга. (Укучылар фикере буенча беренчелек Мәҗит Гафуриның саф татарча язылган хикәясенә бирелә.)



Актуаль иҗтимагый, гыйльми мәсьәләләрне редакция үзе күтәреп чыккан, махсус фикер алышу оештырган төсле җәмәгатьчелек куйган проблемалар да киннән яктыртыла; укучылар тарафыннан бирелгән вак-төяк сорауларга да журнал ихтирам белән мөмкин кадәр тулырак җавап бирергә тырыша. Тирән интеллектуаль хаҗәтләрне канәгатьләндерүгә хезмәт итә торган әсәрләр белән күршедә гапгади көнкүреш мәсьәләләренә, ырым-шырымнарга, гадәт-йолаларга кагылган язмалар да журналда мул урын алган һ.б.[1]

Кыскасы, тормыш һәм аның күренешләре, ихтыяҗлары, мәшәкатьләре никадәр күп төрле, бер үк вакытта һәм гади, һәм гаҗәп катлаулы булган шикелле, «Шура» журналының эчтәлеге дә, анда басылган материаллар да гадәти генә санап чыгуга бирелмәс дәрәҗәдә төрле-төрле, искитәрлек бай иде. Һәрхәлдә, бу басмага карата аны XX гасыр башы татар тормышының «энциклопедиясе» дип бәяләгән фикерләр хакыйкатьтән әллә ни ерак тормый.

Ниһаять, шуны да икеләнмичә әйтергә мөмкин: әдип, галим, фикер иясе, педагог, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддиннең бәхәссез бөеклеге гранит баганаларга тиң нигезләр өстендә торса, шул ныклы баганаларның берсе, һичшиксез, «Шура» журналы иде.

Кыскача гына тасвирланган шушы сыйфаты белән «Шура» журналы үзе чыгып торган елларда да, аннан соң да интеллектуаль җәмәгатьчелегебез игътибары үзәгендә булды. Хәтта тоталитар совет идеологиясе ажгырып торган елларда да татар галимнәренең (чын галимнәрнең, әлбәттә) аның белән кызыксынуы кимемәгән иде, дип икеләнмичә әйтергә мөмкин. Гәрчә, формаль «сыйнфыйлык» һәм «заман таләпләреннән» чыгып, сүздә, декларациядә журналны мөмкин кадәр ныграк тәнкыйть итү мәҗбүри булса да. Дөрес, аерым авторлар, аның «кинәш мәҗлесе» икәнлеген белмичә яки истән чыгарып, кайбер шәхси карашларга хас галәмәтләрне («Шура» әнә болай дип әйткән иде» рәвешендә) бөтен басманың тулаем сыйфаты кебек аңлау һәм аңлату белән чикләнсәләр дә. Шуңа күрә өлкән буын авторларыбыз арасында журнал материалларыннан адрес-фәләнен күрсәтмичә генә файдалану фактлары да аз булмады. Чөнки узып киткән гасыр башындагы иҗтимагый, мәдәни, рухи хәятыбызны яхшылап белергә, аңларга теләгән һәм теләүчеләр өчен «Шура» журналы бетмәс-төкәнмәс чыганаклар хәзинәлеге булып хезмәт итте һәм киләчәктә дә итәчәк.

Кыскасы, кайсы яктан килеп карасаң да, XX гасыр башында якты өметләр белән бер кабынып, гөрләп алган мәдәни тормышыбызның кабатланмас күренеше, хәтта үзенчәлекле тарихи көзгесе булган «Шура» журналын һәрьяклап һәм җентекләп өйрәнү, гадел бәясен бирү, аның эчтәлегеннән файдалану бүген дә безнең алда торган актуаль бурычларның берседер.

Киләчәктә дә шулай булуы шик тудырмый.

♣

[1] Журналның гомум эчтәлеге, эчтәлекнең никадәр төрлелеге, байлыгы, шулай ук аның өйрәнү юлында соңра барлыкка килгән коллизияләр белән киңрәк танышыр өчен карагыз: М. Г. Госманов, Р. Ф. Мәрданов. «Шура» журналының библиографик күрсәткече. – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2000. Ләкин иң әйбәте, әлбәттә, журналның үзен актарып чыгу.

# ИДЕОЛОГИЯ КОРБАНЫ

..Гражданнар сугышының кызган чоры. Шәһәрдә аклар хакимлек итә. Станциядә «үлем эшелоны» дип йөртелгән поезд тора. Менә вагоннарның берсеннән әйбәт кенә киемле кеше чыкты да, арлы-бирле йөренә башлады, күрәсең, һава суларга исәбе... Каяндыр килеп чыккан, сакчы солдат исә ана җикеренде: «Әй, гражданин, монда йөрергә, вагоннарга якын килергә ярамый, таегыз моннан!» Яшь кеше аптырабрак калды. Шунда вагон эченнән кемдер: «Фәтхи, җебеп торма. Тай тизрәк!»—дип кычкырды. Егет, әйтерсең лә, прогулкага чыккан сыман, кулларын артка куеп вокзалдан читкә атлады... Бер-ике атнадан ул инде иптәшләре Габдулла Кариев һәм Зәки Баязитский ярдәме белән фронт сызыгын яшерен генә үтеп, Сембер шәһәренә якынлашып килә иде...



Әйе, бу кеше—инде киң танылып баручы язучы Фәтхи Бурнаш була. Ә ни өчен аны «үлем эшелоны»на утыртканнар, аклар каршында аның гаебе нидә?.. Моны белү өчен үткәннәргә борылып карарга кирәк.

Фәтхи Бурнашның балалык һәм яшьлек еллары татарның күп кенә зыялыларыныкына ошаган. Сембер губернасының Буа өязендәге Бикшик авылы мулласы Закирга 11 балалы гаиләсен алып баруы бик авыр булса да, ул балаларын белемле итәргә тырыша. 1908 елда 9 яшьлек Фәтхине дә, энесе Вафаны да Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә урнаштыра. Әмма аларга матди яктан ярдәм итеп тора алмый, малайлар үз көннәрен үзләре күрәләр. Фәтхи җәйләрен Мәкәрҗә ярминкәсендә пешекче ярдәмчесе булып эшләп, үсә төшкәч казакъ далаларында балалар укытып, энесе белән икесе җан асрарлык акча эшли. Булачак язучының шәрекътәшләре Нәкый Исәнбәт белән Бакый Урманче аны гаять тырыш, укуга сәләтле шәкерт иде, дип язалар. Әдәбиятны бик тә яратуы, яшьтән үк иҗатка омтылуы, шәкертләрнең кульязма журналларында актив катнашуы, еш кына аларны оештыручы да булуы турында сөйлиләр.

Чыннан да ул—сәләтле була. Һәм моны иң башта Габдулла Кариев бәяли. Аны «Сәйяр» труппасына якынайта, әдәби иҗатка дәртләндерә. 1914 елда Фәтхи Бурнаш рус драматургы С. Найденовның «Ванюшин балалары» исемле драмасын тәрҗемә итә, «Сәйяр» аны сәхнәгә куя. 16 яшьлек шәкерт өчен бу зур җиңү була. Беренче уңыш белән канатланган егет шул ук елны «Язмыш» исемле драмасын, 1915 елны «Сукбай», 1916 елны «Саташкан кыз» дип аталган пьесаларын яза. Аларны Габдулла Кариев бер-бер артлы сәхнәгә куя тора. Моннан тыш яшь автор үзен шигърият өлкәсендә дә таныта. 1914—1916 еллар эчендә Фәтхи Бурнаш дистәгә якын поэма иҗат итә. Алар һәм тагын берничә шигырь «Аң», «Балалар дөньясы» дигән журналларда басыла.

Фәтхи Бурнашның тәүге драмалары ук инде аның заман проблемаларына бик тә сизгер булуы турында сөйли. Аларда, бигрәк тә «Язмыш» драмасында, җәмгыятьтәге социаль тигезсезлек өчен борчылу, аны тәнкыйть итү, хатын-кызның гаиләдәге хокуксызлыгына көенү, Беренче империалистик сугышка каршы булу, аның гади халыкка бары тик бәла-каза, авырлыклар гына китерүен фаш итү кебек мәсьәләләр күтәрелә. Бу әсәрләр яшь авторның драманы уңышлы үзләштерә баруын да күрсәтәләр.

Шулай да Ф. Бурнашның бу елларда иҗат иткән әсәрләре арасында поэмалары

унай якка аерылып торалар. Нәкый ага Исәнбәт язучының 70 еллыгына багышланган җыелыштагы чыгышында нәкъ менә шул поэмаларны үз заманы өчен ин уңышлы әсәрләр, Ф. Бурнаш шигъриятенең көчен тулы билгеләүче иҗат җимешләре дип атаган иде. Чыннан да, «Авылда», «Дулкыннар арасында», «Казакъ кызы», «Коркыт», «Шәрекъ кызы», «Айсылу», «Габделмән», «Вакытсыз үлгән апама» кебек поэмаларда авторның шигъри таланты ачык чагыла. Аларның беренчеләрендә дини мотивлар өстенлек ала, гади халыкның рухын мөселманлык тойгылары белән бәйләп чагылдыру үзәктә тора. «Айсылу» поэмасында, мәсәлән, бала вакытында үз милләтеннән көчләп аерылган кызның чит-ятлар тарафыннан тәрбияләнүе сурәтләнә. Ана мул, зиннәтле тормыш булдырылган. Әмма кыз мондый тормыштан канәгать түгел, аның күңеле үз диненә, үз милләтенә тартыла. Ахыр чиктә кыз качып китә, үз милләтенә, үз халкына кайта. Монда билгеле, аның белән дини тойгылар идарә итә, героинянын рухи дөньясындагы үзәкне мөселман диненең көче билгели.

Үз халкына тугрылыклы булырга өндәү, азатлык өчен көрәш мотивлары бигрәк тә «Габделмән» поэмасында ачык куелган. Ханлык баскынчылар тарафыннан яулап алынгач, халыкның бер өлеше урман-далаларга кача, азатлык өчен тинсез көрәшен дәвам иттерә. Сугышчылар арасында хан нәселеннән булган Габделмән дә бар. Ләкин ул тора-бара качкын тормышыннан туя, ризасызлык белдерә башлый, көрәштәшләрен баскынчыларга бирелергә, тыныч тормышка күчәргә өнди. Иптәшләре аның сүзләрен нәфрәтләнеп кире каккач, ул качып китә, дошманына бирелә. Ана зиннәтле тормыш булдырыла, рәхәт, кайгысыз яшәргә уңайлыклар тудырыла. Ул үз милләттәшләрен кыерсыта, каһәрли. Ләкин хыянәтченең бу тормышы озакка бармый. Элегрәк аның тарафыннан мыскылланган кыз аны чәнчеп үтерә. Шулай итеп шагыйрь авыр, әмма ирекле тормышны зиннәтләргә чумган кол тормышыннан өстен куя. Алга узып, шунысын да әйтергә кирәк. Бу темага, ягъни милли азатлык темасына, Ф. Бурнаш совет чорында да әйләнеп кайта. 1927 елда язган «Мөкаррәмә» поэмасында ул бик оригиналь төстә тыныч тормышта яшәп яткан горур черкес халкына патша гаскәрләренең һөҗүмен, ике арадагы тигезсез көрәшне сурәтли. Яулап алынып, мөстәкыйльлеген югалткач та тау халкы баш ими, горурлыгын җуймый. Мәсәлән, патша яугирләре җиңү шатлыгын бәйрәм иткәндә черкесләрнең горур бер вәкиле—чибәр кыз Мөкаррәмә—әмергә буйсынган булып бию биегәндә, ак патшаның полковнигын хәнҗәр белән чәнчеп үтерә һәм тауларга кача.

1917 елда Фәтхи Бурнаш үз исемен киң таныткан ике әсәр иҗат итә. Болар—«Таһир-Зөһрә» трагедиясе һәм «Яшь йөрәкләр» комедиясе. Язучыны соңгы елларда биләгән сораулар инде боларда чын, тулы яңгыраш ала. Алар—иҗтимагый тигезсезлек, гади халыкның авыр хәле, намуслы хезмәтнең тормыштагы роле, саф хисләрнең, аерата мәхәббәтнең кеше язмышындагы урыны... Иң мөһиме шунда: инде бу проблемаларны хәл итүнең юлларын эзләп, яшь автор Февраль һәм Октябрь вакыйгалары арасында сыйнфый көрәш позициясенә килеп чыга. 1917 ел башларында тотынып бер елдан тәмамланган трагедиядә Таһирның хан хакимиятенә каршы, әмма мәхәббәте өчен генә алып барган көрәше әсәр ахырына таба киң гуманистик яңгыраш ала. Соңгы күренешләрдә инде Таһир ханның йөзенә бәреп ачыктан-ачык революцион сүзләр сөйли:

*Канлы куллар! Әйдә, абруйсызлар,*
*Менә инсан—корбан итегез.*
*Ләкин табылыр миннән көчлерәкләр,*
*Тар-мар килер алтын тәхетегез.*
*Нәләт сезгә! Нәләт сарайларга,*
*Сарайдагы тәхеткә!..*
*Җәллад! Бетәсез сез! Кибәсез сез!*
*Хаклык кына якын бәхеткә...,—ди ул.*

Бу сүзләр батыр Таһирныкы булудан, бигрәк Октябрь күтәрелеше алдыннан

илдәге революцион ситуацияне үз күзләре белән күргән, аны күнеле белән кичергән авторның сүзләре икәнен аңлау кыен түгел. Димәк, Фәтхи Бурнаш традицион сюжет кысасы мөмкинлек биргән күләмдә азатлык көрәшен чагылдыра. Галимҗан Ибраһимов трагедиягә шул ноктадан торып бәя бирә дә: «Бу куәтнең үзен кин дөньяга таныткан әсәрләре («Таһир-Зөһрә» һәм революцион поэмалар) пролетариат хәрәкәтенең көчле дулкыннары астында, шулар тәэсире белән чыкты»,—дип яза ул *(«Татарстан хәбәрләре», 1922 ел, 7 февраль).*

Шул ук вакыт аралыгында, дөресрәге Октябрь инкыйлабы көннәрендә иҗат ителеп, 1918 елның башында ук сәхнәгә куелган «Яшь йөрәкләр» әсәрендә сыйнфый идеология инде тагын да ачыграк, үтемлерәк төс ала. Аның геройлары Галимҗан һәм Сәйфетдин байларга каршы революцион сүзләр сөйләп кенә калмыйлар, ә үз мәнфәгатьләрен кулларына мылтык тотып яклыйлар. Авыл яшьләре образларын, гади халык тормышын җанлы итеп сурәтләгән, «...татар драма әдәбиятында «Галиябану»ның революционерланган бер иптәше» (Габдерахман Сәгъди сүзләре) дип бәяләнгән комедия аның авторының революцион рух белән торган саен ныграк сугарыла баруын бик ачык чагылдыра.

Бу ике әсәрнең идея-эстетик әһәмияте шунда: алар милли әдәбиятның яңа дәвергә күчеп баруы чорындагы маяклар булып торалар. Монда Фәтхи Бурнаш— беренчеләрдән. Хәйретдин һәм Сәйфулла образлары гади халыкны яратырга, аның акылын һәм көчен танырга өйрәтәләр, Таһирның тигезсез көрәшен күрү тамашачы һәм укучы күңелендә гади халыкны изүчеләргә карата нәфрәт хисе тәрбияли.

Бүген советлар хакимлек иткән чор турында сүз йөрткәндә ул чордагы уңышлардан бигрәк кимчелекләрне алга куеп сөйләү бар. Ләкин, ни генә әйтмә, ул чорда күп кенә өлкәләрдә бик зур уңышларга да ирешелде. Шуны без әдәбият һәм сәнгатьтә дә күзәтәбез. Бигрәк тә беренче унъеллыклар бу яктан аерылып тора. Коммунистлар идеологиясенең тискәре басымы никадәр көчле булмасын, халыкның сәнгати дөньясына күп казанышлар өстәлде. Бу казанышларга ирешүдә үзләренең талант көчен салган шәхесләрнең иҗаты турында без сокланып сөйлибез, сөйләргә тиешбез. Шундыйлар арасында Фәтхи Бурнаш иң алдынгы урыннарның берсен били. Без аны татар совет әдәбиятын һәм журналистикасын барлыкка китергән, аларның беренче буразналарын сызышкан шәхес буларак тәкъдир итәбез.

Октябрь инкыйлабында большевиклар алга сөргән лозунгларга—милләтләргә тигезлек, җир крестьяннарга, завод-фабрикалар эшчеләргә, канкойгыч сугышны кичекмәстән туктатырга дигән сүзләргә—Ф. Бурнаш чын күңеленнән ышана, яңа тәртипләр урнаштыруга бөтен яшьлек дәрте белән ярдәм итә башлый. Ныклы мәдрәсә белеме һәм үзлегеннән әзерләнеп «Учительская школа»да аттестат алган, каләме үткен булган егетне яңа хакимият тиз күреп ала. Аны РКП(б) ның Сембер губерна комитеты каршында 1918 елның апрелендә чыга башлаган «Көн» исемле гәзиткә редактор итеп билгелиләр. Газетаны оештыруда һәм аның эшен җанлы итеп алып баруда Ф. Бурнаш зур дәрт, осталык һәм активлык күрсәтә. Газетадагы мәкаләләрендә, шигырьләрендә, публицистик язмаларында ул большевиклар идеологиясен нык яклый, шәһәрдә аңлату эше алып баручыларның, һәртөрле мәдәни-агитацион чараларны уздыручыларның иң күренеклеләреннән берсе була. Шәһәрне ак чехлар басып алгач Ф. Бурнаш Уфага кача, ләкин анда аклар кулына төшә. Менә шулай итеп, өч аен төрмәдә уздыргач, ул «үлем эшелоны»на эләгә, Себергә озатыла. Бәхетенә, алда күреп узганыбызча, юлда качу мөмкинлеге туа һәм ул азат ителгән Сембергә кайта, гәзитне «Таң» исеме белән яңадан аякка бастыра. Аның битләрендә язучының үткен сәяси мәкаләләре, шигырьләре, хикәяләре һәм фельетоннары тагын да ешрак күренә. Иҗат эше белән бергә ул халыкны агарту максаты белән еш куела торган концерт-спектакльләр алдыннан чыгышлар ясый, сәяси темаларга лекцияләр укый. Редакторлык эше белән рәттән ана губернада мәгариф эшләрен юлга салу буенча да күп көч сарыф итәргә туры килә. Аның татар теле орфографиясен эшләү буенча Казанда уздырылган фәнни конференциядә катнашуы, төрле курсларда укытуы һ. б. билгеле. 1919 елның 18 апрелендә ул Коммунистлар партиясенә керә.

1918 елның октябреннән Казанда Үзәк Мөселман Хәрби Коллегиясе каршында

ул чордагы иң популяр, киң тарала торган (аның тиражы кайвакыт 30 меңгә житә!) «Кызыл Армия» исемле газета чыга. Оештыру сәләте, көнүзәк темаларга язылган шигырь-поэмалары һәм фельетоннары, ялкынлы публицистик мәкаләләре белән танылган Ф. Бурнаш шуңа редактор итеп чакырыла. Коллегиянең политбүлек башлыгы булып эшләүче Шамил Усманов бу хакта аңа бер-бер артлы телеграммалар суга. Һәм Ф. Бурнаш—1920 елның 11 маеннан бу газетаның редакторы.

Боларның һәммәсе өстенә Ф. Бурнаш әдәби ижатын да һич тә киметми. Ул яна шигырьләр, хәтта зур күләмле әсәрләр язарга да вакыт таба. Мәсәлән, 1919 елда, ягъни бер ел эчендә генә дә, ул 9 поэма яза («Чәчәктән һәйкәл», «Гөлчәчәк», «Сахра каны», «Кичке теләк», «Качкын караванчылар», «Ак каен», «Әҗәл», «Тан алдында», «Икеләнмә»). Ф. Бурнаш шигъриятенең көчен дә беренчеләрдән булып Г. Ибраһимов билгели. Поэмалары турында сөйләгәндә, ул «шагыйрьнең бай хыялын, көчле, табигый агымлы телен, су агышы кебек рәхәт, көчәнмичә язуын» күрсәтеп уза *(«Эшче», 1920 ел, 106 сан).* Һәм шунда ук, революция һәм гражданнар сугышы елларында әдәбият мәйданына чыккан яшь язучылар турында сүз алып барып, «яңа исемнәрнең иң көчлесе, шөбһәсез, Фәтхи Бурнаш иде», дип йомгаклап куя.

Фәтхи Бурнашның журналистлык эшчәнлеге дә үз чорында ук югары бәяләнә. «Известия ТатЦИКа» газите татар партия-совет матбугатының бишьеллыгы унае белән 1923 елның 5 маенда чыгарган «Фабрика печатного слова» исемле кушымтасында: «Ип. Бурнашев хәзер дә татар журналистлары арасында беренче урынны алып тора»,—дип яза. Бу аның «Көн» («Тан»), «Кызыл Армия», (соңрак «Татарстан»), «Безнең байрак» газеталарының редакторы буларак эшчәнлеген бәяләү иде. Аннары Ф. Бурнаш—«Безнең юл» журналының редакторларыннан берсе. Ул «Кызыл дәфтәр» һәм «Чаян» журналларын да оештыра (соңгысына исемне дә ул уйлап таба), аларның редакторы, ә егерменче елларның ахырларында «Татар дәүләт академия театры» исемле «мәҗмуга-программа»ның оештыручысы һәм редакторы була. Актив партия һәм җәмәгать эшлеклесе Фәтхи Бурнаш 1922 елда Татарстан Үзәк Башкарма комитеты әгъзасы итеп сайлана.

Яңа ижтимагый шартларга күчү дәверенең беренче елларында Ф. Бурнашның шигърияте алга чыга. Дистәләрчә поэмалардан тыш ул күп санда шигырьләр ижат итә. Яшь Совет дәүләтен ныгыту, эшче-крестьянның бергәләп яулап алган җиңүләрен саклап калу өчен көрәш—аның шигъриятендә төп тема («Әйдә», «Ярлыга», «Тагы да сәлам хатлар җибәрәм», «Ник болай?», «Ташламаска, бәгърем, сүзең бир», «Теләк, бүләкләр ул көтә», «Бар минем» һ. б.). Темасы белән яңа булган ул шигырьләрдә традицион поэзиядән килгән сурәтләү чаралары шактый өстенлек итә, шуның белән бергә абстракт өндәүләр, чакырулар, тасвирлаулар да урын алган. Аларда конкретлык житеп бетмәү исә ижат методы белән дә бәйле: аның шигърияте, нигездә, романтик шигърият. Шигырьләрдә гражданлык хисе көчле, шагыйрьнең үзәк герое үз рухының тар кысаларыннан үсеп чыга, үз язмышын бөтен халык язмышы белән тиңләп карый. Бу герой, иң элек лирик кичерешләре белән укучы күңеленә якын.

Шулай да Фәтхи Бурнаш язучы буларак, үзен күбрәк драматургиядә танытты. Ижат юлын ул пьеса белән башлаган иде, гомер юлын да сәхнә әдәбиятчысы булып узды. Гражданнар сугышы чорында шигъриятә активрак булса да, ул сәхнә әдәбиятын да онытмый. 20—30 елларда ул—сәхнә тоткан авторларыбызның берсе. Драматургиянең күп өлкәләрендә ул беренчеләрдән саналырга хаклы. Яңа темалар ачуда, жанр формаларын үзләштерүдә... Бездәге беренче тулы канлы трагедия—аныкы («Таһир-Зөһрә»), эпик пландагы халыкчан комедия—аныкы («Яшь йөрәкләр»). Совет чорында тарихи теманы үзләштерүдә дә беренче булып уңышка ул ирешә («Жирсезләр», соңгы исеме—«Хөсәен мирза»). Совет җәмгыяте шартларында яңа тормыш чаткыларын чагылдыруда аның «Камали карт» комедиясе (1925) юл яра. Монда бер әсәр кысаларында ике яссылыктагы геройлар, ике тенденция берләштерелгән. Бер якта—искелек символы төсендә гәүдәләндерелгән, ике хатынын җәберләүче, шактый ук азгын, яңалыкка дошман булган Камали картны фаш итү. Икенче якта—яңа тормышта ан-белемгә омтылган, укуга беренчелекне биргән, шәхси мәнфәгатьләрдән дә бигрәк җәмәгать эшләрен алга

куйган, шул жирлектә аталары белән каршылыкка кергән, гаилә төзүдә иске тәртипләрне танымаган һәм кире каккан яшьләр. Комедиядә сатирик юнәлеш белән янәшә раслаучы юнәлеш янәшә бара. Пьесаның сәхнәгә беренче куелышларына рецензия язган Гадел Кутуй аның иң әүвәл шул яктан мөһим булуын, театрыбыз сәнгатендә яңа юл яруын билгеләп уза *(«Кызыл Татарстан», 1925 ел, 6 декабрь).*

Ил тормышындагы яңа вакыйгаларга, совет рухы белән сугарылган геройларга багышланган пьесаларын Ф. Бурнаш егерменче елларда тагын да иҗат итә: «Хатирә апа», «Урам кызы» (1929) кебек пьесаларында авылда барган үзгәрешләр тасвирлана.

Гражданнар сугышы темасына милли драматургиядә иң башлап Шамил Усманов («Канлы көннәрдә») һәм Галимҗан Ибраһимов («Яңа кешеләр») мөрәҗәгать итте. Ф. Бурнаш алга таба бу теманы тирәнәйтте. Гражданнар сугышының кызган чорында ул мулла кызына мәхәббәте аркасында сыйнфый көрәштән читләшергә тырышып та, соңыннан кызыл көрәшчеләр сафына әйләнеп кайткан Габбасның рухи чайкалуларын сурәтли. Язучының үз сүзләре белән әйткәндә, «гражданнар сугышы чорында интеллигенциянең катлауланудың күрсәтергә» теләп, театрда уңыш казанган «Адашкан кыз» драмасын иҗат итә ул.

Бу темага багышланган әсәрләрдә күтәренке рух, хәтта урыны белән плакатчылык хакимлек итә. Аларның авторлары якты буяулар белән эш итәргә, гадәти булмаганрак хәлләрне сурәтләргә омтылалар, героиканы бирү өчен күзгә бәрелеп торган ситуацияләр сайлана. Болар «Адашкан кыз»ның беренче вариантына да ят түгел. Ә соңгы вариантта язучы революцион көрәш материалын гадирәк бирә. Әгәр дә беренче вариантта Ф. Бурнаш «гомуми, абстракт фикерләүләр» белән агитацияләсә, хәзер инде ул «фактлар белән агитацияләү» юлына баса. Чөнки, дип яза автор үзе, «театр һичбер хәлдә коры агитация урыны гына булып калырга тиеш түгел, ул бөек агитацион бурычларны үзенең специфик, сәнгатьчел чаралары белән үтәргә тиеш».

Гражданнар сугышы темасына Фәтхи Бурнаш кат-кат әйләнеп кайта. 1934 елда русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә чыккан «Театр народов СССР» исемле мәртәбәле, ил халыклары драматургиясендәге иң уңышлы әсәрләрдән тупланган җыентыкта басылган «Лачыннар» романтик драмасын, аннары Татар дәүләт академия театрына кабул ителеп тә, уйналмый калган «Таң» дип аталган тарихи драмасын яза. Боларда, рәсми идеология таләп иткәнчә, коммунист образлары үзәккә куеп тасвирлана. «Таң» әсәрендәге төп геройның прототибы Мулланур Вахитов булуын да әйтеп үтәргә кирәк.

Фәтхи Бурнаш—әдәбиятта һәм сәнгатьтә төп юнәлеш булган реализмны яклаган иҗатчылардан берсе. 1924 елда ул Ш. Усмановлар белән бергә «Октябрь» исемле әдәби күмәк оештыра, төп принцип итеп әдәбиятта һәм сәнгатьтә реализм булырга тиешлеген яклый. Егерменче елларның икенче яртысында имажинизм, футуризм кебек агымнарның вәкилләре Кави Нәҗми, Гадел Кутуйлар белән әдәбиятның кайсы юлдан барырга тиешлеге хакында ул иҗади бәхәсләр алып бара. Моның белән генә дә канәгатьләнми, футурист язучыларның сатирик типларын сурәтләгән, әдәби иҗатта пассивлыкны яклаган каләм әһелләреннән көлгән «Илһам» (1928) исемле сатирик комедия яза.

Утызынчы елларда илдә барган вакыйгаларны Ф. Бурнаш драма әсәрләрендә дә, шигъриятендә дә чагылдырып барырга омтыла. Боларның мөһимнәреннән берсе, мәгълүм ки, авыл хуҗалыгында алып барылган күмәк хуҗалык сәясәте. Әлбәттә инде, партия сәясәтенә һәрчак тугры булган Ф. Бурнаш үз әсәрләрендә колхозлашуны яклый, аның бары тик уңай якларын гына күрә. Сәнгатьчә эшләнешләре белән әсәрләр, нигездә,—югары сыйфатлы. Болар—«Олы юл белән», «Хат», «Ялгыз Ярулла» исемле драмалар, «Колхоз туе» дип аталган (әлеге әсәр беркадәр үзгәртелеп һәм башка фамилия астында XX гасырның икенче яртысына кадәр Г. Тукай исемендәге филармониянең җыр һәм бию ансамбле репертуарында урын алды) инсценировка, «Шатлык» исемле опера либреттосы, «Минлекәй белән Данбулат» поэмасы. Әсәрләр арасында идея-эстетик эшләнеше ягыннан «Ялгыз Ярулла» исемле, язучының репрессияләнүенә кадәр дөнья күргән соңгы пьесасы аерылып тора.

Илдәге сәнәгать өлкәсен җанландыру хәрәкәтенә дә Ф. Бурнаш битараф калмый, «Тукучы Әсма» дигән пьеса яза. Әсәр ул вакытларда еш кабатланган конфликтка— корткычлар белән көрәшкә нигезләнгән. Кызыклы ситуацияләрне, үзәк персонажның шәхес буларак өлгереп-үсеп баруын сурәтләве белән ул утызынчы еллар драматургиясенең казанышларыннан берсе дип саналырга хаклы.

Татар драматургиясенең советлар дәверендәге юлын уңай герой эзләү, шуны алга куеп эш итү характерлый. Андый герой итеп драматурглар җәмгыять интереслары хакына шәхси мәнфәгатьләреннән баш тарткан кешене күзаллыйлар. Җыйнап әйткәндә, ул—коммунист образы. Ш. Усманов һәм Г. Ибраһимовның алда аталган пьесаларында да, Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» драмасында да, К. Тинчуринның «Кандыр буе», Т. Гыйззәтнең барлык дип әйтерлек әсәрләрендә дә, Н. Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов», «Муса Җәлил», «Мәрьям» кебек драмаларында да, Риза Ишморат драматургиясендә дә шундый герой образлары үзәктә тора. Укучы һәм тамашачыны советчыл патриотизм рухында тәрбияләүдә аларның роле зур булды. Әмма, сәнгатьчәлек ноктасыннан караганда, алар әдәбиятның иң мөһим сыйфатларыннан берсе булган психологизмга зыян да салдылар. Чөнки андый герой җәмгыять һәм сыйнфый көрәш файдасына корбанга барганда эчке кичерешләргә тетрәнүләр белми. Белергә тиеш тә түгел, дип таләп ителә. Син коммунистмы?— бәс, шулай икән, уйланып-җебеп торма! Коммунизмга бару юлында икеләнүләр, рухи чайкалулар булырга тиеш түгел! Вәссәлам!

Фәтхи Бурнаш иҗаты да асылда шуның кебек геройларга нигезләнә. Таипов («Камали карт»), Латыйф («Адашкан кыз»), Хатирә («Хатирә апа»), Җәгъфәр һәм Хәтимә («Олы юл белән»), Гольман («Тукучы Әсма»), Сафаров («Лачыннар»), Таймасов («Таң»)—шундый геройлар. Хәтта крепостнойлык дәверен чагылдырган «Хөсәен мирза» драмасының төп герое Муса да шул рухта сурәтләнгән. Хуҗаларга каршы баш күтәргән крестьяннарның җитәкчесе булган егет бу юлда рухи чайкалулар кичерми, мәхәббәтеннән дә кискен төстә баш тарта,—аның өчен азатлык көрәше генә изге.

Шулай да сыйнфый азатлык һәм яңалык өчен көрәшкә килгәндә Ф. Бурнашның кайбер геройлары рухи үсеш кичерәләр. Габбас («Шәмсия»), алда әйтелгәнчә, кызыл партизаннар сафына яңадан кайтканчыга кадәр мәхәббәте белән тартыша. Хәдичә («Адашкан кыз»), сыйнфый көрәш уртасында калып, мәхәббәтен югалта, рухи газаплардан җәфалана. Әсма («Тукучы Әсма») шәхси тормышында хаталану-ялгышулар аша хезмәтнең бөеклеген тануга килә, шәхси бәхетен дә таба. Каракыз («Лачыннар») һәм Зәйтүнә («Таң») мәхәббәтләрендә ялгышулар кичереп, сыйнфый көрәшнең изгелегенә инаналар. Ярулла («Ялгыз Ярулла») күмәк хуҗалыкта булу яхшыракмы, әллә ялгыз хуҗалык корып яшәү кулайракмы, дигән сорауларны хәл итә алмыйча озак кына баш вата, кичерешләр эчендә яши. Шулай итеп, Фәтхи Бурнаш драматургиясе социалистик җәмгыятькә күчү процессының ансат кына бармавын, кешеләрнең бу юлда һәртөрле рухи чайкалулар кичерүен шактый тулы тасвирлый.

Иҗади үсеш юлы асылда драматургия буенча барса да, Фәтхи Бурнаш шигърияткә дә тугрылык саклый. Дөрес, аның шигъри иҗатының иң күтәренке чоры революцияләр һәм гражданнар сугышы чорына туры килә. Шулай да ул 20-30 елларда да күп санда поэмалар («Мазлума», «Мөкәррәмә», «Бохара» һ. б.) һәм шигырьләр яза. Аны Әхмәт Фәйзи шулай характерлый да: «Ул—даими әдәбият эшчесе, даими көрәшче иде. Вакытлы метеор түгел, һәрвакыт янып тора торган йолдыз иде. Чын шагыйрь, драматург буларак та шагыйрь иде». Илдә барган, урыны белән күренекле дә булган, вакыты белән фаҗигале дә, халыкка авырлык та китергән вакыйгалар—Совет дәүләтенең җитәкчесе В. И. Ленинның үлеме, колхозлар төзелү, фабрика-заводлардагы уңышлар, Төньяк котыпны яулау, халыклар дуслыгын ныгыту өлкәсендәге казанышлар һ. б.лар аның шигырьләрендә чагылыш таба. Шагыйрь күренекле шәхесләр турында, алар белән бәйле хәлләрне чагылдырып әсәрләр яза (Г. Кариев, М. Гафури, С. М. Киров, Максим Горький һ. б.ның үлеме, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтов, Н. А. Островскийларга һ. б. бәйле даталар уңае белән). Ф. Бурнаш—татар шигъриятендә «Ватан» исемле

беренче оратория, «Кызыл команда», «Колхозчылар маршы», «Колонналар» кебек маршлар иҗат иткән автор.

Ул—тәрҗемә өлкәсендә дә зур уңышларга ирешкән язучы. Аның татар теле байлыкларын бөтен нечкәлекләренә хәтле белүе А. С. Пушкин, Л. Н. Толстой, И. С. Тургенев, М. Горький кебек бөек язучыларның ул тәрҗемә иткән әсәрләрендә яхшы күренә («Евгений Онегин», «Хаҗи Морат», «Аталар һәм балалар», «Ана» һ. б.).

Язучының һәртөрле яңалыкны тиз күрә һәм яклый белүе тагын да бер өлкәдә—опера өлкәсендә күренә. 1934 елда, татар операсына кадрлар хәзерләү өчен Мәскәү консерваториясе каршында махсус студия ачыла һәм, репертуар булдыру максаты белән студиянең әдәби секторы төзелеп, аны җитәкләү эше Ф. Бурнаш белән М. Җәлилгә тапшырыла. Ф. Бурнаш милли опералар өчен оригиналь либреттолар тудыру белән шөгыльләнә, ә М. Җәлил либреттоларны башка телләрдән тәрҗемә иттерү һәм артистларны җыр текстлары белән тәэмин итү турында кайгырта. Архивлардагы күп санлы документлар аларның бу өлкәдә шактый хезмәт куюлары турында сөйли. Ике-өч ел эчендә әдәби сектор портфелендә ике дистәләп оригиналь һәм күп санлы тәрҗемә либреттолар туплана. Алар алга таба татар операсы һәм балетының беренче күренекле әсәрләре («Качкын», «Алтынчәч», «Шүрәле») барлыкка килүгә нигез булалар.

Ф. Бурнаш, бу яңа эшкә бөтен күңелен бирә, үзе дә либреттолар иҗат итә. Әлбәттә, тәҗрибәсезлек аркасында баштарак либреттолар схематик, кызыксыз чыгалар. Мәсәлән, ул, камилләштерә-камилләштерә «Таһир-Зөһрә»нең алты вариантын иҗат итә. 1938 елның 28 декабрендә М. Җәлилгә җибәргән хатында: «Таһир-Зөһрә»не бик тырышып, озак һәм күп эшләремә, авыру-саулыгыма зарар итеп булса да, бирелеп эшләдем—укыган кешеләр бик яраттылар»,—дип яза. Ул тагын да «Яшь йөрәкләр», «Лачыннар», «Шатлык», «Колхоз туе» кебек зур күләмле, «Югалган шатлык» исемле бер пәрдәлек опера либреттолары иҗат итә. Аларның кайберләренә Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин кебек композиторлар музыка яза башлыйлар. Әмма бу эшләр ярты юлда өзелеп кала—Некрасовның «Рус илендә яшәү кемгә рәхәт» исемле поэмасын тәрҗемә итеп утырган язучыны 1940 елның 24 августында кулга алалар. Солтангалиевчелектә, башка төрле «дошман» эшләрдә («ханнарны, князьларне, сарай һәм мәчетләрне мактап җырлаган» һ. б.) гаепләп аны 10 елга лагерьга җибәрергә хөкем итәләр. Самара шәһәре янындагы «Безымянлаг» (безымянный лагерь) дип аталган лагерьда Ф. Бурнашның эзләре югала...

Хрущёв «җепшеклеге» башлангач, 1956 елда, туганнары аны реабилитацияләү турында гариза бирәләр, аларга шундый рәсми җавап килә: «Ф. Бурнаш 1942 елны кабат хөкемгә тартылды һәм 10 елга ирегеннән мәхрүм ителде. Ул 1946 елның 1 августында үпкә авыруыннан үлде». Ф. Бурнаш турындагы китапларга, фәнни хезмәтләргә шушы дата кереп китә.

Әмма монда да ялган икән! Дөресендә Фәтхи Бурнашның гомере нәкъ 4 ел алданрак, 1942 елның 1 августында өзелгәнлеге мәгълүм булды. Һәм ул һич тә авырып үлмәгән, ә «сугыш вакытында советларга каршы агитация һәм пропаганда алып барганы өчен» дигән нахак гаепләү тагылып, атып үтерелгән...

Шулай итеп, татар совет әдәбиятын һәм журналистикасын оештыручылардан берсе, анда беренче буразналарны сызып, үзенчәлекле әсәрләр иҗат иткән, татар театры тарихында сизелерлек эз калдырган Фәтхи Бурнаш үзе гомере буе инанып һәм бирелеп хезмәт иткән идеологиянең үкенечле корбаннарыннан берсе булды...

**Азат ӘХМӘДУЛЛИН**

♣

# «Татар энциклопедиясе» битләреннән

# Г

**ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН** Нур Габделхәй улы (12.7.1928, Актаныш р-ны, Яңа Байсар а.-22.6.2004, Казан, күмелде Арча р-ны кушлавыч), әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1953). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1952-90 елларда СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына, 1920-40 еллар прозасына, К.Нәҗми иҗатына карый. К.Нәҗми (т. 1-4, 1958-60; т.1-4, 1981-84) әсәрләрен басмага әзерләүдә катнаша. Г. - «Татар совет әдәбияты тарихы» («История татарской советской литературы», М., 1965), «Күпмилләтле совет әдәбияты тарихы» («История советской многонациональной литературы», т. 2, 4, М., 1971-73), «Татар әдәбияты тарихы» (т. 4, 5, 1988-89) фәнни хезмәтләренең аерым бүлекләре авторы.

Әсәр.: Кави Нәҗми. К., 1957; Әдәбият белеме сүзлеге / Төз. Н.Гыйззәтуллин. К., 1958; Әдәбият баскычлары. К., 1976 (автордаш).

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

**ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН** Рафис Әхәт улы (8.3.1955, Сарман р-ны Урта Кәшер а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1993). Казан педагогия ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), республикада чыга торган вакытлы матбугат редакцияләрендә эшли. 1994-97 дә «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында баш мөхәррир. 2000 нән ТР ФА нең Татар энциклопедиясе ин-тында. Балалар өчен «Очучы буласым килә» (1984), «Урман юлы» (1987), «Көтелмәгән сорау» (1990) исемле хикәя җыентыклары авторы. Аларда мажаралы хәлләр балаларга аңлаешлы, гади телдә, матур итеп сурәтләнгән. Геройларының бай күңел дөньясын Г. «Кырау» (1996), «Багалмада кунакта» (1996), «Төнге яңгыр» (2001) дип аталган хикәя җыентыкларында да ачып бирә. Г. шулай ук татар әдәбияты һәм сәнгатенә караган әдәби-тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләр, татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре турында очерклар авторы да.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА** Флёра Сабиржан кызы (6.9.1931, Азнакай р-ны Әсәй а.), шагыйрә, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). 1980 елдан Казан шәһәрендә. Беренче шигырьләре район һәм республика газета-журналларында, «Беренче карлыгачлар» (1968), «Юл башы» (1972) исемле күмәк җыентыкларда басыла. «Чишмә юлы» (1974), «Сәлам хаты» (1981), «Акчарлагым - асыл кошым» (1983), «Утлы минутлар» (1986), «Сер ачкычым - сердәштә» (1990), «Яшеннәрнең күз яше» (1995), «Йөрәгемдә шаулый карурман» (2001), «Башкаемда дөнья исәпләре» (2007) шигъри җыентыклары белән Г. укучы күңелендә нечкә хисле лирик, романтик шагыйрә буларак тәэсир калдыра. Аның шигъриятенә тормыш вакыйгаларын табигый, самими хис-тойгылар аша сурәтләү хас. Кайбер шигырьләре көйгә салынып, популяр җырларга әверелде.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙЛӘҖЕВ** Аяз Мирсәет улы 17.1.1928, Сарман р-ны Чукмарлы а. - 13.3.2002, Казан), язучы, ТАССРның, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978,1985), ТРның халык язучысы (1993). 1948 елда Казан ун-тына укырга керә. 1950 дә «советларга каршы пропаганда өчен» хөкем ителә. Ирекка чыкканнан соң (1955) университетта укуын дәвам итә. 1957-61 дә «Чаян», «Азат хатын» ж-лларында әдәби хезмәткәр, «Совет әдәбияты» ж-лының проза бүлегендә мөхәррир булып эшли. 1963 тә М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курсларны тәмамлый (Мәскәү). Г. таланты бигрәк тә проза жанрында ачыла. Аның авыл прозасы татар халкы тормышында булган кискен борылышларны чагылдыруның ачык мисалы. Үзенең беренче хикәяләрендә үк («Рәтле кешеләр» җыентыгы, 1959) Г. шәхес характерын билгеләүдә әхлак принципларына өстенлек бирә. Бу язучы иҗатында төп тема. 1950-60 елларда иҗат иткән әсәрләрендә Г. әхлаклылык кына кешене бәхетле итә ала дигән гомумкешелек принципларыннан чыгып эш итә. «Дүртәү» (1958) повестында әхлаклылык идеалы булып шәхси бурычны үтәү хисе торса, «Өч аршын җир» (1963; рус теленә тәрҗемәсе «Три аршина земли», М., 1966; 1987 дә Татар акад. т-рында сәхнәләштерелде) повестында - туган җиргә тугрылык. «Бер әү» (1958), «Качак» (1959), «Зәй энҗеләре» (1963) повестьлары һәм «Урманнар артында яшел болын» (1969; рус теленә тәрҗемәсе «Диляра», М., 1973) романында автор совет җәмгыяте кануннарын тәнкыйть күзлегеннән карый һәм кешенең әхлакый

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

йөзе югала баруын күрсәтә. «Урталыкта» (1969) повесте белән язучы «нык үскән социализм» дәверенең совет чынбарлыгы картинасын тудыра, кешенең нилектән конформизмга һәм әхлакый яктан түбәнәя баруга китергән сәбәпләрне эзләргә тырыша. «Җомга көн кич белән» (1979) повестенда этик проблемаларны, шәхес җаваплылыгы, хатын-кызның үзен аямау проблемаларын күтәрә. Авыл тормышын сурәтләгәндә Г. халыкның милли традицияләренә таянса, шәһәр тематикасын яктырткан «Күзгә - күз» (1975), «Мең чакрым юл» (1978) әсәрләрендә мәдәни, интеллектуаль традицияләргә басым ясый, кешенең үз гамәлләренә бәя бирү мәсьәләләрен кискен куя. 1970 еллардагы иҗаты иҗтимагый-фәлсәфи проблемалар, халыкның рухи кыйммәтләрен яңартуны күтәрүе б-н үзенчәлекле. Аларда өлкән буын вәкилләре образлары идеаль герой төсе ала. «Әтәч менгән киртәгә» (1980) повестеның төп герое аркылы , кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә югары әхлак нормаларын чагылдырган автор идеалы гәүдәләндерелә. Әдипнең 1980-90 еллар прозасы татар әдәбиятында үрнәк булып торырлык әсәрләр. А.Литвин белән берлектә язылган «Алтынчы августка кадәр:» (1986-87) роман-хроникасы Идел буенда гражданнар сугышы турында, ул үзенең сурәтләү алымнары белән дә, жанры белән дә аерыла. 1980 нән Г. аерым шәхесләргә, хәзерге җәмгыятькә әхлакый бәя бирүгә, социаль- психологик анализ ясауга зур игътибар юнәлтә. «Яра» (1981-88) повестенда автор шәхескә өстенлек бирелгән шундый җәмгыятьнең әхлакый кыйммәтен ачарга омтыла. «Балта кем кулында» (1988-89) романы белән тоталитар режим шартларында әдәпле, акыллы фикерле, ирекле эш итәргә теләгән интеллигентның фаҗигасен күрсәтә. «Йәгез, бер дога!» (1995) роман-истәлекләре - Г.нең күпьеллык иҗади эзләнүләренең үзенчәлекле нәтиҗәсе. Анда төрмә тормышы, тоткыннарның хокуксызлыгы турында сүз бара, Сталин режимына карата кырыс хөкем чыгарыла. Драматургиясенә татар халкы тормышында булган катлаулы үзгәрешләрнең мәгънәсен аңлатып бирергә, аларны фәлсәфи күзлектән чыгып бәяләүгә омтылу хас. Татар акад. т-рында куелган «Көзге ачы җилләрдә» (1961 дә сәхнәләштерелә), «Әңгер-меңгер» (1971 дә сәхнәләштерелә), «Югалган көн» (1976 да сәхнәләштерелә), «Китмәгез, тургайлар» (1978 дә сәхнәләштерелә) драмаларында җәмгыять төзелеше һәм әхлак нигезләре, кешенең рухи байлыклары арасындагы үзара бәйләнешләр сурәтләнә. Кеше гамәлләренең тискәре ягы «Сары чәчәк ата көнбагыш» (1974 тә сәхнәләштерелә), «Я кайтырбыз, я кайтмабыз» (1975 тә сәхнәләштерелә) тарихи драмаларында да кискен куела. Г.Тукай исем. ТАССР Дәүләт премиясе (1983) һәм А.М.Горький исем. РСФСР дәүләт премиясе (1987) лауреаты.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 4 томда.К., 1993-94; Күңелем серләре: куен дәфтәреннән // Казан утлары. 2000. №11-12.

Әд.: Миңнуллин Ф. Балта явызлар кулында. К., 1994; Сәхапов Ә. Кырыс чынбарлык.К., 1995; Ахунов Г. Язмыш яздырган кыйсса // Мәдәни җомга. 1996. 9 февр.; шул ук автор. Язучы һәм заман // Казан утлары. 1998. №1.

**ГЫЙЛӘҖЕВ** Илдус Сабир улы (15.1.1946, Азнакай р-ны Урсай а.), шагыйрь, авыл хуҗалыгы оешмасы җитәкчесе, ТРның атказ. авыл хуҗалыгы хезмәткәре (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1976 елдан Азнакай р-ны пр-тиелләрендә: «Ленин юлы» (1976-81), «Коммунизмга» (1981-90) к-злары рәисе, «Актүбәнефть» нефть-газ чыгару идарәсе җитәкчесе урынбасары (1992-94), «Татнефть» АҖнең «Никитинский» с-зы директоры (1999 дан «Туйкә» авыл хуҗалыгы кооперативы рәисе). Г.нең шигырьләре публицистик рухта, гражданлык хисләре туган җиргә, аның кешеләренә мәхәббәт б-н сугарылган («Җир китабы», 1988; «Җилкенү», 1990; «Өмет ае», 1993; «Серле мәгарә», 1995; «Хак сүз», 2000; «Чатыртау тылсымы», 2001; «Яратканга күрә», 2006 җыентыклары). «Почёт Билгесе» ордены б-н бүләкләнә. 1985-90 да ТАССР ЮС депутаты.

Әд.: Вәлиев М. Шигырь эшкә барамы? // Каһарманнар кирәк. К., 1990.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙЛӘҖЕВ** Мансур Аяз улы (29.1.1961, Казан), драматург. Рус телендә яза. Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1983). Аның пьесалары буенча Татар академ. т-рында куелган «Бичура» (1989), «Казан егетләре» (1990), «Тагын казан егетләре» (1994), «Баскетболист» (2002) спектакльләре Г.кә уңыш китерде. Пьесалары тупланган «Лунные врата» (1990), «Словарь любви» (2005) җыентыклар, Ч.Айтматовның «Плаха» («Ахырзаман», 1987 дә сәхнәләштерелде) әсәре буенча инсценировка авторы.

Әсәр.: Бичура. К., 2001.

**ГЫЙЛЬМАНОВ** Галимҗан Хәмитҗан улы (1.2.1957, Башкортстан АССРның Дүртөйле р-ны Әсән а.), язучы, әдәби тәнкыйтьче. Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1982-86 да Казан ун-тында укыта. 1986-99 да (өзеклек б-н) Татарстан китап нәшриятында: мөхәррир, 1990 нан балалар-яшүсмерләр әдәбияте редакциясе мөдире. 1999-2005тә ТРның Язучылар берлеге идарәсендә оештыру эшләре буенча рәис урынбасары. 2005тән ТРсы Министрлар кабинеты Аппаратының мәдәният һәм Татарстан халыклары телләрен

үстерү бүлеге баш консультанты. Татар балладаларын өйрәнүгә багышланган «Татарская баллада» (1989), татар әдәбиятына караган тәнкыйть мәкаләләрен берләштергән «Заман сүз сорый» (1991) исемле китаплар, хәзерге татар авылы тормышын чагылдырган «Тозлы яңгыр» (1993) исемле повесть-хикәяләр, «Күңел сурәте» (2003) шигырь җыентыгы авторы. Ш.Бабичның «Зәңгәр җырлар» (1990) һәм «Татар мифлары» (1-2 т., 1996-99) җыентыкларын төзүче. Шигырьләре һәм пьесалары тупланган «Йөгерек гөрләвек» (1998), «Әбием сихерче бугай» (1999), «Көмеш тарак» (2000) китаплары балаларга багышланган. Үзенең «Албастылар» (2001), «Китек ай» (2005), «Оча торган кешеләр» (2007) җыентыкларына тупланган повесть һәм романнары б-н татар прозасында модернистик юнәлештә иҗат итүче язучы булып танылды.

Әд.: Гарифуллин В. Мин - шагыйрь җанлы прозаик // Мәгърифәт. 1994. 5 февр.; Заһидуллина Д. «Албастылар» яки татар прозасында яңа сыйфатлар // Казан утлары. 2001. N11.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГЫЙЛЬМИ** (Гыйльманов) Ләбиб Гыйльман улы (12.6.1906, Самара губ., Бөгелмә өязе Иске Баграҗ а. - 9.5.1938, Казан), язучы. 1923 елда партия мәктәбенә укырга керә (Чистай ш.). 1928-30, 1932-34 тә ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетында эшли (1932 дән 2 нче секретарь). 1930-32 дә Улан-Баторда Монголия рев. яшьләр союзында киңәшче булып тора. 1935-37 дә «Яшь ленинчы» г-тасы, «Пионер каләме» ж-лы җаваплы сәркәтибе, 1937 дә ТАССР Язучылар берлеге рәисе. «Сәнәкчеләр» (1930), «Фронттан» (1935) шигъри җыентыклары, «Аучы Хәмит» (1931), «Чимит Дурже» (1933), «Хикәяләр» (1936) хикәяләр җыентыклары, «Чын мәхәббәт» (1936) романы, «Кайгылы җыр» (1937) пьесасы авторы. Монгол халкы каһарманы Сухэ-Батор турындагы «Эмигрант» романы тәгәлләнмичә кала. Рев-циягә каршы эшчәнлектә гаепләнә, СССР Югары Суды карары б-н атып үтерелә; үлгәннән соң аклана.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Мостафин Р., Даутов Р.Н. Репрессияләнгән татар язучылары // Казан утлары. 1992. N 3.

**ГЫЙЛЬМИ** (Гыйльметдинов) Фәрит Гыйльметдин улы (14.4.1947, Мөслим р-ны Уразмәт а. - 16.10.1993, Зәй р-ны Бигәш а.), язучы. Казан ун-тын (1970) һәм М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курслар (Мәскәү, 1987) тәмамлый. 1970 елдан Әлмәт шәһәрендә: 1972 гә кадәр Тарих һәм мәдәният истәлекләрен саклау җәмгыятенең Әлмәт бүлегендә җаваплы секретарь, 1974-78 дә урта мәктәп укытучысы, 1978-83 тә Әлмәт электр насослары з-дында хезмәтне фәнни оештыру бюросы начальнигы булып эшли. 1988 дән ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә әдәби консультант. Беренче хикәясе «Кызыл таң» г-тасында 1967 дә басыла. «Урсай тау итәгендә» (1977), «Елганың борылган төшендә» (1980) повестьларында сурәтләнгән геройлар - мөстәкыйль тормыш юлына аяк баскан яшь кеше образлары.

Әсәр.: Урсай тау итәгендә: Повестьлар. К., 1981; Су өстендә чәчәкләр: Хикәяләр. К., 1984.

Әд.: Гыйләҗев А. Истә, һаман да истә // Казан утлары. 1997. N4.

**ГЫЙЛЬФАН** (Гыйльфанов) Сафа Гыйльфан улы (1902-1950), шагыйрь, тәрҗемәче. Мәскәү журналистика ин-тын тәмамлый (1934). Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1936-37 елларда Казанда Эшче-крестьян Кызыл Армиясе йорты начальнигы. Беренче шигырьләре матбугатта 1930 елларда басыла башлый. Балалар өчен язылган «Батыр песи» (1936) исемле әкият-поэма авторы.

А.П.Гайдарның «РВС» (1934), А.О.Авдеенконың «Я люблю» («Мин сөям», 1935) романнарын, Г.Мопассан хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә.

**ГЫЙМАДИЕВ** Үзбәк Ибраһим улы (5.8.1920, Башкортстан Респ-касы, хәзерге Аургазы р-ны Яңы Карамалы а. - 13.9.1987, Уфа ш.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1984). Эстәрлетамак пед. училищесын тәмамлаганнан соң (1939) мәктәптә эшли. 1941-43, 1945-46 елларда «Җиңү өчен» г-тасының мөхәррире (Эстәрлетамак ш.). 1944 тә КПСС ның Авыргазы райкомында партия кабинеты мөдире. КПССның Башкортстан өлкә комитеты каршындагы партия мәктәбен (1949), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый (1955). 1949-68 дә «Кызыл таң» г-тасының баш мөхәррире урынбасары. 1968 дән Башкорт ун-тында укыта. Хезмәтләре рев-циягә кадәрге татар сатирик матбугатының идея-эстетик эчтәлегенә, 1917 дән соңгы башкорт матбугатына, Г.Ибраһимов иҗатына карый. Г. шигырьләр, пьесалар, хикәяләр, очерклар һәм Г.Ибраһимов турындагы тәмамланмыйча калган роман авторы.

Хезм.: Сила сатирического слова. Роль и значение татарских сатирических журналов дооктябрьского периода в развитии национальной литературы. К., 1987; Галимьян Ибраһимов -журналист. Өфө, 1967.

Әд.: Узбек Ибрагимович Гимадиев: Библиогр. указ. Уфа, 1981.

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Фуат Мансуровка 80 яшь



*Фуат Шакир улы Мансуров (1928)—дирижер, педагог. Казакъстанның, Татарстан һәм РФның халык артисты (1967, 1975, 1998), Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе (1995). 1949—1967 елларда Казакъ халык музыка уен кораллары оркестры, Казакъстан ССРның дәүләт симфоник оркестры, Абай исемендәге Казакъ опера һәм балет академия театры дирижеры, баш дирижеры. 1967 елдан Мәскәүдәге Зур театрның стажеры, 1969 елдан дирижеры. 1951 елдан Алма-Ата, 1969дан Мәскәү (1980 елдан профессор), 1985тән Казан консерваторияләрендә. Бер үк вакытта Татар опера һәм балет театрының (1968-70), Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры (1986 елдан).*

*Бөтенсоюз конкурсы лауреаты (1966). Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1994).*

(«Татар энциклопедия сүзлеге»ннән).

***

Студент чагында ук аның беренче концертларын тыңлау насыйп булды миңа. Ялгышмасам, Чайковскийның Бишенче симфониясе яңгырады ул чакта. Зал баштарак сихри моң дәрьясында оеп калды, аннары көчле алкышлар белән уянды, аягүрә басты.

Язмыш мине аның белән күп очраштырды. Аның кул астында уйнаган чакларымда бу шәхеснең дирижерлек осталыгына, тәгәллегенә соклана килдем. Ул партитурадагы һәрбер «өтерләр»не үз авырлыгында, үз чамасында, үз яңгырашында бик нык сиземли дигән тәэсир калды.

Музыкада вак-төякләр була алмый. Дирижер өчен иң мөһиме—биниһая авазлар дөньясында иң кирәклесен тоемлау, шуны көчле алымнар белән тыңлаучынын күңеленә җиткерү. Фуат ага Мансуров беркем ишетмәгән авазларны үзенең сихри тылсым-хәрәкәтләре белән безгә нәкъ менә шулай җиткерә дә инде.

Безнең консерваториядә Фуат Мансуровның студентлар белән эшләве, аларга һөнәри осталык мәктәбе үткәрүе, киңәш-ярдәм бирүе мине сокландыра. Ул бит сәнгать өлкәсендәге теләсә нинди партитураны, авторның төп үзенчәлеген югалтмыйча, табигый рәвештә аңлата, шәрехли ала.

Мәскәү консерваториясен тәмамлаган дүрт студент бүгенге көндә аның классында укыйлар, тәҗрибә туплыйлар.

Дирижер пульты артында ул шулкадәр җиңел хәрәкәт итә ки, тамашачылар аның шөгылен бик җиңел дип уйлыйдыр, мөгаен. Ә чынлыкта дирижерның кул хәрәкәтләре артында никадәрле хезмәт ятканын күпләр аңлап бетермәскә дә мөмкин.

Ул, кыя башларына үрмәләгән кыю альпинист сыман, музыка сәнгатенең һаман саен биегрәк үрләренә ашкына төсле. Талантына баш иючеләрнең рәхмәтен, көчен-теләктәшлеген тоеп яши.

**Рубин АБДУЛЛИН,**
*Казан дәүләт консерваториясе ректоры,*
*профессор, Россия Дәүләт премиясе лауреаты,*
*Россия һәм Татарстанның халык артисты.*

***

Фуат ага мине дирижерлык итүенең ихтыяри көче, менә дигән техник башкарылышы белән һәрвакыт сокландыра килде. Безнең беренче дәресләребез жырчы Зилә Сөнгатуллинаның концерт-бенефисен күрсәтүдән башланып китте. Аның беренче өлешендә Зилә студентларның мин житәкләгән татар музыкасы оркестрына кушылып жырлады, икенчесендә—Фуат Мансуров дирижерлык иткән дәүләт симфоник оркестры катнашында.

Әлеге концерттан соң ул мина опера-симфоник әсәрләрне башкаруда ныграк һәм житдирәк шөгыльләнергә киңәш итте. «Соң түгел микән соң?»—дидем, шикләнә төшеп. Фуат Шакир улы мондый мисал белән жавап бирде: атаклы француз дирижеры Шарль Мюнш пульт артыда беренче тапкыр 46 яшендә баскан... Ә мина ул чакта әле 42 генә яшь.

Баш хәрефтән языла торган Мастерлардан уку-өйрәнү беркайчан да соң түгел. Андыйлар өчен оркестрның составы мөһим түгел. Ул безнең халык оркестры белән дә, казакъларның Курмангазы исемендәге халык уен кораллары оркестры белән дә дирижерлык иткән кеше. Иң әһәмиятлесе—музыкаль-художестволы максат куярга һәм шуңа ирешергә. Бервакыт ул кулына мандолина алды һәм рәхәтләнеп уйнап та жибәрде. Анарда, күрәсең, яшерен мөмкинлекләр зур, өстәвенә бер дигән ишетү сәләтенә ия.

Ф. Мансуровтан алган беренче күрсәтмә—әсәрне тулаем колачлаган хәлдә, дирижерлык концепциясенең төп нигезен эшләү. Сер түгел бит: шундый дирижерлар да була—кул хәрәкәтләре белән артык мавыкканы өчен андыйларга карата, физкультура белән шөгыльләнә, дип әйтәләр. Мансуров драматургия сызыгының үсешенә тәнгәл килерлек «умыртка баганасын» дөрес урынга куярга, эре бизәкләр белән эш итәргә өйрәтә. Ул дирижер булып туган. Аның кул хәрәкәтләре үтә төгәллек (мануаль техника) ягыннан нык аерылып тора.

**Ринат ХАЛИТОВ**,
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан консерваториясе профессоры.*

***

Фуат Мансуровның дөньякүләм мәшһүр музыкаль әсәрләрне, шулай ук татар классик композиторлар һәм республикабызда ижат итүче заманыбыз композиторларыбызның симфоник әсәрләрен үз репертуарында сакларга омтылышы һәм аларны янача шәрехләве ул житәкләгән оркестрны музыка сөючеләр алдында ифрат уңыш казануына китерде.

Ф. Мансуров Казанга беренче тапкыр 1962 елда килә. Биредә узган Казакъстан сәнгать декадасында ул симфоник оркестр һәм «Чио-Чио-Сан» операсы белән дирижерлык итә.

Еллар үткәч, аны Казанга симфоник оркестр белән житәкчелек итәргә тәкъдим итәләр. Ул ризалыгын бирә. Халкына мәхәббәте һәм Татарстанның музыка сәнгатен үстерүгә үзеннән өлеш кертү теләге зур була аның. Ул вакыттан бирле, шул берничә дистә ел, Маэстро республикабыз сәнгатенә тугры хезмәт итә.

Симфоник оркестрның илебездә һәм чит илләрдә уңышлы чыгышлар ясавы, әлбәттә, Ф. Мансуров талантына һәм аның армас-талмас ижади эшчәнлегенә бәйле. Аның житәкчелегендәге оркестрның уңышлы эшләве Татар дәүләт филармониясенең дә абруен нык күтәрде.

Үзенең 80 яшьлек юбилеена якынлашып килүче хөрмәтле Маэстробыз Фуат Шакир улының хәзерге көндә дә зур ижат энергиясе белән эшләве күпләрне сокландыра.

**Айрат АРСЛАН**,
*Россиянең һәм Татарстанның халык артисты*

## Габдулла Галиевкә 80 яшь



Укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелек яратып кабул иткән повестьлар, хикәяләр авторы Габдулла Гали улы Галиев 1928 елның 10 гыйнварында Әгерҗе районының Төрдәле авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. 1943 елда Кырынды мәктәбенең җиденче сыйнфын тәмамлагач ул колхозда эшли башлый. Ә 1952 елда Габдулла Алабуга медицина училищесына укырга керә һәм аны тәмамлагач авыл медпункты мөдире итеп (башта Тат. Шаршады, аннары Кырынды авылларында) билгеләнә. Лаеклы ялга чыкканчы Г. Галиев шушы эшендә эшли.

Иҗат белән ул алтмышынчы елларда шөгыльләнә башлый, газета-журналларга мәкаләләр, очерклар яза. Соңга таба үзенең көчен драматургиядә сынап карый: аның «Яшел елан», «Гөлгенә» дигән пьесалары үзешчәннәр көче белән авыл сәхнәләрендә куела. Ә инде «Айдар», «Солдат кайтты» әсәрләре исә 1966-74 елларда Минзәлә драмтеатры репертуарына кертелә.

Туксанынчы елларда Г. Галиев проза әсәрләре яза башлый.

Аның «Үкенеч» (1995), «Кичер мине, Сурия» (1997), «Хәзрәт малайлары» (2002), «Кырык дүртнең буранлы кышы» (2006) исемле проза китаплары Татарстан китап нәшриятында басылган. Г. Галиевнең шулай ук Иҗауда дөнья күргән «Минем бабай умартачы» дигән китабы да бар.

## Госман Гомәргә 75 яшь



Детектив әдәбият жанрына караган күп санлы повестьлар һәм публицистик язмалар авторы Госман Гомәргә бу айда 75 яшь тулды.

Госман Гомәр 1933 елның 10 гыйнварында Балык Бистәсе районының Чирмешән авылында туа. Урта белем алгач Казан дәүләт университетның журналистика бүлеген тәмамлый.

Г. Гомәр ярты гасырдан артык гомерен татар вакытлы матбугатына багышланган актив иҗат кешесе. Аның укучыларга яхшы таныш булган «Юлбарыс тырнагы», «Шаһмиран», «Мөһер», «Упкын», «Элмәк», «Каты борын», «Зиндан» һ.б. повестьлары бар. Язучының «Чия чебене» повесте буенча өч серияле нәфис фильм төшерелә.

Госман Гомәр—Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Журналистлар берлегенең Х. Ямашев исемендәге премиясе лауреаты.

**Редакциядән:**
***Каләмдәшләребезне юбилейлары белән кайнар котлыйбыз, аларга ныклы сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез!***

Балачак белән яшьлек арасындагы гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

**Рәйсә ЮСУПОВА**

# ТЭТЧЕР МАҖАРАЛАРЫ

## Көтелмәгән кунаклар

...Җәйнең соңгы көннәре—август азагы иде бу. Бер төнне мин күз яшьләремә буылып уяндым: көчегебезне бүреләр урлаган, имеш. Имеш, кешеләрне ярдәмгә чакырам, «Тэтчер! Тэтчер-рр!» дип тә кычкырып карыйм, тик мине ишетүче юк; җитмәсә тавышымны да бүреләрнең хоры булә:

«У-у-ү-э...»

«У-у-ү-э...»



...Йә Хода, ярый әле төш кенә бу, дип калтыранам. Шөкер, төш кенә... дип юанам, урам утларының тәрәзәбезгә төшкән яктысына да куанып.

Ә өстәге катта бәби елый: у-у-ү-э, у-у-ү-э... Һәм мин йөрәгемнең дөп-дөп тибүен җиңеп, җиңел сулап куям.

Беләм, йоклый алмаячакмын инде бүтән. Торырга кирәк, булмаса... Кырык эшем кырык якта көтеп торганда, болай яту килешми.

...Чәй кайнатып, ашарга әзерләп бетергәндә генә—ирем уяныр вакыт—алты тулды. Йокы бүлмәбезгә, аны уятырга ашыктым. Ирем инде торган, гадәтенчә балконда физик күнегүләр ясау белән мәшгуль әнә. Кулы белән ымлап, мине дә чакыра җитмәсә. Вакытым булмаса да, йөзендәге серле елмаюны шәйләп, янына чыктым. Ул урамга ымлый: «Карале, «тегеләр» тагын килгән бит»,—ди.

...Балконыбыз каршындагы тамашаны күреп, мин телсез калдым. Алты эт! Алтау... Тезелешеп, бер-берсеннән яртышар метр гына ара калдырып утырганнар әнә. Ә күзләре... өмет тулы күзләре балконыбызга текәлгән. Цирк этләремени, өрми-нитми, утырган килеш кенә койрыкларын болгап, мине сәламләгән булалар. Ә ирем... Ирем исә аларга ишарәләп: «Этләр бездән акыллырак шул,—ди.—Ә без—кешеләр... Ялкау бит без, ялкау. Йә, кайсы егетнең кызы йоклаганда саклап торганын ишеткәнең бар? Менә сине... йокыдан уянуыңны берьюлы алты егет саклаганы булдымы?!»—дип шуклана. Һәм шундук залга, креслода йоклап ятучы этебезгә эндәшә: «Әй, Тэтчер, егетләрең килгән әнә, ә син, понимаешь, йоклап ятасың»,—дип көлә.

Тэтчерыбыз, билгеле инде, ике генә сикерә һәм... һәм башын балконның рәшәткә челтәренә тыгып, күрше-тирәне уятудан курыккандай ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдап, «һау» дип ала. Дусларын сәламләве бу.

...Маэмаебыз инде ишек янында—сабыр гына көтеп утыра. Аның белән сөйләшә-сөйләшә ирем дә киенә. «Син, Тэтчер, кара аны, егетләр дип дөньяңны онытма. Сәгать сигездә апаң эшкә китә. Ә хәзер инде җиденче ярты. Сәгать

ярымнан, как штык, өйдә бул!»—дип, әмерен юллый, сәгатенә дә күрсәтеп-күрсәтеп ала...

Мин тәрәзәгә капланам. Шофер әнә машинасының киереп ачкан ишегенә таянып директорының утырганын көтә. Ирем утырырга ашыкмый сыман, ул әле «егетләр» уратып алган көчегебезне күзәтә. Ә тегесе, Тэтчерыбызны әйтүем, дусларының бирсенә дә аерым игътибарын юнәлтмичә генә, «менә мин» дигәндәй, башын мәгъруранә күтәрә төшеп бер бөтерелеп алды да алга ыргылды. Аның артыннан дәррәү кубып «егетләр» ташланды.

...Кинәт кенә сискәндереп ишек кыңгыравы чылтырады. Аңа чәлпәрәмә килгән касәмнең чыңы кушылды. Идәнгә чәчелгән керәчләренең ялтыравына сокланып, ишек ачарга кирәклеген дә онытып торам икән ләбаса—чылтырау янә кабатланды.

—Апа-а!—дим ишегемне ачып, һәм күреп алам: ул үзе генә түгел. Аның артында әнә килене белән оныгы да елмая.

—Әлфияләрне озата килүем әле бу. Сентябрь җитә бит. Айгөл мәктәбенә ашкына. Поезд көтеп Петровскида утырганчы, Казанда йөриселәре килде. Кибетләр ачылганчы дип сиңа кердек әле менә,—ди апам, иртүк килеп керүләренә аклангандай.

Чәй яңарткан арада мин Айгөл белән сөйләшкәләп алам. Өченчегә бара икән инде Айгөлебез. Әле быел юбилее да булачак—ноябрь башында ук ун яшь тулачак икән үзенә. Шуңа күрә аларны кунакка чакырган да инде дәү әнисе.

—Казаныбыз ошадымы соң?—дигән булам.—Әллә үзегезнең Ижевск матурракмы?

—И Казан матур, и Ижевск. Дәү әни миңа все-все показала: и зоопарк, и цирк!—ди Айгөл. Ә үзенең күзләреннән... бриллиант нурлары бөркелә.

Мин иманеп китәм. Йә Хода, әтисенә бигрәкләр дә охшаган шул: чибәрләрнең дә чибәре—бу сеңлем. Бәхеткәйләрең генә булса иде, ярабби, дип, күңелемнән генә теләп алам. Әтисенең генә... кызы туганчы ук дөнья куюы,һай,аяныч. Һәм, ирексездән, егерме алты яшьлек хәрби очучы улын югалткан апама да күз салып алам.

Ул әнә оныгына диваныбыз түрен бизәүче «Мехлы аю»ны сузып маташа. Үзе: «Ошыймы сиңа, кызым? Ошаса, апкит син бу уенчыкны»,—дип кодалый.

Айгөл исә миңа карый: ачуланмыйммы, янәсе. «Рөхсәт» дигәнне белдереп, мин башымны кагам.

—Ишетмисезмени, ишегегезне кемдер кага анда,—диеп, Әлфия дә безнең янга чыга.

Сәгатькә күз ташлап алам: сигез тулган икән шул инде. Тэтчерны кертеп, мин ванна бүлмәсендә су әзерләгән арада, Айгөл зарланып ала:

—Маэмай һаман ишек янында утыра. Чакырып-чакырып та килми...

—Аягын юмыйча үтми инде ул,—дип аңлатам сеңлемә.

...Ә бераздан Айгөлнең чырык-чырык көлүе бүлмәләрне тутыра. Ошбу ике бала, Айгөл белән Тэтчерны әйтүем, йөгерә-сикерә, шуыша-шуыша, дөбер-шатыр килеп качышлы уйнау белән мәшгуль. Чын тамаша инде менә!

Айгөл маэмайны ваннага ябып куя да, үзе йокы бүлмәсенә—йә шифоньерга, йә караватт астына кача. Тэтчер исә туп-туры ул качкан урынга барып туктый һәм миңа карый: бераз гына эзләгән булып кыланыйммы, янәсе. Керфегемне кагып «әйе» дигәнне аңлатам. Ул инде залга чыгып диван артларын караган була, кухняны да калдырмый,балконны да урап керә,ишек төбеннән дә әйләнеп килә һәм... һәм шуннан соң гына Айгөл качкан урынга килеп, «һы» дип аваз сала. «Менә син кайда икәнсең», дию инде бу. Һәм шушы мәлдә кием шкафы «шартлый».

Оныгының шатлыгы, күрәм, апама да күчкән. Ул елмаеп:

—Бигрәк дусландыгыз әле, кызым. Икегез дә бер үк яшьтәге бала булгангадыр инде,—ди.

—Бер яшьтә түгел лә без. Миңа скоро 10 яшь тула, ә маэмайга—6 гына ай,—дип җаваплый оныгы.

Мин аңлатып бирүне кирәк табам.

—Кешеләр яше белән этләр яше тәңгәл килә алмый. Чөнки маэмайлар ун-

унбиш ел гына яши. Унсигез-унтугыз ел яшәүче этләр гомумән бик сирәк. Кешеләрнең 90-94 яшенә тиң булыр иде бу. Ә Тэтчерның 6 ае нәкъ менә синең 10 яшеңә туры килә. Хәзер икегез дә бер үк яшьтәсез.

—Ә Тэтчерга 1 яшь булганда?..—ди Айгөл.

—Бу инде 20 яшьлек кыз дигән сүз.

—Әгәр ул 14 ел яшәсә...

—Димәк, кеше гомеренең 75 яшен яшәгән була инде ул.

Апам янә оныгына эндәшә.

—Карале, кызым, әллә соң картаеп беткәнче Тэтчерны үзең белән алып кына китәсеңме?! Әнә апаңны да бер мәшәкатьтән коткарыр идең...

Аның болай шуклануы кәефемне кырды. Һәм мин коры гына:

—«Курчак аю» түгел бит ул. Тэтчер—акыллы җан, гаиләбез члены,—дип бүлдем.

...Инде эшкә китәргә җыенып, мин апага акча сузам: Айгөлгә бирәр бүләк алырсың, диюем бу.

Күрәм, алар китәргә ашыкмыйлар шикелле. Ә миңа ашыгырга кирәк: сәгать 10да җыелыш буласы. Мин үземнең җыелышка ашыгуымны һәм кибетләрнең дә инде ачылыр вакыты җитүен искәртеп алам.

Апамның исе дә китми:

—Күршеләрегездә калдырырмын ачкычыңны. Безгә әле иртәрәк,—ди.

Тэтчер әйтмешли, «һы»! Кунакны куып чыгармассың бит инде.

Аларга хәерле юл теләп, ачкычны кайсы күршедә калдыру мәслихәт булуын аңлатып, ишеккә юнәлдем. Тэтчер, гадәттәгечә, ишек янына килеп озатып калды.

## Хыянәт

Ул көнне...

Ул көнне кичен Тэтчер мине каршы алмады. Гадәттә, эштән кайтып ишекне ачам гына, ул шундук пәйда була, һәм мин чишенгән арада, йә, хәлләрең ничек, бик арымадыңмы дигәндәй, күзләрен мөлдерәтеп янымда утыра. Эштә булган хәлләрне сөйли-сөйли мин әкрен генә чишенәм. Һәм, гаҗәп, үземдә рәхәт бер бушану тоям: дөнья мәшәкатьләре, вак-төяк көнелсезлекләр онытылып тора. Ә бу юлы... бу юлы—юк, күренми Тэтчерым. Бүлмәләрне дә урап чыгам—юк инде, юк! Ә бәлки... бәлки ирем көндезге ашка кайтып, урамга чыгаргандыр үзен?

Шундук телефонга ябышам.

—Юк,—ди ирем,—обедка кайтмадым, ресторанда гына ашадым. Балкон ишеге ачык калмаганмы соң? Бәлки «егетләре» килеп чакыргандыр үзен.

«Егетләр» күрдем дип өченче кат балконыннан сикерергә җүләр дип беләсеңме әллә син аны, дим күңелемнән генә; шулай да үземдә бәләкәй генә өмет уяна.

Ишегенең биген ачып балкон бусагасын атлыйм һәм... аптырап калам: Ходаем, Тэтчерыбызның «егетләре» килгән ләбаса! Алтау! Әйе, әйе, алтысы да... Димәк... димәк, болар Тэтчерны күрмәгәннәр. Аны йә апа, йә Айгөлләр алып киткән, димәк.

Телефоннан гына такси чакырдым. Һәм шәһәр читендәге Петровски бистәсенә караңгы төшкәнче үк барып та җиттем.

Мине күргәч, апам агарынып китте.

—Син?!.. Ничек киләсе иттең?

—Тэтчерны алырга килдем. Безне такси көтә әнә.

—Этең бездә түгел бит.

—Ә кайда соң ул? Айгөлгә биреп җибәрдеңме?

—Урамда йөри торгандыр. Эт бит ул бүледә йөрергә тиеш.

—Кайсыгыз чыгарды соң аны урамга? Өйдә сез калдыгыз лабаса!

—Мин берни дә белмим. Синнән соң туры Петровскига кайтып киттем.

—Сүз куешып урладыгыз инде алайса.

...Урлаганнар! Әйе, әйе, урлаганнар!!!

Ошбу уй башыма дулкын-дулкын булып бәрелде. Һава җитми башлады, тез буыннарымның җегәре бетте, һәм мин урындыкка ишелдем...

Таксиның туктаусыз сигналы кайтырга кирәклекне искәртә. Аякларымны көчкә сөйрәп, мин урамга, һавага чыктым.

Юл буе мин үз-үземне юатып кайттым. «Бүледә», Казанда гына булса, кайтачак бит ул, кайтачак. Гади генә эт түгел ич ул—минем Тэтчерым. Башка этләр кебек өрми, нәкъ кешечә—быдыр-быдыр сөйләшә; татар һәм рус телләрендә сөйләгәнне аңлый, хәтта ки уй-теләкләрне дә тою, сизү сәләтенә ия...

Күк йөзен әнә йолдызлар бизәгән. Бу йолдызларга карап та өйгә юл табарсың, Аллаһы боерса, дип, күңелемнән генә Тэтчерыма эндәштем. Һәм ничектер җиңелрәк булып китте, җаным беркадәр тынычланды, ышаныч туды.

Билгеле, мин бер-бер артлы Тэтчерның маҗараларын да күз алдыма китердем.

...Шулай беркөнне иртә белән мин иремә улыбызның дипломлы килеш һаман эш табалмый йөрүен искәрттем. Ирем:

—Дөрес әйтәсең, Искәндәрнең эш проблемасын хәл итәргә кирәк!—дип сөйләнә-сөйләнә киенә дә башлады.

—«Эшен» бетергәч тә өйгә кертеп җибәрерсең,—дип, мин аңа Тэтчерны да ияртттем.

Ике сәгатьтән соң ирем үзе генә кайтып керде.

—Тэтчер кайда?!—дидем мин бусагада ук.

—Бәй, кермәдемени? Мин бит аны лифтка утыртып кертеп җибәргән идем.

Бергәләп эзли башладык: йорт тирәсен әйләнәбез, очраган бер кешедән сорашабыз—юк, берәү дә белми, беркем дә күрмәгән безнең Тэтчерыбызны!

Аптыраган бер мәлдә сигезенче подъездан Марс исемле эте белән Динис дигән үсмер чыкты һәм туп-туры безнең янга килде.

—Әллә Тэтчерны эзлисезме? Мин аны бая, ике сәгатьләр элек күрдем. Ул үзебезнең тукталышта 9 нчы трамвайны көтеп утыра иде.

—Ничек инде ул—9 нчы трамвайны?!

—Мин 14нче трамвайдан төштем. Тэтчер аңа утырмады. Ә моның артыннан 9нчы килә иде.

...Без 9 нчы трамвайда улыбыз Искәндәр янына ашыктык.

Ишекне улыбыз Тэтчер белән бергәләп ачты.

—Димәк, Искәндәрнең эш проблемасын Искәндәр янында, аның фатирында хәл итәбез, һәм бу эштә син дә катнашырга тиеш, дип уйладың инде син, ә, Тэтчер?—диде ирем һәм көлеп җибәрде...

Ә тагын бервакыт... Әйе, иремнең энеләренә баргач, янә хәйран калдырды бу акыллы җан.

...Ишекне безгә кодагый-әби, ягъни килендәшемнең әнисе ачты.

—Чәй эчәдер идем әле,—дип, безне дә кухняга чакырды. Һәм ул шундук киявеннән зарлана башлады.

—И кызымның бәхеткәйләре булмады шул. Интегеләр дә яши инде балакаем. Көн күрсәтми бит Әнвәр энегез мескенкәемә. Яклашсам, миңа да акыра-бакыра...

Нәкъ шушы мәлдә кухня бусагасында Әнвәр үзе дә дә күренде. Һәм аны Тэтчер, «быдыр-быдыр» килеп, тирги башлады.

—Җә инде, Тэтчер, ачуланма; моннан ары алай эшләмәм. Чын менә! Мин бит аларны яратып кына орышам,—дип акланды беркайчан, беркем алдында да сер бирмәүче энебез.

Әмма маэмаебызның гына туктарга һич исәбе юк, тетмәсен тетепме-тетә энебезнең.

Тэтчерның әрләвенме, әллә инде күз карашынмы... артык күтәрә алмыйча, Әнвәр залга чыкты. Тик маэмай да артыннан калмады; анда кереп тә әле бик озак тиргәде үзен.

Кодагыебызның исләре-акыллары китте. Кәефе күтәрелде: «Ай, акыллы Тэтчерыгыз»,—дип мактый-мактый куанды. Хәсрәтле йөзенә көләч нур иңде. Сөенү шатлыгы бөтен барлыгын биләде.

Сөенмәслекмени: үзен аңлаучы, яклаучы бар икән ләбаса!..

...Йә, шушындый акыллы җан өйгә юл таба алмасмы?!.. Җитмәсә, ис сизү сәләте дә гаять көчле ич әле үзенең. Әйтик, иремнең кайтып җитәренә өч-дүрт чакрымлап ара калганда, ул инде ишек янына килеп утыра. Йөзләгән-меңләгән машина дулкынында «үзенекен» ничек тоядыр, Хода белсен.

Бермәлне безгә бер чиләк чия күтәреп хезмәттәш кызларым килеп керде. Һәм:

—Сиңа мәшәкате әзрәк булыр, бу чияне төшеннән чистартып чыгыйк әле,— дип, үзләре шундук эшкә дә тотынды.

Кешеләрне яратучы, кунаклар килгәнгә сөенә белүче Тэтчерыбыз, билгеле инде, каршыбызда утыра. Әмма бераздан... бераздан ул тәрәзәгә карап алды да, колакларын тырпайтып ишеккә йөгерде. Кызларның чакыруына исә, «абыйны гына каршы алам да, киләм» дигәнне аңлатып, башы белән ишеккә ымлады.

—Әй, Тэтчер, кайда абыең, 7-8 минут үтте бит инде? Кил безнең янга, юкка алданып утырма анда,—дип, кызлар көлешә башлады. Тэтчер исә, «белмисез шул» дигәндәй, безнең тарафка башын мәгърурәнә борып акыллы күзләрен шук елтыратып алды да, янә ишеккә текәлде.

Нәкъ шул мәлдә, кызларны хәйран калдырып, ишек кыңгыравы чыңлады. Һәм ирем... кунаклар булуына Тэтчердан ким куанмаучы көләч йөзле ирем бусагада пәйда булды...

—Төшмисезмени?—дип, шоферның кулыма орынуы уйларымнан айнытып җибәрде. Шунда гына мин кайтып җитүемне, таксиның йортыбыз каршына ук килеп туктаган булуын шәйләдем.

...Өченче катка әллә очып мендем, әллә өч кенә атладым; ишеккә килеп каплангач кына еш-еш сулавымны тойдым. Ишек шундук ачылды.

Иремнең сораулы карашына да бары күзләрем генә җавап бирә алды: «Тэтчер белән икегез бергә кайтасыз дип көткән идем...»

Иремнең сораулы карашына да бары күзләрем генә җавап бирә алды: «Тэтчер белән икегез бергә кәтәсездер кебек тоелды». Иремнең күзләре исә: «Мин дә бергәләп кайтуыгызга өметләнгән идем», дип җаваплады, ә куллары бусагага аша миңа сузылды. Һәм мин аның киң күкрәгенә капланып ачы күз яшьләремне койдым.

...Икенче көнне газеталарда Тэтчерны күрүче яки табучы кешегә бүләк вәгъдәләгән белдерүләр калдырып, мин вокзалга, Ижевскидан килүче поездны каршыларга йөгердем.

...Состав буенча бер вагоннан икенче вагонга йөгерә-атлый, проводницаларга бер үк сорауларны кабатлыйм:

«Ижевскига барганда сезнең вагонга көчек һәм ун яшьлек кызы белән утыз биш яшьләрдәге ханым утырмадымы?..»

«Күрмәдегезме?..»

«Ишетмәдегезме?..»

Чалара башлаган мыеклы машинист агай гына күңелдә өмет уятырлык сүз әйтте:

—Өч вагонның проводницалары студент кызлар иде. Менә алар белсә генә инде...

—Алар кайда? Кайсы вагоннарда?

—О-о, алар үзләренең институтларына йөгерде бугай шул инде. Сентябрь җитте бит.

—Кайда укыйлар?

—Монысын сезгә отделкадрда гына әйтә алырлар.

...Аяныч, кадрлар бүлегенең ишеге йозаклы иде...

Кичен... кичен ирем яңалык җиткерде: ул вокзал башлыкларында булган. Анда аңа белешергә һәм үзенә хәбәр итәргә вәгъдә биргәннәр.

Ә тагын ике көннән аларның хәбәре иреште: чыннан да студент кызлар вагонында бер кыз бала юл буе көчеге белән уйнап барган. Алар Ижевскида гына төшкәннәр.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# Чайнворд «Табигать»




1. Планетабыздагы иң салкын материк;
2. Төче сулыкларда яшәүче иң гади төзелешле хайван;
3. Көньяк Америкадагы иң озын һәм күп сулы елга;
4. Баласын терелэй тудыручы ерткыч балык;
5. 1492 елның 12 октябре ... материгы ачылган көн дип санала;
6. Суда йөзеп йөрүче зур боз кантарлары;
7. Йолдызлар системасы;
8. Иң эссе материк;
9. Беренче булып көньяк котыпка баручы Норвегия сәяхәтчесе;
10. Гигант планеталарның берсе;
11. «Өч диңгез артына сәяхәт» исемле китапны язучы, XV гасырда Һиндстанга сәяхәт ясаган рус сәүдәгәре;
12. Африканың иң озын елгасы;
13. Антарктиданың яр буйларында очрый торган үсемлек төре;
14. Үзәгенә Кояш куеп, Галәмнең яңа моделен төзегән поляк астрономы;
15. Җиргә иң якын йолдыз;
16. Су өстендәге «Төньяк полюс—1» фәнни станциясен оештыручы рус галиме;
17. Күк җисемнәрен күзәтү приборы;
18. Беренче булып Җирнең шар рәвешендә икәнлеген фаразлаучы грек математигы;
19. Җир өсте формасы;
20. Бөҗәкләрне өйрәнүгә бөтен гомерен багышлаган француз галиме;
21. Кыйммәтле минераллар һәм элементлар катнашкан тау токымы;
22. Көньяк Америкада яшәүче дөньядагы иң зур соры күбәләк;
23. Җирдә яткан таш һәм таяклардан гына файдалана белгән иң борынгы кеше;
24. Организмның микроскопик иң кечкенә кисәкчеге;
25. (Уртадагы рәсемдә) Америка материгын ачучы;
26. Дөньядагы иң тирән күл;
27. Иң гади зурайту приборы;
28. Җир шарын әйләндереп алган һава катламы;
29. Африка саваннасының иң зур ерткыч хайваны;
30. Ак диңгезгә коя торган елга да, җинел автомобиль маркасы да.

***Чайнвордның җаваплары 179 биттә.***

Төзүчесе—**Зөфәр ХИСАМОВ**
*Буа, Түбән Наратбаш*

Харис
Закиров

# КАРАМЗИН НӘРСӘ ДИГӘН

ХИКӘЯ

Мәктәптән кайтып керүгә оныгының бер-бер хәбәр ирештерәсенә Фәнил күнегеп бетте инде. Киресенчә, Илшатлары тыныч кына кайтып керсә, әллә берәр күңелсезлек булганмы дип шикләнеп тә куя әле ул.

Әмма Илшатның мыштым гына кайтып кергән көне юк диярлек. Әнә бүген дә тупсадан үтүгә үзе өчен бик тә мөһим санаган хәбәрен әйтеп салды:

—Славикка сотовый алганнар. Супертелефон. Диктофоны да бар, фотога да төшерә, аның белән Интернетка да чыгып була.

Элегрәк Илшат: «Бүген ике «бишле» алдым» яки: «Без бу якшәмбедә театрга барабыз»,—дип кайтып керә торган иде. Соңгы вакытта исә хәбәрләр кемнең нинди әйбер алганын әйтүгә кайтып кала башлады. Славикның супертелефонына кадәр әнә Фәргатьнең, Артурның, Ирекнең әтиләре кесә телефоны алганнар иде.

Бүгенге хәбәрнең дә, аннан элеккеләренең дә үз бакчасына ыргытылган таш икәнен, әлбәттә, аңлый Фәнил. «Samsung» телевизоры, «Panasonic» видеокамерасы, «Olympus» фотоаппараты да шундыйрак сүздән соң пәйда булды аларның өендә. Ул вакытта Фәнил эшли иде әле. Хезмәт хакын чамалап тотканда кирәк әйберләрне алып була иде. Ә хәзер... Хәзер хәл башкачарак. Шуңа күрә дә ул: «Улым, мин бит хәзер пенсиядә. Ә пенсия акчасы бик аз. Әбиеңнеке белән минекен кушкач та очын-очка ялгап барырга гына җитә. Бүгенге көндә син ул кесә телефоныннан башка да яши аласың. Сабыр ит. Бер җаен табарбыз. Бәлки үзеңә дә бераз акча эшләп алырга туры килер»,—диюдән башка сүз әйтә алмады.

Оныгы, аның җавабыннан канәгать калмаса да, каршы да килеп маташмады. Чөнки пенсия акчасының яртысыннан артыгы фатирга, газга, телефонга түләргә китә дип бер генә тапкыр әйтмәде бит ул аңа. Моның өстенә, мәктәп фондына, класс фондына, сакчы хезмәткәргә (террорчылык галәмәтләре мәктәпләргә үтеп кергәннән соң пәйда булган сакчылар) түләү, һәм ниһаять, ашханәдә ашау өчен акчаны Илшат дәү әтисе кулыннан үзе ала бит.

Ә Илшатка кием-салым алырга, ашатырга-эчертергә, киносына-театрына күпме акча кирәк. Хәер, боларны санап бетерерлекмени? Бер елны әнә сәяхәткә дә җибәреп кайтарды ул оныгын.

—Дәү әти, безнең класс укучыларын экскурсиягә алып баралар. Санкт-Петербург бик матур шәһәр икән. Баручыларга өч ярым мең акча алып килергә куштылар. Безнекеләрнең барысы да диярлек язылды,—дип кайтып керде бер көнне Илшатлары. Бер уйлады, ике уйлады Фәнил. Оныгы нәүмизләнеп калса гомере буе онытмаячак. Һәлак булган әтисенә, энкечелеккә бирелеп улын биаталарына калдырып киткән әнисенә түгел, аңа, дәү әтисенә үпкә тотачак ул.

Сынап карады соң бу язмыш дигәне Фәнилне. Гөлфиясе белән ике малай үстергәннәр иде алар. Олысы инде үсеп җитте, кул арасына керә башлады дигәндә генә юл һәлакәтенә эләгеп дөнья куйды. Кечесе, Илшатның әтисе, чечен җирендә башын салды. Ә килен дигәннәре бераз аларда торып карады да, әллә ире белән булган фаҗигане кичерә алмады, әллә замана шаукымына

иярде—эштән кайтып кергәндә үзеннән аракы исе килә башлады. Иренең үлеменә ел да тулмастан икенче кешегә кияүгә чыкты. Тик менә торып кына китә алмады. Хәзер киленнәренең кайда йөргәнен дә белми Фәнил.

Язмыштан узмыш юк дип, оныгын тәрбияләргә үзе алынды. Фәнил үзе дию һич арттыру түгел,—Гөлфиясе әнә базар тирәсендә йөри, арахис чикләвеге, көнбагыш, чупа-чупс сатыштырып азмы-күпме акча юнәтә.

Җан биргәнгә җүн бирәм, дигән бит Ходай. Фәнил дә күктән төшкәнне көтеп ятмый. Өстәге катта яшәүче Каюм абзый аны бухгалтерия документларын төпләргә, «дело»лардагы кәгазьләрне китап рәвешенә китерергә өйрәткән иде. Кварталга бер тапкыр яки ел тәмамлангач шактый гына төшемле әнә шул эш белән шөгыльләнеп алмаса, тагын да авыргарак туры килер иде әле.

Фәнилгә, төп хезмәт урыныннан тыш, гел өстәмә эш белән дә шөгыльләнергә туры килде. Оныгы яшендә ул үз хаҗәтләре өчен генә түгел, тулаем гаиләләре хәлен җиңеләйтим дип тә тырыша иде. Алар дәүләткә түләгән салымнарның берсе—бәрәңге тапшыру иде. Әнә шул бәрәңге заданиесен гөлҗимеш хисабына үтиләр иде алар. Әле дә хәтерли, уналты кило кипкән гөлҗимеш бер центнер бәрәңгене алыштыра иде. Күп, бик күп җыйды Фәнил ул табигатьнең бу бүләген. Капчык тутырып. Соңыннан, үзе профилакторийга эләккәч кенә, гөлҗимешне нигә җыйдырганнарын аңлады Фәнил. Аннан төнәтмә ясап ял итүчеләргә эчертәләр икән. Гөлҗимештә «С» витамины лимондагыга караганда да күбрәк икән.

Шомырт, балан, миләш, карлыган кебек урман җимешләрен җыю да калмады Фәниллләрдән. Сигезенчедә укыганда балан кагы сатып кышкы ботинка, унынчыга күчкәч тал кайрысы сатып кул сәгате алды әле ул.

Техникумда укыганда да эш җаен тапты. Студентларга бирелә торган стипендия, тыйнак кына итеп тукланганда да, ике атнадан артыкка җитми иде. Шуңа күрә Фәнилгә вагон-вагон ташкүмер, терлек тиреләре бушатырга туры килде. Кайбер тиреләрнең бәйләгән җепләре өзелеп китеп, иренենә, күзләренә эләккән тоз бөртекләренең ачысын күп еллар үткәч тә онытмады ул.

Нигә хәтергә төшерде соң әле боларны Фәнил? Ә, әйе, күп нәрсә чагыштырып карауда беленә дигәннән искә төшә шул мондый вакыйгалар. Чагыштыру, чагыштыру аша ниндидер бер нәтиҗәгә килү адәм баласының канында инде ул. Әнә шуңа күрә Фәнил дә үзенең үсмер еллары белән оныгыныкын чагыштырмый кала алмый. Ә чагыштыру аерманың бик зур булуын күрсәтә.

—Син миңа илле сум акча бирә алмыйсыңмы?

Илшатның көн дә булмаса да, атнасына ике-өч тапкыр кабатлый торган җөмләсе бу. Дөрес, көне-көне белән мондый җөмләдә илле урынына егерме яки ун саннары яңгырый. Вакыты белән йөз саны да килеп керә.

Бирә инде Фәнил оныгы сораган акчаны, бирми нишләсен. Ләкин биргән саен: «Мин ун, егерме сумны гына әтидән дә, әнидән дә сорамый, үзем табарга тырыша идем», дип уйлап куя.

Җәй көне урман җимешләре сатса, кышын нарат күркәсе тапшыра иде ул.

Ә монда әнә урманга да барасы юк. Элек-электән зур шәһәрләр адәм балалары өчен сыену һәм туену урыны булган. Хәтта сугыш елларында да. Чөнки илдә чыпчыкка җим бетмәгән кебек, зур шәһәрдә кешегә эш табылмый калмый. Әнә катыргы тартмаларны гына ал! Подъезд төпләрендә, кибет яннарында, чүплекләрдә тулып ята бит алар. Базар тирәләрен әйткән дә юк. Җый да, кабул итү пунктына илтеп сат!

Шулай бер вакыт, мең тапкыр сөйләгәнче бер тапкыр күрсәтү хәерлерәк дип, оныгы белән һава суларга чыкканда ул ике тәгәрмәчле «Ельцин арбасы»н да алды. Россиянең беренче президенты Борис Ельцин хөрмәтенә халыкта шундый исем алган арбаларны кемдә генә күрмисең хәзер. Ил халкы байларга һәм ярлыларга бүленгәч, урта хәллеләр һәм очын-очка ялгап баручыларның төп таянычына әйләнде ул арба.

Бер тын һава сулап йөргәннән соң алар базар мәйданчыгына сугылдылар.

Нинди генә әрҗәләр юк монда! Әфлисуннан, мандариннан бушаганнары ап-ак булулары белән күзгә ташлансалар, тавык фабрикасы кулланган озынчалары ирләрне битараф калдырмый. Тот та төзү материалы итеп куллан! Агач әрҗәләр күп түгел. Күрәсең, алып-сатарлардан артканы гына. Ә менә катыргы тартмалар... Алар белән мәйданчыкның яртысы тулган.

—Менә болайрак итик әле,—дип башлады сүзен Фәнил,—бер зур тартманы арбасына салып. Аннан соң кесәсеннән пәке чыгарып, веграк тартмаларны кисәкләргә турый башлады. Улының да өлеше керсен дип, вакланасы тартмаларны үзе янына китерергә кушты.

Унбиш-егерме минут та үтмәстән, алар вакланган кисәкләрне өч зур тартмага тутырып, арбаларына урнаштырып бау белән бәйләп тә куйдылар.

Бер урам аша гына урнашкан «Стимул» кибетендә кеше күп түгел иде. Булганнары да корт-коры гына, пенсия яшендә иңәнлекләре чырайларына ук язылган. Алар да катыргы тартмаларны ике кулга тотарлык итеп вак бәйләмнәргә бүлгәннәр. Шул рәвештә үлчәүгә куялар да, тиярен алып чыгып китәләр.

Әле күптән түгел генә Фәнил бер кило катыргының туксан тиен торганын ишеткән иде. Алар бирегә килгән көнне бер сумга җиткән. Үлчәү хуҗасы сузган акчаны Фәнил оныгына алырга кушты. Алып килгән йөкләре унсигез килограмм икән.

Бер караганда бу сумма исне китәрерлек булмаса да, юлда да аунап ятмый бит. Ул акчага ике икмәк алып була. Хәер, моны аңлау өчен ул акчаны үзеңә табарга, бер бөтен ипи алу өчен этешә-төртешә чиратта торырга кирәк шул. Фәнилгә мондый хәлләрне аз кичерергә туры килмәде. Сигезенче-унынчы сыйныфларда туган авылыннан кырык чакрым ераклыктагы урта мәктәптә укыганлыктан һәм ул чорда мәктәптә ашханә-фәлән булмаганлыктан Фәнилгә һәр өч ашауны үзенә кайгыртырга туры килә иде. Әнә шул өч ел эчендә терсәк сугышы ярдәмендә икмәк алулар бихисап булды.

Әле ярый шундый көч куеп кеше башы сыярлык кына икмәк бирә торган тәрәзә янына килеп җиткәч чыгарып салырга акчаң булса. Әнә шул акчаны табу өчен Фәнил мәктәп урнашкан авыл кешеләренең утыннарын кисешергә дә, сентябрь аенда бәрәңге казышырга да тартынмады.

—Йә, ничек соң, акча эшләве кызыкмы?—дип сорады ул Илшатыннан, кайтыр юлга борылгач.

—Ярый инде, мәктәпкә илткән макулатура өчен безгә бөтенләй дә түләмиләр бит әле.

Шушы соравын биреп, кабул итү пунктына ясалган бу сәяхәтнең ошау-ошамавыннан бигрәк, үз көче дә кергән оныгының шушы юл белән акча юнәлтүгә мөнәсәбәтен беләсе килгән иде Фәнилнең. Ләкин ул көткән җавабын ишетмәде. Ә көткән җавабы: «Без бу «Стимул»га малайлар белән йөрербез әле»,—иде.

Аның каравы, бабай оныгының җавабыннан бер мөһим нәрсәне аңлады. Кызыксындыру—менә нәрсә кирәк адәм баласына. Бу фикере аны янә мәктәп елларына алып кайтты.

Укулар башлангач, ял көннәрендә укытучы апалары аларны экскурсиягә алып чыга иде. Әллә кайларга түгел, авылдан өч-дүрт чакрым ераклыктагы урман кырыендагы аланлыкка гына. Тамак ялгарга—йомырка белән ипи. Укытучы апалары ике малайга биштәр күтәртә иде. Ул капчыкларда нәрсә бар иде дисезме? Кыяр, әйе, гап-гади кыярлар. Колхозның яшелчә бакчасыннан. Ул елларда кыяр-помидорны, кәбестә-кишерне авыл кешеләре бик аз үстерәләр иде. Ә менә Фәнилнең әнисе күпләп утырта иде яшелчәләрне, аларга су сибү еш кына аның җилкәсенә төшә иде. Өйдә кыяр тансык ризык саналмаса да, колхозныкын ашау күңелле, үзең кебек малай-шалай, кыз-кыркыннар белән аеруча... Яшелчә бакчасыннан алган кыяр экскурсия вакытында гына түгел, башак җыйганда да, җитен йолыкканда да үз эшен эшли иде.

Өйләренә кайтып җиткәнче оныгының бер генә тапкыр да сорау

бирмәвеннән, нинди дә булса фикер әйтмәвеннән Фәнил «катыргы операциясе»нең уңышлы чыкмавын аңлады.

Көн артыннан көн үтә торды. Тиздән җәй җитәчәк. Каникул якынлашкан саен Фәнилнең башында өлгергән план да тәгаенрәк төс ала башлады. Ә план бик гади. Җәен авылга оныгын да алып кайтырга.

Алдагы елларда авылга кайткан Фәнил мәрхүм абыйсының улына каен һәм имән пиннегe бәйләште. Төбәге-төбәге белән «миллек», «себерке» дип аталган, мунча кергәндә чабынырга яратучылар өчен алыштыргысыз бу табигать бүләгеннән туганының малае шактый табыш ала икән. Нигә әле Фәнилгә дә бу эшне башкарып карамаска ди? Илшаты бер диган ярдәмче булачак. Пиннек әзерләү базардан катыргы ташу түгел инде ул. Саф һавалы каенлыкта йөрү үзе бер рәхәт! Пиннек бәйләү туйдырса, берара җир җиләге җыярга мөмкин. Авыл кешеләре җир җиләге сатарга да өйрәнеп киткәннәр. Пластмасс чиләк белән өйләре янындагы эскәмиягә куялар да, караштырып торалар. Машиналы кешеләр җиләкне күреп туктыйлар да акча түләп алып китәләр.

Быел Фәнил хуҗалары калдырып киткән йортта яшәп торырга дип сөйләшкән иде. Алай туганнарыннан кырын караш тоймаса да, озаклап торырга уйлагач шундый фикергә килгән иде ул.

Шәһәр шау-шуыннан соң авыл дулкын ярып арыгач ял итәргә туктаган пароходны хәтерләтә. Авылның һавасы да, яшәү рәвеше дә бөтенләй бүтән шул инде. Тынлыктан, һаваның сафлыгыннан изрәп китәсең. Таң алдыннан сандугачлар сайрый, кичен, сөт исләре чыгарып, сыерлар көтүдән кайта. Һәр тарафта яшеллек, су буена төшсәң чулт-чулт чумган балыклар күзгә ташлана. Чабарлык булып үскән үләннәр эчендә чикерткәләр чырылдый.

Табигатьнең бу тамашасы ошады Илшатка. Аеруча кармак белән балык тоту хуш килде аның күңеленә. Оныгының шул манзаралардан рәхәтлек кичергәнен күреп-тоеп торганда: «Әйдә, ял итсен. Пиннеккә июнь азаклары—июль башларына кергәч тотынырбыз»,—дип уйлады Фәнил һәм акрын гына бу эшкә әзерләнә башлады.

Соңгы елларда авылда атны мотоцикл алыштырганлыктан, Фәнилгә дә мотоцикл табарга туры килде. Авылда яшәгән чакта хезмәт юллары бергә башланган якын дусларының берсе ярдәм кулын сузды аңа. Үз вакытында гаилә корган һәм хәвеф-хәтәрсез генә яшәп яткан бу дустының бер генә түгел, ике мотоциклы бар икән. Әнә шул сиртмәле арбасы да булган мотоцикл пиннек хәзерләгән чорда бабай белән оныкның аерылмас дустына әйләнде.

Каенлык авылдан шактый ерак иде. Мотоциклда элдермәсәң, тиз генә барып җитә алмыйсың. Пиннеккә бару балык артыннан йөрү дә түгел инде ул. Чабынырга ярардай каен ботакларын кискәннән соң өйгә алып кайтырга, пөхтәләп-таманлап бәйләргә һәм киптерергә кирәк. Киптерә торган җиренә кояш нурлары үтеп керә торган булмасын.

Вакыты белән көн саен, кай арада ике-өч көнгә бер тапкыр барып кайта торгач, пиннекләр саны күзгә күренеп артты. Бер көнне ата белән ул санап караганнар иде, аларның саны дүрт йөздән арткан булып чыкты. Бисмилла әйтсәң, җитәрлек икән. Данәсен унар сумнан сатсаң да бер кесә телефоны алырлык акча күренә. Җитмәсә, авылда чакта җыелып барган пенсиясеннән өстәргә булыр. Иң мөһиме, моңа Илшатның үз көче дә керә. Фәнилнең бөтен теләгәне әнә шуннан—оныгын азмы-күпме хезмәткә тартудан, эшкә өйрәтүдән гыйбарәт иде бит.

Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына ди. Ижау шәһәреннән юлга кузгалган, Казан каласы аша үтәчәк буш машина пиннекләрне төяргә ризалык бирде. Шул ук көнне кичке якта алар Фәнилләрнең гаражында иде инде.

Хәзер инде эш аларны сатып акчага әйләндерүгә терәлеп калды. Ләкин бу көннәрдә Фәнилнең эчке халәте мунча янына басарлык түгел иде әле. Тегe яки бу эшне башкарыр алдыннан адәм баласы аңа рухи яктан әзер булырга тиеш. Аннан, август азагында мунчага йөрүчеләр дә аз була.

Аның каравы, вакыт дигәнең улы Илшат өчен үзенчәрәк акты. Каникул вакытында аерылып торган сабакташ дуслары белән очрашып кайткан саен

сүзен һаман бер төрлерәк дәвам итте ул: «Җәй көне Айратка велосипед алганнар... Айдарның әтисе хоккей формасы алам диган. Быел дүрт малайның шундый киеме булачак...»

Санаулы көннәр түгел, санаусызлары да сизелми уза торган заманда вакытны тоймый каласың. Әнә ике көннән Илшат мәктәпкә барачак.

Шактый озак йөрделәр алар кибетләрдә. Үзенә булса, Фәнил әллә кайчан алган булыр иде инде. Аңа сөйләшерлек булса шул җиткән, телефонның төп вазифасы—кешеләрне сөйләштерү бит инде. Ә менә Илшатка ул фотога да төшерсен, йокыдан да уятсын, сөйләшкәнне язып та алсын, калькуляторы булсын, вакытны күрсәтсен, тагы әллә ниләр эшләсен!

Пенсия яшенә җитеп мондый әкәмәтне күргәне юк иде Фәнилнең. Шуңа күрә бу «бәләкәч» аның үзендә дә кызыксыну уята башлады һәм ул, соңгы таңкаләрен түләп, оныгы сораган шактый кыйммәтле «LG» маркалы телефонны сатып алды.

Өйгә кайтканда Илшатны алыштырып куйдылар диярсең. «LG»ны кулына тотыру белән кемгәдер шылтыратырга, сөенечен уртаклашырга тотынды ул. Иптәшләренең номерларын хәтерендә ничек калдырган да, телефон экранында сурәтләр чыгарырга, музыка яңгыратырга кайчан өйрәнгән диген. Күрәсең, «фәләнгә телефон алганнар» дип сөйләнгәндә үк бу аппаратның хикмәтенә төшенгән булган.

Өстеннән зур йөк төшкәндәй, Фәнил бер-ике көннән телефон кайгысын бөтенләй диярлек исеннән чыгарды. Беренче сентябрь көнне дә дөнья мәшәкатьләре якасыннан ычкындырмады аны, оныгын мәктәпкә озата алмады... Шул көнне үк Илшат телефонсыз кайтып керде.

—Минем телефонны урладылар. Спортзалда кесәмнән алганнар,—диде дә, ничек кинәт елый башласа, шулай туктап та калды.

Телефонның паспортын, магазинда акча түләгәнгә бирган чекны алып, киттеләр милициягә.

—Иртәме-соңмы, килеп чыгар телефоныгыз. Казанда һәр көнне урланган, талап алынган телефоннар саны йөзгә җитә,—диде Фәнилгә бу очракны документлаштырган өлкән лейтенант.

«Һәр көнне йөз телефон?!». «Һәр көнне йөз телефон?!». Өенә таба атлаганда ни өчендер нәкъ менә шушы җөмлә, шушы сан яңгырады аның башында. Кайчан бетәр бу хәл, бетәрме? Кайчаннан бирле дәвам итә бу урлашу? Мәктәп эскәмиясеннән башлансын инде, җә!

Сораулар шулай бер-бер артлы арта торды. Кем генә бу сорауларга җавап табар да, кем генә моңа чик куя алыр икән. Әнә Германия, Төркия кебек илләрдә урлашу бөтенләй юк диләр бит.

Үзенә үзе бирган сорауларга җавапны үзе үк тапты Фәнил. Кайчандыр укыганы исенә төште. Русның олуг язучысы һәм тарихчысы Карамзиннан кемдер Россия тормышына хас үзенчәлекне бер сүз белән әйтеп бирүне сорагач, ул болай диган:

—Воруют-с!

---

***174 биттәге чайнвордның җаваплары:***

1. Антарктида; 2. Амеба; 3. Амазонка; 4. Акула; 5. Америка; 6. Айсберг; 7. Галактика; 8. Африка; 9. Амундсен; 10. Нептун; 11. Никитин; 12. Нил; 13. Лишайник; 14. Коперник; 15. Кояш; 16. Шмидт; 17. Телескоп; 18. Пифагор; 19. Рельеф; 20. Фабр; 21. Руда; 22. Агриппа; 23. Австалопитек; 24. Күзәнәк; 25. Колумб; 26. Байкал; 27. Лупа; 28. Атмосфера; 29. Арыслан; 30. «Нива».

# АПТЫРАГАН ӘЛЕ МОНДА

«Ак җилкән»кәй!

Сиңа хат язарга булдым бит әле менә.

Шушы яшемә җитеп минем җилкән күргәнем юк икән. Агын да, берниндиен дә.

Пиратларның җилкәне кара булган ди. Тагын ал җилкән дә бар бит әле. Ассоль дигән кыз балага бер әкиятче бабай әйткән булган, киявен сине ал җилкәнле карабта алып китәр, дип. Көткән инде кызый. Һәм—килгән бит теге караб. Яшь, матур капитан алып та киткән үзен. Тик ул капитанга әйткән булганнар шул, бер җүләр кыз өзелепләр көтә, диеп. Шуннан соң теге инде җилкәнен алга алыштырган, сатып алып.

Миңа кичә 16 яшь тулды. Миңа ни көтәргә икән?

Безне ал җилкәнле карабта да, ак җилкәнлесендә дә алып китмәсләрдер шул инде.

Әллә нинди бит бу дөнья хәзер. Әле ярый укыйм гына. Мәктәптә уку бетәр ич ул. Аннары кая барырмын? Институтларга хәзер зур акча төртеп кенә керәсе ди. Мин теләгәненә күбрәк тә кирәк ди әле ул. Әти белән әни нәрсәнедер сатып акчасын бәлки табарлар да иде. Бердәнбер кызлары өчен. Тик минем алай иттерәсем килми шул. Кадерле кыз дигәч тә, артык кыйммәткә төшәрмен. Аннары, взятка биреп кергәч, шуны җирәнми алган кешеләрдән укыгач, нинди врач-доктор булам инде мин? Ире кинәт чирләп киткән бер күрше апа әниемә сөйләп торды, хәзер күп икән бит алар, акча сыдырып, кешене дәвалау турында уйлап та карамаучылар.

Ничек яшәргә дә белгән юк, аптыраган әле. Классташ кызларым компьютер дип шаша. Кайберләре әлләниләр карап бетерәләр икән. Безнең гимназиядә ярый әле, башка мәктәпләрдә кызлар арасында тәмәке тартучылар, малайларны уздырып сүгенүчеләр күп икән.

Хәерче дә буласы килми, матур киенеп яшисе, илләр, диңгезләр күрәсе килә. Ә.Сләр Рәләр кебек тә буласым килми. Тәмам аптыраган. Шул аптыраганга язам да инде.

Әтинең абыйсы милли хәрәкәткә йөрде, ул татарлар мөстәкыйль булсын ди. Әнинең энесе, начальник, «Единая Россия» да «Единая Россия» ди. Әти намазны калдырмый. «Өйгә бер тиен дә хәрәм кермәсен», ди. Әни чүпрәк саткалый, «Хәйләсез дөнья файдасыз», ди. Өйдә гел тавыш, бәхәс. Әле дә «бала дәрес әзерли» дип кенә туктап калдылар. Ә «бала» дәрес әзерләми, сиңа хат язып утыра, «җилкән»кәй.

Мин үзебезнең гимназия кызларын беләм, башка кызыйлар ничек яши икән ул?..

**Фәния Г.,**
**Казан кызы**

***«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:***
***420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».***

## Камил Сәгъдәтшин



Сәгъдәтшин Камил Шәмгун улы (Камил Сәгадәт) 1952 елның 29 февралендә Татарстанның Куйбышев (хәзерге Спас) районы Иске Рәҗәп авылында туа. Урта мәктәпне тәмамлагач Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый. 1974–1976 елларда Казан телевидениесендә яшьләр өчен тапшырулар мөхәррире, 1976–1978 елларда Комсомолның Татарстан өлкә комитеты инструкторы, 1978–1982 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты газета-журналлар нәшриятында партия оешмасы секретаре. Шуннан соңгы елларда Камил Сәгъдәтшин республика профсоюзларының берләштерелгән "Яңа Аваз" һәм "Новое слово" газеталарында баш мөхәррир.

Беренче шигырьләре мәктәптә укыган чорда Болгар шәһәрендә нәшер ителүче "Яңа тормыш" газетасында, "Яшь ленинчы" һәм "Ялкын" балалар матбугатында басыла. Аның исеме "Казан утлары" журналы укучыларына да яхшы таныш. Шигырьләре берничә тапкыр журналыбызда басылып чыгу белән бергә Камил Сәгъдәтшин берникадәр вакыт "Казан утлары"ның җаваплы сәркатибе вазыйфаларын башкарды.

1992 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр ул "Ватаным Татарстан" газетасында бүлек мөхәррире булып эшли. Журналист буларак берсеннән-берсе кыю, тирән эчтәлекле мәкаләләре вакытлы матбугатта әледән-әле басылып тора. 1998 елда "Җан ярам" һәм 2002 елда "Янам әле хәзергә" дип исемләнгән шигырь китаплары басылып чыкты. Илледән артык популяр җырлар авторы.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның "Бәллүр каләм" бүләге иясе.

2007 елның декабрь аенда кабул итү коллегиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә бирүчеләр: Мөдәррис Әгъләм, Барлас Камалов, Госман Садә, Әхәт Сафиуллин) язучылар берлеге идарәсе Сәгъдәтшин Камил Шәмгун улын (Камил Сәгадәт) Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.



***—Татар теленә рәсми рәвештә дәүләт теле статусы бирелүгә дә инде 15 еллап вакыт узды. Ләкин аны гамәлгә кертү парламент карарларында һәм хөкүмәт программаларында күзалланганнан күпкә катлаулырак булып чыкты. Әйтик, республикабыз вузларында татар телендә югары белем алу мәсьәләсе хәл ителерме, әллә ул буш хыял гына булып каламы?***

**Хөсәен Хәсән улы ВӘЛИӘХМӘТОВ, язучы-публицист, психология фәннәре кандидаты:**

—Бу мәсьәлә бөтен татар матбугатын, бөтен галимнәр, мөгаллимнәр даирәсен, туган телебезнең язмышы һәм киләчәгенә битараф булмаган барлык зыялыларны да борчый, әлбәттә.

Кеше дөньяга килү белән әйләнә-тирә мохитнең бик көчле тәэсиренә, йогынтысына юлыга. Дөрес, теге яки бу холык, сәләт чаткылары билгеле бер микъдарда ата-бабалары нәселеннән кан белән дә бирелә аңа. Ләкин иң мөһиме— тәүге тапкыр йөзгә-йөз очрашкан мохит, социаль тирәлек. Әнә шул тирәлек, мохит милли булса, татарныкы булса (тел ачылу, бишек җырлары, өлкәннәрнең догамөнәҗәтләре, әкиятләре һ.б.), дөньяга килгән яңа кеше дә шул шартларга тартыла, яраклаша башлый. Һәм бу яраклашуны, милли мохитне балигъ булганчыга кадәр саклау мәслихәт.

Кешедәге иң катлаулы, иң четерекле дөньяны психология фәне өйрәнә дә инде.

Минә ни өчен дә барлык фәннәр арасыннан психология белән педагогиканы (тәрбия!) беренче планга куялар. Татарча укытуны да безгә нәкъ әнә шул үзара тыгыз бәйләнгән фәннәрдән башларга кирәк иде. Кызганыч, бездә әлегә аның бер генә китабы да, дәреслеге дә юк. Шулай ук психологияне татарча укыту методикасы да, программасы да эшләнмәгән диярлек.

Дөрес, Татарстан халыклары телләрен саклау һәм үстерү турындагы мәгълүм программа кысаларында шактый гына эшләр эшләнде. КДУ, ТДГПУ, КДТУ (КАИ), КТУ (КХТИ), архитектура-төзелеш университеты һәм башка югары уку йортларында төгәл фәннәрне татар телендә укытучы галим-профессорларыбыз барлыкка килде. Алар тарафыннан азмы-күпме саллы дәреслекләр, сүзлекләр, укыту әсбаплары язылды. Безнең «Мәгърифәт» газетасы да татар телендә югары белем бирү темасын даими яктыртып бара.

Шул ук елның КДПУ (хәзерге ТДГПУ) җитәкчелеге мине психология кафедрасына эшкә чакырды һәм беренче көннән үк шундый шарт куйды: психологияне татарча укыта башларга! Сентябрьдә дәрескә барганда дәфтәр калынлыгында гына булган русча-татарча психология терминнары сүзлеге эшләп бастырып алдым. Студентлар белән үзара эшлекле мөнәсәбәт урнаштыру, катлаулы фәнне үз телебездә өйрәнә башлауга җәлеп итүдә бик тә ярап куйды ул. Мөхтәрәм профессор Җәүдәт ага Вилкеев (хәзер ана 80 яшь) белән татарча лекцияләр укыйбыз. Фәнне рус телендә өйрәнә башлаганнар да акрынлап күнектеләр, хәтта татарча курс эшләре, рефератлар да язарга батырчылык иттеләр.

Әгәр дә без үзебезне гыйлемле, укымышлы, зыялы милләт вәкилләре итеп танытырга телибез икән, олы фән дөньясының барлык тармакларын да үз ана телебездә өйрәнергә, өйрәтергә, үз профессорларыбызны, белгечләребезне үстерергә бурычлыбыз.

## Шамил Бикчуринның тууына 80 ел

Үткән гасырның житмешенче-сиксәненче елларында Татарстан нефтьчеләренә багышланган романнары өчен республика әдәби җәмәгатьчелегеннән җылы фикерләр һәм күпләгән хуплау сүзләре ишеткән Шамил Мотыйгулла улы Бикчурин 1928 елның 3 гыйнварында Әлмәт районының Минлебай авылында туа. Авылда һәм Әлмәттә укып ун сыйныф тәмамлагач ул 1945 елда Казанга килеп, ике ел театр училищесында укый, аннары берникадәр вакыт Әлмәт драма театрында актер булып эшли. 1948-1952 елларда армиядә хезмәт итә. Аннары ул Әлмәттә төрле эшләрдә эшли, 1958-62 елларда Лениногорскида чыга торган «Ильич васыятьләре» газетасы редакциясендә промышленность бүлеген житәкли, 1965-67 елларда Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укый.

Ш. Бикчуринның нефтьчеләргә багышланган мәкаләләре һәм хикәяләре 1957 елдан «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында басыла башлый. Алар соңрак аерым җыентык булып та дөнья күрә.

1961 елда Ш. Бикчурин үзенең «Тальян моңы» исемле музыкаль комедиясен яза һәм бу әсәр шул ук елны Әлмәт театрында, ә бераз соңрак Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә куела. Авторның икенче драма әсәре «Бергә, гомергә» Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә 1964 елда уйнала.

Алтмышынчы елларның икенче яртысында Ш. Бикчурин нефтьчеләр турында киң планлы проза әсәре язуга керешә. 1972 елда «Каты токым» романы «Казан утлары» журналында басылу белән әдәби җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итә. Роман соңрак татар, рус һәм словак телләрендә китап булып басыла.

1980 елда Ш. Бикчурин «Тирән катлам» исемле икенче романын да тәмамлый һәм ул «Казан утлары» журналында дөнья күрә (1981 ел, 4-5 саннар). Роман соңрак русчага тәрҗемә ителеп «Волга» журналында да басыла.

Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Ш. Бикчурин 1978 елда «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнә.



Халык язучысы Гариф Ахунов (1925-2000) яшәгән йортка истәлек тактасы кую мизгелләре. 2000 ел.



Мәшһүр җырчы Хәйдәр Бигичев (1949-98).
80 нче елларда алынган фото.



Әлмәт төбәгендә яшәгән язучылар. Сулдан уңга: Шамил Бикчурин (1928-91), Җәмит Рәхимов (1935-96), Әдип Маликов (1921).
80 нче еллар.



*Композитор Нәҗип Җиһанов (уңда) һәм галим Гыйлем Камай. Сул якта журналист Венера Ихсанова. 1963 елда Әлмәттә яшь нефтьчеләрнең X слеты үткән көннәрдә.*



*Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттах (уңда) һәм тарихчы галим Индус Таһиров. 1998 ел.*



*Драматург Риза Ишморат (1903-95) яшь язучылар белән бергә. Сулдан уңга— Мөдәррис Вәлиев, Хәйдәр Гайнетдинов (1952-2000), Мөдәррис Әгъләмов (1946-2006) һәм Рашат Низамиев. 1982 ел.*

## Ямаш Игәнәйнең тууына 70 ел

*Вакыт җиткәч, шиңәр барыбыз.*
*Гап-гади гөл генә бары без—*
*Гомерегез гүзәл чагында*
*такыялар үреп калыгыз!*

Әлеге юллар шагыйрь, публицист, милләтпәрвәр шәхес—Ямаш Игәнәй шигыреннән. Узган гасырның 80нче еллар татар шигъриятендә ул үзенең тормышяшәеш хакында, кичергәннәре турында фәлсәфи уйланулар рәвешендә язган кыска шигырьләре һәм публицистик язмалары белән билгеле.

Ямаш Игәнәй (Ананий Нестерович Малов) 1938 елның 10 гыйнварында Сарман районының Ләке авылында туган. Сарман урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, ул Лубян урман техникумында укый. Бераз вакыт Башкортстанның урман хуҗалыгында үз белгечлеге буенча эшли. Армия сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң (1958-60), туган районының Рактамак һәм Азалак авылы мәктәпләрендә балалар укыта, бер үк вакытта Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә читтән торып укый. 1967 елны университетны тәмамлаганнан соң Баулы, соңрак Мамадыш район газеталарында хатлар бүлеге мөдире булып эшли.

Житмешенче елларда күмәк җыентыкларда аның шигырьләре басыла башлый. Мамадышта яшәү чорында Я. Игәнәйнең иҗатына Шәйхи Маннур белән якыннан танышуы һәм газета редакциясе каршындагы «Агымсу» әдәби иҗат берләшмәсе эшендә катнашуы уңай йогынты ясый. 1981 елда аның «Сәфәр чыгам» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә.

Сиксәненче елларда ул Чаллыда «Кама таңнары» газетасы редакциясендә тәржемәче булып эшли. 1982 елда Язучылар берлегенә кабул ителә. Бу елларда аның кече яшьтәге балалар өчен «Йолдыз булып ян» (1983) һәм «Хәзинәләр иле» (1984) исемле китаплары чыга. 1986-87 елларда шагыйрь Язучылар берлегенең Чаллы оешмасында сәркәтип булып эшли. 1987 елда басылган «Игелекле китап»—авторның җыйнама төстәге чагыштырмача тулы җыентыгы.

Я. Игәнәй кыска һәм ачык итеп язарга омтыла. Яктылык һәм моң, уйчанлык һәм самимилек күп аның шигырьләрендә. Шулай ук ул нечкә тоемлы, хисчән лирик шагыйрь:

*Кырказ тавышы камыш булып шыткан күлдә.*
*Сандугачның җыры чәчәк аткан гөлдә.*
*Каян килә тылсымлы бер аһәң дисәм—*
*Сөю булып сарылгансың йөрәгемә...*

Туксанынчы елларны ул «Аргамак» журналы, «Керәшен сүзе» газеталары белән хезмәттәшлек итә. Бу чорда аның кан-кардәшләребез Кырым татарларының фаҗигале язмышын чагылдырган «Бәддога» (1994 ел) китабы басылып чыга. Китап тарихи документларга нигезләнеп язылган.

Ямаш Игәнәй 1997 елда 59 яшендә вафат булды.

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТАТАР ҖЫРЫ ДӨНЬЯ ИҢЛИ

16-17 ноябрь көннәрендә М. Җәлил исемендәге дәүләт опера һәм балет театрында Рәшит Ваһапов исемендәге III Халыкара татар җыры фестиваленең йомгаклау концертлары булып узды. «Инде өч ел дәвамында Рәшит Ваһапов исемендәге җыр фестивале бөтен дөньяны яулый», ди фестивальнең генераль директоры Рифат Фәттахов. Чыннан да, бу фестиваль, татар халык җыры бәйрәме буларак, Россиянең һәм чит илләрнең байтак шәһәрләрендә уткәрелеп, күп меңләгән тамашачыларның олы ихтирамын яулады. Бу фестивальләрдә җыр сәнгатенең олуг осталары һәм яшь талант ияләре катнаша. Фестивальдә катнашу җырчылар өчен мәртәбә санала. Фестиваль исеменә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев җибәргән котлауда мондый сүзләр бар: «Сезне татар бәйрәме белән чын күңелдән котлыйм. Хәзерге заман шартларында милли мәдәниятне саклауның әнә шулай яна юлларын эзләргә тиешбез... Фестивальгә яңа иҗади казанышлар һәм ачышлар, ә татар җырын сөючеләргә әлеге гүзәллектән һәм аралашудан чын ләззәт алуларын телим».

Фестивальдә дөньякүләм танылган җырчылардан Бибигөл Төләгәнова һәм Зураб Соткилава да чыгыш ясады.

Яшь башкаручылар конкурсында җиңү яулаучыларның барысына да дипломнар, акчалата премияләр, истәлекле бүләкләр бирелде. Шундый зур конкурстан дипломант һәм II, I дәрәҗә лауреат исеме алган яшь җырчылар язмышына мәшһүр Рәшит Ваһапов иҗаты, вафатына шактый еллар үтсә дә, тәэсир итә. Чөнки бу фестивальдә Ваһапов репертуарында булган әсәрләрне башкару— төп шартларның берсе. Әлеге зарурият яшьләргә генә түгел, мәртәбәле кунак сыйфатында җыр бәйрәменә чакырылган Бибигөл Төләгәнова (Алматы), Тимур Абдикеев (Санкт-Петербург), Зураб Соткилава (Мәскәү), Идрис Газиев (Уфа) кебек танылган сәнгатькәрләргә дә кагыла.

Төрле номинациядә I дәрәҗә лауреатлары булып «Хыял» (Казан) һәм «Лугари» (Украинадан килгән 10 егетнең бары тик берсе генә татар) ансамбльләре, Венера Юлгилдина (Уфа) һәм Федор Тарасов (Мәскәү), Айгөл Сагынбаева, Рөстәм Асаев һәм Марсель Вәгыйзов (Казан) танылды.

Гран-прига исә Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең II курс студенты (профессор Зилә Сөнгатуллина классы) Филүс Каһиров лаек булды. Ана «Алмаз-холдинг» зәркән компаниясе җитештергән алтын медаль белән «Жигули» машинасы ачкычларын фестиваль конкурсының жюри рәисе, мәшһүр җырчы Илһам Шакиров тапшырды.

Фестивальдә татар җыр сәнгатенең ветеран җырчылары Фәридә Кудашева, Әлфия Афзалова, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Зөһрә Сәхәбиева да җиңүчеләргә жюри бүләкләрен тапшырдылар.

Фестиваль концертларында атаклы дирижер Фуат Мансуров җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры катнашты.

27 нобрьдә Рәшит Ваһапов исемендәге фестиваль концерты Мәскәүдә, Чайковский исемендәге концертлар залында да зур уңыш белән үтте.

## ДИНИ БЕЛЕМНЕҢ ДӨНЬЯВИ КӨЧЕ БУЛСЫН

РФ Дәүләт Думасы депутатлары дини уку йортларын тәмамлаучыларга дәүләт дипломнарын тапшыру мөмкинлеген бирәсе федераль законга төзәтмәләр мәсьәләсен кертте.

Бу хакта РФ Хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары (хәзер ул Россия Президенты вазифасына кандидат) Дмитрий Медведев Казанда Россия Ислам университеты мөгаллимнәре белән очрашуда белдерде. Әлеге чарада Президент Минтимер Шәймиев, РФ Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Александр Коновалов катнашты.

«Дини уку йортларының белем бирү программаларын дәүләт стандарты буенча аккредитацияләү мөмкинлеген тудыру турындагы тәкъдимне дөрес, дип саныйм. Бу хакта махсус киңәшмәдә дә сөйләшү булды, әлеге мәсьәлә Россия Президенты мөселман лидерлары белән очрашканда да күтәрелде»,—диде РФ Хөкүмәте каршындагы дини берләшмәләр мәсьәләләре комиссиясен җитәкләүче Дмитрий Медведев.

Дини вузларда да дәүләт дипломы бирелә башлаячагы турындагы яңалыкны Россия Ислам университеты ректоры, сәясәт фәннәре докторы Рәфыйк Мөхәммәтшин да хуплады.

«Дини уку йортларының хокукый статусы проблемалар тудыра килде. Федераль законга төзәтмәләр гамәлгә кергәч, бу проблема хәл ителәчәк, мөселман уку йортлары өчен янадан-яңа мөмкинлекләр ачыла-

чак»,—диде ул. Чыннан да, дини уку йортларын тәмамлап, Ислам турында этрафлы гыйлем алган белгечләр шул дәүләт дипломыннан башка мәктәпләрдә «Дөнья диннәре тарихы» дәресен дә укыту хокукыннан мәхрүм бит.

Татарстан Диния нәзарәте рәисе Госман хәзрәт Исхакый вәкыфны да закон нигезендә гамәлгә кертү мәсьәләсен кузгатты.

Очрашуда Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин, мәгариф һәм фән министры Н. Вәлиев катнашты.

## КАЗАНДА ИРАН КОНСУЛЛЫГЫ ЭШЛИ БАШЛАДЫ

ТР Президенты каршындагы халыкара мәсьәләләр буенча дәүләт киңәшчесе—Тышкы элемтәләр департаменты директоры Тимур Акулов Иран Ислам Республикасының Казан шәһәрендәге Генераль консулы Реза Багбаг Кондори белән очрашты. Очрашу барышында сәүдә-икътисади, мәдәни һәм фәнни-белем бирү хезмәттәшлеге мәсьәләләре турында фикер алышынды.

Иран дипломатын әлеге вазифага билгеләү Россия һәм Иран арасындагы Решт шәһәрендәге (Иран) килешү нигезендә башкарылды.

Реза Багбаг Кондори үзенең консуллык вазифаларын үтәячәк округ Татарстан, Башкортстан, Коми, Мари-Эл, Удмуртия, Чувашия республикаларын, Киров, Оренбург, Пермь, Самара, Свердловск, Ульяновск, Чиләбе өлкәләрен үз эченә ала.

## ХАЛЫКЛАР АССАМБЛЕЯСЫ ОЕША

«Казан» милли мәдәният үзәгендә Татарстан милли-мәдәни оешмалары ассоциациясенең IX конференциясе үтте. Анда Республика халыклары ассамблеясын оештыру мәсьәләсе хәл ителде. Конференциядә катнашкан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин: «Татарстан халыклары ассамблеясын оештыру республика өчен бик мөһим. Алдагы ике елда республикадагы дуслык, толерантлыкны ныгыту өчен кулдан килгәннең барысын да эшләргә тырышырбыз»,—диде.

Ассоциация президенты Сәгыйть Жаксыбаев сүзләренчә, ассамблеяны булдыру Республиканың бөтен халыклары белән дә нәтиҗәле эшләү мөмкинлеген тудырачак. «Әмма ассамблея булу өчен безгә әле устав кабул итәргә кирәк. Ә киләчәктә һәр шәһәр, һәр районда ассамблеяның бүлекчәсен булдыру күздә тотыла»,—диде ул.

## КОЛ ГАЛИГӘҺӘЙКӘЛ БУЛЫР

Татарстан Премьер-министры Р. Миңнеханов рәсми визит белән Ульяновск өлкәсендә булды. Республика Хөкүмәте башлыгы көрәш буенча Ульяновск өлкәсе II чемпионатын ачу тантанасында катнашты.

Шуннан соң өлкә Хөкүмәте бинасында Татарстан белән Ульяновск өлкәсе арасында килешүгә кул куелды. Биш елга төзелгән бу килешү икътисадның күп кенә тармакларында, фән һәм югары технологияләр, мәгариф, мәдәният, сәламәтлек саклау, дәүләт яшьләр сәясәте һәм туризм, физик культура һәм спорт өлкәләрендә бергәләп эшләүне һәм хезмәттәшлек итүне күздә тота.

Журналистлар сорауларына җавап биреп, ТР Премьер-министры Р. Миңнеханов һәм өлкә губернаторы С. Морозов Ульяновск үзәгендә татар шагыйре һәм мәгърифәтчесе Кол Галигә һәйкәл урнаштырылачагын белдерделәр. 2009 елда Ульяновскида Россия күләмендә Сабантуй бәйрәмен үткәрү дә күздә тотыла.

## КОНКУРС ЙОМГАКЛАРЫ

15 ноябрьдә Татарстан Җөмһүрияте мөселман массакүләм мәгълүмат чаралары һәм нәшриятларының беренче фестивале кысаларында журналистлар арасында уздырылган беренче конкурска йомгак ясалды.

Бүгенге көндә Татарстанда нәшер ителүче 59 газета һәм китапны, 20 телевидениерадиода яңгыраган тапшыруларны карап тикшергәннән соң, Диния нәзарәтенең матбугат хезмәте җитәкчесе Әхмәт хәзрәт Халиков рәислегендәге мәртәбәле жюри «Мөслимә» газетасы мөхәррире Ә. Әдиатуллинага («Мөселман журналистикасына керткән өлеше өчен»), «Татарстан—Яңа Гасыр» телевидениесе режиссеры Р. Юсуповка («Мөселманнар турында иң яхшы телевизион сюжет»), «Российская газета» хәбәрчесе С. Брайловскаяга һәм хәбәрче В. Рәхимовага («Татарстандагы массакүләм мәгълүмат чараларында рухи тормыш турында иң яхшы язма»), «Ислам info» газетасының татарча чыгарылышы мөхәррире Х. Гәрәйгә һәм РИУның матбугат хезмәте җитәкчесе, «Форум» газетасы мөхәррире Н. Максимовага («Татарстандагы мөселман массакүләм мәгълүмат чараларында рухи тормыш турында иң яхшы язма»), «Полиграфия-нәшрият комбинаты» дәүләт унитар предприятиесе директоры Ә. Мадьяровка һәм «Иман» нәшрияты хезмәткәре Р. Вәлиуллинга («Мөселман нәшрияты эшчәнлеге үсешенә өлеш керткән өчен»), «Ислам нуры» газетасы мөхәррире Х. Шәрифкә («Татарстанның иң яхшы мөселман массакүләм мәгълүмат чарасы»), Нурлат районы «Дуслык» газетасына, «Время и деньги» газетасы хәбәрчесе С. Сайганова («Оештыручыларның махсус номинациясе») мөфти Госман хәзрәт Исхакый дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырды. Конкурсны оештыручылар тарафыннан Чаллы телевидениесенә, «Мәдәни җомга», «Иман» газеталарына, «Татар мөселман календаре»на (мөхәррире—Фәния Хуҗиәхмәт), «Көмеш кыңгырау» газетасының «Фатиха» кушымтасына (Чаллы) кызыксындыру бүләкләре бирелде. Шулай да иң зур бүләк

быел хаж кылуга бушлай юлламалар булгандыр, мөгаен. Мондый бәхет Р. Гаффар, С. Нәҗмиев, Х. Гәрәй, Р. Юсупов, Р. Вәлиуллин, Р. Минһаҗ әфәнделәргә насыйп булды.

Журналистларга бүләкне тантаналы рәвештә тапшырган вакытта мөфти хәзрәтләре мондый бәйгеләрнен ел саен үткәреләчәген һәм киләчәктә дә каләм ияләрен хажга җибәрү мөмкинлеге булачагын искәртеп узды.

### СӘНГАТЕБЕЗНЕҢ СҮЛМАС ТАКЫЯСЫ

Даны дөньяга таралган Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленә—70 яшь. Сәнгатебезнең йөзек кашы булган әлеге коллективның юбилей тантанасы—М. Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында узды. Иң элек алар тамашачыга үзләренең «Җиде энҗе» дигән яңа программасын тәкъдим итте. Коллективны Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева тәбрикләде. Ул ансамбльнең беренче оештыручысы Зөләйха Әхмәтованы, элекке җырчыларны, озак еллар сәнгать җитәкчесе булган Лима Кустабаеваны, танылган биючеләрне искә алды. Аннары коллективка Президентның Рәхмәт хатын тапшырды һәм бер төркем сәхнә осталарына мактаулы исемнәр бирелүен игълан итте. Солистлар Рамил Миңлегалиевкә, Лилия Сорокинага, биюче Рамил Шәйдуллинга Татарстанның атказанган артисты, милли аяк киемнәре тегүче Евгений Бабушкинга Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелде. Мәдәният өлкәсендәге казанышлары медаленә баш хормейстер Нияз Гәрәев, хормейстер Венера Гәрәева, балетмейстер Раилә Гарипова, баянчы Рәшит Мостафин, киендерүче Римма Бүләкова лаек булды. Мәскәүдән, Карелиядән, Абхазиядән дә ансамбльне котларга килгәннәр иде. Коллективның сәнгать җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Айрат Хәмитов залда утырган ветераннарга рәхмәтен җиткерде. Шушы көннәрдә генә дөнья күргән, ансамбль тарихына багышланган китап та тамашачыларга тәкъдим ителде.

### АРАЛАР ЯКЫНАЯ

Күптән түгел генә Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында Кытайдан ике делегация булып китте.

ТДГПУ һәм Кытайның биш вузы арасындагы дуслык җепләре аеруча көчле. Болар—Пекинның халыкара укыту университеты, Тяньцзуның чит телләр университеты һәм Линья, Хунань шәһәрләрендәге, Гуансийск педагогика уку йортлары.

Кытай делегатлары 2 көн дәвамында ТДГПУ белән якындагы биш елда хезмәттәшлек итү турында сүз алып барды. Мондый килешүгә беренче тапкыр 1991 елда кул куелган иде, аның нигезендә ТДГПУда кытай бүлеге ачылды. Хәзер Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты кытай теле белгечләре әзерли. Моннан тыш, ике югары уку йорты арасында тәҗрибә уртаклашу күркәм гадәткә керде.

ТДГПУ шулай ук Кытайның Шанхай педагогика университеты белән дә багланышлар урнаштырырга өлгерде.

### ЖУРНАЛИСТЛАР КИҢӘШТЕ

Казанда «Евразия мультимедиа журналистикасы-2007: Көнчыгыш һәм Көнбатышның интеграцияләнгән маркетинг коммуникацияләре» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция булды. Журналистиканың мультимедиа төренә багышланган әлеге форум тәүге тапкыр үткәрелде. Аны ТР Фәннәр академиясе, КДУның журналистика һәм социология факультеты оештырды. Аның эшендә Германия, Япония, Беларусь, Таҗикстан илләреннән, шулай ук Мәскәү, Барнаул һәм башка шәһәрләрдән белгечләр катнашты.

### МУЗЫКА ҺӘМ ПЕДАГОГИКА

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетының музыка факультетында IV Халыкара фәнни-гамәли конференция узды. Аның темасы «Музыка һәм педагогика: педагог-музыкантларны һөнәри әзерләү проблемасы» иде.

Казанга җыелган 80нән артык кунак арасында Япония, Германия вәкилләре дә бар иде. Алар музыкаль-педагогик белем бирү проблемалары турында сөйләште. Шулай ук укытучылык һәм музыка сәнгате арасындагы багланышлар, укытуда яңа технологияләр куллану, чит ил тәҗрибәсе турында да сүз алып барылды.

### ТАГЫН БЕР УКУ ЙОРТЫ

Казанда Россия дәүләт туристлык һәм сервис университеты филиалы ачылды. Әлеге вуз—Россиядә сервис белгечлекләренең барлык дәрәҗәләре һәм спектрын, педагогик һәм фәнни кадрларын комплекслы әзерли торган бердәнбер уку йорты.

Хәзер биредә 100гә якын студент белем ала. Казан филиалы «Сервис», «Социаль-мәдәни сервис һәм туристлык», «Оешма менеджменты» белгечлекләре буенча студентлар туплый.

### МӘГАРИФ РЕФОРМАТОРЫ

Габдулла Тукайның әдәби музеенда дин һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Барудиның тууына 150 ел тулуга багышланган фәнни укулар булып үтте. Мәгълүм булганча, Г. Баруди—атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен оештырып, шунда 35 елга якын мөдәррис булып, җадит мәктәпләре өчен күп

санда дәресләкләр, Ислам дине тәгълиматын заманга яраклаштыру кирәк икәнен бәян иткән һәм шуна ирешү юлларын күрсәткән дини-фәлсәфи хезмәтләр язып, «Әд-Дин вә Әл-әдәб» исемле әхлакый журнал чыгарып, Шәрекъ халыкларының борынгы язма һәм басма китапларын җыю белән шөгыльләнеп, гаять бай китапханә туплап, халкыбыз алгарышы, мәдәният һәм мәгърифәтебез үсеше өчен күп көч куйган шәхес. Фәнни укуларда аның җәдиди мәгариф системасын булдырудагы роле, дини эшчәнлеге, Барудилар нәселенең шәҗәрәсе, ул чыгарган «Әд-Дин вә Әләдәб» журналының тарихы турында бик әтрафлы чыгышлар ясалды.

### «ӘКИЯТ»—ТӨРКИЯДӘ

Төркиянең Бурса шәһәрендә «Бурса Карагез» дип исемләнгән XIII халыкара курчак һәм шәүлә театрлары фестивале булып узды. Анда Казанның «Әкият» театры да катнашты.

Тамашачылар хозурына Лев Кожевниковның «Казлар-аккошлар» спектакле тәкъдим ителде. Әлеге тамаша Германия һәм Франция фестивальләрендә дә күрсәтелде. Тольяттида узган «Иволга» курчак театрлары фестивалендә әлеге спектакль өчен «Әкият» театры диплом белән бүләкләнгән иде.

### ЯЗУЧЫЛАР СЕМБЕР ҖИРЕНДӘ

Ульяновск өлкәсенең Иске Майна районы, Иске Кызылсу мәктәбендә фронтовикшагыйрь Сәхаб Урайскийның тууына 100 ел тулу уңаеннан мемориаль такта куелды. Тантанада Ульяновск өлкәсенең Законнар чыгару җыены рәисе Борис Зотов, Иске Майна муниципаль районы башлыгы Сергей Галант катнашты. Урайскийның якташларын Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев сәламләде.

Кичен Ульяновскиның Китап сараенда Татар китабы бәйрәме үткәрелде. Ульяновск өлкәсендә Татарстан Республикасы көннәре кысаларында Татар милли-мәдәни автономиясе оештырган бу бәйрәмдә өлкә губернаторы Сергей Морозовның милләттәшләребезне котлавы ирештерелде. Кичәдә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары Рифкать Әхмәдуллов, җирле шагыйрьләр Иделбикә, Равил Шәрифуллин, Рифкать Хисмәт һәм башкалар белән бергә Казаннан килгән кунаклар, язучылар Вакыйф Нуриев, Лирон Хәмидуллин, шагыйрә Эльмира Шәрифуллина һәм яшь җырчы Зөбәрҗәт Минсафина чыгыш ясадылар.

### РУМИНЫ ИСКӘ АЛДЫЛАР

Тууына 800 ел тулу уңаеннан, ЮНЕСКО 2007 елны Мәүлана елы дип игълан иткән иде. «Диалог-Ауразия» (ДА) хәрәкәтенең Татарстан бүлеге, Казан дәүләт университеты галимнәре 30 нче ноябрьдә ТР Милли китапханәсендә бөек суфый шагыйрьгә, дин әһеленә багышлап «түгәрәк өстәл» үткәрде. «Мәүлана Җәләлетдин Руми мирасы һәм хәзерге заман» дип аталды ул сөйләшү. Бөек шагыйрь иҗатының бүгенге көн өчен әһәмияте турында «ДА» хәрәкәтенең Татарстан бүлеге рәисе, шагыйрь Разил Вәлиев, әдәбият галимнәре Хатыйп Миңнегулов, Резеда Ганиева, Фәрит Яхин, Асия Рәхимова һ. б. катнашты. «Түгәрәк өстәл» утырышын тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков алып барды.

### ЮБИЛЕЙЛАР, ӘДӘБИ-МУЗЫКАЛЬ КИЧӘЛӘР...

***

Җөмһүриятебезнең әдәби җәмәгатьчелеге күренекле шагыйрь, драматург һәм публицист, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, республиканың атказанган сәнгать эшлеклесе Рөстәм Мингалимнең 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Шушы уңайдан 27 ноябрь көнне Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева юбиляр яшәгән фатирда булып, шагыйрьгә Президентыбызның Рәхмәт хатын тапшырды, республикабыз җитәкчелеге исеменнән ана нык сәламәтлек һәм яңадан-яңа иҗат уңышлары теләде. Әңгәмә барышында Рөстәм Мингалимнең татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә, иҗади алмаш тәрбияләүгә зур өлеш кертүе рәхмәт хисләре белән искә алынды.

Очрашуда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, ТР Дәүләт Советының даими комиссиясе рәисе, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире, шагыйрь Зиннур Мансуров катнашты. Ә 26 ноябрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Рөстәм Мингалимнең юбилее уңаеннан «Мин—яралы шигъри сагыш» дип исемләнгән әдәбимузыкаль кичә үткәрелде. Анда Татарстан сәнгать осталары Равил Шәрәфи, Илдус Әхмәтҗан, Фәнис Җиһанша, Зөлфирә Зарипова, Клара Хәйретдинова, Гөлзадә һ. б. башкаруында шагыйрьнең әсәрләре, аның шигырьләренә язылган җырлар, спектакльләрдән өзекләр тәкъдим ителде, шагыйрьләр Газинур Морат белән Ләбиб Леронның үзләре укуында юбилярга багышланган шигырьләре яңгырады.

Юбилей кичәсендә Татарстан мәдәният министры урынбасары Айрат Җаббаров, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов тәбрикләү сүзе белән чыкты. Тантанада Рөстәм Мингалимнең якташлары—Самара өлкәсенең Камышлы районыннан килгән кунаклар да катнашты.

Әдәби-музыкаль кичәне Рабит Батулла белән Айсылу Лерон алып барды.

***

Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театры бинасында күренекле режиссер Празат Исәнбәтне искә алу кичәсе узды. Иң элек әлеге талантлы шәхескә багышланган китап тәкъдим ителде. Җыентык Татарстан мәдәният министрлыгы һәм Камал театры булышлыгы белән чыгарылган. Бу китапта режиссерның талантлы рәссам да булуы ачык чагыла.

Кичәдә артистлар А. Галиева, И. Баһманов, Р. Тажетдинов, Н. Ихсанова, Н. Гәрәева һ. б. Празат Исәнбәт хакында сөйләделәр, иҗатының театр үсешендәге ролен бәяләделәр. Искә алу кичәсендә үз вакытында П. Исәнбәт тарафыннан куелган «Зөләйха», «Яшь йөрәкләр», «Җан Баевич» спектакльләреннән өзекләр күрсәтелде.

***

Актерлар йортында шагыйрь Егор Уткинның 75 еллык юбилее билгеләп үтелде. Әдәби-музыкаль кичә Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлеге, Менделеев район хакимияте тарафыннан оештырылган иде. Ике сәгать дәвам иткән бу кичә әдәбият сөючеләр, бигрәк тә керәшен татарлары вәкилләре өчен зур бәйрәм булды.

***

Казанның М. Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йортында шагыйрь һәм әдәбият тәнкыйтьчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Наис Гамбәрнең тууына 60 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Ул «Яшәп каласы килә...» дип исемләнгән иде. Арабыздан иртәрәк китеп барган каләм әһеленең әлеге шигъри сүзләре искә алу кичәсенең үзенчәлекле лейтмотивы буларак кабул ителде. Шагыйрьнең сәхнәдән яңгыраган шигырь-җырларында да, аның турында сөйләнгән истәлекләрдә дә, башка концерт номерларында да шәхес язмышы аша яшәү мәгънәсен ачу, халык талантларына карата сакчыл мөнәсәбәттә тору зарурлыгы игътибар үзәгенә алынган иде.

Искә алу кичәсендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Марсель Галиев, юбилярның якташ каләмдәшләре Харрас Әюп, Фоат Садриев, Ләбиб Лерон, Мөҗәһит, Рөстәм Зарипов, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров һ. б. Наис Гамбәр иҗаты турында сүз әйтеп, истәлекләре белән уртаклашты, җырчылар Римма Ибраһимова, Искәндәр Биктаһиров, Азат Тимершәех, нәфис сүз осталары Хәлим Җәләй, Илдус Әхмәтҗан, Луара Шакирҗан шагыйрь сүзләренә язылган җырларны һәм аның шигырьләрен башкарды.

Кичәне шагыйрә Шәмсия Җиһангирова алып барды.

***

Язучы Индус Сирматовның 70 яшьлек юбилее унаеннан туган ягы Актаныш районы үзәгендә аның иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә узды. Анда муниципаль район башлыгы Энгель Фәттахов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе, «Мәйдан» журналының баш редакторы Вахит Имамов, «Ялкын» журналының баш редакторы Эльмира Закирова, телевидение режиссеры Зәйтүн Яркәев һ. б. катнашты.

Чыгыш ясаучылар аның иҗатын һәм татар телевидениесендәге эшчәнлеген югары бәяләделәр. Китапханә залында Индус Сирматов китаплары, аның әсәрләре басылган, телевидение фонды язмалары куелган күргәзмә дә оештырылган иде.

***

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, тәрҗемәче һәм филология фәннәре кандидаты Флера Тархановага 60 яшь һәм шагыйрәнең иҗат эшенә 35 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә узды.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов шагыйрәне иҗатташ каләмдәшләре исеменнән котлады, аңа уңышлар теләде. Күренекле артистлар Рафаэль Сәхәбиев, Мирсәет Сөнгатуллин, Рамил Миндияр, Зөлфия һәм Җәвит Шакировлар шагыйрә сүзләренә язылган популяр җырларны башкардылар.

***

М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында Татарстанның халык артисты, М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты, Кырымның атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлзадә Сафиуллинаның юбилей кичәсе узды. Ул кичә «Каһарман җырлар фестивале» шигарендә узды. Җырчыны Татарстан премьер-министры урынбасары—Мәдәният министры Зилә Вәлиева котлады һәм Мактау грамотасы тапшырды. Г. Сафиуллина—Кырым җирендә берничә мәртәбә уздырылган «Сөембикә варислары» фестивален оештыручы буларак та төрки халыклары сәнгатькәрләре арасында абруйлы шәхес. Тантаналы кичәгә башкорт, уйгыр, тува, хакас, нугай, казакъ, кырым татарлары вәкилләре дә килгән иде һәм алар җырчының һәм сәнгати, һәм иҗтимагый эшчәнлегенә зур бәя бирделәр.

***

Танылган драматург, артист, язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Юныс Сафиуллинның 60 еллык юбилее Казандагы Шәриф Камал мемориаль фати-

ры-музеенда «Ак күнелле кеше» дигән әдәби-музыкаль кичә белән билгеләнеп үтелде.

Ю. Сафиуллин байтак пьесалар («Әллә өйләнергә инде?», «Менә без дә үсеп җиттек», «Ни булган бу ирләргә?», «Әбидә кунак егетләре», «Йөзек һәм хәнҗәр», «Бердәнберем минем» һ. б.) авторы.

Юныс Сафиуллин Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында утыз елга якын әдәби бүлекне җитәкли.

* * *

«Сәйдәш» мәдәни үзәгендә Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург Рәдиф Сәгъдинең 50 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Юбилярны мәдәният министрлыгы урынбасары А. Жаббаров, Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, К. Тинчурин, Г. Кариев һәм Буа театры җитәкчеләре һәм режиссерлары Ф. Мөсәгыйтов, Р. Әюпов, Р. Садриев һ. б. котлады. Тамашачыларга К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры тарафыннан драматургның «Сынган беләзек» исемле спектакле күрсәтелде.

* * *

Г. Державин исемендәге премия лауреаты, шагыйрә Лилия Газизованың иҗат кичәсе үткән Актерлар йорты ул көнне интеллектуаль салон җыенын хәтерләтте. Кичәгә шагыйрәнең иҗатын яратучылар, язучылар, сәнгать кешеләре күп җыелган иде. Шагыйрәнең шигырьләрен рус һәм татар телләрендә Казан театр училищесы студентлары башкарды. Л. Газизова иҗаты турында язучылар Т. Галиуллин, И. Ибраһимов, И. Иксанова, рәссам З. Гыймаев, актер В. Кешнер һ. б. сөйләде. Кичәне ихлас матур итеп шагыйрә үзе алып барды һәм шигырьләрен укыды.

## УЧИЛИЩЕ ЮБИЛЕЕ

Казан театр училищесы үзенең 85 еллык юбилеен Марсель Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йортында уздырды. Анда республиканың хакимият әгъзалары, Казан театрлары актерлары, сәнгать әһелләре килгән иде.

«Училищеда Россия һәм Татарстан театр сәнгатен дөньяга танытып, данын яклаучыларны тәрбияләүдә җитди һәм кирәкле эш алып барыла»,—дип белдерде Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева. Шулай ук ул Казан театр училищесының элеккеге студенты Чулпан Хаматова белән Казан яшь тамашачылар театрының элеккеге артисты Владимир Ильинның бар илгә танылган артистлар булуын искәртеп үтте.

Министр уку йортына музыкаль үзәк, 300 мең сумлык сертификат бүләк итте. Биредә эшләүчеләргә Мәдәният министрлыгының Мактау грамоталарын тапшырды.

## ГАЛИМ ҺӘМ ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Актаныш районы Иске Айман авылында мәктәп, китапханә, медпункт, мәдәният йортын бер түбә астына сыйдырган җәмәгать бинасы ачылды. Шушы бинаның диварына бу авылда туып-үскән галим, шагыйрь Зәет Мәҗитовка мемориаль такта куелды. Аны ачу тантанасында Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, язучылар Нәбирә Гыйматдинова, Рифә Рахман һәм Камил Сәгъдәтшин катнашты.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕНӘ ХӨРМӘТ

**Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына** лаек булдылар:

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертkәне өчен шагыйрь **Мингалимов Рөстәм Гали улы**;

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, милли мәдәниятне һәм фәнне үстерүгә лаеклы өлеш керткәне өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы **Арсланов Мөхәммәтгали Гыйльмегали улы**;

Татарстан Республикасы хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, татар халкының тарихи-мәдәни мирасын саклауга лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең әйдәүче фәнни хезмәткәре **Хәйруллин Әнвәр Нәҗип улы**.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Кышкы кич».

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Равил Вәли**.

# Яңа китаплар




**Кадыйр Сибгатуллин.** Бер ноктада: шигырьләр, поэмалар, баллада.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.—560 б. Тиражы—2000 данә.


Кадыйр Сибгатуллин (1942—1994)—шигърияткә 60 нчы еллар башында килгән шагыйрьләрнең талантлы бер вәкиле. Ул озак еллар үзенең туган ягы Балык Бистәсендә, сонрак Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итте.

Анын «Әманәт», «Гамь», «Инану», «Таннар, кичләр», «Әйтте шагыйрь» кебек китаплары үз вакытында бик күп поэзия сөючеләрнең күңелен яулаган иде. «Бер ноктада» дигән бу җыентык—сайланма китап. Анда шагыйрьнең төрле елларда иҗат ителгән шигъри әсәрләре тупланган. Китап шагыйрьнең 65 еллыгы унае белән чыгарылган.




**Рим Идиятуллин.** Хәерле кич!: шигырьләр, кечкенә драмалар, хикәяләр.—Казан: Тат. кит. нәшр., 2007.—271 б. тиражы—1500 данә.

Рим Идиятуллин—Уфада яшәп иҗат итүче күренекле татар шагыйре. Анын китаплары күп түгел: нибарысы дүртәү. Беренчесе—«Хәерле иртә» дип исемләнгән булса, бу «Хәерле кич» дип атала. Казанда беренче тапкыр чыккан әлеге җыентыкны сайланма шигырьләр китабы дип тә әйтеп була. Китапнын башында һәм ахырында шагыйрь иҗаты турында ике мәкалә-язма бирелгән. «Танылмаган талант» дигәнен Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәжми, икенчесен, «Шәп шагыйрь шул!» дигәнен Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин язган. Һәр ике автор да Рим Идиятуллинның татар шигъриятендә үзенең лаеклы урыны булуын, талантының зурлыгы турында язалар. Бу китап—шуна дәлил.



Равил Вәли

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)